Дәрдемәнд иҗатында иҗатында игътибарны үзенә җәлеп иткән мәсьәләләрнең берсе – шигырьләрдәге образ, авторның рупоры булган лирик герой. Билгеле ки, әдәби әсәрдә үзенең эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын нәфислек белән, укучының күңеленә үтеп керерлек итеп бәян итүче образны лирик герой дип атыйлар. Бүгенге көндә дә язучы иҗатындагы «автор – лирик герой» , «автор – лирик мин» бәйләнешләрен ачыклауга нокта куелмаган. Безнеңчә, лирик герой – автор тарафыннан билгеле шәхес сыйфатлары бирелгән хикәяченең шартлы образы, лирик әсәрләрдә беренче заттан чыгыш ясаучы. Әдәби әсәрдә үзенең эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын нәфислек белән, укучының күңеленә үтеп керерлек итеп бәян итүче образны лирик герой образы дип атау гадәткә керде әдәбият белемендә. Дәрдемәнд шигъриятендәге лирик герой мәсьәләсе татар әдәбиятчыларының игътибарыннан читтә калмады.

1986 елда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» җиде томлыкның өченче томында Дәрдемәнд иҗатына багышланган битләрдә бу мәсьәләгә шактый урын бирелә [3]. Бу томда күренекле әдәбият белгече Гали Халит Дәрдемәнд иҗатының серләрен ачуга, лирик герой мәсьәләсен яктыртуга зур өлеш кертә.

Билгеле ки, XX йөз башы татар әдәбиятын тиз арада азатлык идеалы биләп алды. Татар шигъриятендә азатлык романтикасы белән илһамланган лирик герой алга чыкты. Аның көчле генә тавышы ишетелде. Шуның белән бергә үк аның электән килә торган мәгърифәтчелек идеалы тагын да ачыкланып, күтәрелеп китте дисәк дөрес булыр. Һичшиксез, бу вакытта татар шигъриятенең үзәгендә мәгърифәтчелек һәм милли азатлык белән рухланган герой тора. Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Н. Думавиләрнең һәммәсенә барыннан да элек шундый герой уртак. Бу шагыйрьләрнең инкыйлабта күтәрелгән мәсьәләләрне яктырту һәм аңлауларында нинди генә аерма булмасын, аларның поэзиясендә гомуми азатлыкка, милләтнең уянуына, аның мәгърифәтле якты киләчәгенә гашыйк булган һәм матур, бәхетле язмышына ышанган яшь кеше образы алга чыкты. Аларның шигъри герое заманның бик әһәмиятле мәсьәләләре турында кыю фикер йөртә, үгет-нәсихәт бирә, әмма аның хис-кичерешләре, психологик дөньясы бик аз гәүдәләнә... Яисә, рухи сурәте туып өлгермәгән әле, дию дөрес.

Чор шигъриятенең талантлы вәкиле булган Дәрдемәнднең тормышка һәм тарихка мөнәсәбәте нигезендә яткан фәлсәфә, Г. Халит билгеләнгәнчә, – фаталистик караш, космик пессимизм аның иҗатын үтәдән-үтә сугара. Мәсьәлән, Тукай, Дәрдемәнд һәм Рәмиевнең лирик геройларын үзара чагыштырып караганда, Г. Халит шагыйрьләрнең дөньяга карашлары белән бәйле рәвештә алар иҗатында әлеге проблемаларның төрле мәгънә алуын, төрлечә хәл ителүен ачыклый: Дәрдемәнд тормышка һәм тарихка тирән фәлсәфи мөнәсәбәт белдерә, С.Рәмиев исә явыз чынбарлыкка үзенең бунтын, протестын, ләгънәт һәм нәфрәтен белдерүгә басым ясаса, инде Тукай шигъри дөнясындагы лирик героендагы «җан диалектикасына» килсәк – монда ул кичерешләр колачының, чынбарлыкка мөнәсәбәтенең киң һәм тирән эчтәлекле булуын күребез. Тукай лирик героеның мондый мәгънәсен Г. Халит бу герой образында татар җәмгыяте вәкиленең характеры, аның интеллектуаль һәм мораль йөзе ничек чагылуы белән бәйләп аңлата. Шул нигездә шагыйрьләрнең иҗат стиленә мөһим аерымлыклар хасил була, алар поэзиядәге төрле юнәлеш вәкилләре булып алга басалар [3, 210 б.].

Галим фикеренчә, Дәрдемәнд лирик герое – элегик герой. Аңарда явызлык белән бәрелештә туган трагизм юк. Ул пассив, ягъни язмыш каршында баш ияргә өнди. Тукай, С. Рәмиевләрнең лирик геройлары белән чагыштырганда, Дәрдемәнд геройларының тавышы үзгә... Ул – милли тарих барышын сурәтләүче. Шул ук вакытта шигырьдәге кичерешләре – Дәрдемәнд үзе яшәгән җәмгыять вәкилләренеке.

Югарыда китерелгән Г. Халит тарафыннан Дәрдмәнднең лирик героен пассив дип атау сораулар тудыра. Киресенчә, безнеңчә, Дәрдемәнд шигъри образы – актив герой: ул борчыла, уйлана, эндәшә, сораулар яудыра, уйланырга мәҗбүр итә.

Дәрдемәнд үз шигырьләрен нигездә, газәл, мәдхия (ода), мәсәл, робагый (дүртюллык), фәрд (икеюллык) кебек кече жанрларда иҗат итә. Күпчелеге – оригинал әсәр. Арада фарсы әдибе Сәгъдидән (XIII йөз), Пушкиннан алынган берничә иркле тәрҗемә дә бар. Югарыда әйтелгән Дәрдемәнднең шәркый жанрларга мөрәҗәгать итүе исә афористик, хикмәтле сүз әйтү, кешеләргә тәэсир итү көчен арттыру, заман мәсьәләләрен тиз вакыт эчендә шигъри юлга салып халыкка җиткерү һәм бу жанрларны заман рухында яңартып бирүне күз уңында тота. Лирикада, лирик герой гәүдәләндерүдә сөйләм төгәл, аһәңле, һәр сүз аерым бер мәгънәви һәм эмоциональ көчкә ия булырга тиеш. Шигъри сөйләмдә яңгыраш, ритм, образ – бар да әһәмиятле. Чөнки мәгънә сүзләр ярдәмендә табыла. Образлылык читләтеп әйтүгә корыла, символик, аллегорик образлар, тел-сурәтләү чаралары бик күп була. Җиңел укылышлы теле, төгәл сыйфатлаулары, куәтле фикере ярдәмендә Дәрдемәнд ике-өч кенә җөмләне шигырьдә дә гомумиләштерү тирәнлегенә ирешә. Моның классик мисалы итеп «Кораб» шигырен алырга була.

Дәрдемәнд лирик герое, нәкъ башка мәҗнүн җаннар кебек үк үзенең сөйгәненә ихлас соклана, аның бик күпләр арасында бердәнбер, тиңе юк зат икәнен исбатларга алына.

Иҗтимагый гаделлек темасы – Дәрдемәнд иҗатының үзәк темаларыннан. Шагыйрь аны төрле яклап куя һәм хәл итә. Традиция рухында хөкемдар һәм халык проблемасы алына. Монда – хакимиятле өстеннәр һәм мохтаҗ түбән катлам кешеләре мәсьәләсе. Гаделлекнең асылын шагыйрь хөкемдарының һәркемгә тигез игелегендә күрә. Үзенең идеалын ул Тәүраттагы мифик гадел патша – Сөләйман образында гәүдәләндерә, ягъни яһүди, христиан һәм мөселман дөньясының соклангычы булган мисалга мөрәҗәгать итә. Димәк, Дәрдемәнднең мәхәббәт шигырьләрендә лирик герой үтә нечкә күңелле, тәмле телле, ихлас зат. Әмма ул һич тә хисләр колы түгел, шагыйрьнең үзенә хас булганча, акыл кысаларында калып, фикер йөртә. Үзенең мәгърифәтчел идеяләре, фәннең, гыйлемнең куәтен данлавы, кешенең таныл-белү сәләтенә соклануы шагыйрьнең иҗатында өметсезлек төп мотив түгеллеген күрсәтә.

2016 елда чыккан «Татар әдәбияты тарихы» сигез томлыкның дүртенче томында Дәрдемәнд иҗатына багышланган бүлектә лирик герой темасына карата галимә Диләрия Марат кызы Абдуллина тарафыннан кызыклы фикерләр белдерелә: «Дәрдемәнд шигырьләрендәге эчке пафос һәм лирик героеның XX йөз башы татар шигъриятендә

калыплашкан пафос һәм геройдан аерылып торуын да күрсәтергә кирәк. Бу үзенчәлек аның «Каләмгә хитап» әсәрендә үк аерылып тора». Алга таба галимә чагыштырма планда үзенчәлекле күзәтүләр ясый: «1905 елда М. Гафури («Шатлык шигыре») каләмгә мөрәҗәгать итеп, аны милләтнең зур шатлыгын уртаклашырга чакырган булса, 1906 елда (Дәрдемәндтән соңрак) Г. Тукай («И каләм!») каләмгә милләтне мәгърифәтле итү эшен йөкләде. Әлеге шагыйрьләрдән аермалы буларак, Дәрдемәнд каләмнең вазифасын башкада күрде. Беренче рус инкыйлабы вакыйгаларының милләт язмышына йогынтысын ул үзенчә бәяләде. Бу үзгәрешләрне, С. Рәмиевчә, таң вакытына тиңләмәде, Тукайча, кояш конбатыштан чыкты дип, гайре табигыйлек күрмәде. Гафурича, шатлык дулкынында күккә ашмады, ә аларга сак мөнәсәбәттә булырга, үткәннәргә күз салып, тарих хаталарын кабатламаска чакырды. Дәрдемәнд каләменә үз заманының вакыйгаларын киң тарихи яссылыкта ачу бурычын йөкләде». Д.М. Абдуллинаның тикшерүләре Дәрдемәнд иҗатын өйрәнү юлында бер адым булып тора.

Бүгенге көндә дә кайчандыр Г. Халит әйткән фикер актуаль булып кала: Дәрдемәнд иҗаты серләре тулысынча ачылып бетмәгән, шигырьләрен тиешле шәрехләү, шул исәптән шагыйрь гәүдәләндергән образларның асылын тулысынча ачу бүген дә көн үзәк бурычлардан санала [6, 28 б.].

**Әдәбият исемлеге**


1. Гобәев Р. Дәрдмәнднең тормыш юлы һәм шәҗәрә // Мәгариф. – 1995. – № 10. – Б. 25–27.
2. Дәрдемәнд. Исә җилләр: шигырьләр, истәлек-язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 254 б.
3. Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 3 т. (1905–1917). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.– 598 б.
4. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 4 т. XX йөз башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1916.– 533 б.
5. Шарипов М.С. Модернизм в национальной культуре начал XX века.// Славянские этносы, языки и культуры в современном мире: материалы VII Международной научно-практической конференции, посвященной 95-летию доктора филологических наук профессора Леонида Михайловича Васильева (г. Уфа, 23 сентября 2021 г.) / отв. ред. В.Л. Ибрагимова, Л.А. Киселева. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2021. – С. 312–331.
6. Шарипов М.С. Дәрдемәнд иҗатын өйрәнүдә герменевтика методы. //Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей X Всероссийской научно-практической конференции (9 декабря 2022 г.) / отв. ред. И.Ф.Зарипова; И.К. Фазлутдинов. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2022. – С. 328–332.
7. Шарипов М.С. И. Гаспринский и его отношения с братьями Рамиевами.//Актуальные проблемы современной татарской филологии: материалы VII Всероссийской научно-практической конференции, посвященной 100-летию образования Республики Башкортостан и 110- летию создания Башкирского государственного университета (г. Уфа, 13 декабря 2019 г.) / отв. ред. М.С. Шарипов. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2019. – С.28–32.


© Ахмадуллина С.М., 2025

УДК 811.512.142

**Ахматова М.А.,**
*профессор кафедры карачаево-балкарской филологии КБГУ,*
*г. Нальчик, Россия*

# КЪАРАЧАЙ-МАЛКЪАР ТИЛДЕ БИР ТАМЫРЛЫ АТ ЭМ ЭТИМ СИНОНИМЛЕНИ ЛЕКСИКА-ГРАММАТИКА ТЮРЛЮЛЕРИ

***Аннотация.*** *Статьяда къарачай-малкъар тилде жюрютюлген бир тамырлы ат эм этим синонимлеге лексика-грамматика жаны бла къаралады. Быллай синонимле къуралыуларына кёре бошла эм къошла боладыла, морфология эм синтаксис мадарла бла къураладыла. Магъаналарына кёре бир бирине синонимлик этген бир тамырлы атла тукъум атла, энчи атла, затны белгилеген атла, жыйымдыкъ эм абстракт атладыла. Бир бирине синонимлик этип келген бир тамырлы этимле асламдыла, кеслери да баш, зорлаучу, къысылыучу айырма формалада тюбейдиле.*

***Баш магъаналы сёзле:*** *къарачай-малкъар тил, бир тамырлы синонимле, тилни энчи кесеклери, лексика, морфология.*

Бирси тюрк тилледеча, карачай-малкъар тилде да бир тамырлы синонимле кёп тюбейдиле. Быллай шарт бек эрттегили сёзледе да эсленеди [13]. Алимле аланы лексиканы тюрлю-тюрлю къауумларында [12], фразеологизмледе да [7; 11] тюбегенлерин чертедиле. Тюрк тил билимде синонимлени тинтиу бла байламлы быллай алимлени ишлери барды [2; 3; 4; 5; 6; 8; 10], магъаналары бир неда бирге жууукъ болгъан сёзлени юсюнден ишле да кёпдюле [1; 9] эм д. б. Бу статьяда магъаналары бир неда бирге жууукъ болуп, аффикслери уа башха (кеслери да сёз къурауучула) болгъан сёзле, башхача айтханда, бир тамырлы синонимле лексика-грамматика жаны бла тинтиледиле. Бир тамырлы синонимле къарачай-малкъар тилни баш эм болушлукъчу кесеклеринде да тюбейдиле. Къарачай-малкъар тилде атлада бла этимледе тюбеген бир тамырлы синонимле, тюрлю-тюрлю шартлагъа кёре, къауумлагъа юлешинедиле. Къуралыуларына кёре бош эм къош боладыла, кеслери да морфология эм синтаксис мадарлагъа кёре къураладыла.

Къарачай-малкъар тилде бир тамырлы ат синонимле морфология къурамларына кёре бошла эм къошла боладыла: *огъурлукъ – огъурлулукъ, бугъумуч – бугъунчакъ – букъгъуч, хырс туз – къая туз, сабий-сюбюй – сабий-балий – сабий-балыкъ, дары-дарман – дарман-дары: Къошунну жерге салып, / Ыспас этди къызлагъа: / ‘Бу къошуннга хар заман / Турсун **огъурлукъ** агъа’. Бизге толгъан ай бла жангы толу **огъурлулукъ** келгенди. Мында **дарман-дары** жокъ, багъар онг жокъ. [Фельдшер:] Сайра жиляп башлагъанда, **дары-дарман** бла чумаданчыгъымы алып, жолгъа чыкъдым.*

Магъаналарына эм грамматика энчиликлерине кёре тамырлары бир болгъан ат синонимле быллай разрядланы къурайдыла: тукъум атла, энчи атла, абстракт атла, затланы белгилеген эм жыйымдыкъ атла.

Бир тамырлы тукъум атла бирча затланы атлары боладыла: *комбайнчы – комбайнер, огъурлукъ – огъурлулукъ*, энчи атла уа жангыз затланы атлары боладыла: *Илкер – Илкерле*: *Чочайланы Абдулсалам мюлкню **комбайнёру** болуп ишлегенли он жылдан атлагъанды. Колхозну алчы **комбайнчысы** Мирзантов Аскер район эришиуледе хорлагъанды.*

Тукъум атланы асламысы жылны кезиулерин: *жаз – жаз башы, кюз – кюз арты*; табийгъат болумланы: *бузлауукъ – бузкъаудан*; тюрлю-тюрлю жерлени атларын: *тёш – тёшлеу, сырт – сыртлыкъ*; усталыкъны: *моторчу – моторист, тракторчу – тракторист* белгилейдиле. Юлгюле: *Озгъан **кюз** къургъакъ эди. Алтын **кюз арты** келди биягъы. Кюн бетде гелеу кырдык **бузкъаудан** болгъанды. Орамла **бузлауукъдула**, машинала къыйналып жюрюйдюле. Ол (Масхут) **моторчу** болуп ишлегенли он жылдан атлагъанды. Мустафир **моторист** бла эки ай ишлегенлей, ишни халын ангылайды.*

Бир тамырлы ат синонимлени ичинде энчи атла да бардыла: адам атла: *Кезий – Кезийбан*; къыралны аты: *Россей – Арысей – Эресей, Грузия – Гюржю*: ***Эресейден** келген къонакъны сыйын кётюре билигиз! Нечик узундула, Тауусула билмейин, **Арысейни** темир жоллары! Залийханланы Михаил **Россей** Федерацияны Илмула Академиясыны академигиди.*

Бир тамырлы тукъум атланы ичинде бир бирине синонимлик этип келген кёзюнг бла кёрюрге, къолунг бла къатылыргъа болгъан затланы атлары эм абстракт атладыла: *эшме – эшим – эшимди, къабакъ – къабакъ эшик, саудюгер – саудюгерчи, сёгюм – сёгюнч – сёгюу, къоркъуу – къоркъунч* эм д.б. Юлгюле: *Мурат **къабакъны** бояп бошаргъа анасы базардан къайтды. Кече белинде **къабакъ эшик** къагъылды. Жигит жигитлей къалыр тап жаннга **къоркъуу** жерде. Аны жюрегине **къоркъунч** кирген эди.* Башда берилген абстракт атланы белгидеген бир тамырлы синонимлени кёплюк сан формалары болмайды.

Бир бирине синоним болуп келген, кёзюнг бла кёрюрге, къолунг бла къатылыргъа болгъан затланы атлары къарачай-малкъар тилде ашарыкъланы, къумачланы, битимлени эм д. б. затланы белгилейдиле: *картоф – гардош, хыртлы къатапа – сыртлы къатапа – къурт къатапа, габу – габушур, маймёз – мёз.* Быллай синонимлени тамаллары асламысында къуралмагъанла боладыла. Юлгюле: *Элни ичинде, суу боюнунда, чегет жанын **габу** басып, бир уллу гыйы таш болгъанды. Деменгили ташланы **габушурлары** фарс кюйюзлени оюйларына ушайдыла. Аман къатынны хуржунунда гыржыны болур, иги къатынны кюбюрюнде **мёзю** болур. Къатапа, **маймёз**, акъ гетен, сирнек, сапын дей келгенлей, фактурада жазылгъан элли килограмм къайнагъан сары жау жетмейди.*

Къарачай-малкъар тилни ат кесегинде тюбеген бир тамырлы къош синонимле компонентлери жерлери бла алышынып къураладыла. Быллай синонимлени асламысы жыйымдыкъ магъананы билдиреди. Кеслерин да юч къауумгъа юлеширге боллукъду: 1) эки компонентни да магъаналары болады, кеслери да бир бирине синонимлик этедиле: *ыспас-бюсюреу – бюсюреу-ыспас, кюч-къарыу – къарыу-кюч, къоншу-тийре – тийре-къоншу,* саулукъ-эсенлик – эсенлик-саулукъ эм д. б.; 2) бир компонентни магъанасы барды, бирини уа жокъду (редупликация амал бла къуралгъандыла): *сабий-сюбюй – сабий-балий – сабий-балыкъ, дауур-дууур – дауур-сууур – дауур-сюйюр, жабу-жубу – жабу-жаха* эм д. б.; 3) эки компонент да субстантивленнген этим формаладыла: *келген-кетген – кетген-келген, баргъан-келген – келген-баргъан, алыш-бериш – бериш-алыш, бериу-алыу – алыу-бериу* эм д.б.

Башда берилген къауумладагъы бир тамырлы синонимле бирча затланы жыйымдыкъ кёргюзтедиле. Алай бла, жангызлыкъ формада келгенликге, кёплюкню белгилейдиле. Юлгюле: *Нартла Ёрюзмекден **эсенлик-саулукъ** сордула. Сизге тилейме **саулукъ-эсенлик**. Халкъ **ыспасын-бюсюреуюн** Жулдуз этип такъгъанды сени кёкюрегинге. Жан-жаныуар хар бири кесича табийгъатха **бюсюреуюн-ыспасын** айтады. Жашла жыйылыпдыла, **жабу-жаха** къыстау барады. Асыры **жабу-жубудан**, аланы не айтханлары ангылашынмайды. **Дауур-дууур** бираз шошайгъанлай, Зулкъарней жетди. **Дауур-сюйюр** жангыдан башланды, талай адам бёрклерин кёкге-кёкге атдыла.*

Башда айтылгъаннга кёре, къарачай-малкъар тилде бир тамырлы синонимле былай къураладыла: морфология мадар бла: *эшме – эшим, кёрюм – кёрюмдю* эм д. б.; 2) синтаксис мадар бла: *ачыгъаууз – ауузачыкъ, эркегырыу – эр киши* эм д. б.; 3) морфология-синтаксис мадар бла: *сыртлы къатапа – хыртлы къатапа, саулукъ-эсенлик – эсенлик-саулукъ* эм д. б.

Къарачай-малкъар тилде бир бирине синонимлик этип жюрюген бир тамырлы этимле аслам тюбейдиле: *тийир- – тийдир-, букъ- – бугъун-, юркют- – юркдюр-, шошай- – шошлан-, бездир- – безит-, алыш- – алышындыр-* эм д. б. Бир бирине синонимлик этип жаланда эки бош этим угъай, бош этим эм къош этим да жюрюйдюле: *мудахлан – мудах бол, даула – дау эт, сабырлан – сабыр эт (бол)* эм д. б. Къарачай-малкъар тилде морфология амал бла къуралгъанла баш, зорлаучу, къысылыучу айырма формалада тюбейдиле.

Баш айырманы формасында жюрютюлгенле эки тюрлюдюле:

а) эки синонимден бири къуралгъан, бири уа къуралмагъан: *жора- – жорала-, бат- – батыл-, биш- – бишгеклен-, кеч- – кечир-* эм д. б.: *Магомет, келгенлеге сабырлыкъ, игилик*

***жорай***, *жютюрек къарады. Ол кесини сёзюню асламысын энергетиканы айныууну вопросларына* ***жоралагъанды***;

б) эки члени да къуралгъанла: *ачыулан- – ачыусун-, ёчюк- – ёчюклен-, ачыулан- – ачыусун-, азай- – азлан-, байын- – байыкъ-* эм д. б.: *– Ийман бла ёллюксюз, жаназыгъыз къылыннықъды, къалай ангыламайсыз, жамагъат?! – деди* ***ачыуланып*** *Хасан афенди. Ол кюн Махсют бек* ***ачыусунуп*** *эди, кёп тюрт сёз айтды.*

Бир бирине синонимлик этген къысыучу айырмадагъы этимле быллай аффикслени болушлукълары бла къураладыла:

а) *-гъыз/-гиз, -гъуз/-гюз, -дыр/дир, -дур/-дюр*: *киргиз- – кирдир-, тургъуз- – турдур-, кёргюз- – кёрдюр-*: *Устаз, жашчыкъны ёрге* ***турдуруп***, *дерслеге талай кюнню нек келмей тургъанын сорду. – Татлы жукълап тургъан сабийлени тёшеклеринден* ***тургъузуп***, *ашыкъ-бушукъ кийиндирдик*;

б) *-ыт/-ют, -дыр/-дюр, -т – -дир*: *саркъыт- – саркъдыр-, юркют- – юркдюр-, кепчит- – кепдир-*: *Аяз бираз* ***кепчитгенден*** *сора, жайылгъан гебенлени жангыдан батанла этдик. Жамилят жууугъан быстырларын иги* ***кепдирмей*** *жыйды да итиу салып башлады*;

в) *-из/-ыз, -дир/-дыр*: *эмиз- – эмдир-, тамыз- – тамдыр-, агъыз- – акъдыр-*: *Алим онбир фашист самолетну* ***агъызады***. *Мутай мирзеуню тирмен ташха алгъындан эсе аз* ***акъдырады***, *ун да энди ууакъ болады*;

г) *-ыл + -т – -дыр: атылт- – атдыр-, батылт- – батды-р*: *Эки кере да гранатла быргъап, ала штабны* ***атдыргъан*** *эдиле. Минала салып да биз жауну талай танкын* ***атылтханбыз***.

Зорлаучу айырма экиленнген аффиксден да къуралыргъа болады, алай а магъанасы тюрленмейди: *айтыл- – айтылын-, табыл- – табылын-, этил- – этилин-, элтил- – элтилин-, буюрул- – буюрулун-, чакъырыл- – чакъырылын-, бегитил- – бегитилин-* эм д. б.: ***Чакъырылынмай*** *келгенле Аскер бла Атайдан сора да бар эдиле.* ***Чакъырылмай*** *келген къонакъ сыйланмай кетер.*

Бир бирине синонимлик этген бир тамырлы этимле жаланда бир айырма формада болмай, эки айырма форманы арасында да бир бирге синонимлик этедиле. Синоним тизгинни бир члени баш айырма формада, бирси уа къысыучу неда къайтыучу айырма формада боладыла: *боша- – бошат-, бит- – битдир-, кючле- – кючлендир-, эриш – эришлен-, къоркъ- – къоркъун-, букъ- – бугъун-, къыз- – къызын, таукелле- – таукеллен-* эм д. б.: ***Къызып*** *келген 'Волга' / Тюз юсю бла ётдю, / Жагъып аны (кирпини) жолгъа, / Жол азыгъы этди. Теке уа бютюн* ***къызынып***, */ Окъча барып башлады. / Хусейни, тюпбаш чюелтип, / Жол тюбюне ташлады. Хар ким кёлюндегин айта, бир бирине* ***эришгенден*** *чам эте, кечени ауурлугъу кетгинчи олтурдула. Ол (Люба) манга* ***эришленип*** *этеди алай. Ол хал бла жанындан тойдуруп,* ***эришленип***, *жашына келинин къойдурур.*

Алайды да, къарачай-малкъар тилде сёдегей айырма формала синоним тизгинни бек аз къурайдыла: ойлан- (къайт. а.) – ойлаш- (араш а.), жаздыр- (къысыу. а.) – жазыл- (къайт. а.), алдан- (зор. а.) – алдат- (къысыу. а.): *(Тахир): Оллахий, бу жол болмаса, былай* ***алданмагъан*** *эдим. Махти, Назиляны кука сёзлерине* ***алдатып***, *юйдегисинден айырылды. Оюм бла* ***ойлансанг***, *юйлю болурса.* ***Ойланмай*** *сёлешген, аурумай ёлюр. Эсимдеди кёп хатагъа байланнганым, хата этип тюшюннгеним,* ***ойланнганым***, */ Тенгчиклени, сабийлени уруп, къыйнап, / Аналагъа кёрюнмейин айланнганым. Билмегенни алдагъан терлемейди, / Кёп* ***ойлашып*** *акъылын жерлемейди. Осуятымы алып окъусанг, /* ***Ойлашып***, *мыйынг ашланыр.*

Алайды да, къарачай-малкъар тилде бир тамырлы синонимле тилни энчи кесеклеринде да тюбейдиле. Быллай синонимле морфология, синтаксис амалла бла къураладыла. Къуралыу жаны бла бош эм къош сёзле боладыла. Магъаналарына кёре тюрлю-тюрлю затланы, ишни бардырыуну, этиуню белгилейдиле.

## Список литературы

1. Алиева Т.К. Проблемы отграничения вариантности слова от смежных явлений // Вестник Пятигорского государственного лингвистического университета. – 2005. – № 3–4. – С. 88–92.

2. Ахматова М.А. Однокоренные синонимы в карачаево-балкарском языке: автореф. дисс. ... канд. филол. наук. – Махачкала, 1997. – 19 с.

3. Болганбаев А. Синонимы в казахском языке: автореф. дисс. ... докт. филол. наук. – Алма-Ата, 1971. – 92 с.

4. Гузеев Ж.М., Ахматова М. А. Однокоренные синонимы в карачаево-балкарском языке. – Нальчик: Издательский отдел КБИГИ РАН, 2014. – 128 с.

5. Сейдалиев Н.Ф. Стилистические синонимы в современном азербайджанском языке. – Баку, МВМ, 2010. – 124 с.

6. Суранчиева Б. Синонимы в киргизском языке: автореф. дисс. ... канд. филол. наук. – Фрунзе, 1971. – 21 с.

7. Улаков М.З., Хуболов С.М. Адвербиальные фразеологизмы как репрезентаторы различных типов конкретизаторов в карачаево-балкарском языке // Вестник Северо-Осетинского государственного университета имени К. Л. Хетагурова. – 2014. – № 2. – С. 213–216.

8. Умбаров Н. К вопросу об аффиксальной синонимии // Вопросы романской филологии: Уч. зап. Ташкентский ун-т, 1968. – Вып. 318. – С. 19–21.

9. Уразбаева З.Г. Вариантность слова в современном башкирском литературном языке: автореф. дисс. ... канд. филол. наук. – Уфа, 1980. – 20 с.

10. Ханбикова Ш.С. Татар телендә синонимнар. – Казан: Университет нәшрияты, 1961. – 197 б.

11. Хуболов С.М. Семантические разряды компаративных фразеологизмов в карачаево-балкарском языке // Известия Кабардино-Балкарского научного центра РАН. 2015. № 1 (63). – С. 290–294.

12. Ketenchiev M.B., Dodueva A.T., Uzdenova F.T., Khubolov S.M. Names of months and national linguistic picture of the world on material of Karachai-Balkarian folklore and literature// Dilemas contemporáneos: Educación, Política y Valores. 2019. Vol. 6, iss. S7. Article Number: 13.

13. Novgorodov I.N., Gadzhiakhmedov N.E., Ketenchiev M.B., Kropotova N.V., Lemskaya V.M. Chulym Turkic is a Uralian Kipchak language, according to the Leipzig-Jakarta list / Advances in Intelligent Systems and Computing. – 2019. – Vol. 907. – P. 411–419.

© Ахматова М.А., 2025

УДК 811.512.145

**Баймухаметова Л.А.,**
*студент 2 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Гайнуллина Г.У.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

# БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫРГАЗЫ РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ДИАЛЕКТАЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация.*** *Әлеге мәкаләдә Башкортстан Республикасының Авыргазы районы диалектизмнарының фоникасы, фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре карала.*
***Терәк сүзләр:*** *лексика, морфология, фонетика, диалектлар, диалектизмнар*

Бүгенге көндә глобализация һәм телләрне стандартлаштыру шартларында җирле диалектлар югалу куркынычы астында кала. Шушы шартларда диалектларны өйрәнү, документлаштыру һәм киләчәк буыннарга тапшыру – аеруча мөһим бурыч. Авыргазы районы диалектлары – татар теленең байлыгын күрсәтә торган бер чыганак, һәм аларны фәнни яктан өйрәнү зур әһәмияткә ия. Диалектларның әһәмияте социаль һәм мәдәни яктан да зур. Аларның ярдәмендә без төбәкнең этник составы, тарихи элемтәләре һәм мәдәни традицияләре турында күбрәк белә алабыз. Диалектлар үзенчәлекле мәдәниятнең бер өлеше булып торалар, аларны өйрәнү һәм саклау телнең киләчәген тәэмин итү өчен кирәк.

Бүгенге көндә татар теленең кайбер диалектлары югалу куркынычы астында тора. Мәгариф һәм массакүләм мәгълүмат чараларында гадәттә әдәби тел кулланыла, ә диалектлар көндәлек сөйләмдә генә саклана. Бу исә аларның югалуына китерергә мөмкин.

Шуңа күрә диалектларны өйрәнү, документлаштыру һәм саклау бик мөһим. Диалектлар – телнең тарихи һәм мәдәни мирасын чагылдырган элементлар булып торалар, аларны саклау милли үзаңны үстерүгә һәм телнең киләчәктә яшәешен тәэмин итүгә ярдәм итә.

Авыргазы районы диалектларында татар теленең гомум нормаларыннан тайпылган, җирле сөйләмгә генә хас булган үзенчәлекле фонетик күренешләр күзәтелә. Бу үзенчәлекләр, нигездә, авазларның үзгәреп әйтелешендә, авазлар төшеп калу яки өстәлүендә, сингармонизм законының үзенчәлекле кулланылышында чагыла. Авыргазы районы диалектларында аерым авазларның икенче аваз белән алышынуы очрый. Бу күренеш, нигездә, борынгы тел формаларының саклануы һәм күрше телләр белән тел-контактлар нәтиҗәсе булып тора.

- [ч] авазы еш кына [ш] рәвешендә ишетелә: *чәч → шәч, чәчәк → шачак*
- [г] авазы [к] белән алмаштырыла: *кыргый → кыркый, бәйрәмгә → бәйрәмкә*
- [к] – [х] авазлары арасында күчеш күзәтелә: *кыйммәт → хыйммәт, кул → хул*

Кайбер сүзләрдә авазларның төшеп калу күренеше күзәтелә. Бу сөйләмнең ритмик кыскалыгына һәм җирле аралашу теленә бәйле: *барасыңмы → барсыңмы, ала идем → ал'идем.* Кайбер очракта, киресенчә, авазлар өстәлә: *укыган → укыганлы, барган → барганлы.* Сузык авазларның үзгәреше – Авыргазы районы диалектларында иң еш очрый торган күренешләрнең берсе:

-[ө], [ү] авазлары кыскарак, кайвакыт [е], [и] рәвешендә әйтелә: *күрә → керә, түрдә → тердә*; [ы] авазы киңәйтелеп әйтелә: *кыз → кыйз, кылган → кыйлган.*

Авыргазы районы диалектларындагы фонетик үзенчәлекләр җирле тел мохите, тарихи үсеш, шулай ук башкорт, рус һәм башка телләр белән тыгыз бәйләнештә формалашкан. Бу үзенчәлекләр татар теленең диалектологиясе өчен әһәмиятле материал булып тора һәм фәнни яктан аерым игътибар таләп итә. Аларны өйрәнү телнең региональ вариантларын системалы тикшерүгә, тел үзгәрешләрен һәм сакланышын аңлауга ярдәм итә.

Авыргазы районында яшәүче татар халкының сөйләмендә, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләр һәм авыл халкы телендә, әдәби тел нормаларыннан шактый тайпылышлар күзәтелә. Алар лексик, фонетик үзенчәлекләр белән беррәттән, морфологик өлкәне дә колачлый.

Авыргазы районы диалектларында килеш кушымчалары еш кына үзгәртелеп әйтелә. Бу үзгәрешләр, нигездә, сөйләмнең гадиләшүе, фонетик үсеш, җирле тел традицияләренең саклануы нәтиҗәсендә барлыкка килә:

– Юнәлеш килеше: *мәктәпкә → мәктәпкәе, кибеткә → кибеткәе, эшкә → эшкәе.*

– Чыгыш килеше: *авылдан → авылнан, клубтан → клубдан.* Монда [д] һәм [н] авазларының алмашуы күзәтелә.

- Урын-вакыт килеше: *йортта → йорттае, базарда → базардае.* Мондый формалар халык сөйләменең үзенчәлекле ритмикасын тудыра.

Иялек килешендә кушымча үзгәрешләре: *әнинең күлмәге → әнинен күлмәге.* Монда кушымча еш кына авазларның төшеп калуы, йә кыскартылып әйтелүе нәтиҗәсендә үзгәрә.

Фигыль – татар телендә иң катлаулы һәм бай морфологик категорияләрнең берсе. Авыргазы районы диалектларында фигыль формаларының үзенчәлекләре шактый төрле.

Үткән заман формалары: *укыган иде → укыганды, кайткан иде → кайтканды. Б*у формада "иде" фигыле [ды/де] формасына кыскара, сөйләмдә еш очрый.

Киләчәк заман: *барырмын → барым, киләчәкмен → килмен.*

Татар теленең диалектлары, бигрәк тә Авыргазы районы кебек Башкортстан территориясендә урнашкан төбәкләрдә, лексик яктан шактый бай һәм үзенчәлекле. Лексик үзенчәлекләр телне өйрәнүдә мөһим урын алып тора, чөнки алар төбәк халкының көнкүреше, менталитеты, тарихи-мәдәни үсеше, этнографик үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләнгән. Авыргазы районы халкы сөйләмендә сакланып калган күп кенә сүзләр әдәби телдә кулланылмый, яки бөтенләй билгеле түгел. Күп очракта бу сүзләр борынгы төрки элементларны, иске татар лексикасын, башкорт теленең үтеп керүен, шулай ук рус теленнән кергән үзгәртелгән алынмаларны күрсәтә.

Этнографик һәм көнкүрешкә бәйле лексикага халыкның көндәлек тормышында кулланыла торган, әдәби телдә сирәк очрый торган сүзләр керә.

- *сөңгәч* – чиләктән вак чүмеч, кечкенә савыт,
- *түшлек* – аш пешерү өчен кулланыла торган тимер яки балчыктан ясалган савыт,
- *карсак* – бүре баласы (балалар уенында, фольклорда да очрый),
- *зәмбил* – үреп ясалган капчык, сумка.

Бу сүзләрнең күпчелеге авыл халкының хуҗалык эшләре, аш-су, кием-салым, йорт җиһазлары белән бәйле. Алар халык телендә буыннан-буынга тапшырылып килә.

Авыргазы районы халкының табигать белән тыгыз бәйләнеше, игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүе нәтиҗәсендә, табигать күренешләренә бәйле сүзләр шактый актив кулланыла:

- *чүмәлә* – печәнне өеп куелган зур өем
- *кыркын* – көтүдән кайткан терлекләрне төнге торуга бүлү урыны
- *сөбә* – йомшак кар
- *тәңгәл* – кечкенә күл яки күл өстендәге су җыелмасы

Күпчелек шундый сүзләр төбәк халкының табигатьне тоюын, аның элементларын төгәл тасвирлау өчен кулланган сүз байлыгын күрсәтә.

Диалектларда әдәби телдә югалган борынгы төрки лексик элементларның сакланып калуы – тел тарихын өйрәнү өчен кыйммәтле чыганак. Авыргазы районы сөйләмендә:

- *йал* – ял итү генә түгел, ә «пычак яллау», «йорт эшен ял белән башкару» кебек күптөрле мәгънәдә,
- *каба* – агач савыт.
- *җилем* – сыек бал, сироп,

- *карга* – кайбер җирлектә «каз» мәгънәсендә кулланыла. Бу сүзләр еш кына фольклорда, халык җырларында, әкиятләрдә дә очрый.

Авыргазы районының лексик үзенчәлекләре татар теленең байлыгы, тарихы һәм үсеш юнәлешләре турында тулы картина тудыра. Бу сөйләмдә төрки тамырлы сүзләр, башкорт һәм рус телләреннән алынмалар, көнкүреш-көндәлек тормышка бәйле терминнар, хис-кичерешне белдерүче образлы сүзләр урын ала. Шушы үзенчәлекләрне өйрәнү – халык телен саклау, милли үзаңны ныгыту, тел белеменә нигезле фәнни караш тудыру өчен мөһим. Диалект лексикасы – телнең рухи байлыгы, һәм ул халык хәтерен, мәдәниятен саклап килүче төп күрсәткечләрнең берсе булып тора.

Авыргазы районы татар диалекты – татар теленең төньяк-көнбатыш диалект төркеменә кергән, үзенә генә хас булган фонетик, морфологик, лексик үзенчәлекләре белән аерылып торучы бер лингвистик катлам. Әлеге диалект формалашуында берничә тарихи, этник һәм географик фактор йогынты ясаган: Башкортстан территориясендә күп гасырлар дәвамында татарларның, башкортларның һәм русларның янәшә яшәве, күпкырлы мәдәни мөнәсәбәтләр, миграция процесслары, шулай ук табигать шартлары һәм көнкүреш үзенчәлекләре.

Фонетик яктан караганда, сөйләмдә авазларны йотып әйтү, сингармонизмның саклануы, сузыкларны үзенчә үзгәртеп әйтү кебек күренешләр күзәтелә. Морфологик үзенчәлекләр арасында фигыль формаларының үзгәреше, кушымчаларның вариантлары, кайбер сүз төркемнәренең куллану үзенчәлекләре аеруча игътибарга лаек. Лексик яктан исә сөйләм шактый бай: көндәлек тормыш, халык һөнәрчелеге, табигать күренешләре белән бәйле сүзләр; борынгы төрки сүзләрнең сакланып калуы; башкорт һәм рус телләреннән кергән алынмаларның җирле үзенчәлекләргә яраклашып үзгәртелүе күзәтелә.

Авыргазы районы татарлары сөйләмендә сакланып калган бу диалекталь үзенчәлекләр – безнең телебезнең тарихын, халыкның фикерләвенә, дөньяны күзаллавына хас булган үзенчәлекләрне чагылдыручы кыйммәтле мирас. Диалектларны өйрәнү – татар теленең үсеш юнәлешләрен, эчке байлыгын тирәнтен аңлау өчен фәнни һәм мәдәни яктан мөһим.

Шуңа күрә Авыргазы районы диалектын өйрәнү һәм саклау гына түгел, ә аны киләчәк буыннарга тапшыру да – тел һәм мәдәниятне саклау юнәлешендә зур әһәмияткә ия гамәл. Диалектлар – телнең тере формасы, халыкның йөрәгендә яшәүче, тормыш белән үрелеп баручы рухи байлык ул.

**Кулланылган әдәбият**


1. Бурганов М.З. Татар диалектологиясе. – Казан: Мәгариф, 2005.
2. Махмутова Р.З. Татар теленең төньяк-көнбатыш диалектлары. – Казан: ТКН, 2010.
3. Хөсәенов Г.Х. Татар теле диалектлары. – Казан: Фән, 1987.
4. Салихов Ф.С. Татар диалектологиясенә кереш. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2001.
5. Хәйруллина А.М. Башкортстан татарлары сөйләменең лексик үзенчәлекләре. – Уфа: БашДУ, 2012.
6. Татар теленең диалекталь сүзлеге. – Казан: Фән, 1990.
7. Юнусов М.З. Диалектларны өйрәнүнең фәнни нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2004.


© Баймухаметова Л.А., 2025

УДК 821.512.145

**Баймухаметова Л.А.,**
*студент 2 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Халиуллина А.Г.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

# Ф. БАТТАЛ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ АВТОР ПОЗИЦИЯСЕ

***Аннотация.*** *Бу мәкаләдә танылган татар язучысы Фәнзаман Баттал иҗатында автор позициясен чагылдыру үзенчәлекләре тикшерелә. Әдәбиятта «автор» төшенчәсенең төрлечә аңлатылуын анализлап, мәкалә авторның әсәрнең төрле элементлары аша үзенә хас булган позицияне, дөньяга карашны һәм эстетик мәгънәне ничек ачуын тикшерә. Ф. Батталның сатирик әсәрләренә таянып, авторның геройларга мөнәсәбәте, аларны иҗат итүдә сатирик алымнарны куллануы, шулай ук совет һәм постсовет чоры феноменына бәя бирүе ачыклана. Мәкалә әхлакый кимчелекләрне, акылсызлыкны тәнкыйтьләүдә авторның сатира мөмкинлекләрен дә күрсәтә.*

***Терәк сүзләр:*** *автор позициясе, сатира, хикәяләү методы, персонаж, сатирик пафос, гипербола, абсурд, татар прозасы, образлар системасы*

Әдәби иҗатны фән һәм публицистикадан, дин һәм фәлсәфәдән, җитештерүче хезмәт һәм сәясәттән әдәбилек аерып тора. «Сәнгатьнең үзенчәлеге аның эстетик табигатеннән үсеп чыга» [5, 24 б.]. Ягъни шәхес рухи дөньясының ихтыяҗларын иҗат канәгатьләндерә, кешеләр арасында эстетик мөнәсәбәт урнаштыра. Автор исә шул рухи ихтыяҗларны канәгатьләндерүче бербөтен әсәрне иҗат итүче булып тора. Хәзерге әдәбият белемендә бу төшенчәгә төрлечә билгеләмә бирәләр: «Автор – әдипнең үз әсәрендә катнашу, иҗади «мин»ен белдерү чарасы, хикәяләүче, лирик герой аша белдерелә торган бөтенлекне образ; язучы-автор белән тәңгәл килмәсә дә, сурәтләнгәннәргә мөнәсәбәт белдерүче һәм бәя бирүче әсәрнең төрле элементларында үз позициясен ачык күрсәтүче. Текст эчендәге автор яки имманент автор дип йөртү кабул ителгән» [5, 11 б.]. Әдәбият белгече Н.А. Кожевникова «Автор образы иң элек хикәяләү алымында чагыла» [3, 3 б.] дип билгеләи. Шулай ук бер үк вакыйгага карата автор да, хикәяләүче дә, персонаж да төрле караштa булырга мөмкиннәр дигән кызыклы фикер әйтә.

Бүгенге сатира өлкәсендә эшләүче язучыларның берсе Фәнзаман Батталның да үзе тудырган катлаулы геройларына карата үз позициясе, үз мөнәсәбәте бар. Чыннан да, тикшеренүләрдә ассызыклануынча, Ф.Батталның «сатирик амплуадагы әсәрләрендә гәүдәләндерелгән типлар үзләренең катлаулылыклары, эчке дөньяларының тирән сурәтләнелеше белән аерылып торалар» [4, 166 б.]. Позициясен автор ачыктан-ачык та, киная, төптә яткан мәгънә ярдәмендә дә белдерүгә ирешә. «Иптәш Сталин булсамы?!» хикәясендәге Сәмигуллинга карата мыскыл итү, көлүне укучы беренче юллардан ук күрә. Биредә хикәяләү Сәмигуллинның үз тарафыннан алып барыла, ләкин бу һич тә авторга үз позициясен күрсәтергә комачауламый. Сүз сәнгатендә һәр детальнең мөһим булуы безгә мәгълүм. Диалог, монолог, персонажларның сөйләме аша автор безгә ниндидер вакыйганы гына бәян итеп калмый, ә чорга, персонажларга бәя бирә. Үзен «Тауариш Сталин»нын якын дусты дип хәбәр сатучының монологы бик кызык. «Серп и Молот» заводын берүзе җылытып торган кәчигәрнең» [1, 11 б.]. Сталин белән сөйләшеп утыруы, ил башлыгының Сәмигуллинга завод директоры вазифасын тәкъдим итүе була алмастай хәл. Автор персонажының сөйләме ярдәмендә аңа булган мөнәсәбәтен белдерә. Сәмигуллинның сөйләмен «әтчәйни егет», «кәчигәр», «әфтәритле», «упшыжития», «җәвитсә», «тучны», «хараша», «партрит», «фифируз», «грамыт», «нәчәлник», «расчут» кебек сүзләр чуарлый. Безнең алга уку-язуны үзләштермәгән, илдәге хәлләрнең дә асылына төшенеп бетмәгән герой

килеп баса. Нәкъ шушы герой үткәннәргә һәм бүгенгегә бәя бирүче булып тора. Күпмедер Сталин шәхесенә һәм заманына карата дөрес сүзләр дә ишетелә: «Ул заманда бит кеше аралаш аталар иде» [1, 12 б.]. Биредә авторның үзенең фикере яңгырый дисәк тә була. Автор Совет чорындагы гади эшче психологиясен тотып ала алган: Самигуллин үткәннәрне кайтарырга теләүчеләр рәтендә, һәм ул үз позициясен дә аңлатырга омтыла. Ләкин автор аңардан көлә.

«Мәет белән очрашу» хикәясендәге Зәет тә көлке объекты булып тора. Без Зәет исемле егетнең үз сәламәтлеген чиктән тыш кайгыртып, мәгънәсез тормыш алып баруын күзәтәбез. Хикәяләү аның дусты исеменнән бара, Зәеткә ул мондый бәя бирә: «Караватына ятар алдыннан, өстәл лампасына үтә якты лампочка бора да, сәгать буе шәрә тәнен тикшереп утыра: теге яки бу бетчәсе зураймаганмы, төсен, равешен үзгәртмәгәнме, кан тамырларының берәрсендә тараю-киңәю галәмәте сизелмиме, жыерчык-мазар артмаганмы?...» [2, 139 б.]. Геройның сәламәтлеген кайгырту күренеше чамадан тыш күпертелеп, ягъни гипербола алымы ярдәмендә тасвирланыла. Автор позициясе нәкъ шушы арттыруда күренә. Язучы укучы хөкеменә абсурд ситуация чыгара. Геройның эш-гамәлләре акылга сыймаслык. Зәетне исә автор көлү объекты итеп ала.

«Алланың кашка тәкәсе» хикәясе исә «Демократия аркасында кеше булды китапханәче Иргали» [1, 111 б.] дип башлана. Беренче юллардан ук авторның бу персонажга кире мөнәсәбәте тоела. Иргали хакында автор болай яза: «Демократия чаңының беренче авазлары яңгырауга ук Иргали кулына каләм алды. Алып кына калмады, карага манды. Манып кына калмады, язып та куйды: «Хөрмәтле редакция...» [1, 112 б.]. Биредә сатирик пафос турында әйтергә урын бар. «Сатирик пафос тормыштагы тискәре якларны тәнкыйтьләү, кире кагу» [5; 135 б.]. Автор үзәккә укучыда тискәре мөнәсәбәт уятырлык героен куеп, үзенең тискәре көлүен җитди, уйланып-борчылып көлү белән бәйли. Ашханә мөдирен, кирпеч заводы директорын, район җитәкчесен, министрны тәнкыйть утында беркемнән дә куркып тормыйча яндыра ул. Иргали үзенең гамәлләре хакында болай ди: «Гаепле кеше, кем булуына карамастан, кылган гамәле өчен җавап бирергә тиеш. Бу дөньяда беребез дә алланың кашка тәкәсе түгел. Курка торган күлмәкләр сиксән бишенче елда ук тузды, туганкаем...» [1, 114 б.]. Хикәяләүче аның адресына «Утка керсә дә сүзеннән кайтмас, өстенә танк килсә дә чигенмәс...» [1, 114 б.] дигән сүзләрне әйтә. Бу арттыру алымы шулай ук көлү коралы булып тора. Ә инде Иргалинең чын йөзе азактан ачыла.

Хикәяләүченең бөтен мебельне, иң кадерле китапларны үзенең өенә ташып бетергән директоры хакында мәкалә язарга тәкъдим итүен катгый рәвештә кире кага. «Минем але бу дөньяда яшисем, ай саен хезмәт хакы аласым килә» [1, 114 б.], – ди ул. Авторның бу үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, дан артыннын гына куучыга тискәре мөнәсәбәте «сискәнеп куйды», «мескен», «аяк очына гына басып», «ыңгырашкан тавыш», «бер кулы белән йөрәген тотты, икенчесе белән маңгаендагы тирләрен сөртеп алды», «кипкән телен көчкә әйләндереп» дигән сүзләрендә чагыла. Хикәянең исемендә үк авторның позициясе күренә. «Алланың кашка тәкәсе» дип ул Иргалине атый.

«Күзле багана» хикәясендә «Өеннән биш-алты адымда гына кукыраеп баскан Бөек Шәхес һәйкәле» [1, 44 б.] өчен хәвефләнүче Зөлхиҗҗә әбигә карата әсәр башында автор теләктәшлек белдергән кебек тоела. Беркатлы әбинең, даһиның сыны соңгы елларда саламторханга ошый башлавын күреп, шәһәр Советы рәисенә хат язу тарихы автор тарафыннан бик гадәти күренеш итеп сурәтләнелә. Әбинең өзгәләнүләре «Бөек Шәхес һәйкәленә куңелем сызып яшәгәндер, бер елда ун еллык картайдым», «Зинһар, төзәттерегез, чарасын күрегез. Кыл очында torгандай гына тора бит ул хәзер...» [1, 45 б.] кебек хат юлларында күрсәтелә. Ләкин әби үз мәнфәгатьләрен кайгыртып эшли. Безгә бу хакта әбинең сеңлесенә, үзе кебек ялгыз яшәүче Зөлхия карчыкка язган хатыннан мәгълүм була. «Ярый төшсен әйдә. Болай да кулына каратып күп алдады.... Иллә дә мәгәр ул Һәйкәл өчен еллар буе сызып яшәүче мин генә булдым. Ни өчен дисәң, бүген-иртәгә ул минем өемә авачак!» [1, 46 б.]. Автор бу героен яратып сурәтли. Ялгыз яшәгән карчыкның психологиясен белеп эш итә

ул. Шушы ук әсәрдә «Бөек Шәхес» образына авторның мөнәсәбәте күренә. «Кукыраеп баскан Бөек Шәхес һәйкәле», «саламторхан», «күз көеге» кебек сүзләр әсәрдә аңа адреслана.

Фәнзаман Батталның геройлар галереясендә кемнәр генә юк: мафиянең котын алган Мәгъфия, олыгыйган көнендә «Мисс-Тулбай» титулына лаек булган Ләүфелмәхфүзә карчык, Сталинның үзе белән сөйләшеп утырган Сәмигуллин һәм башкалар.

Шулай итеп, Ф.Баттал автор-скриптор буларак геройларына үз позициясен генә белдереп калмый, а чорга бәясен дә бирә. Ф. Баттал җәмгыятебезгә хас тискәре сыйфатларны, әхлакый бозыклыкларны чор героен тасвирлаганда ачып бирүгә ирешә.

**Кулланылган әдәбият**


1. Баттал Ф. Бака да бата: Юмористик һәм сатирик хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 160 б.
2. Баттал Ф. Сигезенче оҗмах: Сатира һәм юмор, мәзәкләр базары, гыйбрәтле хәлләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.
3. Кожевникова Н.А. Типы повествования в русской литературе XIX-XX вв. – М.: Институт русского языка РАН, 1994. – 336 с.
4. Халиуллина А. Г. Заман һәм герой. – Уфа: БГПУ им. М. Акмуллы, 2007. – 206 с. – EDN VVVCOZ.
5. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.


© Баймухаметова Л.А., 2025

УДК 81'33

**Байрамукова А.И.**,
*профессор кафедры русского языка*
*ФГБОУ ВО «Карачаево-Черкесский государственный университет имени У.Д. Алиева»,*
*г. Карачаевск, Россия*

# ГЕРМЕНЕВТИЧЕСКАЯ ПРАКТИКА ИСТОЛКОВАНИЯ В.И. ДАЛЯ С ПОМОЩЬЮ ПОСЛОВИЦ И ПОГОВОРОК В ХУДОЖЕСТВЕННЫХ ТЕКСТАХ И «ТОЛКОВОМ СЛОВАРЕ ЖИВОГО ВЕЛИКОРУССКОГО ЯЗЫКА»

***Аннотация***. *В статье анализируется герменевтическая работа В.И. Даля по истолкованию пословиц и поговорок в художественных текстах и «Толковом словаре живого великорусского языка».*

***Ключевые слова:*** *пословицы, поговорки, герменевтика, словарная статья, художественный текст, словарные иллюстрации.*

Рубрика «Пословица – поговорка» из сборника «Пословицы русского народа» В.И. Даля подчеркивает важность пословиц для русского народа: «Старинная пословица не мимо молвится. Без пословицы не проживешь. Добрая пословицы не в бровь, а прямо в глаз. Над кем пословица не сбывается?» [2; 377].

С помощью пословиц и поговорок В.И. Даль помещает читателя в жизненные центры, проанализированные коллективным разумом народа. В художественных и художественно-публицистических текстах подчеркивается жизненность и непререкаемый авторитет пословиц: «… ***вот правду говорят наши пословицы***: всякую шутку к себе применяй, и шути, покуда краска в лицо не выступила!» (Автор, «Охота на волков») [3; 335]; «… ***по русской пословице***: первая брань лучше последней…» (Автор, «Генеральша») [3; 269]; «…есть пословка: в уйме (лесу) не без зверя, в людях не без лиха; ***а пословка на ветер не***

***говорится***» (Автор, «Колдунья») [4; 370]. Механизм повествования зиждется в том числе и на пословицах и поговорках. Главное выводится через синонимическое повторение пословиц и поговорок.

Герменевтическая работа В.И. Даля с пословицами и поговорками в художественных текстах характеризуется: **1) использованием пословиц и поговорок в речи героев; 2) использованием их в речи самого автора.**

1. Пословицы и поговорки **используются в речи героев** в виде каскада с целью разъяснения. «- ***Кинь корочку в гору,*** – говорил Долгай, ***выворачивая на изнанку смысл этой пословицы***: – придет к тебе в пору; не пожалей за рубль алтына, а не придет рубль, так придет полтина; кому счастье, кому талан, греби денежки в карман; не пойдешь в звонари, не попадешь и в пономари: кто смелый, кто счастливый, у кого на роду написано разжиться с легкой руки, из-под наперстка доски, в легкий день субботний! Что бабушка! аль за внука в солдаты идешь? – закричал он громогласно старушке, которая сгорбившись несла на плече продавать какое-то старое ружье... Народ захохотал, но смелый и счастливый не выходил: видно изверились на сегодняшний день, или берегли копейку на кружало» («Небывалое в былом или былое в небывалом») [3; 33];.

Подобно тексту словарной статьи, в которой в качестве словарных иллюстраций В.И. Даль предлагает блок пословиц и поговорок, в художественном тексте прояснение смысла идет за счет сцепления пословиц и поговорок.

«- По пустякам ты тревожишь их милость, – сказал он относительно заявления пропажи: – не и вправду им служить на нашего брата. Ты рублем прост, я умом прост; а по простому уму моему**,** что тише, то и лучше; за толчком не гонись, разве одного мало, так поди за другим... ***Так надо жить и всякому человеку; сам только никого не затрагивай, не обижай, а коли тебя обидят, нужды нет; в душе и сердце прости по-христиански, а по уму-разуму и для своей же пользы смолчи; не то вместо одного обидчика, набежишь на семерых.***

- Хорошо наставление ваше, Андрей Алексеевич, – сказал я: -да ину пору больно накладно. Ведь не на то же они поставлены, чтоб быть поголовно мошенниками и сживать со свету честных людей...

- Не осуждай, тёска, да не осужден будешь. Не особое же поколение для того на свете нарождается; попали бы мы с тобой туда, и мы были бы таковы же; стало быть, ***не гребень волос чешет, а время; не время волос белит, а кручина. Против попущения Божия спорить не станешь...*** » («Небывалое в былом или былое в небывалом») [3; 35];.

2. Одна пословица или поговорка **используется в речи героев** и участвует в процессе истолкования. «- Как ваша милость не верит, – сказал толковый и словоохотливый старик: – ***есть пословка: в уйме (лесу) не без зверя, в людях не без лиха; а пословка на ветер не говорится***. Не знаю я твоего имечка и отчества, а коли повелишь, ***расскажу я тебе бывальщину***, так вот сам скажешь опосля, каково дело это, верить аль не верить. Я вишь пораскалялся, ночь долга будет, станет поры еще и выспаться» (Хозяин избы, в которой остановился автор, автору «Колдунья») [3; 370].

3. Блоки пословиц и поговорок **используются в речи самого автора**, так как помогают автору прийти к адекватному прояснению смысла того или иного понятия: «Напротив, воспитатели покойника твердили ему на словах и в поучениях всегда противное, то есть приказывали быть правдивым, честным, прямым, даже добродетельным; да вот беда, – ***от слова не сбудется, криком изба рубится; поле – и все-то в один переклик, да не перейдешь сам, так и не будешь там, хош кричи, не кричи.*** Покойник же следовал наставникам своим всегда и во всем, доколе ходил между нами в тяжелке своем, то есть он всегда хвалил одну правду и всем наказывал любить ее; но ***он не путал слова и дела, и, различая одно от другого, как привык видеть сызмалу, говорил всегда, что должно, а делал, что было нужно***» (Автор, «Бред») [3; 101];. Каскад пословиц и поговорок является одним из герменевтических операторов, умело использованным в художественном и лексикографическом тексте.

4. Нередко одна пословица или поговорка используется **в речи автора** для уточнения смысла: «Напрасно предводитель старался вразумить генеральшу, что и сама она в деле этом не права, что вражде этой и взаимной мести конца не будет, если обе стороны станут продолжать подобную расправу, что самоуправство было тут обоюдное, ***и что, по русской пословице: первая брань лучше последней, надо это бросить и покончить,*** – все напрасно… « (Рассказчик, «Генеральша») [3; 269].

Следует отметить, что существует определенные закономерности ввода пословиц и поговорок в художественные тексты: наиболее частотно сцепления пословиц и поговорок используются в текстах, рисующих «русский мир», материальные и духовные составляющие этого мира («Русские сказки, из предания народного изустного на грамоту гражданскую переложенные, к быту житейскому приноровленные и поговорками ходячими разукрашенные Казаком Владимиром Луганским» (1832), «Солдатские досуги» (1843), «Картины русского быта» (1848–1861), «Матросские досуги» (1853), «Два сорока бывальщинок для крестьян» (1862), «Новые картины русского быта» (1861–1868), в повестях и рассказах, связанных с миром повседневности русского человека). Тексты данных циклов в буквальном смысле этого слова расцвечены пословицами и поговорками, участвующими в прояснение художественной реальности. Но наибольшей степенью использования пословиц и поговорок отличаются «Русские сказки».

Использование приема нанизывания пословиц и поговорок позволяет автору сказок концептуализировать понятия. «*…**Но бодливой корове Бог рога не дает; с иного сорвал бы и голову, так не ухватишь и волоса; норовишь соседу в бровь, а попадешь себе же в глаз!***» (Автор, «Сказка о Рогволоде и Могучане царевичах») [3; 39].

Назовем **общие тенденции употребления пословиц и поговорок** в художественных текстах и Словаре В.И. Даля: 1) тематическое сцепление пословиц и поговорок в блоки; 2) употребление синонимичных форм пословиц и поговорок.

По верному замечанию В. Аникина, «Являя в «Толковом словаре» пример словоупотребления, пословицы одновременно характеризуют строй народных мыслей и суждений о мире и жизни. Без пословиц было бы затруднительно дать самое толкование слов, тонких оттенков их смысла. Пословицы стали органической частью «Толкового словаря», а самая мысль внести их в словарь – не просто счастливая идея Даля, а следствие всех мыслей его о языке народа. Это выношенное убеждение» [1; 389]. Данное высказывание подчеркивает витальность языка и знания Словаря В.И. Даля.

Пословицы и поговорки, являющиеся словарными иллюстрациями к лексемам Словаря, демонстрируют авторитетное для В.И. Даля коллективное народное знание.

Рассмотрим параллели использования пословиц и поговорок в художественных текстах и Словаре. **Параллелизм привлечения пословиц и поговорок в художественные тексты и словарные статьи** заключается в: 1) объединении пословиц и поговорок в блоки, 2) использовании нарастающего порядка ввода пословиц и поговорок с целью прояснения смысла понятия.

Отрывок художественного текста: «*Есть притча короче носа птичья: жениться не лапоть надеть, а одни лапти плетутся без меры, да на всякую ногу приходятся! И истинно: жена не гусли: поигравши на стенку не повесишь, а с кем под венец, с тем и в могилу – приглядись, приноровись, а потом женись…*» («Сказка об Иване, молодом сержанте, удалой голове, без роду, без племени, спроста без прозвища») [3; 6]. С помощью ***процедуры жонглирования пословицами и поговорками*** В.И. Даль излагает житейский народный опыт по этому вопросу. Пословицы и поговорки формируют у читателя концептуальное представление о женитьбе.

*аспирант кафедры татарской литературы КФУ*
*Научный руководитель* – **Юсупова Н.М.,**
*профессор кафедры татарской литературы КФУ,*
*г. Казань, Россия*

## РӘДИФ ГАТАШНЫҢ 1960–80 НЧЕ ЕЛЛАР ИҖАТЫНДА КӨНЧЫГЫШ ҺӘМ ФОЛЬКЛОР ТРАДИЦИЯЛӘРЕ СИНТЕЗЫ

***Аннотация.*** *Мәкаләдә Рәдиф Гаташның 1960-80 еллар милли әдәбиятына керткән өлеше һәм аның шигърияте үсешенең төп тенденцияләре ачыклана. Аның иҗатында фольклор традицияләрен үстерүнең төп алшартлары күзәтелә, шуңа бәйле рәвештә ул татар шигъриятендә яңа офыклар ача. Анализ барышында Р.Гаташның шигъри табышлары ачыклана, модернистик эзләнүләргә хас үзенчәлекләр ассызыклана.*

***Терък сүзләр:*** *Р. Гаташ, поэзия, фольклор традицияләре, поэзия, тенденция, стиль.*

1960–1980 еллар – традицион татар шигъриятенең эчтәлек, хис һәм фикерне җиткерү формалары, бигрәк тә әдәби-эстетик хасиятләр ягыннан өр-яңа үзгәреш кичерү вакыты. «Аның алдагы чорлар белән чагыштырганда башкарак юнәлештә үсеп китүе фәлсәфи һәм сәнгати фикердәге яңалыклар, әдәбиятның иҗтимагый кануннарны алга куйган идеологик кысалардан чыгуга омтылышы, дөньяны, яшәешне образлы кабул итүнең яңа яклары ачылу белән аңлатыла» [1, 4 б.].

1960 нчы елларда әдәбиятка бер төркем талантлы шагыйрьләр ташкыны килә. Болар: Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Ренат Харис, аларга Рәшит Әхмәтҗанов, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Зөлфәт, Мөдәрис Әгъләмов кушылып китә. Бу сәләтле шагыйрьләр арасында Рәдиф Гаташ та була.

Рәдиф Гаташның эчке дөньясы, яшәү рәвеше шул кадәр үзенчәлекле, ул «дәвер кемнең дәвере» булуына карамастан, бер генә «җылы», дәрәҗәле урынны шагыйрь булудан тагын да өстен күрмичә, һәр заман дөнья мәшәкатьләренә артык әһәмият бирмичә, шигырь кебек пакъ хисләрен, кешелеклелеген саклап кала белә [5, 183 б.].

Рәдиф Гаташ – шәрык, төрек, Аурупа һәм рус әдәбиятлары өлкәсендә энциклопедик белемгә ия булган шагыйребез дә. Шагыйрь Роберт Миңнуллин Р.Гаташның бу үзенчәлеге турында сокланып болай дип язган: «Гаташны тыңларга кирәк! Шагыйрьне белер өчен, аның шигъриятен ныграк аңлар өчен, шигырьләренең асылына, серенә ихластан төшенер өчен, һич югында, бер генә булса да аның үзен тыңларга, сәхнәдән шигырь сөйләгәнен күрергә кирәк. …Сәхнәдә ул бөтенләй башка Гаташ. Бөтенләй башка эффект! Шигырьне яшьләрчә, дәрт белән, бөтен дөньясын онытып, экстазга бирелеп Гаташ кына укый ала!…»

Рәдиф Гаташны күп кенә шагыйрьләр (Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Чулпан Зариф, Луиза Янсуар һ.б.) остазы дип атый. Өр-яңа аһәңнәр белән майданга килгән, 60 нчы еллар шигъри буынында үзенчәлекле дөнья хасил иткән Рәдиф Гаташ бар чордашларының уй-хисләрен, янарышка, үзенен яңгыравык танышы белән майданнарга алып чыккан шагыйрь дә. 1965 елда Рәдиф Гаташның «Гөлләр су сорый» исемле беренче шигырь китабы дөнья күрә. Бу китапта урын алган «Ирләр булыйк», «Мин дөресен сөйлим»,«Төш», «Җилкән», «Кое», «Егерме дүрт йолдыз һәм унҗиде диңгез», «Әни, жибәр

мине срак сәяхәткә» кебек шигырьләр тирән хискә һәм фәлсәфи эчтәлеккә ия. Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Шәүкәт Галиев кебек танылган татар шагыйрьләре Гаташнын беренче китабына уңай бәя бирәләр.1968 нче елда шагыйрьнең «Кояшлы утраулар», 1969 нчы елда «Диңгез эзлим» исемле шигырь китаплары да басылып чыга. «Гөлләр су сорый» исемле китабында шагыйрьнең балачак хыяллары яңгыраш тапкан. «Кояшлы утраулар» исемле китабында Гаташ күз алдыбызда тормыш фәлсәфәсен аңлый башлаган, җитлеккән егет булып гәүдәләнә, «Дингезне эзлим» китабында ул, әйтерсең лә, яшьлеге белән хушлашып, яңа тормыш ишеген ача. 1970 нче елларда шагыйрьнең «Күңел ташлары», «Балачак иле» кебек шигырь китаплары дөнья күрә. Гаташның бу китаплары яшьлек һәм мәхәббәтне уртак хис итеп күрсәтә. Шагыйрьнең күңеле ерак сәяхәтләргә сусый, диңгезләрне һәм күктә ялтыраган йолдызлары якыннан күрү теләге белән яна. 1973нче елда Рәдиф Гаташның «Тел ачкычлары», 1976 нче елда «Йолдыз жиле», 1978 нче елда «Ирләр булыйк», 1980 нче елда «Чакыру», 1987 нче елда «Мәхәббәткә – мәрхәмәт» исемле шигырь китаплары басылып чыга. Ул елларда шагыйрь әле Рәдиф Гаташ исеме белән түгел, Рәдиф Гатауллин буларак иҗат итә һәм шигырьләрен дә Ауропа шагыйрьләренә ымсынып, ирекле назым белән яза.

Инде 1960 нчы елларда ук яшь шагыйрь Шәрык шигъриятенә тартыла башлый. Бу исә аның әсәрләренә кабатланмас үзенчәлекле төсмер бирә. 1960 нчы еллар шигърияте өчен бу яңа бер үзенчәлек. Р. Гаташның Шәрык аһәннаренә аваздаш бер шигыренә мисал:

Янган йөрәк,сузылган кул –
Минеке.
Ике толым, кап кара күз –
Синеке
Егерме ике кояш эзе –
минеке
Уналты из, гөлчәчәкләр-
Синеке.

Шагыйрь иҗатын ике чорга бүлеп күрсәтергә мөмкин. Беренче чор шагырьнең яшьлек шигырьләреннән торса («Кайтыгыз, минем сөюнең былтыргы бураннары!», «Европада татар шагыйрьләре» китаплары), икенче чор – робагый һәм газәлләр дәвере. Бу чор лирикасы тулысынча диярлек мәхәббәт хисенә дан җырлауга багышланган. Шагыйрь биредә ачышлар ясый. Рәдиф Гаташ Көнчыгыш һәм Көнбатыш синтезы нигезендә Шәрык компонентын җанландырып җибәрә һәм нәтиҗәдә татар робагыйлары һәм газәлләрен иҗат итә.

Рәдиф Гаташ ижаты күпкырлы, анда тематика төрлелеге сокландыра. Ул күк йөзе һам галәм белән бәйле фольклор образларына, символларына мөрәҗәгате аша кеше хис-кичерешләрен, жир кешесенең туган туфрагыннан булуын, мәхәббәт төсмерләренең төрлелеген, анага һәм хатын-кызга, шулай ук хезмәт кешеләренә дан жырлау юлларын эзли һәм таба. Татар шигъриятендә беренчеләрдән булып Рәдиф Гаташ бер текст эчендә символның традицион мәгънәсе һәм яңа мәгънәсе ярдәмендә мөстәкыйль эчтәлекләр тудыруга ирешә. Шагыйрынең кайсы гына әсәрен укысаң да, аның үз шәхесе ачык төсмерләнә. Кояш-Ай-Йолдызларга мөрәҗәгать итеп мәхәббәт хисен генә зурлап калмыйча, ә туган ил, ватан, туган җир табигате кебек изге төшенчәләрне шигырь укучыга җиткерүнең «гаташча» үзенчәлеген булдыра. Нинди генә темага язмасын, романтик шагыйрь икәнлеген оныттырмый. Рәдиф Гаташ ихлас күнелле, рухи дөньяга тәэссир итүче каләм остасы булып таныла.

Диңгез белән таныш, рәсемен күреп түгел,
Колач салып, дулкын чачен тарап,
Гөлләр белән дуслаш,
Кояш белән, йолдыз белән сөйләш, –
Чиксезллекне ярат.

Бу өзек Рәдиф Гаташның «Мине ярат, – димим сиңа» дип башланган шигыреннән. Исламда Күкнең изгелеген, илаһилыгын, Аллаһы Тәгаләнен фәрештәләрнең, бу дөньядан киткән пәйгамбәрләрнең мәңге шунда гомер кичерүе инкарь ителми. Күк, Ай, Кояш,

Йолдызлар – борыңгы мифологиядә байтак халыкларда серле-сихерле, тылсымлы, могъҗизалы урын. Ай, Кояш һәм Йолдызлар культы, аларны изгеләштерү, аларга табыну Шәрыкта борыңгыдан хөкем сөрә. Кояшны илаһилаштыру борыңгы төркиләрдә дә булган. Моны Рәдиф Гаташ та инкарь итми. Заманның коточкыч күренешенә багышланган «Манкортлар» шигырендә дә Р. Гаташ Кояшны изгеләштерә. Мисал өчен:

....Сөйләшәләр икәү.
Сөйләшәләр,
Алар өчен, бәлки кызарып,
Гүя аксакал бер, Бөек Ата, –
Кояш чыга... Бата...
Шул манкортлар өчен...
оялып!

Безнен очен Кояш – Жиһанның төп атрибуты. Ансыз Жирдәге тормыш мөмкин түгел. Шагыйрь дә үзенен һәрбер шигъри сүзен, адымын, сулышын Кояш белән бер рәткә куеп карый. Мисал өчен: «Жиде төн» бәйләменнән

Мин гашыйк
Кешеләргә мин,
Безнен өчен бит бар да дус? («Дөнья бит!»)

Р. Гаташ жирдәге могъҗизалар белән генә канәгатьләнә алмый, шагыйрь Ай, Кояш, Йолдызлар арасына күтәрелеп, шунда ижат итә башлый кебек. Мисал өчен, «Кеше – гашыйк» шигыреннән:

Ашыктыра Кояш,йолдыз мине,
Җилләр ашыктыра.

Халыкара мифологиядә Айга табыну Кояшка табынынулардан кимрәк сүрәтләнә. Ай культы кайчандыр гарәп илләрендә дә таралган булган. Идел-Чулман Болгарында Ай да, Кояш та илаһи бер затлар дип күзалланган.Соңрак Ай һәм Кояш образларның төп функциясе әдәби-эстетик юналеш ала. Ай образы халык иҗатында, язма әдәбиятта, бигрәк тә хәзерге шигърияттә, шул исәптән Рәдиф Гаташ поэзиясендә дә, билгеле бер чагылыш таба. Шагыйрь Шәрык шигъриятенең борыңгыдан килгән тәжрибәсенә таянып лирик геройның сөйгәнен Ай белән чагыштыра.

Кадерлем, Кояш кызы син,
Бәхетнең бер туганы.
Шатлыкның нәкъ ай кебеге –
Түтәрәге, тулганы ( «Кояш кызы»1966)

Идел йортка чакыру» шитырендә инде Гаташ татар халык җырлары үзенчәлегенә таяна. Мисал өчен:

Бездәгечә түгел сездә Кояш,
Икенчерәк монда Ай нуры...

«Айны тапмадылар» (1963) шигырендә ай һәм күңелләрдәге мәхәббәт, сафлык, яктылык, матурлык янәшә куеп сурәтләнә.

Йолдызлы күк турында карашларның байтагы безнен көннәргә хәтле киткән һәм хәзерге татар шигъриятендә дә кин чагыла. Йолдыз, йолдызлар символлары шигырләрнең күпчелегендә очрый. Биредә шагыйрь халыкара, шуның белән бергә төрки-татар мифологиясе мәгълүматларына таяна. Шагыйрь лирик геройның сөйгәнен Йолдызга тиңли.

Урамыннан күпме үткәнем бар.
Юк күренми иркәм көндезен.
Кичен генә чыга йолдыз кебек –
Кичен генә яна йолдызым ( «Мин дөресен сөйлим»)

Шагыйрь иҗатында шулай ук гөл, кош, алма, кое, болыт, болан, аккош, карчыга, аксакал, көтүче, алиһә, кебек фольклор символлары да урын ала. Бу образларны тудырып Р. Гаташ халык җырларына якыная. Мәсәлән:

Сиңа хатым, ерак ярым!

Җырдагыча: «Карчыга!
Төш каршыма, хат языем
Мин бүген канатыңа-
Тапшыр җаныкаема» («Карчыга канатында»)

Йөрәге яна микән?
Шунда әллә дәвасы? –
Кар ярып аккан елгадан
Сузылып су эчә урманда, –
Күрдем болан баласын! («Тагын болан баласы»)

Бу образлар, халык җырларыннан, урта гасыр шигъриятеннән билгеле, таныла торган сурәтләр булганга, укучы тарафыннан символ статусында укыла. Алга таба символлар һәм янәшәлекләр ярдәмендә әйтелеп бетмәгән фикерләргә юл күрсәтү Гаташ авангард эзләнүләренең иң көчле сыйфатларыннан берсе булып формалашып җитә [6].

Р. Гаташ иҗатында халыкчан образларны, халыкчан күренешләрне ирекле формага урнаштыру өстенлек ала. Моның иң күренекле, матур мисалы шагыйрьнең «Шулай тиеш идеме, очраклымы?..» (1964) шигыре.

– Апрель, – дидем. Ә син Май булгансың.
– Йолдыз, – дидем. Ә син Ай булгансың.
Алмагачлар чәчәк атканда,
күбәләкләр куып йөри идең
ак күлмәктән язгы бакчаңда.

«Җиде төн (Гарәп мотивлары)» циклы аерым игътибарга лаек. Ул гашыйк лирик геройның мәхәббәтен, Шәрыктагы Шәһрезадә экиятләре юлы кебек, җиде төн итеп сурәтли. Шушы юлда, кереш өлештә күрсәтелгәнчә, герой сөюдән котылу юлын эзли:

...бармы ул мәңгелек көчтән
коткарыр бер-бер чара?

«Төн» саен хисләр үзгәрә бара. Беренче төн – күреп гашыйк булу, икенче төн – яратканга төшенү, өченче төн – сөю белән горурлану, дүртенче төн – яратуның җавапсыз булу мөмкинлегеннән борчылу, бишенче төн – көтү, алтынчы төн сөю хисенең мәңгелеген аңлау булып яңгырый.

Әй җиһан! Сөюгә лаек
горур яшәргә өйрәт!
Мәңге яшәргә өйрәт!–

диюче лирик герой мәхәббәтнең кешене горур булырга чакыруын ассызыклый. Җиденче – шигырьне йомгаклаучы төн мәхәббәтнең кешедәге сәләтләрне ачуын, иҗатка алып килүен белдерә.

Р. Гаташ XIII гасыр шагыйре Кол Галиның «Кыйссаи Йосыф» әсәренә төс сюжет төш күрү сюжетына «Ышанмыйм», «Яралы җыр», «Яралар», «Төш», «Төш һәм өн» һ.б. шигырьләрендә еш таяна. «Егерме дүрт йолдыз, һәм үнҗиде диңгез» («Мәхәббәтнамә» 1965) бәйләмендә шагыйрь күктәге йолдызлар арасында йөрү генә түгел, үз йолдызын кабызуны максат итеп куя. Унике, унсигез, егерме дүрт йолдыз саны Р. Гаташ иҗатында фольклор традицияләре чагылышы.

«Бу җиһанда нинди фал ул – Кигәвен?..». әсәрендә символлар: багъ – дөнья, гөл һәм кол – гашыйклар образлары янәшәсендә Кигәвен – бәхеткә каршы төшүче, аны фаш итүче символы кулланыла. Шагыйрь аны «Һәр бәхетнең сагында» торучы буларак тасвирлый. Таһир-Зөһрә дастанына ишарә ясап, Зөһрәгә гашыйк һәм әлеге мәхәббәтне җимерүче Кара батыр исеме дә телгә алына. Ләкин шигырьнең соңгы юлларында шагыйрь бу өчпочмакны тормышның гадәти законы кебек тәкъдим итә:

Гомерләрнең шул матур бакча ямен,
Күңелләрнең кабатланмас гөлләрен
Күрү – сәнгать безгә: җыр да шул юлда...

Гаҗәп: мин дә шунда, дисең, Кигәвен!

Радиф Гаташ иҗатыннан башка хәзерге татар поэзиясен күз алдына китереп булмый. Шагыйрьнең романтик иҗаты модернистик эзләнүләр белән үрелеп бара. Форма өлкәсендәге тәҗрибәләр: халык җырлары, урта гасырлар Шәрык әдәбияты үлчәм-вәзенен, шигъри һәм образлылык калыбын, үзенчәлекле алымнарын файдалану, аларга охшатып стильләштерү, әсәрләрнең эчтәлеген тирәнәйтүне һәм киңәйтүне , һәрбер мизгелне кешеләр язмышы тарихын сүрәтләүне үстерә. Милли әдәбиятыбызда моңа кадәр кулланылмаган юлларын ача. Рәдиф Гаташ шигърияте без карый торган вакыт аралыгында татар әдәбиятына яңалыклар алып килгән, аның сыйфатый үзгәрешен тәэмин иткән, эзләнү офыкларын киңәйткән иҗат буларак бәяләнергә лаек.

**Кулланылган әдәбият**


1. Галиуллин Т., Йосыпова Н. Басынкы елларның дәртле шигъ-рияте // Татар шигърияте: 1960–1980 еллар. – Казан: Мәгариф, 2007. – 4 б.
2. Гатауллин Р. Китмә хыял!: Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәш., 1986. – 80 бит.
3. Гаташ Р. Әйтте каләм! / Гомер багъларында. – Казан: Яз, 2020. – 480 б.
4. Гаташ Р. Яратуга ярлык! Сайланма лирика. – Казан : Яз, 2021. – 256 б.
5. Зариф.Ч. «...Чын Нух гомере – җанында, Йосыф аһы хисендә – күз яшендә!» Шагыйрь Рәдиф Гаташка 80 яшь/ «Мин дөньяга хисләрем һәм мәхәббәт аша карыйм» Р. Гатауллин исемендәге I фәнни-гамәли республика конференциясе материаллары (2021елның 14 нче мае, Казан) / ред. Зәйни Р.Л. – Казан, 2021. – 183 б.
6. Заһидуллина Д.Ф.1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. – Казан. Татар. кит. нәшр.. 2015
7. Хисамов Н.Ш. Татар шагыйрьләре: монографик мәкаләләр, иҗат портретлары һәм этюдлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 287б.


© Гильманова Г.М., 2025

УДК 811.512.145

**Гильметдинова А.А.,**
*студент 2 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Зарипова И.Ф.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*Уфа, Россия*

# МӘДӘНИ ФЕНОМЕН БУЛАРАК ПРЕЦЕДЕНТ ИСЕМ: ЧЫГАНАКЛАРЫ ҺӘМ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

***Аннотация***. *Әлеге мәкалә прецедент исемнәр – аерым мәгънәгә ия һәм танылa торган сүзләр һәм әйтелмәләр төшенчәсен ача. Автор тарафыннан аларның барлыкка килү чыганакларына нигезләнгән классификация тәкъдим ителә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, лингвокультурология, ялгызлык исем, уртаклык исем, прецедент исем.*

Телдә сүзнең кулланылыш даирәсен киңәйтүдә, мәгънә мөмкинлекләрен күрсәтүдә метафорик күчеш зур роль уйный. Читләтеп әйтү нигезендә сүз яңа ассоциацияләр тудыра, һәм алар, милли аң аша үткәрелеп, миллилек күзлеге аша аңлатылып, сүзләрдә реальләшәләр. Әйбер, предметлар арасындагы охшаш һәм аермалы якларга нигезләнеп, атаманы күчерү телдә киң таралыш тапкан. Безнең фикеребезчә, мәгънә катламының тирәнлеге тел байлыгын билгеләү критерийларының әһәмиятлесе буларак каралырга хокуклы.

Коннотатив мәгънә ялгызлык исемнәренең окказиональ кулланылышында (икенчел номинациядә) тагын да ачык сизелә, чөнки бу очракта исем, үзенең төп сыйфатларын югалта төшеп, уртаклык сүзләренә якынлаша. Гадәттә, мондый төр күчеш татар милли мохитендә киң кулланыла торган, эчтәлегендә аерым күзаллаулар тудыра торган исемнәрдә ачык чагыла. Мәсәлән, *Мамай явы, Хуҗа Насретдин, Шәкүр карак, Шомбай, Мәҗнүн гыйшкы* кебек очраклар татар халкының күпчелегенә таныш. Аерым бер контекст эчендә ялгызлык исем семантик яктан киңәя, уртаклык сүзләренә хас эчке формага ия була башлый.

Әлеге үзгәрешләр арасында прецедент исемнәрнең барлыкка килүе һәм кулланылышы аеруча игътибарга лаек. Прецедент исемнәр – лингвистик һәм мәдәни феномен буларак, телнең чагылдыру мөмкинлекләрен киңәйтә, сөйләмгә образлылык һәм тәэсирлелек өсти.

Прецедент исем төшенчәсе хәзерге лингвистикада мөһим урын алып тора. Галимнәр әлеге терминны билгеле бер мәдәни җәмгыятьтә киң танылган, мөһим мәгънәгә ия булган һәм даими рәвештә кулланыла торган исемнәрне билгеләү өчен файдаланалар. Прецедент исемнәр телдә төрле функцияләр башкара, сөйләмнең коммуникативлыгын, экспрессивлыгын һәм стилистик байлыгын тәэмин итә [1, 72 б.].

Прецедентлык проблемасы XX гасырның 80 нче елларыннан башлап тикшеренүчеләрнең зур кызыксынуын уята. Бу мәсьәләгә күп кенә галимнәрнең (Ю.Н. Караулов, Ю.А. Михалева, В.Г. Костомаров, Н.Д. Бурвикова, А.А. Евтюгина, В.В. Красных, И.В. Захаренко, Д.Б. Гудков, Г.Г. Слышкин, Ю.Б. Пикулева һ.б) фәнни хезмәтләре багышланган.

Лингвистикада прецедентлык теориясенең нигезләре Ю.Н. Караулов, В.В. Красных, Д.Б. Гудков кебек галимнәрнең хезмәтләрендә салынган. Алар тарафыннан «прецедент текст» (ПТ), «прецедент ситуация» (ПС), «прецедент исем» (ПИ) һәм «прецедент феномен» (ПФ) төшенчәләре кертелә [2, 238 б.].

ПИнең функцияләренә мөрәҗәгать итеп, тикшеренүчеләр «ул я ялгызлык исем, я прецедент исем буларак кулланыла ала» дигән нәтиҗәгә киләләр [4, 203 б.]. Д.Б. Гудков фикеренчә, ялгызлык исемнәр материаль характерга ия (монда конкрет кешеләрнең, урыннарның, вакыйгаларның һ.б. исемнәре турында сүз бара), алар ПИ аермалы буларак, денотатка ия. Шулай итеп, ПИ – ялгызлык исемнәрнең бер төре булып тора. Моңа охшаш

нәтиҗә Е.А. Флейшерның диссертациясендә ясала. Ул ялгызлык исемнәрдә уртаклык исемнәргә караганда киңәйтелгән сигнификат булуын билгеләп үтә. Аның фикеренчә, «ялгызлык исемнәрнең һәм прецедент исемнәрнең мәгънәләре бер үк структураны тәшкил итә, бу аларның уртак табигатен тагын бер кат ассызыклый: прецедент исемнәр ялгызлык исемнәр белән уртаклык исемнәр арасында аерым класс формалаштырмый, ә ялгызлык исемнәрнең өстәмә категориясен генә тәшкил итә» [7, 63–64 б.].

Прецедентлык теориясендә Р.З. Назарова һәм М.В. Золотарев ПФның түбәндәге төп билгеләрен ачыклый: 1) сылтамалылык, ягъни ПФның беренчел чыганакка мөрәҗәгать итү сәләте; 2) компонентның мөһимлеге, ПФның билгеле бер лингвомәдәни җәмгыятькә хас булган төрле кыйммәтләрне чагылдыруы белән аңлатыла; 3) үрнәк булу, аны ПФның реаль факт яки күренеш өчен берәр төрле үрнәк/шаблон булып тору сәләте итеп карыйлар; 4) кулланылышның семиотик характеры, ягъни ПФның билгеләмәнең тулы берәмлеге буларак чыгыш ясый алуы. Бу билгеләр прецедент феномен структурасындагы барлык элементларга хас, структурага прецедент текст (ПТ), прецедент гыйбарә (ПГ), прецедент ситуация (ПС) һәм прецедент исем (ПИ) керә. Башка прецедент феноменнардан аермалы буларак, прецедент исемнәр үз үзенчәлекләренә ия. Прецедент исем дип аталыр өчен, исемнең берничә төп билгесе булырга тиеш:

1. Танылу. Прецедент исемнәр мәдәни берләшмәнең күпчелегенә яхшы таныш булырга тиеш.
2. Әһәмиятлелек. Прецедент исемнәр билгеле бер вакыйга, шәхес яки күренеш белән бәйле булырга һәм җәмгыять өчен әһәмиятле мәгънәгә ия булырга тиеш.
3. Даими кулланылыш. Прецедент исемнәр көндәлек сөйләмдә, әдәби әсәрләрдә, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка коммуникация өлкәләрендә еш кулланылырга тиеш [5, 45–55 б.].

Прецедент исемнәр тикшеренүчеләр тарафыннан төрле яссылыктан карала. Д.В. Подрёзова рус мәдәнияте вәкилләренең когнитив базасына керүче прецедент исемнәрнең мәгънә эчтәлеге һәм төзелеш динамикасын өйрәнә. Е.В. Петрова төрле дискурс һәм лингвомәдәниятләрдә кулланылучы прецедент исемнәрнең концептуаль структурасын анализлый. А.В. Терещенко тарафыннан сәнгать һәм газета-публицистик стильләрдә кулланылучы рус һәм инглиз прецедент антропонимнары һәм топонимнары чагыштырма аспектта тикшерелә.

Лингвистикада прецедент исемнәрне өйрәнү актив үсеш этабында. Бу тел берәмлекләре төрле яктан карала, аларның функцияләре, текстларда һәм дискурста эшләү үзенчәлекләре анализлана. Хәзерге вакытта бу темага багышланган фәнни хезмәтләрнең саны елдан-ел арта бара. Галимнәр прецедент исемнәрнең төшенчәсен ачыклау, аларны төрләргә бүлү, классификацияләү, кулланылыш үзенчәлекләрен һәм стилистик функцияләрен билгеләү мәсьәләләренә игътибар итә.

XX гасырның икенче яртысында прецедентлыкны өйрәнү өчен җирлек номинация теориясе белән шөгыльләнүче авторлар (А.В. Суперанская, А.А. Реформатский) тарафыннан әзерләнә, алар прецедентлыкның критерийларын болай билгели: аерым мәгънә, еш кулланылыш һәм идентификацияләү функциясен үтәү.

Прецедент исемнәр телдә берничә мөһим функция башкара. Коммуникатив функция прецедент исемнәрнең сөйләм процессын җиңеләйтүендә һәм тизләтүендә күренә. Чөнки сөйләмдә катнашучылар өчен уртак мәгълүмат кыры булдырыла. Прецедент исемнәр мәгълүматны кыска һәм төгәл итеп җиткерә. Экспрессив яктан прецедент исемнәр сөйләмгә эмоциональлек һәм тәэсирлелек өсти. Стилистик үзенчәлекләре буенча прецедент исемнәр сөйләмне образлы, метафорик тасвирлый [6, 56-65 б.].

Татар телендә прецедент исемнәргә түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: мәсәлән, *Тукай, Сөембикә, Казан, Шүрәле*. Бу исемнәрнең һәрберсе татар халкының тарихы, мәдәнияте яки әдәбияты белән бәйле һәм тирән мәгънәгә ия. Алар татар телендә сөйләшүчеләр арасында киң танылган һәм даими рәвештә кулланыла.

Димәк, прецедент исемнәр – телнең мөһим элементы буларак, сөйләмне баетуда, мәдәни кодны саклауда һәм тапшыруда зур роль уйный.

Тел белемендә прецедент исемнәрнең өйрәнү алымнары һәм ысулларын түбәндәгечә билгелиләр:

1. Лингвокультурологик алым. Хәзерге телнең мәдәният белән бәйләнешен өйрәнүгә юнәлтелгән.

2. Когнитив алым. Прецедент исемнәрне катлаулы структура буларак өйрәнергә, прецедент мәгънәсен формалаштыручы когнитив һәм тел механизмын ачыкларга һәм тасвирларга мөмкинлек бирә.

3. Чыганакларны анализлау. Тикшеренүчеләр билгеле концептуаль сфералар, мәсәлән, дин, сәясәт, әдәбият, сәнгать белән бәйле прецедент исемнәрне өйрәнәләр.

4. Дискурсив алым. Өйрәнү өчен билгеле бер дискурс ноктасы буларак, барлык прецедент исемнәрне чыганак даирәләрен чикләмичә анализлыйлар.

Прецедент исемнәрне өйрәнү перспективалары да билгеле. Мәсәлән:

1. Диахроник анализ. Лингвомәдәни берләшмәдә прецедент феноменнар составы үзгәрү сәбәпле, вакыт узу белән, прецедент исемнәрнең когнитив потенциалын өйрәнү.

2. Башка прецедент феноменнарның концептуаль структураларын өйрәнү. Мәсәлән, прецедент ситуация, прецедент гыйбарә һәм прецедент текст.

3. Прецедент исемнең когнитив потенциалының аның танылу һәм таралу дәрәҗәсенә бәйлелеген ачыклау. Танылган һәм киң таралган исемнәрнең аз танылганнардан аермасын күзәтү.

Прецедент исемнәрне өйрәнү – лингвистиканың актуаль юнәлеше. Бу юнәлеш телнең коммуникатив, мәдәни һәм когнитив аспектларын өйрәнүгә юнәлтелгән. Татар теле белгечләренең һәм чит ил галимнәренең хезмәтләре бу өлкәдәге тикшеренүләр өчен теоретик нигез булып тора.

Прецедент исемнәрнең чыганакларын билгеләү – тел белемендә мөһим мәсьәлә, чөнки бу аларның мәгънәсен, кулланылу үзенчәлекләрен, мәдәни контекстын һәм җәмгыятьтәге ролен аңларга ярдәм итә. Прецедент исемнәр төрле чыганакларга нигезләнеп барлыкка килергә мөмкин, һәм аларның һәрберсе телгә һәм мәдәнияткә үзенчәлекле йогынты ясый.

Прецедент исемнәр, ялгызлык исемнәрнең өстәмә категориясен тәшкил итеп, төрле онимнарга төркемләнергә мөмкин:

1. Тереклек ияләре һәм тере дип саналган затларның исемнәре: антропонимнар, зоонимнар, мифонимнар.

2. Җансыз әйберләрнең атамалары: топонимнар, космонимнар.

3. Комплекслы объектларны атаучы ялгызлык исемнәр: берләшмә һәм оешмаларның атамалары; хрононимнар; бәйрәм, тантана атамалары; төрле чараларның атамалары; әдәбият һәм сәнгать әсәрләре атамалары; документонимнар; табигать афәтләренең атамалары; фалеронимнар [6, 145 б.].

Тел белемендә прецедент исемнәр чыганаклары буенча берничә төргә бүленә:

1. Мифология һәм фольклор – прецедент исемнәрнең иң борынгы һәм мөһим чыганакларының берсе. Халык авыз иҗаты, мифлар, әкиятләр, легендалар һәм риваятьләр кешеләрнең аңында ныклы урын алган образлар, символлар һәм вакыйгалар тудыра. Бу образлар гасырлар дәвамында буыннан-буынга күчеп, халыкның мәдәни кодына әверелә. Мәсәлән:

*Нинди **Алып** борган агымны? ... (Л. Сәгыйдуллина)*

*Ике аккош булып кылансак та,*
***Сак белән Сок** кына без бары. (М. Кәбиров)*

*Оранымны **Аждаһалар** йотты*
*Төркиләрнең телсез вакыты. (И. Фазлетдинов)*

2. Тарих – тарихи вакыйгалар, күренекле шәхесләр һәм тарихи урыннар шулай ук прецедент исемнәрнең мөһим чыганагы булып тора. Тарихи исемнәр халыкның тарихи хәтерен сакларга, милли үзаңны үстерергә һәм буыннар арасындагы бәйләнешне ныгытырга ярдәм итә.

*Чор, дәверләр таләп итсә, тагын*
*Туып торыр яңа **Җәлилләр**... (М. Мирза)*

*Тәгәрмәчтә – **Акмуллалар** җаны,*
*Күчәренә кылган уралган. (И. Фазлетдинов)*

*Хушлашулар иле **Колумбы** — син.*
*Ә синнән сон?!. Жиңел – кайсысы?!. (Л. Сәгыйдуллина)*

3. Әдәбият – әдәби әсәрләр, аеруча классик әсәрләр, прецедент исемнәрне формалаштыруда һәм таратуда зур роль уйный.

*Син **Ләйлә**, мин **Мәҗнүн** булып,*
*Парлап үтәсе иде. (М. Кәбиров)*

*Күпме **Гамлет** миндә һәлак булды*
*Үзе белән үзе көрәшеп! (Л. Сәгыйдуллина)*

*Шуның белән туктатамын*
***Донжуанлык** шигырен. (М. Вафин)*

*...**Дон Кихотлар** нәселеннән иде*
*Ник нәкъ аны алдың арадан?!. (Л. Сәгыйдуллина)*

4. Географик атамаларның да прецедент исемгә күчүен күзәтә алабыз. Мәсәлән:
***Бермуд өчпочмагы** булып,*
*Килеп чыктың каршыма. (М. Вафин)*

***Болгарлардан, Алтын Урдалардан***
*Бабаларым мине күзәтә. (И. Фазлетдинов)*

*Тик һәркемнең үз **Парижы**! (Р. Гаташ)*

Шулай итеп, тупланган практик материалны анализлау нигезендә татар поэзиясендә прецедент берәмлекләрнең күпкырлы, полифоник функцияләре ачыла. Алар, бер үк вакытта, тарихи хәтерне яңарта, автор позициясен күрсәтә һәм укучыда интертекстуаль ассоциацияләр тудыра.

Прецедент исемнәрнең төп үзенчәлекләре булып танылу, мәгънә байлыгы, эмоциональ тәэсир көче, ассоциативлык һәм мәдәни әһәмиятлелек тора. Бу үзенчәлекләр прецедент исемнәрне телнең мөһим элементына әверелдерә һәм сөйләмне баетуда, мәдәни кодны саклауда һәм тапшыруда зур роль уйнарга мөмкинлек бирә. Прецедент исемнәрне өйрәнү телнең табигатен, мәдәният белән бәйләнешен һәм җәмгыятьтәге ролен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Зарипова И.Ф. Прецедент исемнәрнең кулланылыш үзенчәлекләре: чыганаклар һәм символика // Күп милләтле Евразия арауығында төрки телдәре: хәҙерге торошо, үҫеш тенденциялары һәм перспективалары: Филология фәндәре докторы, профессор, Рәсәй Федерацияһының юғары профессиональ белем биреүҙең почётлы хеҙмәткәре, БР Фәндәр

академияһы академигы Марат Вәли улы Зәйнуллиндың тыуыуына 90 йыл тулыуға арналған Халыҡ-ара фәнни-ғәмәли конференцияның материалдар йыйынтығы (Өфө, 2025 йылдың 6 ноябре) / яуаплы мөхәррир Г.Р. Абдуллина. – Өфө: Өфө университетының РНҮ, 2025. – Б. 72–76.

2. Зарипова И.Ф. Символика прецедентности: лингвокультурологическийанализ литературных кодов // Национальные литературы республик Поволжья: проблемы межкультурной коммуникации [Электронный ресурс]: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 22-24 октября 2025 г.) / под ред. Ф.С. Сайфулиной. – Электрон. текстовые дан. (1 файл: 4,64 Мб). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2025. – С. 237–241. – Систем. требования: Adobe Acrobat Reader. – URL: https://dspace.kpfu.ru/xmlui/bitstream/handle/net/ 185530/NatLitPovolzhia_2025.pdf. Загл. с титул. экрана.

3. Караулов Ю.Н. Русский язык и языковая личность. – М.: Наука, 1987. – 264 с.

4. Красных В.В. Этнопсихолингвистика и лингвокультурология. – М.: Гнозис, 2002. – 284 с.

5. Красных В.В. «Свой» среди «чужих»: миф или реальность? – М.: Гнозис, 2003.

6. Слышкин Г.Г. От текста к знанию: Базовые концепции и методы когнитивной лингвистики: Учебное пособие. – М.: Academia, 2004.

7. Терещенко А.В. Прецедентные антропонимы и топонимы в художественном и газетно-публицистическом стилях (сопоставительный аспект): дис. … канд. филол. наук. – Волгоград, 2006. – 206 с.

© Гильметдинова А.А., 2025

УДК 812.512.145

**Даутов Г.Ф.,**
*доцент кафедры филологии Елабужского института КФУ,*
*г. Елабуга, Россия*

## XIX ГАСЫРНЫҢ I ЯРТЫСЫНДА ПОЭЗИЯ ҮСЕШЕ

***Аннотация.*** *Мәкалә XIX гасырда иҗтимагый тормышта да, дини өлкәдә дә реформаторлык чоры буларак билгеле булган социаль-икътисади үзгәрешләргә багышлана. Бу процесстан ул вакыттагы медиакиңлек ролен башкарган әдәбият та читтә калмаган.*

***Тerәк сүзләр:*** *әдәбияттагы мотивлар, әдәбият үсеше, иҗтимагый тормыш, үзенчәлекле гасыр.*

XIX гасыр татар әдәбияты күзгә ташланып, бүгенге көн укучысын үзенә тартырдай әсәрләр белән аерылып тормый. Ләкин ул, дәүләтчелеге җимерелгәннән соң беркадәр торгынлык кичергән язма әдәбиятның дөньявилыкка күчешен, үзгәрешләрен тәэмин итеп, «Алтын чор» дип бәяләнгән XX йөз башы алгарышына нигез салган чор.

XIX гасыр әдәбияты үсешенә берничә фактор йогынты ясый һәм аның үзенчәлеген билгели. Билгеле булганча, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, халыкның әйдәп баручысы булган морзалар катламы юкка чыгарыла, я рус дәүләтенә хезмәткә күчерелә. Язма әдәбиятның яшәешен үз кулларына руханилар алалар. Ягъни, әдәбиятның эчтәлеген профессиональ руханилар билгели. Икенчедән, самодержавиянең көчләп чукындыру һәм руслаштыру сәясәтенә каршы татарлар Ислам динен киртә итеп куялар һәм болар әдәбиятның дини эчтәлекле булып, бар нәрсәне дә Илаһиятка мөнәсәбәттә бәяләүгә китерәләр. Монда муллаларның ул чор икенче тормышында гаять зур роль уйнаганлыгын да истә тотарга кирәк, чөнки кеше туып, аңа беренче юридик акт – исем кушудан башлап, – салкын җир куенына ясин укып иңдергәнчегә кадәр, мулла инсанны бөтен яшәеше буйлап озата бара. Әмма, «Татар ижтимагый аңы үсешендә… инде XVIII гасырда ук борылыш

күзәтелә, фәлсәфи-эстетик, дини-этик карашлар системасын яңабаштан аңлау хәрәкәте башлана. Бигрәктә соңгы унъеллыкта иҗтимагый мәйданга аяк баскан каләм ияләре үзләре өчен дә каршылыклы халәткә керәләр: диннең һәм аның сагындагы мәчетнең җәмгыятьтәге өстенлеген кире какмасалар да, стихияле рәвештә чынбарлыкны, тарихны, матди дөньяны үткәндәге мирасны ачу хыялы белән яналар» [3: 33 б.].

Өченчедән, монда әдәби тарихи традицияләр да зур роль уйный, чөнки, Х. Миңнегулов язганга, «Хәзәрләр һәм болгарлар, ягъни безнең әби-бабаларыбызның мөһим бер өлеше, төрки кавеннәр арасында беренчеләрдән булып, ислам динен кабул итәләр, үзләренең дөньяга карашларын, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен «Коръән» рухы белән яраклаштыралар» [1: 114 б.].

Ләкин дөньяның өзлек үсеш-үзгәрештә, аграр ил булган Россияга да Европадан промышленность керә башлый. Хәер, моны Көнбатыш йогынтысына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде, чөнки халык санының үсеше аның яшәешен, ихтыяҗларынын канәгатьләндерүнең яңа ысулларын эзләргә, чараларын табарга этәрә. Ничек кенә булмасын, К. Аблязов болай дип күрсәтә: «… важнейшим центром мануфактурной промышленности в данный период являлась Казань. В 1800 г. в Татарских слободах г.Казани успешно работали 10 кожевенных, 3 козловых и 11 мыловаренных заводов.». Шушы ук сүзне Казанда яшәүче, руслашкан немец галиме К.Фукс та куәтли: «Кожевенный завод Казанского первого гилдии купца Мустафы Муртазина Суюрова находится в Ново-Татарской слободе, имеет 10 чанов, из коих в каждом по 100 юфтевых кож красных, всего 1 тыс., продаются на Нижегородской ярмарке. Яловочные кожи сырьем покупаются на месте у разных торговцев… Кожевенный завод Казанского 1-й гильдии купца Мусы Измайлова Апанаева. Находится в Новой Татарской слободе, имеет 17 ларей, из коих в каждом по 70 козлов. Разной величины черных козлов выделывается 40 тыс., кои продаются в Кяхте [2: 37 б.].

Ягъни, XIX гасыр башында шактый гына күләмдә товар чыгаручы промышленность барлыкка килә һәм, – монысы шулай ук әһәмиятле, – бу, баштарак цехлар, соңрак заводлар, татар эшлеклеләренеке була. Товар бар икән, аның сатып алучысы да булырга тиеш. Шул рәвешле, тулысынча автономно, үзен-үзе бөтен көнкүреш әйберләре белән тәэмин итеп яшәсән татар авылына товар-акча мөнәсәбәтләре үтеп керә. Диния Нәзарәте оешып, указ бирү аркылы муллаларны хөкүмәтнең үзенә хезмәткә куюына каршы башланган абызагыйлар (гомуми җыен һәм аксакаллар советыннан тыш, һәр авылның башлыгы булып тагын бер кеше – абыз(ил агасы) тора. Абызлар җирле властьның даими вәкилләре дип саналалар һәм идарә итүнең аерым функцияләренә ия булалар. **XVI-XVIII гасырлар мәгълүматлары күрсәтелгәнчә, абыз вазифаларын шәхси сыйфатлары һәм хезмәтләре белән аерылып торган кешеләр башкарган. Болар, халык арасында абруй һәм хөрмәт казану белән бергә, укымышлылык ягыннан да таныганнар. Алар, остаз һәм киңәшчеләр генә тугел, укытучылар, табиблар һәм судьялар да булганнар. Аерым кешеләр һәм гаиләләр арасында килеп чыккан барлык бәхәсле очракларда авыл халкы, киңәш сорап, абызларга мөрәҗәгать иткән.)** [4: 208] хәрәкәтенә, шагыйрләрьнең мал артыннан кууга борчылулары да килеп кушыла. Һәм ул шактый гына кызыклы трансформация – дини эчтәлекнең дөньяви мотивлар белән үрелеп бирүенә китерә. Моның бигрәк тә кызыклы үрнәге итеп Әбелмәних Каргалыйның (1782 – якынча 1833) «Тәрҗемән хаҗи Әбелмәних» әсәрен китерергә мөмкин. Китап тезмә белән язылган ун хикәяттән тора, хикәятләрнең сюжеты дини риваятьләрдән алынган, ләкин ахырдагы нәтиҗәләрен, уйлануларын, шагыйрь үз чорына, үз заманы проблемаларына китереп ялгый.

**XVIII гасыр ахырында Диния нәзарәте оешу, шуның белән бәйле рәвештә югарыда телгә алынган абызагыйлар хәрәкәте һәм фәнни әдәбиятта оппозиция гел әдәбият дип аталган юнәлеш формалашу да сүз сәнгатенә дөньяви мотивларның торган саен тирәнрәк үтеп керүен күрсәтә.**

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: XIX гасырның I яртысында, төрле факторлар йогынтысында, татар әдәбияты зур үзгәрешләр кичерә һәм үзеннән соң киләчәк чорга җирлек әзерли.

**Кулланылган әдәбият**

1. Миңнегулов Х. Дөньяда сүзебез бар... – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 114 б.

2. Фукс К. Краткая история города Казани и её уезда. – Казань, 1817. – 37 с.

3. Харрасова Р., Гомәров И. Поэзия үсеше. Татар әдәбияты тарихы, 8 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 33 б.

4. Хисамутдинов Г.М. Социально-экономический строй и общественные отношения татар в эпоху феодализма – Татары Среднего Поволжья и Приуралья. – М.: Наука, 1967. – 208 с.

© Даутов Г.Ф., 2025

УДК 811.512.145

**Еникеева Д.Д.,**
*студент 3 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Зарипова И.Ф.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГЕНДЕР КОМПОНЕНТЛЫ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫҢ ИДЕОГРАФИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация.*** *Мәкалә татар телендә гендер компонентлы фразеологизмнарны тасвирлауга багышлана. Әлеге тотрыклы әйтелмәләрнең гендер компонентларының идеографик классификациясе тәкъдим ителә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, лексикология, фразеология, фразеологизм, гендер компонент.*

Телнең лексикасы һәм фразеологик катламы халыкның тарихын, географиясен, иҗтимагый-сәяси төзелешен, яшәү шартларын, көнкүрешен барлык билгеләре, үзенчәлекле яклары белән чагылдыру сәләтенә ия. Тел үзе тәэмин иткән халыкның мәдәни-тарихи хәзинәләрен саклый, шулай ук хәзерге заман белән бәйле фактларны да ачып сала. Шул сәбәпле фәндә телнең мәдәни трансляторы ролен үти торган фразеологик әйтелмәләрне өйрәнү ихтыяҗы һәрвакыт булган һәм хәзер дә кимеми [1, 114 б.].

Фразеология фәненең үсешенә француз лингвисты Ш. Балли (1865–1947) идеяләре йогынты ясый. Фразеология, мөстәкыйль тел тармагы буларак, рус тел белемендә XX гасырның 40 нчы елларында формалашып җитә. Рус фразеологиясе турында беренче теоретик мәгълүматлар А.А. Потебня, И.И. Срезневский, Ф.Ф. Фортунатов хезмәтләрендә бирелә. 50 нче елларда В.В. Виноградов хезмәтләрендә фразеологиягә кагылышлы төп төшенчәләр ачыклана, өйрәнү бурычлары билгеләнә, юнәлешләр күрсәтелә. Алга таба фразеологизмнар, телнең структур берәмлекләре буларак, А.И. Смирницкий, О.С. Ахманова хезмәтләрендә яктыртыла, шулай ук фразеологизмнарны төркемләү, аларның составы, ясалыш-структур үзенчәлекләре, семантикасы, лексикографик тасвирлау, лингвокультурологик аспектта тикшерү, башка телләр белән чагыштырып өйрәнү белән бәйле мәсьәләләр В.Л. Архангельский, Н.Н. Амосова, В.П. Жуков, А.В. Кунин, Н.М. Шанский, В.М. Мокиенко, В.Н. Телия һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш таба. Төрки телләрдә фразеологизмнарны өйрәнү дөнья һәм рус филологларының фәнни эзләнүләре белән параллель алып барыла [3].

Татар телендә дә фразеологик берәмлекләрнең төрләрен һәм үзенчәлекләрен өйрәнүгә, аларны системага салуга багышланган хезмәтләр мәгълүм. Мәсәлән, Ш.А. Рамазанов, Г.Х. Әхәтов, Л. Җәләй, Н.Б. Борһанова, Л.Г. Мәхмүтова, Г.Х. Ахунҗанов, Р.А. Йосыпов,

С.Ш. Поварисов, В.Х. Хаков, Ф.С. Сафиуллина, Х.Ш. Мәхмүтов кебек галимнәрнең хезмәтләрендә татар фразеологиясе төрле яклап тикшерелә: «фразеологизм» һәм «фразеология» төшенчәләренә билгеләмә бирелә, фразеологизмнарның сүзләрдән һәм гади сүз тезмәләреннән аермасы аңлатыла; бу төр әйтелмәләрнең барлыкка килү, туплау, аларны төркемләү мәсьәләсе кузгатыла; фразеологик әйтелмәләрнең стилистик кулланылышы яктыртыла, аларның семантик, грамматик һәм лексикографик үзенчәлекләре тасвирлана, башка телләргә тәрҗемә итү проблемалары турында мәгълүмат бирелә, этимологияләре ачыклана һ.б. [6, 191 б.].

Тел белемендә фразеологизмнарга багышланган хезмәтләрнең күп булуына карамастан, «фразеологизм категориясе» төшенчәсе конкрет билгеләнмәгән, төр һәм күләм-состав мәсьәләсе хәл ителеп бетмәгән. Телдәге кыска әйтелешле, составлары буенча бөтен булган, телдә әзер килеш саклана һәм кулланыла торган һәр төрле әйтем-тәгъбирләрне (мәсәлән, канатлы сүзләрне, мәкаль һәм әйтемнәрне, атама-терминнарны, афоризмнарны һ.б.) фразеологизмнар составында карауны хуп күрүчеләр аз түгел [2, 136 б.]. Татар фразеологизмнарының компонентларын тикшерүгә багышланган хезмәтләр дә таләп ителә. Мәсәлән, гендер компонентлы фразеологизмнарга багышланган махсус хезмәтләрнең бүгенге көндә аз булуы безнең тарафтан сайланган теманың актуальлеген билгели. Мондый фразеологизмнарны компонентларының идеографик үзенчәлекләре буенча түбәндәге төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин:

1. **Вакыт мәгънәсен белдерүче фразеологизмнар:** ***әби патша*** *заманында* (бик күптән, әллә кайчан); *җиде* ***бабадан*** *килгән* (бик күптәнге, борынгы; борынгыдан мирас булып калган); ***хан*** *заманы* (болгар-татарларының үзләренә мөстәкыйль хөкүмәт сөргән, бәйсез заманнары); ***ата-баба*** *заманы* (борынгы тарихи заман, үткән гасырлар).

2. **Урын мәгънәсен белдерүче фразеологизмнар:** ***хан*** *юлы* (киң, такыр юл. Хәзер юл ачык дигән мәгънәдә әйтелә); ***патша*** *җәяү бара торган җир* (бәдрәф); *бакыр* ***бабай*** *бакчасы* (элек Казанда рус шагыйре Державинга куелган һәйкәл торган бакча, хәзер бу урында М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасы); *анда* ***эти*** *белән* ***әни*** *генә юк* (базар, мәйдан яки күргәзмә кебек халык һәм төрле товар, мал тыгылып яткан җир).

3. **Кешеләр арасында төрле мөнәсәбәт белдерүче фразеологизмнар:** ***ир-ат*** *арасы* (элек татар хатын-кызларына ирләр арасында буталып йөрү гаеп саналганда һәм, гаиләдән тыш, ирләр үзенә, хатын-кызлар үзенә бүленебрәк яшәгәндә ирләр төркеме «ир-ат арасы» дип йөртелгән); *эшең бетте,* ***Зөбәйдә*** (шушының белән эш тәмам димәктән. Эш төшкәндә генә кирәк булып, эш беткәч кирәге калмаган кеше хакында); *бер җирдә ике* ***Сөләймән,*** *берсенә әйтсәң берсе сөмәйгән* (берсенә бер сүз әйтсәң, икенчесенең хәтере кала торган ике кеше турында); ***Әмәк*** *белән* ***Шәмәк*** (бер-беренә тагылып йөрүче, аерылмас дуслар турында); *ак* ***бабай*** (бабай кешене исеме белән исемләмичә, кадерләп, олылап эндәшү сүзе).

4. **Туганлык мөнәсәбәтләрен белдерүче фразеологизмнар:** *ак карт* ***атай*** (әнинең бабасының бабасы); *төп* ***кодалар*** (кияү яки киленнең ата-анасы, туганнары); ***абзыкаем*** *ак мыек* (агай-энечелек, әшнәлек, кода-кодагыйлык, үз туган-тумачаңны гына кайгырту); *якын* ***әби*** (әтисенең әнисе); *ерак* ***әби*** (әнисенең әнисе).

5. **Кешенең характер үзенчәлекләрен белдерүче фразеологизмнар:** *шома* ***егет,*** *тәти* ***егет*** (тыштан көяз, франт, булдыклы күренгән, арты ничек булып чыгуы шиклерәк егет); *әпчи* ***карчык*** (күп сөйләүчән, һәр нәрсәне төпчеп сораша торган, тикшереп, акыл өйрәтеп торырга яратучан хатын-кызга карата әйтелә); *сакаллы* ***марҗа*** (гайбәтче ир, ялачы, доносчы, сатлык, шпик); *атлы* ***казак*** *булма* (гел үрә басып әтәчләнергә, гайрәт орып кешегә команда бирергә, җикеренергә яратучыга кисәтү урынында әйтелә); *җен* ***карчыгы*** (мәхәббәтсез, тискәре); *бүре* ***малае*** (кешеләр белән аралашмыйча, кешегә буйсынмыйча үз иркендә яшәүче турында); *ут* ***егет*** (бик булдыклы, уңган, дәртле егет).

6. **Интеллектуаль үзенчәлекләрне белдерүче фразеологизмнар:** *аны* ***Мәнди анасы*** *да белә* (аңгыралык мисалына әйләнгән. Мәнди нәселе тиле булып, анасы да шундый булган, ул Гөләп җиңги исеме белән китерелә); ***атаңның*** *баш сөяге* (аңсыз, аңгыра, атаңнан акыл-ми аласы урынга, корыга баш сөяге генә алган нәмәстә димәктән); ***мужик*** *чабатасы* (бик түбән,

тупас кеше турында); *мәчет таш,* ***мулла*** *юкагач* (форма-кыяфәт ягы шәп килгән дә акылы гына эшләми, башы надан дигән мәгънәдә көлеп әйтем); ***йорт хатыны*** (йорт эчендә, йорт даирәсендә генә ир хатыны булып яшәгән, фикри ягы чикле хатын димәктән).

**7. Физиологик үзенчәлекләрне белдерүче фразеологизмнар:** ***хур кызы*** (оҗмах кызы, гомерлек яшь, гүзәл кыз); ***су анасы*** *кебек гүзәл* (ямьсезлеккә мисалдан); *сөяк* ***патшасы*** (эре сөякле, ябык, зур гәүдәле кеше); *яңа төшкән* ***яшь килен*** *димәсләр* (яше олыгая башлагач, артык бизәнүдән туктап, үз-үзен юатып әйтем).

**8. Кешеләрнең эшчәнлеген һәм һөнәрен белдерүче фразеологизмнар:** ***кендек әбисе*** (элек акушеркалар булганчы бәбине тудырышкан, кендеген кисеп, юып бәйләгән әби); *суык* ***дипломат*** (базар дипломаты. Агай-эне арасында закон сатып, ашап-эчеп йөрүче, ходатай); *бер сәгатьлек* ***Хәлифә*** (очраклы рәвештә, кыска гына вакытка башлык урынына куелган кеше турында); ***Гиппократ*** *оныклары* (врачлар); *ак* ***офицер*** (ак армия офицеры); *атлы* ***казак*** (Россия патшалыгында Дон далаларында атманнар җитәкчелегендәге махсус атлы гаскәри халык).

**9. Кешенең үз-үзен тотыш үзенчәлекләрен белдерүче фразеологизмнар:** ***ата*** *казыгыз күкәй саламы* (сүзе булмаган килеш бер дә урынсыз, ахмак сүз сөйләп куйган кешегә: – Ата казыгыз йомырка саламы дигән кебек булды бу, – дип ишарә белән әйтелә); *үзебез тапкан мал түгел,* ***атай*** *тапкан җәл түгел* (ата-анадан мираска калган малны кадерсезләп, туздырып бетерү турында); *мукшының уңган* ***килене*** *аяк өсте ашый* (ашыгыч һәм утырыр өчен урын җитмәүдән табын янында тәлинкәсен күтәреп аяк өсте ашарга туры килүгә мисалдан әйтәләр); *ат ите ашаганга кызыккан урыс* ***малае*** *кебек* (кешенең үзенә ярамаган берәр нәрсәгә ымсынуына карата әйтелә); *андый гына мулла* ***кызында*** *да була* (кечерәк гаепне кичереп үткәрергә тиешлек хакында).

**10. Эш-процессларны белдерүче фразеологизмнар:** *сукыр* ***аучы*** *кыек атып туры тидергән шикелле* (сәләтсез кеше дә кőтелмәгәндә әллә нидә бер ялгыш атып туры тидерүенә, уңышлы ирешеп куюына мисалдан әйтем); *ак сакаллы* ***карт*** *булган булыр идем* (тәҗрибә җитмәүдән бер хата эш эшләгәнгә үкенеч белдергәндә китереп әйтелә); ***әбисен*** *таныту* (кыйнау, тукмау); *эшең бетте,* ***кодагый*** (шушының белән эш тәмам димәктән).

**11. Көнкүрештәге төрле әйберләрне белдерүче фразеологизмнар:** *фәсле* ***малай*** (элекке патша Россиясендә эшләнгән рус аракысы. Шешә башы кызыл сургуч белән пичәтләнгән булуы белән кызыл фәс кигән төреккә охшатып әйтелгән. Малай диелү – шуның ярты шешәсе); *хәерче* ***марҗа*** *төенчеге* (җыен вак-төяк әйбер җыентыгы); ***ана*** *бәпкә* (түбә кыегындагы ике атламаның ырмаулысы, киртлесе); *тишек* ***улы*** *ясау* (тишеккә салынган ямау хакында).

Шулай итеп, сөйләмне бизәп, образлы итеп тасвирлый торган чаралар – фразеологизмнар арасында гендер компонентлы фразеологизмнар да еш очрый. Бу фразеологизмнарда ир-ат яки хатын-кыз белән бәйле сүзләр, образлар яки ассоциацияләр ачык күренә. Алар татар фразеологик фондында аерым, мөһим урын алып тора. Бу гендер компонентлы фразеологизмнарны системалы рәвештә туплап, гендер билгесенә карап төркемнәргә бүлү аларның нинди үзенчәлекләргә ия булуын, нинди образларны чагылдыруын ачыкларга ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Еникеева Д.Д., Зарипова И.Ф. Татар телендә гендер компонентлы фразеологизмнарның лексик-семантик үзенчәлекләре // Актуальные проблемы современной татарской филологии: Сборник статей XII Международной очно-заочной научно-практической конференции, посвященной юбилеям ветеранов кафедры: 100-летию со дня рождения Народного писателя Республики Башкортостан, доктора филологических наук, профессора С.Ш. Поварисова, 90-летию со дня рождения доктора филологических наук, профессора Р.Г. Сибагатова, 85-летию со дня рождения кандидата филологических наук, доцента Р.М. Мухаметзянова. – Уфа, 2024. – С. 114–120.

2. Зарипова К.Р., Зарипова И.Ф. Фразеологизмы с зооним-компонентом, характеризующие человека, в русском языке // Актуальные проблемы современной

татарской филологии: Сборник статей XII Международной очно-заочной научно-практической конференции, посвященной юбилеям ветеранов кафедры: 100-летию со дня рождения Народного писателя Республики Башкортостан, доктора филологических наук, профессора С.Ш. Поварисова, 90-летию со дня рождения доктора филологических наук, профессора Р.Г. Сибагатова, 85-летию со дня рождения кандидата филологических наук, доцента Р.М. Мухаметзянова. – Уфа, 2024. – С. 135-141.

3. Зәкиев М.З., Галиуллина Г.Р. Татар лексикологиясе. Өч томда. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т.I. – 352 б.

4. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. I Том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989.

5. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. II Том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989.

6. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015 – Т. I. – 352 б.

© Еникеева Д.Д., 2025

УДК 811.512.145

**Еникеева Л.Р.,**
*магистрант 3 г. о. Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель* – **Каримова З. С.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## ТАТАР ДӨНЬЯ ТЕЛ КҮРЕНЕШЕНДӘ КИЕМ-САЛЫМ АТАМАЛАРЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

***Аннотация***. *Бу мәкаләдә татар дөнья тел күренешен формалаштыруда кием-салым исемнәренең роле тикшерелә.*

***Терәк сүзләр:*** *тел, кием атамалары, мәкальләр, әйтемнәр, мәдәният, дөнья тел күренеше, символика, лингвокультура, когнитивизм, концепт.*

Тел – ул милләтнең хәтере, күңел көзгесе, яшәеш кодлары тупланган тере дөнья. Һәр сүз, һәр атама үзендә халыкның дөньяны ничек тоюын, яшәешкә мөнәсәбәтен саклый. Татар телендә кием лексикасы – шушы рухи һәм матди мәдәниятнең иң төгәл чагылышы. Кием – кешенең тышкы кыяфәте генә түгел, ә аның эчке дөньясын, статусы, холкы һәм хәтта динен дә чагылдыручы символ. Татар халкының киемнәре, аларның исемнәре һәм кулланылышы аша без милләтнең тарихын, тормыш рәвешен һәм күңел җылысын тоя алабыз.

Тел – халыкның рухи мирасы, фикерләү формасы һәм мәдәни хәтере. Татар теленең дөнья-күренеш системасында кием төшенчәсе матди дөнья элементыннан күпкә киңрәк мәгънәгә ия: ул кешенең социаль һәм мәдәни үзенчәлекләрен гәүдәләндерүче символик концепт булып тора. Кием аша татар халкы үзен дөньяда таныта, үзенең рухи кыйммәтләрен һәм эстетик идеалларын саклый.

Хәзерге чорда глобальләшү һәм цифрлашу процесслары нәтиҗәсендә милли мәдәниятләр яңача формада чагыла. Татар телендә традицион киемгә бәйле сүзләр һәм образлар яңа мәгънәләр ала, әмма милли нигез сакланып кала. Мәсәлән, «калфак», «читек», «камзул» кебек сүзләр хәзер дә татар хатын-кызлары һәм ир-егетләре образының мәдәни маркерлары булып тора. Бу күренеш татар халкының милли үзаңын саклау һәм үстерү омтылышын күрсәтә, шуңа күрә «кием» төшенчәсен дөнья-күренеш элементы буларак өйрәнүнең актуальлеге бәхәссез.

Кием-салым атамаларын төрле аспектларда өйрәнү буенча тел белемендә байтак теоретик хезмәтләр бар. Соңгы вакытта лингвомәдәни, когнитив һәм этнолингвистик юнәлешләргә өстенлек бирелә. Мәсәлән, Л.Ф. Тухбиева татар телендә кием һәм баш киемнәре лексикасын тарихи үсеш һәм социаль функция ягыннан өйрәнеп, кием атамаларының төркемчәләнеш системасын ачыклаган [7; 119 б.]. С.В. Суслова татар костюмының этнографик һәм семиотик үзенчәлекләрен тикшерә, аны «мәдәни код» итеп бәяли [6; 220 б.]. З.Н. Кириллова татар һәм чуаш телләрендә кием атамаларын чагыштырып, татар теленең сакчыл табигатен һәм традицияләргә тугрылыгын күрсәтә [4; 56 б.].

А.Г. Юсупова татар телендә кием компонентлары катнашкан тотрыклы әйтемнәрне тикшереп, аларның символик йөкләнешен ачыклый [7; 102 б.]. Ф.К. Сагдеева һәм Д.Р. Гайнанова татар телендә концепт төшенчәсен когнитив яссылыкта өйрәнеп, киемнең телдәге мәгънәви структурасын мәдәни модель буларак аңлата [5; 160 б.].

Татар халкының кием-салым атамалары күп төрле, бу мәкаләдә без аларның бары тик кайберләренә генә тукталабыз, аларның татар дөнья тел күренешендә тоткан урынын ачыкларга тырышабыз.

Борынгы чорлардан ук татарлар киемгә зур мәгънә биргәннәр. Кием кешене табигатьтән саклау өчен генә түгел, ә аны җәмгыятьтә билгеләүче бер билге дә булган. Телдәге атамалар моны бик яхшы күрсәтә: «калфак», «камзул», «чалма», «чәчәкле яулык», «тун» кебек сүзләр кеше турында күп нәрсә сөйли алган. Әйтик, «калфак» хатын-кызның яшьлеген, нәзакәтен һәм зәвыгын күрсәткән, ә ир-атларның «чалмасы» – гыйлем, дин һәм хөрмәт символы булган; «тун» – кешенең статусын (бай, ярлы) билгеләгән; «яулык» – хатын-кызның җәмгыятьтәге урынын күрсәткән: яулыксыз кыз – кияүгә чыкмаган; яшь, кияүгә чыккан хатын – аллы-гөлле яулык; кияүдә булган, олы яшьтәге хатын – кара, бер төсле яулык; хөрмәтле, өлкән бай хатын – җепселле, бизәлгән яулык – югары керем. Ә бу сүзләр бүген дә үзләренең асылын югалтмаган, алар татар теленең мәдәни хәтерендә саклана.

Кием атамаларының телдәге үсеше дә үзе бер көзге. Татар кииеме – ул төрки тамырлы сүзләр белән баетылган, әмма аңа фарсы, гарәп һәм урыс сүзләре дә үтеп кергән. Бу – татар халкының күпкырлы мәдәни бәйләнешләренең җимеше. Әйтик, «камзул», «чапан», «яулык», «тун», «калфак» – уртак төрки нигездән, «чалма» һәм «сәдәф» – гарәп чыганаклы, ә «пальто», «чабата» – урыс теленнән кергән. Әмма тел аларны үзенчә үзләштерә: татар сөйләмендә бу сүзләр яңача яңгыраш һәм милли төс ала. Мәсәлән, «чапан» сүзе еш кына мәрхәмәт һәм җылылык белән бәйләнә, «калфак» исә ана җылысы, горурлык һәм зәвыклелек символы итеп кулланыла.

Рафис Корбанның «Әхмәров» дип аталган роман-хроникасы [3] Исхак Әхмәров тормышына, эшчәнлегенә багышланып, аның аеруча гыйбрәтле сәхифәләрен чагылдыра. Үзәккә төп герой белән бәйле вакыйгалар куелып, аның бала чагыннан алып, 1941 ел ахырына кадәрге вакытны үз эченә ала. Әсәрнең биографик катламында әлеге шәхеснең бала чагы, яшүсмер еллары, туган ягы белән бәйле хәлләр укучы күз алдыннан үткәрелә. Казан артындагы татар авылында үскән малайга дөньякүләм хәлләргә йогынты ясарлык зур эшләр башкарырга көч-таяныч каян килә соң? Билгеле инде, телләр өйрәнүгә сәләт табигатьтән килә, әмма әлеге мөмкинлекне ачу, аннан дөрес файдалана белү кешенең характеры, аң-акылы белән тыгыз бәйле. Автор фикеренчә, Исхак авылда яшәгәндә үк күзәтүчән булып, һәрнәрсәне күңеленә сеңдереп үсә, максатчанлык, ихтыяр көче кебек сыйфатлар аңа әби-бабадан, анадан, авылдашларыннан күчә. Яшьтән үк бабасы кебек мари телен өйрәнүе, башка халык вәкилләре белән иркен аралаша алуы малайның күңелен үстерә. Казанга килгәч тә, ул үзен күрсәтә ала, тиз таныла һәм дәрәҗәле вазифаларда эшли башлый. Шуңа да аны күреп алалар һәм тышкы разведка эшенә җәлеп итәләр. Вакыйгалар барышында Исхак гаять тыныч, сабыр, үзсүзле һәм җаваплы, үз эшен теләп, кирәклеген аңлап башкаручы булып ачыла.

Романның иҗтимагый-сәяси катламында сурәтләнгән вакыйгаларда чор рухын, аның каршылыкларын ачуга да шактый урын бирелә. 1930 еллардагы репрессияләр нәтиҗәсендә, кешеләр арасында бер-берсенә ышаныч бетә, шикләнеп карау гадәти хәлгә әйләнә. Тышкы разведка кебек яшерен һәм серле оешма да болардан котыла алмаган, күрәсең. Америка Кушма Штатларындагы резиденцияне ябып, Мәскәүгә чакырып кайтарылган Исхак та төрлечә тикшерүгә дучар була. Аның турыдан-туры җитәкчесе булган Базаровның атып үтерелүе бу куркынычны тагы да арттыра. Автор фикеренчә, Берия тырнагыннан котылу өчен кискен адым ясый ул: хатыны һәм баласы була торып, АКШ коммунистлары җитәкчесе Эрл Броудер сеңлесе кызы Һелен Лаурига өйләнә, аны үзе белән Мәскәүгә алып кайта. Бериянең аерым эш-гамәлләрендә, Сталинның вакыйгаларга бәйле караш-фикерләрендә әлеге дәһшәтле чорның куркыныч авазы чагыла. Шунысы игътибарга лаек, туган авылына

кайткан Исхак үзенең яшьлек елларын, инкыйлаблар чорын искә төшерә. 1918 елны Кызыл Армия олауларын талау, шуның өчен, тикшереп тә тормыйча, авылның алты егетен атып үтерү кебек хәлләрнең ахыр чиктә илдәге режимны, аның куркыныч идеологиясен тудыруы турында нәтиҗә ясарга этәрә.

Р. Корбанның игътибар үзәгендә 1940–41 елларда дөньяның капма-каршы лагерьларга бүленеп, чимал һәм территорияләр өчен ачыктан-ачык сугыш башлануы тора. Ул, билгеле инде, Икенче Бөтендөнья сугышы, соңрак Германиянең Советлар Союзына һөҗүм итүе, Ерак Көнчыгышта Япония агрессиясе куркынычы туу, АКШның сугышка катнашып китүе кебек вакыйгалар белән тыгыз бәйле була. Менә шул шартларда совет разведчиклары тырышлыгы белән гаять мөһим сәяси хәл ясала – АКШ хөкүмәте агрессияне авызлыклау өчен Япониягә ультиматум куя. Нәтиҗәдә Япония Перл-Харбордагы Америка хәрби базасына һөҗүм итә һәм ике ил арасында сугыш башлануга китерә. Япония Ерак Көнчыгышта СССРга каршы сугышу уеннан баш тарта, чөнки аның ике фронтта сугыш алып бару мөмкинлеге булмый. Бу исә Көнчыгыштагы күпсанлы дивизияләрне Мәскәүне сакларга кайтаруга юл ача. Әлеге сәяси һәм хәрби нәтиҗәләргә китергән «Кар» операциясен уйлап табучы Исхак Әхмәров булып, аны Виталий Карпов тормышка ашыра.

Әсәрнең уйланма катламында тышкы разведка эшенә, аның оештырылу үзенчәлекләренә дә шактый урын бирелә. Автор бу урында документлардан да иркен файдалана һәм вакыйгаларның ышандыру көчен арттыра. Әйтик, бер төр разедчикларның үз исеме белән ил посольствосында берәр вазифа башкаруы, шул ук вакытта төрле мәгълүматлар җыюы, икенче төрләренең исә яшерен рәвештә башка кеше исеме белән илдә яшәве, махсус агентлар табып, шулар аша эш итүе кебек хәл-вакыйгалар китап укучыны җәлеп итә. Р. Корбан жанрның чикләрен бермә-бер киңәйтеп җибәрә. Нигездә документаль-детектив әсәргә сәяси эчтәлекле әсәрләргә хас интрига килеп керә. Катлаулы мөнәсәбәтләргә тартылган илләр тарафыннан кабул ителгән сәяси документлар, аларның ил-дөнья өчен әһәмияте, әлеге эш-гамәлләрнең нәтиҗәсе автор күзаллавында бирелә. Разведка кебек катлаулы эшнең эчтәлегенә тирән кермәстән, автор берничә күренеш аша аның эчтәлеген, авырлыгын, разведчиклардан никадәр акыл, осталык, эчке тоемлау таләп иткәнен ача. Әсәр жанры шул рәвешле фантастика, табышмак, документальлек, уйланма кебек элементлар белән байый, тулылана.

Романның жанр табигатенә хас үзенчәлекләр төп герой – реаль шәхес Исхак Әхмәров образының бирелешенә дә йогынты ясый. Табигатьтән бирелгән сәләтне үстерә барып, ул яшерен агент булып чит илдә эшли алу дәрәҗәсенә ирешә. Моның өчен телләргә сәләт, табигый аң-акыл, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен ачу осталыгы кирәклеге укучыга яхшы аңлашыла. Документаль фактлар һәм автор уйланмасы аша аның гыйбрәтле әдәби образы оеша.

Шуның белән бергә, роман-хрониканы сәнгати планда баету, тулыландыру да сорала. Исхак Әхмәровның шәхес буларак формалашуына бәйле вакыйгаларны киңәйтү, геройның шәхси тормышын, каршылыклы гаилә тарихын үтемле, гыйбрәтле, укучыны кызыксындырырлык итеп ачу сорала. Разведка эшенең детальләренә игътибарлы булу, аның эчтәлеген тирәнәйтү, гомумән, разведка эшенең асылы, аның үзенчәлекләре турындагы урыннар да җитдирәк якын килүне сорый. Разведчик буларак И. Әхмәров эшчәнлегенең кызыклы, гыйбрәтле, шул ук вакытта куркыныч эш буларак ачылышы тулысынча ышандырмый.

Шулай итеп, «Әхмәров» роман-хроникасында танылган разведчик Исхак Әхмәров тормышы, эш-гамәлләре илнең тышкы разведка эшчәнлегенә бәйле сурәтләнә. Әлеге теманы ачуга автор вакыйгаларның шәхси, иҗтимагый, публицистик, уйланма катламнары аша килә. Әсәрнең жанрында сәяси, фантастик, документаль, табышмак алымнары урын алып, үзгә бер жанр формасы тәшкил итәләр. Романның төп герое И. Әхмәров реаль кеше, әмма ул автор уйланмасы ярдәмендә баетылып, төрле планда ачыла. Әсәр хәзерге татар әдәби процессындагы эзләнүләрне аңлауга, бәяләүгә хезмәт итә.

**Әдәбият исемлеге**

1. Габидуллина Ф.И. Трансформации фольклорных образов в прозе М. Кабирова (на примере произведения «Когда они проснулись» («Убырлар уянган чак») // Фольклор и фольклористика XXI в.: актуальные направления и перспективы исследовательских практик. Материалы III Международной научно-практической конференции, посвященной 85-летию профессора БГПУ им. М. Акмуллы А.М. Сулейманова (1939–2016). – Уфа, 2024. – С. 73–76.

2. Ганиева А.Ф. Переоценка прошлого в творчестве Гарифа Ахунова 1980-х годов // Тюркский мир в современных реалиях: проблемы языка, литературы, истории и культуры: XII Международная тюркологическая конференция (г. Елабуга, 18 апреля 2024 года) / – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2024. – С. 144–148.

3. Корбанов Р. Әхмәров: роман-хроника; кереш сүз авт. Р. Гайнетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 149 б.

4. Макарова В.Ф. Зөлфәт Хәкимнең «Серле тәңкә» романында романтизм һәм метафизик реализм синтезы // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: материалы IV Международного научно-практического семинара, посвященного 85-летию Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова (9–10 октября 2024 г., Казань) / сост. Л.И. Фахрутдинова. – Казань: ИЯЛИ, 2024. – Б. 194–199.

5. Халиуллина А.Г., Галина Г.Г. Нравственные ценности народа в повести современного башкирского прозаика Мунира Кунафина «Плыл по океану рыжий остров» // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – 2023. – Т. 16. № 8. – С. 2571–2576.

© Закирьянов А.М., 2025

УДК 821.512.145

**Закирова А.Л.,**
*студент 3 курса Елабужского института КФУ*
*Научный руководитель –* **Габидуллина Ф.И.,**
*доцент кафедры филологии Елабужского института КФУ,*
*г. Елабуга, Россия*

## РАБИТ БАТУЛЛАНЫҢ «КЫЛДАН НЕЧКӘ, КЫЛЫЧТАН ҮТКЕН» КЫЙССАСЫНЫҢ ЖАНР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация.*** *Мәкалә хәзерге татар әдибе Рабит Батулланың «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» әсәренең жанр үзенчәлеген хәзерге татар әдәбиятында кыйсса жанрының яңадан торгызылуы контекстында анализлауга багышлана. Тикшеренүнең актуальлеге, бер яктан, әдипләрнең милли мәдәни кодның бер өлеше булган борынгы жанрлар белән кызыксынуының яңаруы, икенче яктан, мәктәп программасында мондый әсәрләрнең жанр үзенчәлекләренең җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәве белән аңлатыла. Хезмәттә кыйсса жанрына билгеләмә бирелә, аның характерлы сыйфатлары Батулла әсәренең идея эчтәлеген, образлар системасын һәм сәнгати үзенчәлеген анализлау мисалында ачыклана.*

***Терәк сүзләр:*** *татар әдәбияты, Рабит Батулла, кыйсса, жанр, образ.*

Хәзерге татар әдәбияты үзенең милли тамырларына кайту һәм борынгы жанрларны яңарту юнәлешендә актив үсеш ала. Аерым алганда, кыйсса – Шәрекъ әдәби традициясеннән килеп чыккан, тарих, дини хикәя һәм фольклорны берләштерүче эпик жанр – яңа формада яңарып килә. Рабит Батулла – бу процессның иң яхшы вәкилләренең берсе. Аның «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» әсәре – кыйсса жанрын заманча әдәби контекстта үстерүнең ачык үрнәге.

Кыйсса термины Коръәнне тәфсирләүче һәм дини хикәяләр сөйләүче – кыссаслар эшчәнлегеннән килеп чыккан. Р. Әхмәтьянов үз сүзлегендә әлеге сүзнең гарәп теленнән килүен һәм башлангыч мәгънәсен «суд вакыйгасын сөйләү» дип билгели [1, 133 б.].

Татар әдәбияты галиме Х.Й. Миңнегулов кыйссаны түбәндәгечә билгели: «Кыйсса – Шәрекъ әдәбиятларында һәм фольклорында эпик (кайвакыт лиро-эпик) жанр атамасы. Кыйссада, гадәттә, гадәттән тыш, кызыклы, мавыктыргыч, драматик, гыйбрәтле вакыйгалар бәян ителә. Сюжет үсеше кайвакыт лирик кичерешләр, төрле уйланулар белән кушылып бирелә. Кыйсса конфликты үзенең кискенлеге, кайвакыт трагик характерда булуы белән аерылып тора. Күп кыйссаларда күчмә сюжетлар, төрле легендалар, риваятьләр, хәтта мифлар эшкәртелә» [4, 77 б.].

Кыйсса еш кына дастан белән якын китерелсә дә, алар арасында принципиаль аермалар бар. Дастан күбрәк халыкның батырлык эпосы, коллектив героик эпоска нигезләнә, ә кыйсса – шәхес язмышына, аның рухи эзләнүләренә, иман сынавуларына үзәкләшкән. Ул дини-дидактик яки романтик-маҗаралы хикәягә якынрак. Ләкин аерым әсәрләрдә бу чикләр шелтәләнә ала, гомуми Шәрекъ әдәби традициясе аларны берләштерә.

Кыйссаның төп үзенчәлеге булып аның дини мотивлар һәм образлар (пәйгамбәрләр, әүлияләр, изге затлар) белән нык бәйләнеше тора. Моңа фантастик һәм мифологик элементларның бай кулланылышы өстәлә, алар ярдәмендә автор реаль вакыйгаларны метафизик дәрәҗәгә күтәрә, гыйбрәтле мәгънәләргә баетып бирә. Шулай ук кыйссага хас үзенчәлек – бу фаҗигавильлек, гаепсезлек корбанының азабы һәм ахырда әдәби-фәлсәфи гаделлек торгызылу темасы.

Татар әдәбияты тарихында кыйсса жанры үсеш, таркалу һәм яңарыш чорларын кичергән. Урта гасыр әдәбиятында («Кыйсса-и Йосыф», «Хөсрәү вә Ширин») ул алдынгы урынны алса, XIX гасырда һәм XX гасыр башында халык арасында киң тарала. Ләкин 1917 елдан соң, совет чоры идеологиясе шартларында, дини эчтәлекле булганга күрә, жанр тулысынча онытыла, бастырыудан чыгарыла һәм әдәби процесстан читләштерелә. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында, милли үткәннәргә һәм рухи мираска булган кызыксыну үсеше, суверенитет көчәюе аркасында, кыйсса яңадан яңарыш кичерә. **Р. Батулла, Р. Низами, Г. Гыйльманов** кебек язучылар бу жанрны яңадан тергезүдә һәм үстерүдә әйдәп баручы рольне уйныйлар.

Хәзерге авторларның әсәрләре тарихка, легендаларга, мифологиягә, ислам мотивларына мөрәҗәгать итүдә традициягә бәйлелекне саклап кала. Шулай ук алар жанрны ныклап яңарталар: психологизмны тирәнәйтәләр, авторлык уйлануларны кертәләр, хәзерге заман прозасының чараларын кулланып, аны повесть яки кече роман формасына якынлаштыралар. Ләкин үзәк берләштерүче элемент булып Шәрекъ әдәби традициясенә, мифологик хыялга һәм милли дөньяга караш, рухи-әхлакый эзләнүләргә таба булган ориентация тора. Яңарыш кичергән кыйсса – бу татар әдәбиятында милли сүзнең, рухи идентичностьне саклауның мөһим чарасына әйләнә.

Рабит Батулла Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында күпсанлы әсәрләр авторы. «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» һәм «Апуш – Тукай» – аларның иң күренеклеләре. Автор үз әсәрләренең жанрын «кыйсса» дип билгеләүне сайлый, һәм бу очраклы түгел. Бер яктан, бу аңа тарихи фактлар белән үтә каты бәйләнеп калмый, иҗади хыялга юл ача, икенче яктан, тамырлы милли жанрга мөрәҗәгать итү милли үзаңны формалаштыруга хезмәт итә.

«Кылдан нечкә, кылычтан үткен» бөек шагыйрьнең соңгы көннәренә багышланган. Әсәр кыйсса жанрының төп үзенчәлекләренә туры килә.

**Драматизм һәм гыйбрәтлелек.** Тукайның үлеме монда ялгыз фаҗига буларак түгел, ә бөтен татар милләтенең тарихи сынау вакытындагы авырлыклары, мәдәни һәм рухи җимерелү куркынычы символы итеп сурәтләнә. Шагыйрьнең авыруы һәм аңсызлыгы милли авыруның, халыкны үлемгә тартучы авыр чирнең метафорасына әйләнә. Бер үк вакытта, аның көрәше халык рухының җиңелмәслеген символлаштыра. Бу фаҗигадән автор укучыны халык тагынмы шундый сынауларны кичерсә, тарихны кабатлавыннан сакланырга чакырып, тирән гыйбрәтләр чыгара.

**Символик һәм мифологик образлар.** Әсәрдәге символ-антиподлар мөһим роль уйный, сюжетка мифологик тартым һәм философи гомумиләштерү кертә. **Каракош** – ул татар мәдәниятен һәм рухилыгын юк итәргә омтылган дошман империясенең, басым һәм золымның яшеләй торган, мифик образы. Ул Тукайга һәм аның иҗатына каршы торучы барлык көчләрне берләштерә. **Шәүлә** – яшерен эзәрлекләүче, күзәтүче, шагыйрьгә тынычлык бирми торган һәм аның соңгы көннәрендә рухи пычкаулык тудыра торган образ. Бу образлар ярдәмендә автор тарихи конфликтны Яхшылык һәм Яманлык арасындагы бөтендөнья көрәш дәрәҗәсенә күтәрә.

**Реаль һәм ирреальнең берләшүе.** Батулла осталык белән тарихи шәхесләрне (Ф. Әмирхан, Х. Ямашев, С. Рәмиев) һәм вакыйгаларны документаль төгәллек белән сурәтләүне мистик-символик элементлар белән бергә куллана. Тукайның Каракош һәм Шәүләне күргән төшләре, хыяллары һәм галлюцинацияләре аның эчке дөньясын ача, әмма шулай ук конкрет-тарихи каршылыкны Яхшылык һәм Яманлык арасындагы метафизик көрәш дәрәҗәсенә күтәрә. Реаль дөнья белән мистик хыял дөньясының чикләре юкка чыга, бу укучыга шагыйрьнең рухи трагедиясен һәм аның халкының язмышы өчен борчылуын тулырак аңларга мөмкинлек бирә.

**Герой образы.** Батулла сурәтләгән Тукай – ялгыз тарихи шәхес түгел, ә сайланмалык сыйфатлары һәм авыр миссия белән билгеләнгән зат. Автор аның образын «нур» мотивы аша рухи яктыртучы, халыкка юл күрсәтүче ролендә тәкъдим итә. Бу, үз чиратында, кыйссалардагы традицион пәйгамбәр яки әүлия образлары арасында ачык параллель тудыра. Тукай образын шулай «изгеләштерү», аңа рухи-эшартый характер бирү Шәрекъ әдәбияты традицияләренә нык таянуын күрсәтә, әмма бу «изгелек» дини түгел, ә милли мәгънәдә – халкы өчен корбан булу, аның язмышы өчен җавап бирү сыйфатында ачыла.

**Композиция.** Әсәрнең композициясе ачык боҗралы төзелешкә ия: ул Тукайның авыруы һәм якын үлеме турындагы хәбәр белән башланып, шул ук фаҗигадә тәмамлана. Бу ысул укучыда фаҗиганең кирәкмәслеген, язмышның рәнҗегүчән бәраберелеген хис иттерә, трагик эффектны максималь дәрәҗәдә көчәйтә. Ләкин, моңа карамастан, әсәрнең финалы тормышны раслаучы югары лирик нотада яңгырый: халык тавышы, аның хәтере аша шагыйрьнең үзе һәм аның иҗаты үлемсез, алар милләтнең рухи терсәгендә яши, дигән өметле, көчле игълан белән тәмамлана.

Шулай итеп, Рабит Батулланың «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» кыйссасы – бу үткәнне хәтерләү түгел, ә киләчәккә юнәлгән сәнгать эше. Ул татар халкының җиңелеп бетмәүчән рухи көчен, тарихи давылларда да үз төшенчәсен, үз тамырларын саклап калу сәләтен күрсәтә. Тукай образы аша безгә бүгенге көндә дә үз эшеңә, халкыңа тугрылык, мәгънә һәм максат эзләү турында өйрәнәсе килә.

Хәзерге заман әдәбиятында милли жанрларны яңарту – ул мәдәни үзаңны саклауның иң нык чарасы. Батулла кебек авторлар кыйссаны яңача уку безгә борынгы әдәби мирасның баетылып бетмәгән, ә безнең заманда да тирән мәгънәгә ия икәнлеген исбатлый. Бу юнәлеш татар әдәбиятын даимилек һәм үзгәреш, традиция һәм яңарыш арасындагы бәйләнешне тагын да баетырга мөмкинлек бирә.

Үзенең кимендә меңьеллык тарихы булган кыйсса жанры бүген дә үзенең рухи-әхлакый потенциалы белән кыйммәтле. Ул укучыны тарихка, гадәттән тыш вакыйгаларга гына түгел, ә кешенең эчендәге дөньяга, аның яшәү мәгънәсен эзләвенә дә чакыра. Шуңа күрә Батулланың әсәре безнең бүгенге тормышыбызда да үз урынын тапкан – ул безгә рухи тәмамлангырлык, үз-үзеңне ачу һәм милли бердәмлек хисен уятырга ярдәм итә.

Шуның өстенә, әдәбиятның үсеше һәрвакытта традицияләрне саклау һәм аларны яңача ачу юлы белән бара. Рабит Батулланың иҗаты – нәкъ менә бу юлның уңышлы үрнәге. Аның хезмәте татар әдәбияты тарихында кыйсса жанрын яңарып, аны заманча темалар һәм проблемалар белән баетырга мөмкинлек ачты. Бу безгә киләчәк буын язучылары өчен дә мөһим юнәлеш бирә, аларның да үзләренә генә хас тавыш табуларына, үткәннән көч алып, хәзерге заманга сөйләшә белүләренә ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.
2. Батулла Р. Кылдан нечкә, кылычтан үткен: кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2008. – 224 б.
3. Батулла Р. Апуш – Тукай: кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 192 б.
4. Миңнегулов Х.Й. Татар әдәбияты: Урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 10–11 нче сыйныфлары өчен дәреслек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 320 б.
5. Нигъмәтуллина Ю.Г. Жанрлар үзара бәйләнешендә: татар прозасының үсеш тенденцияләре. – Казан: Казан университеты нәшр., 1988. – 168 б.


© Закирова А.Л., 2025

УДК 811.512. 145

**Зарипова И.Ф.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

# КУШМА СҮЗЛӘР ЯСАЛЫШЫНДА БАШКАРУ БӘЙЛӘНЕШЕ: ИНКОРПОРАЦИЯ КҮРЕНЕШЕ

***Аннотация.*** *Әлеге мәкаләдә ияртүле бәйләнешнең төп төрләреннән берсе булган башкару бәйләнешенең – фигыльнең актантлары белән кушылуның (инкорпорацияләнү) – сүз ясалышында ролен тикшерүгә багышлана. Хәзерге татар телендә инкорпорацияләнгән актант һәм сирконстант тибы буенча классификация тәкъдим ителә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, агглютинация, сүз ясалышы, грамматика, ияртүле бәйләнеш, башкару бәйләнеше, валентлык, фигыль, актант, инкорпорация.*

Татар телендә сүз ясалышының күптөрле ысуллары бар, алар һәркайсы тел белеменең аерым тармагы белән бәйләнештә: фонетик ысул – фонетика, лексик-семантик ысул – лексикология; морфологик, синтаксик, морфологик-синтаксик ысуллар грамматикага карый. Синтаксик ысул белән кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма исемнәр ясала. Традицион рәвештә тюркологиядә һәм татар тел белемендә соңгы вакытта сүз ясалышының бу төре сүз кушу ысулы дип йөртелә башлады [21, 144 б.].

Сүз кушу – сүз ясалышының «ике яки сирәк очракта берничә гади нигезне бер кушма сүзгә берләштерүдән гыйбарәт» булган ысулы. Кушма сүз компонентлары арасында, тел структурасының төрле берәмлекләрендәге кебек, компонентларның грамматик билгеләре һәм лексик эчтәлеге буенча сайланылуында чагыла торган төрле мөнәсәбәтләр була. Лексик һәм грамматик каршылык аркасында теләсә кайсы сүз теге яки бу кушма сүзнең компоненты була алмый» [19, 210 б.]. Сүз кушу (синтаксик) ысулы белән ясалган сүзләрнең компонентлары үзара тигез хокуклы һәм тигез хокуклы булмаска мөмкин. Бу шулай ук сүз компонентлары арасында үзара грамматик бәйләнеш булуын дәлилли. Мәсәлән, *тирә-як* сүзе тигез хокуклы мөнәсәбәткә кергән тезүле бәйләнештәге компонентларны берләштерә. Кушма сүзнең компонентлары ияртүле бәйләнешкә керсә, алар арасында ияртүле мөнәсәбәт күзәтелә: *башваткыч, эшкуар, җир җиләге*. Димәк, татар телендә синтаксик ысул нигезендә ясалган сүзләрнең компонентлары үзара тезүле һәм ияртүле мөнәсәбәт нигезендә бәйләнгән була.

Телдә ияртүле бәйләнеш – сүзләр бәйләнешенең сөйләм оештыруда иң әһәмиятле төре. Хәзерге татар телендә компонентлары ияртүле бәйләнештә булган кушма сүзләрнең түбәндәге типлары бар: «1) компонентлары атрибутив бәйләнештә булган кушма сүзләр; 2) компонентлары объект бәйләнешендә булган кушма сүзләр; 3) компонентлары хәл бәйләнешендә булган кушма сүзләр» [18, 193 б.]. Моннан тыш, «татар телендә компонентлары предикатив мөнәсәбәттә булган кушма сүзләрне дә аерып күрсәтергә

мөмкин» [20, 37 б.]. Мәсәлән: *минбеләмлек, үзбушаткыч, үзбилгеләнеш, көнбатыш, көнчыгыш, буйсыну, үзйөрешле.* Атрибутив мөнәсәбәттән тыш, башка очракларда сүз кушылуның төп компоненты булып фигыль тора. Ул күбесенчә башкару бәйләнеше нигезендә, үзенең семантик валентлыгын тутыру өчен, актантлары белән кушыла, ягъни инкорпорацияләнә.

«Инкорпорация мәсьәләсе лингвистикада мөһим проблемалар белән бәйле: сүз һәм сүзтезмәнең үзара нисбәте белән, сүз һәм җөмлә чикләре мәсьәләләре белән, җөмләнең кисәкләргә бүленеше белән һ.б. Инкорпорациянең асылына караган мәсьәләләр тикшеренүчеләр арасында бәхәсләр уята. Кайбер тел белгечләре инкорпорацияне сүз ясалышы ысулы буларак карый, икенчеләре – синтаксик мөнәсәбәтләрне белдерү ысулларының берсе буларак, өченчеләре аны морфология һәм синтаксис кисешкән урында торучы уникаль морфологик-синтаксик күренеш буларак тикшерә» [1, 73 б.].

Традицион рәвештә инкорпорация турындагы күзаллау билгеле бер фигыльнең сүз формасы составына исем нигезен кушуга бәйле, нәтиҗәдә «исем (алмашлык) + фигыль» тибындагы кушма сүз ясала.

Мондый төрдәге фигыльләр сүз ясалышы системасында сүз кушу мисаллары буларак өйрәнелә. Кушма сүзләр буларак, мондый фигыльләр инкорпорациянең аерым очрагы булып тора.

«Исем + фигыль» моделе буенча ясалган башкару бәйләнешенә нигезләнгән кушма сүзләр татар теледә дә күзәтелә: *кульюгыч (кул + юуу), елъязма (елны + язу), газүткәргеч (газ + үткәрү), сусаклагыч (су + саклау), тизәйткеч (тиз + әйтү)* и т.д.

Нинди генә телдә булса да фигыль сүз төркемнәре арасында аерым урын били, чөнки нәкъ менә фигыль җөмлә үзәге булып тора һәм ситуациядә катнашучыларның санын һәм тибын билгели [7, 44 б.]. Башкару бәйләнешендә булган фигыльне валентлыкның семантик теориясе позициясеннән өйрәнү гомуми тел белеме, семантик синтаксис һәм функциональ грамматика проблемалары белән шөгыльләнүче хәзерге тикшеренүчеләрдә елдан-ел зуррак кызыксыну уята.

Кайбер тикшеренүчеләр «инкорпорация полисинтетик телләр структурасының билгесе булып тора һәм аларның грамматик төзелешенең үзенчәлеген билгели» дип саный [9]. Ә башкалар «телләрдә инкорпорация агглютинация белән бәйле һәм шуңа күрә бу телләр агглютинатив телләр белән берләштерелергә тиеш» дип раслый [13].

Е.А. Смирнова фикеренчә, «фигыль актантларының инкорпорацияләнүе полисинтетик телләрдә генә түгел, ә башка телләрдә дә киң таралыш ала, чөнки инкорпорант комплекслар – мәгънәне тапшыруның иң экономияле ысулы, бу исә тел экономиясе законының чагылышы булып тора. Хәзерге заман кешесенең тизләшә барган тормыш темпына бәйле рәвештә вакытны һәм көчне экономияләү зарурлыгы телдәге экономияләү тенденциясенең активлашуына китерә. Тел экономиясе кешенең мөмкин кадәр азрак тел чараларын кулланып һәм мөмкин кадәр азрак көч сарыф итеп, мөмкин кадәр күбрәк белдерергә омтылуыннан гыйбарәт, ул лингвистикада телнең нормаль табигый яшәешенең төп һәм кирәкле принципларының берсе буларак карала. Телдә лингвистик экономия принцибы үз нигезендә тел билгесенең ике өлешенең асимметриясе, ягъни ачыклаучы белән ачыкланучының аермасы ята торган күренешләрдә чагыла. Бу полисемия, синонимия, омонимия, кыскартулар һәм аббревиатуралар, диффузия, эллипс, субституция, нейтральләшү, синкретизм һәм инкорпорация» [16].

Тикшеренүчеләрнең «инкорпорация» төшенчәсенең асылына карашлары төрле. Кайбер галимнәр (Р.З. Гинзбург, И.А. Муравьева) фикеренчә, «күп кенә һинд-европа телләрендә тышкы яктан инкорпорант комплексларга охшаган яңа фигыльләр барлыкка килүгә карамастан, аларны инкорпорация мисаллары дип санарга ярамый. Капма-каршы позиция дә бар. М.А. Анохина, О.Ю. Афанасьева, Л.В. Мерзлякова, Л.Ф. Омельченко һ.б. кебек тикшеренүчеләр мондый мисалларда фигыльнең ситуациядә мәҗбүри һәм факультатив катнашучыларны үз составына алу үзенчәлеге чагыла торган инкорпорацияләүче телләрнең аерым билгеләре бар дип саныйлар. Мондый төзелмәләр инкорпорация мисаллары булып

саналырга мөмкин, чөнки семантик яссылыктан караганда, алар мөстәкыйль синтаксик позициядә торучы нинди дә булса актант белән фигыль бәйләнешенә туры килә» [22, 63 б.].

«Инкорпорация» төшенчәсенә билгеләмә бирүдә дә фикер төрлелекләре күзәтелә.

В.А. Плунгян фикерне белдерүнең иң компакт ысулының ачык мисалы булып «җөмләнең бер сүзендә бөтен фикер берьюлы төрелгән» инкорпорация тора дип саный [14, 173 б.].

О.С. Ахманованың лингвистик терминнар сүзлегендә инкорпорация ярдәмче элементлар белән бер-берсенә тоташкан тамырларны кушып сүз ясауның продуктив ысулы (яки синтагматик берәмлекнең аерым төре) буларак карала [4, 177 б.].

В.Н. Ярцева редакциясендәге Зур энциклопедик сүзлектә инкорпорациягә түбәндәге билгеләмә бирелә: «инкорпорация – сүзтезмә компонентларының (өлешчә И.) яки җөмләнең барлык кисәкләренең (тулы И.) синтаксик бәйләнеше ысулы, бу очракта компонентлар формаль күрсәткечләреннән башка бербөтен булып оеша» [22, 193 б.].

В. Гумбольдт фикеренчә, инкорпорациянең асылы шунда: «җөмләне аның барлык кирәкле өлешләре белән бергә сүзләрдән төзелгән бербөтен итеп түгел, ә, асылда, аерым сүз итеп карау» [5, 144 б.].

И.И. Мещанинов билгеләвенчә, инкорпорациягә «тышкы яктан сүзне хәтерләтүче, төгәлләнгән мәгънәви эчтәлеккә ия булуы белән җөмләгә туры килүче кушылма рәвешендәге бербөтен синтаксик төзелмә» керә [9, 30 б.].

«Инкорпорациянең үзенчәлеге, – П.Я. Скорик фикеренчә, – аның ярдәмендә ике һәм аннан да күбрәк нигезле (тамыр да, ясалма да) морфологик конструкция ясалуыннан гыйбарәт, өстәвенә башка шартларда (башка контекстта) бу нигезләр мөстәкыйль сүзләр рәвешендә бирелә» [15, 27 б.].

Хәзерге лингвистикада төрле структуралы телләрдә дә инкорпорациянең күзәтелүе турында мәгълүматлар бирелә. Соңгы дистә елларда грамматика теориясе һәм типологиясе өлкәсендәге яңа тикшеренүләр, шулай ук лингвистиканың референция теориясе, прагматика, дискурс теориясе кебек өлкәләренең көчле үсеше белән бәйле рәвештә инкорпорациянең күп аспектларына яңача карау мөмкинлеге барлыкка килә. Болар барысы да лингвистика фәненең хәзерге үсеш дәрәҗәсенә туры килерлек гомумиләштерелгән тикшеренү үткәрү зарурлыгын күрсәтә.

Гадәттә инкорпорацияләнүче актант белән фигыльләр фигыльләрнең генә түгел, ә башка сүз төркемнәренә караган кушма сүзләр ясалышы өчен дә мотивлаштыручы нигез булып хезмәт итә. Без инкорпорацияне киң мәгънәдә – семантик-синтаксик күренеш, ягъни фигыльнең үз составына актантларны һәм сирконстантларны, ситуациядә катнашучыларны алуы буларак карыйбыз.

Хәзерге татар телендә инкорпорант комплексларның мондый типларын аерып карарга мөмкин: «исем / алмашлык + фигыль», «рәвеш / сыйфат + фигыль», «сан + фигыль» һәм «фигыль + фигыль» схемалары буенча ясалган сүзләр. Иң киң таралганнары – составында «исем / алмашлык + фигыль» схемасы буенча ясалган, актанты ингерент рәвештә белдерелгән төрле сүз төркемнәренә караган кушма сүзләр [6, 448 б.].

Актантларның төре буенча фигыльләрнең түбәндәге классификациясен тәкъдим итәргә мөмкин:

**1. Эш-хәлнең субъектын белдерүче актант белән фигыль** бәйләнеше нигезендә: 1) исем: *минбеләмлек (мин + беләм), үзбушаткыч (үзе + бушату), үзбилгеләнеш (үзе + билгеләнү), көнбатыш (көн + бату), көнчыгыш (көн + чыгу)*; *үзагым (үзе + агу);* 2) фигыль: *буйсыну (буй + сыну), үзбилгеләнү (үзе + билгеләнү);* 3) сыйфат: *искиткеч (ис+китү); искитмәүчән (ис + китмәү); үзйөрешле (үзе + йөрү), коточкыч (кот + очу), котчыккыч (кот + чыгу)* сүз төркемнәре ясала.

**2. Эш-хәлнең объектын белдерүче актант белән фигыль:** 1) исем: *урынбасар (урын + басу), эшкуар (эш + куу), эшсөяр (эш + сөю), алъяпкыч (ал + ябу), башваткыч (баш + вату); көнбагыш (көнгә + багу); ташбасма (таш (тан) + басу); ташъязма (таш (ка) + язу);* 2) сыйфат: *башимәс (баш + имәү), коточыргыч (кот + очыру), канечкеч (кан + эчү),*

*канкойгыч (кан + кою);* 3) фигыль**:** *атказану (ат + казану)* кебек сүз төркемнәре ясалу өчен мотивлаштыручы нигез булып тора.

**3. Актант-локатив белән фигыль бәйләнеше:** 1) исем: *атменәр (атка + мену), суүсем (суда + үсү);* 2) сыйфат: *йорттума (йортта + туу)* сүз төркемнәренә караган кушма сүзләр ясый.

«Рәвеш / сыйфат + фигыль», «исем + фигыль», «сан + фигыль» һәм «фигыль + фигыль» структур схемалары буенча ясалган инкорпорант комплекслар, нигездә, исемнәр, сыйфатлар һәм рәвешләр ясалу өчен нигез булып хезмәт итә.

**Эш-хәлнең үтәлүен белдерүче актант (сирконстант) белән фигыль** бәйләнеше нигезендә мондый сүз төркемнәренә караган кушма сүзләр ясала:

а) исемнәр: *тизәйткеч (тиз + әйтү), тикторыш (тик + тору); кулъязма (кулдан + язу); автотөягеч (авто(автомат рәвештә) + төяү); алыпсатар (алып + сату); чөйязма (чөй (белән) + язу); ярымүткәргеч (ярым + үткәрү);*

б) сыйфатлар: *тизаткыч (тиз + ату), тиктормас (тик + тормау), тигезүзгәрешле (тигез + үзгәрү);*

в) рәвешләр: *бертуктамый (бер + туктамый), бертуктаусыз (бер + туктау), кушучлап (куш + учлау).*

**Дәрәҗә һәм күләмне белдерүче актант (сирконстант) белән фигыль** бәйләнеше нигезендә «сан + фигыль» схемасы буенча *йөзьяшәр (йөз (ел) + яшәү), кырыгалдар (кырык + алдау),* «исем + фигыль» схемасы буенча *көньяшәр (көн + яшәү), елъязма (ел + язу)* кебек кушма исемнәр ясала.

Шулай итеп, әлеге фигыльләрнең семантик структурасын тирәнрәк аңлау, аларның лексик мәгънәләре белән грамматик үзенчәлекләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, шулай аларның сүзтезмәләрдә һәм сүз ясалышында кулланылышын анализлау татар теленең когнитив аспектларын ачуда яңа мөмкинлекләр тудырачак. Аларның инкорпорация механизмын ачыклау хәзерге татар теленең сүз байлыгын һәм грамматик системасын тулырак аңларга ярдәм итәчәк.

## Кулланылган әдәбият

1. Анохина М.А. Явление инкорпорации в английской глагольной лексике: на материале адвербиальных глаголов английского языка: дисс. ... канд. филол. наук. – Барнаул, 2006. – 195 с.

2. Анохина М.А. Семантическая инкорпорация как один из способов реализации когнитивной модели глагола (на материале английского языка) // Ползуновский вестник. – 2006. – № 3. – С. 73–82.

3. Афанасьева О.Ю. Глаголы с инкорпорированным обстоятельством образа действия в английском языке и семантическая редупликация (на материале современного английского языка): автореф. дисс. ... канд. филол. наук. – Челябинск, 1991. – 15 с.

4. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. Изд. 2-е, стереотипное. – М.: Едиториал УРСС, 2004. – 576 с.

5. Гумбольдт В. Избранные труды по языкознанию: Пер. с нем. / Общ. ред. Г. В. Рамишвили; Послесл. А.В. Гулыги и В.А. Звягинцева. – М.: ОАО ИГ «Прогресс», 2000. – 400 с.

6. Зарипова И.Ф. Инкорпорация при глагольном управлении как один из видов словообразования в современном татарском языке // Вестник Башкирского университета. – 2021. Т. 26. – № 2. – С. 447–454.

7. Зарипова И.Ф. Беспослеложное двойное управление как средство расширения структурной схемы предложения в татарском языке (на материале двухвалентных глаголов и имён существительных) // Актуальные проблемы теоретической и прикладной филологии: Материалы XI Международной научно-практической конференции. – Уфа, 2023. – С. 43–54.

8. Мерзлякова Л. В. Семантическая структура глаголов современного английского языка с инкорпорированными актантами: дисс. ... канд. филол. наук. – Л., 1986. – 177 с.

9. Мещанинов И. И. Агглютинация и инкорпорирование // Вопросы языкознания. – 1962. – № 5. – С. 24–31.
10. Мещанинов И.И. Члены предложения и части речи. – М.-Л.: «Наука», Ленингр. отд-ие, 1978. – 378 с.
11. Муравьева Н. А. Типология инкорпорации: дисс. ... док-ра филол. наук. – М., 2004. – 286 с.
12. Омельченко Л.Ф. Типы лексических значений композитных производных слов // Филологические науки. – 1992. – № 1. – С. 86–93.
13. Панфилов В. З. К вопросу об инкорпорировании. На материале нивхского (гиляцкого) языка // Вопросы языкознания. – 1954. – № 6. – С. 6–27.
14. Плунгян В. А. Почему языки такие разные. Популярная лингвистика. – М.: АСТ-Пресс Книга, 2010. – 274 с.
15. Скорик П.Я. Очерки по синтаксису чукотского языка. Инкорпорация. Под.ред. И.И. Мещанинова. – Л.: Ленингр.отд-ие Учпедгиза, 1948. – 176 с.
16. Смирнова Е.А. Функционирование глаголов с инкорпорированными актантами: автореф. дис. …канд. филол. наук. – Пермь, 2013. – 24 с.
17. Смирнова Е.А., Шустова С.В. Инкорпорантные комплексы в английском языке // Вестник Волжского университета имени В.Н.Татищева. – 2013. – №3 (13). – С. 60–71.
18. Татар грамматикасы. Т.I. – Казань, 1995. – 511 с.
19. Татарская грамматика. Т.I. – Казань, 1995. – 583 с.
20. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.
21. Юсупова Л.Р., Зарипова И.Ф. Субстантивация в татарском языке как морфолого-синтаксический способ словообразования // Гуманитарные и социальные науки. – 2024. – Т. 103. – № 2. – С. 144–149.
22. Языкознание. Большой энциклопедический словарь / Гл. ред. В. Н. Ярцева. 2-е изд. – М.: Большая Российская энциклопедия, 2000. – 688 с.

© Зарипова И.Ф., 2025

УДК 81.23

**Ибрагимова А.Н.,**
*инструктор обучающего курса для учителей английского языка*
*по программе «Бамбино Монтессори» в дошкольных учреждениях,*
*учитель в частном образовательном центре,*
*г. Гунсан, Республика Корея*

## ЛИНГВОКУЛЬТУРНЫЕ ОСОБЕННОСТИ ВЫРАЖЕНИЯ ВЕЖЛИВОСТИ И ИЕРАРХИИ ЧЕРЕЗ ОБРАЩЕНИЯ У КОРЕЙЦЕВ И ТАТАР

***Аннотация***. *В статье рассматриваются лингвокультурные особенности обращений в татарском и корейском языках как средство выражения вежливости, социальной дистанции и иерархии. Автор описывает общие и специфические черты обращения в двух культурах, анализируя их семантические и культурные функции. Особое внимание уделяется роли обращений в поддержании гармоничных межличностных отношений и соблюдении норм речевого этикета. В обеих культурах выбор формы обращения определяется возрастом, статусом и степенью близости собеседников.*

***Ключевые слова:*** *лингвокультурые особеннсоти, обращения в языке, корейский язык, татарский язык, вежливость, иерархия, уважение, конфуцианство.*

Язык выступает не только средством коммуникации, но и инструментом, через который считываются ценности, культурные практики и картина мира конкретного народа.

Особое место в этом процессе занимают обращения – лексико-грамматические средства, с помощью которых инициируется, поддерживается и регулируется контакт между собеседниками.

Через формы обращения проявляются такие культурные категории, как вежливость, уважение, субординация и эмоциональная близость [2, с. 55; 3, с. 45].

Восточные языки, в том числе татарский и корейский, демонстрируют ярко выраженную зависимость языкового поведения от социальных факторов – возраста, статуса, степени родства, принадлежности к определённой группе [1, с. 22; 4, с. 34]. В отличие от западноевропейских языков, где обращение чаще носит нейтральный или формальный характер, в татарской и корейской культурах обращение является неотъемлемым элементом этикета и показателем межличностных отношений [3, с. 46; 5, с. 14].

Для сравнения: в английском типичны Mr., Mrs., Sir, Madam; во французском – Monsieur, Madame; в немецком – Herr, Frau – то есть формы, поддерживающие вежливую дистанцию и статусную нейтральность.

Актуальность исследования обусловлена стремлением глубже описать лингвокультурные механизмы проявления вежливости в тюркской и восточноазиатской традициях и сопоставить их в межкультурной перспективе.

Цель работы – выявить общие и специфические черты функционирования обращений в татарском и корейском языках и определить их социокультурную нагрузку.

В фокусе анализа – основные типы обращений (официальные, дружеские, ласковые, нейтральные и грубые), а также их историко-культурные предпосылки, функции и прагматические параметры.

Употребление терминов родства в позиции обращения имеет свои особенности в различных языках. У некоторых народов данные единицы используются только по отношению к родственникам (например, у англичан) [7]. В русском языке сфера применения данных наименований гораздо шире: их используют при обращении к родственникам, знакомым и незнакомым [2]. В тюркских языках, в том числе и татарском, указанные слова также представлены достаточно разнообразно и имеют свою специфику речевой реализации [3; 4].

Ткаким образом в татарском и корейском языках показывается что они основаны на уважении, иерархии раскрывая черты восчточной культуры

И в татарской, и в корейской традициях выбор формы обращения определяется возрастным и статусным различием, а также степенью близости: младшие демонстрируют почтение, старшие – заботливое внимание. К перекрестным чертам относятся наличие специализированных форм уважительности, активное использование родственных терминов за пределами семейного круга и избегание прямого называния по имени старших.

В татарском языке слова абый («старший брат») и апа («старшая сестра») применяются не только в семье, но и по отношению к старшим коллегам или незнакомым людям как форма уважения [3, с. 46].

Аналогичную функцию выполняют корейские обращения 형 (страший брат), 누나 (сестра мужа), 오빠 (старший брат), 언니 (сестра обращение девушки), используемые для обозначения старших по возрасту друзей или коллег [1, с. 26; 4, с. 35].

В оба языка избегают прямого произношения имени и выбирают родственные или титульные формы, а уровень вежливости зависит от ситуации: в кругу семьи допускается простая форма речи, в официальной – повышенно уважительная [5, с. 15].

Ключевое отличие систем проявляется в способе языкового кодирования уважительности. В татарской речи вежливость выражается преимущественно лексически – через местоимения (*син / сез*), этикетные слова (*әфәнде, ханым, укутучы апа*) и интонацию. В корейском же языке она закреплена морфологически: существуют отдельные уровни речевых

стилей (до семи), которые передаются с помощью окончаний –요 (йо), –(으)세요(-ысейо), –(으)십니다 (-щимнида)[1, с. 27; 2, с. 56].

Различие прослеживается и в культурных источниках. Татарская система испытала влияние ислама и арабско-персидской традиции (*хәзрәт, әфәнде, остаз*), тогда как корейская формировалась под воздействием конфуцианской модели и включает титулы 선생님 (учитель), 사장님 (директор), 교수님 (профессор) [3, с. 47; 4, с. 36].

В обращениях к родителям татары используют формы без специальных суффиксов – Әни, Әти, а корейцы – с обязательным –님, например 선생님 (учитель), 부장님(начальник отдела, менеджер), 어머님 (мама) [1, с. 29].

Несмотря на эти различия, обе системы выполняют схожие коммуникативные функции: выражают уважение, поддерживают гармонию и фиксируют социальные роли собеседников [2, с. 58; 5, с. 16].

Иллюстративный ряд: Исәнмесез! – 안녕하세요! («Здравствуйте!»), Сез ничек сез? – 잘 지내세요? («Как вы?»), Рәхмәт сезгә! – 감사합니다! («Спасибо!»), Укытучы апа / абый – 선생님 («Учитель»).

В корейском языке еще имеется элемент противоположности в речевом этикете : вежливая речь (존댓말 – чунденмаль) и простая речь (반말 панмаль – невежливая речь), Они показывают социальные отношения, возраст и степень близости между собеседниками. 존댓말 вежливая речь употребляется при обращении к старшим, незнакомым людям и в официальной обстановке. Для неё характерны специальные грамматические окончания –요, –(으)세요, –(으)십니다, выражающие уважение, например: 안녕하세요? – «Здравствуйте?», 감사합니다! – «Спасибо!

Напротив, 반말 используется между близкими друзьями, ровесниками и младшими, отражая доверие и эмоциональную близость: 안녕? – «Привет?», 고마워! – «Спасибо!». 어디에 가? – куда идешь?

Использование 반말 (фамильярной речи) по отношению к старшему воспринимается как невежливость и нарушение конфуцианских норм общения [4, с. 34]. Аналогичное разграничение существует и в татарском языке, где различие между формальной и неформальной речью выражается не грамматически, а лексически – через выбор местоимений син («ты») и сез («Вы») и соответствующих вежливых форм [3, с. 46; 5, с. 14].

Система обращений в татарском языке подразделяются на официальные и уважительные, дружеские и повседневные, а также ласковые и эмоциональные формы [3].

Официальные и уважительные обращения употребляются в ситуациях официального и формального общения, а также при выражении почтения к адресату [3, с. 5]: – *Әфәнде* – «господин»; – *Ханым* – «госпожа»; – *Туташ* – «девушка», обращение к незамужней женщине; – *Хөрмәтле...* – «уважаемый...» (в письмах, публичных выступлениях); – *Кадерле...* – «дорогой...» (в дружеских и торжественных обращениях); – *Ватандашлар* – «граждане, сограждане» (официальное обращение); – *Хезмәттәшләр* – «коллеги, сотрудники».

Дружеские и повседневные обращения Ьспользуются в неформальной коммуникации, в кругу друзей, коллег или земляков [5]: – *Җәмәгать*! – «граждане», «ребята»; – *Дуслар*! – «друзья!»; – *Дустым* – «мой друг»; – *Иптәшләр*! – «товарищи»; – *Егетләр*! – «парни»; – *Кызлар*! – «девушки»; – *Якташлар*! – «земляки!».

Ласковые и эмоциональные обращения характерны для семейной или эмоциональной речи, выражают любовь, заботу и привязанность [3, 5]: – *Матурым* (минем)! – «красивая(ый) моя(мой)»; – *Кадерлем* (минем)! – «дорогая(ой) оя(мой)»; – *Җаным* (минем)! – «душа моя»; – *Бәгърем* (минем)! – «сердце моё»; – *Сөеклем* (минем)! – «любимая(ый)»; – Кояшым (минем)! – «солнышко моё» и.т.д

Официальные и уважительные обращения в корейском языке применяются в формальной, деловой и образовательной среде, а также при обращении к старшим [1, с. 4]: – 선생님 (сонсэнним) – «учитель», «господин»; – 사장님 (саджанним) – «директор»; – 회장님 (хвечханним) – «председатель»; – 교수님 (кёсунним) – «профессор»; – 아버님 / 어머님 – «уважаемый отец / мать»; в официальных письмах – 존경하는... – «уважаемый...»; – 친애하는... – «дорогой...» 귀화 – уважаемый

Дружеские и повседневные обращения в корейском языке используются среди знакомых, друзей и коллег [1, 4]: – 형, 누나, 오빠, 언니 – «старший брат/сестра» в зависимости от пола говорящего; – 동생 – «младший»; – 친구 – «друг» (ровесник); – 여러분! – «дорогие друзья!».

Ласковые и эмоциональные обращения типичны для семейной и романтической речи, отражают эмоциональную близость [1, 4]: – 자기야! – «дорогой/дорогая!»; – 여보! – «дорогой/дорогая!» (между супругами); – 우리 애기! – «наш малыш»; – 내 사랑! – «моя любовь»; – 귀염둥 и! – «милый/милая»; – 우리 엄마 / 우리 아빠 – «наша мама / наш папа»; – 손님 – гость. клиент». 형님 (хённим) – уважительное обращение к старшему брату или к мужчине, который старше по положению. Но теперь в современном корейском мире в силу европеизации в медицинских учреждениях обращаются по имени в конце добавляя суффикс – 님. Используется мужчинами, чтобы подчеркнуть почтение и дружескую близость. Суффикс –님 добавляет высокий уровень уважения (по сравнению с просто 형 – страший брат).

Аналогом в татарской культуре может считаться обращение «абый» («старший брат») или «абый әфәнде» в особо почтительной форме [1, с. 4]. Хочется рассмотреть еще одно обращениеу корейцев 형님 – (хённим ). Оно может быть использовано в отношении старшей сестры мужа или Онни. А также уважительное обращение к жене старшего брата 형수님 (хёнсуним, используют это обращение мужчины). Можно сравнить с татарским обращением «абыйның хатыны» («жена старшего брата») или с употреблением апа («старшая сестра») в широком уважительном смысле [3, с. 5]. Указывает не только на семейные связи, но и на иерархическую вежливость внутри семьи.

В татарском языке, как и в корейском, существуют обращения, которые могут восприниматься как невежливые или фамильярные, если они употреблены в неподходящей ситуации. Однако, в отличие от корейской системы, где грубость чаще всего выражается грамматически – через формы типа 야 (эй), 너 (ты) и отсутствие окончаний вежливости, – в татарской речи невежливость передаётся лексически и интонационно, через выбор слов, эмоциональные оттенки и контекст [3, с. 47; 5, с. 15].

Фамильярность в татарском языке может проявляться в упрощении обращения или в употреблении нейтральных слов без вежливого контекста. Например, форма син допустима между равными по возрасту, но при обращении к старшему она воспринимается как нарушение речевого этикета. Фраза эй син! («эй ты!») может звучать резко в зависимости от интонации.

В разговорной речи встречаются и просторечные, уничижительные формы: җүләр, тиле («глупый», «сумасшедший»), а также заимствованные ахмак и дурак. В зависимости от

ситуации и тона эти слова могут использоваться шутливо между близкими людьми или иметь явно оскорбительный характер.

Для татарской речи особенно характерна интонационная грубость: повышение голоса, резкое ударение или приказной тон воспринимаются как невежливость даже без употребления грубых слов. Это отличает татарский язык от корейского, где грубость фиксируется морфологически, то есть на уровне грамматической формы (Кис сонг Хун, 2015, с. 30;).

Таким образом, татарский язык также имеет формы грубых и фамильярных обращений, но их выражение происходит преимущественно на лексическом и интонационном уровне, тогда как в корейском языке невежливость структурно закреплена в грамматике. В обеих культурах использование грубых форм оценивается отрицательно, так как противоречит основным принципам уважения, субординации и социальной гармонии. Так, в корейском языке система обращений имеет не только лексическую, но и морфологическую основу, отражающую многоуровневую систему вежливости. Она закрепляет в языке традиционные ценности конфуцианского общества: почтение к старшим, коллективизм и гармонию в человеческих отношениях

**Список литературы**

1. 김성훈 Ким Сонг Хун. 한국어 경어법 연구 [Исследование корейской системы вежливости]. – 서울 [Сеул]: 한국문화사, 2015. – С. 21–29.

2. Brown P., Levinson S. Politeness: Some Universals in Language Usage. – Cambridge: Cambridge University Press, 1987. – pp. 55–60.

3. Хакимова Ф. Ф. Этикет татарской речи. – Казань: Таткнигоиздат, 2003. – С. 45–48.

4. Ким Ын Чжон. Коммуникативные особенности корейского этикета // Вестник КФУ, 2018. – № 3. – С. 33–38.

5. Набиуллина Р. М. Лингвокультурные особенности татарского речевого поведения. – Казань: КФУ, 2016. – с. 12–16.

6. Шайхиева Г.М. Коммуникативно-прагматические особенности обращений в татарском речевом этикете // Филология и культура. – 2013. – № 1 (31). – С. 114–119.

7. Основные особенности обращений в английскойи русской коммуникативных культурах // URL:http: // www.culttoday.ru/cultstorys-71-1.html (дата обращения 03.03.2013)

8. Савойская Н.П. Лингвокультурологические особенности концепта «вежливость»: На материале казахского, русского и английского языков // URL: http://www.dissercat.com/.../lingvokulturologicheskie-osobennosti-kontsep (дата обращения 29.10.2025)

9. Алимжанова Г.М. Сопоставительная лингвокультурология// URL: http: gendocs.ru/v25157/алимжанова_г.м._сопоставительная_...1.doc (дата обращения 29.10.2025).

10. Ромазанова О.В. Коммуникативно-прагматические аспекты обращения в разноструктурных языках: на материале английского и татарского языков: дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2007. – 200 с.

© Ибрагимова А.Н., 2025

УДК 821.512.145

**Идрисова Э.М.,**
*магистрант 3 г.о. Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Фазлутдинов И.К.,**
*доцент татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮДӘ МАТУР ӘДӘБИЯТ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ

***Аннотация***. *Матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру башлангыч сыйныф укучыларының сөйләмен үстерә, баета, тулыландыра, сөйләмне формалаштыруга һәм камилләштерүгә ярдәм итә.*

***Терәк сүзләр:*** *башлангыч сыйныфлар, мәгариф системасы, татар теле, китап, яңа социаль һәм икътисади шартлар, акыл тәрбиясе.*

Безнең тормышыбыз гел үзгәреп тора, алга бара, гел яңарышта. Яңа иҗтимагый һәм икътисадый шартлар мәгариф системасында үзгәртеп коруга китерде. Бүген белем бирү учреждениеләрендә эшләүче татар теле укытучылары алдында торган бурычларны иң мөһиме – рус телле балаларга татар телен, татар телле балаларга рус телен өйрәтү, аларны халкыбызның тарихы, гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре, мәдәнияте белән таныштыру да бик мөһим [1, 16 б].

Белем бирү системасына куйган төп бурыч – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү. Бөек совет педагогы А.С. Макаренко: «Балаларны дөрес итеп тәрбияләү – безнең бәхетле картлыгыбыз, начар тәрбияләү – киләчәктәге кайгыбыз, күз яшебез, башка кешеләр һәм бөтен ил алдында гаебебез», дигән [2, 28 б.]. Димәк, балаларның нинди булып үсүе, барыннан да бигрәк, аларны ничек тәрбияләвебездән тора. Безнең бүгенге тормышыбыз фән һәм техника прогрессы белән тыгыз бәйләнештә тора һәм алар кеше тормышының бөтен өлкәләренә дә үтеп кергән. Баланы өйдә, бакчада, урамда электрон дөнья әйләндереп алган. Хәзер балалар тәпи китү, сөйләшә башлауга караганда пульт, телефон, компьютер төймәләренә басарга иртәрәк өйрәнәләр дисәк тә, ялгыш булмастыр. Без матур әдәбият, китап уку икенче пландарак калган тормышта яшибез дисәм дә була, чөнки бүгенге көндә китапханәгә барып китап алучы, өйгә вакытлы матбугат әсәрләрен яздыручы гаиләләр саны кимегәннән-кими бара.

Аларга алмашка электрон китап-журналлар килә. Балаларга әкият, шигырьләр укучы ата-аналар һәм гаиләләр саны да кимегәннән-кими бара. Балалар аралашуга мохтаҗлык кичерә башларга мөмкин дигән фикерләр дә яңгырый. Бала дөрес итеп сөйләшкәндә генә, әдәби тел нормаларын сөйләмдә кулланганда һәм сөйләмендә эзлеклелек булганда гына аның зиһене, логик фикерләү сәләте, игътибары, танып белү эшчәнлеге үсә. Әлбәттә, сөйләм үстерүне матур әдәбияттан башка күз алдына да китереп булмый. К.В. Закирова, Р.Х. Ягафарова, С.Г. Вагыйзов, Н.С. Карпинская үз хезмәтләрендә әдәби әсәрләр баланың рухи үсүендә һәм сөйләме камилләшүендә төп роль уйнавына басым ясыйлар [1, 33 б.]. Матур әдәбият әсәрләре мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен әйләнә-тирә дөнья, табигать, кешеләр тормышы турында тулы мәгълүмат бирә. Әдәби әсәрләр балаларның танып-белү сәләтен үстерә, бала үз фикерен әйтә белергә өйрәнә, сүз байлыгы үсә, ә сөйләм эчтәлекле, бай була бара.

Акыл тәрбиясе бирүдә дә матур әдәбият әсәрләренең роле зур. Әдәби әсәрне тыңлаганда балалар эзлеклелеккә, эчтәлеккә игътибар итәләр, әдәби образларга анализ бирәләр, ә аннан соң эчтәлек турында үз фикерләрен әйтәләр.

Әхлак тәрбиясе бирүдә дә әдәби әсәрләр зур роль уйный. Әсәрләрне тыңлап, балалар уңай һәм тискәре сыйфатларны аерырга өйрәнәләр, матурлыкка, изге эшләргә сокланалар, усаллыкка нәфрәтләнәләр. Шул рәвешле, балаларда уңай образлар аша уңай сыйфатлар тәрбияләнә.

Яңа укыту-методик комплектың сөйләм үстерү бүлегендә балаларга ана теле өйрәткәндә кулланыла торган матур әдәбият әсәрләренең исемлеге бирелгән. Шул комплектка нигезләнеп махсус чыгарылган әдәби әсәрләр җыентыгы «Балачак аланы» – «На поляне детства» бик отышлы методик кулланма дип саныйм. Бу кулланмага әдәби әсәрләр балаларның яшь үзенчәлекләре буенча тупланып, һәр төркем өчен аерып күрсәтелгән [1, 48 б.]. Җыентыкта тупланган әдәби әсәрләр шөгыльләр өчен генә түгел, ә бала бакчага килгәннән кайтып киткәнче кулланырга мөмкин булган материал тупланган. Әсәрләр уку, сөйләү һәм яттан өйрәнү максатыннан күрсәтелгән. Балаларны әдәби әсәрләр белән таныштыруда иң киң кулланыла торган ысул – тәрбияченең әсәрне укуы. Укыганда тәрбияченең әсәргә мөнәсәбәте балалар үрнәк булып тора. Әгәр әсәр зур күләмле булса, аны тәрбияче укый, әгәр күләме зур булмаса, укытучы аны яттан сөйләргә мөмкин. Икенче ысул – сөйләү, ягъни текстның эчтәлеген сөйләп бирү, текстны кыскарту. Гадәттә, әкиятләр, шигырьләр сөйләнелә. Кыска шигырьләрне яттан сөйләү файдалырак. Бу өченче ысул булып тора. Ничек кенә булмасын, балаларга иң якын һәм алар ярата торганы– әкиятләр. Әкиятләр бала туганнан алып соңгы кадәр озатып баручы әдәби әсәр ул. Әкиятләр баланың сөйләмен үстерүдә иңбай, мөһим элементларның берсе булып тора. Алар үзләренең гадилеге, герой сүзләренең билгеле бер тәртиптә кабатланып баруы белән сабый күңеленә бик тиз үтеп керә һәм әдәби әсәр белән танышу процессын җанлы һәм кызыклы итә: «Мин ак калач, ак калач», «Бер, ике, өч, дүрт, биш – тарталар, тартып чыгара алмыйлар» һ.б. мондый кабатланулар балаларның телен шомартырга, әкиятнең өзекләрен үзлектән сөйләргә теләү теләге уятырга ярдәм итә [2, 55 б.]. Мин үз эшемдә әкиятләрне сөйләм үстерү максатыннан төрлечә кулланам: башта аудиоязмаларда тыңлыйбыз, булганнарын интерактив тактада карыйбыз, сәхнәләштерәбез. Шулай ук «Бу нинди әкияттән?» дидактик уенын да отышлы дип саныйм. Башлангыч сыйныф укучылары әкияттән өзек карыйлар яисә тыңлыйлар һәм әкиятнең исемен атыйлар, өзекне сөйлиләр. Еш кына алар үзләре дә әкиятләрне үзләренчә дәвам итә яки яңа әкиятләр иҗат итә алалар.

Балалар иҗатын һәрвакыт хупларга, иҗатларын һәрьяклап үстерүдә ярдәм итәргә кирәк. Бу алымнар балаларның сөйләм телләрен үстерүгә зур этәргеч ясый. Шулай ук соңыннан әкиятне яисә видеосюжетны тавышсыз карау да бик уңышлы. Алар әкиятне үзләре сюжетка нигезләнеп сөйлиләр.

Әдәби әсәрләрне укыганда күрсәтмәлелек чаралары: рәсемнәр, уенчыклар, слайдлар һ.б. куллану бик тә мөһим. Бу геройларның кичерешләрен аңларга ярдәм итә. Әсәрне искә төшерү максатыннан өйрәнелгән таныш әсәр буенча башлангыч сыйныф укучылары белән дидактик уен оештырырга мөмкин. Уен барышында аралашу аларның сөйләмен активлаштыра, үз фикерләрен дәлилләү сәләтен үстерә [1, 39 б.].

Үтемле алымнарның берсе булып әсәрнең аерым урыннарын (балаларга аеруча ошаган һ.б.) сайлап алып уку тора, бу алым уен ярдәмендә, викторина рәвешендә үткәрелергә мөмкин.

Кайбер очракларда мәктәпкәчә яшьтәге балаларга әсәрдәге сүзләр аңлашылмый, бу очракта ул сүзләр балаларга аңлатыла. Ләкин уку барышында аерым сүзне аңлату өчен бүленергә ярамый. Чөнки бу – баланың текстны аңлау сәләтен киметә, фикерен чуалта.

Киң кулланыла торган алымнарның берсе – иллюстрацияләр куллану. Иллюстрация – әсәр эчтәлеген аңлатып бирүче рәсем. Иллюстрацияләрне әсәрне уку барышында һәм укып бетергәч куллану да отышлы була дип саныйм.

Икенча алым – әсәр буенча әңгәмә. Бу комплекслы алым – күрсәтү һәм сүз алымнары. Әдәби әсәр буенча эшне түбәндәгечә алып барырга мөмкин: әсәрне укыганнан соң, укучылар үз фикерләре белән уртаклашалар, укытучы дә әңгәмәдә катнаша, әсәрдән өзекләр китерә, ә аннан соң әсәрне кабат укый. Укучылар белән бергә әсәргә карата ясалган рәсемнәр карый.

Катлаулы эчтәлекле әсәрләр өчен сорау бирү алымы куллану отышлырак була дип уйлыйм: Уйлап карагыз әле, сезнең кем турында сөйләшәсегез килә һәм ни өчен? (Төп геройны табу h.б.).

Мондый сорау алымы фикерләүне киңәйтә һәм тирәнәйтә. Матур әдбият белән таныштыруда мультимедиа чараларын да бик актив кулланыла. Әсәрне аудиоязмадан тыңлау, шулай ук яңа укыту-методик комплектына нигезләнеп эшләнгән видеосюжетлар, мультфильмнар карау да бик отышлы. Алар баланың кызыксынуын тагын да арттыра, сүзлек запасын баетуга һәм сөйләм телен үстерергә ярдәм итә дип уйлыйм.

Матур әдбият әсәрләре белән таныштыру эшчәнлекләре башлангыч сыйныф укучылары сөйләмен үстерә, баета, аны тагын да тулыландыра, сөйләмне формалаштырырга һәм камилләштерергә ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият**


1. Кашапова М.Ф. Иң гүзәл тел – туган тел. – Казан: РИЦ «Школа», 2019.
2. Закирова К.В. Балачак аланы. – Казан: РИЦ, 2021.
3. Халык авыз иҗаты әсәрләренең сөйләм телен үстерүдәге әһәмияте URL: http://sabyem.ru/?p=9692


© Идрисова Э.М., 2025

УДК 811.512.145

**Ислакаева А.С.,**
*студент 3 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Зарипова И.Ф.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры,*
*г. Уфа, Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ МӨНӘСӘБӘТ ФИГЫЛЬЛӘРЕНЕҢ МӘГЪНӘВИ ҺӘМ БЕЛДЕРЕЛЕШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация.*** *Мөнәсәбәт фигыльләренең семантик үзенчәлекләре татар телендә катлаулы һәм күпкырлы тикшеренү өлкәсен тәшкил итә. Мәкаләдә әлеге типтагы фигыльләрнең мәгънәләрен формалаштыручы семантик компонентлар, шулай ук фигыльләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре анализлана. Текстның бөтенлеген формалаштыруда мөнәсәбәт фигыльләре мәгънәсенең контекстуаль шартлылыгына һәм аларның текстның бөтенлеген формалаштырудагы роленә аерым игътибар бирелә. Тикшеренү әдәби текстлар материалында алып барыла, бу мөнәсәбәт фигыльләрен куллануда һәм аларның функциональ йөкләнешендә актуаль тенденцияләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, морфология, фигыль, мөнәсәбәт фигыльләре, семантика*

Тел җәмгыять яшәеше белән тыгыз бәйләнгән. Телдә кеше эшчәнлегенең төрле яклары һәм эш вакытында аның җәмгыять, табигать, әйләнә-тирә белән күп төрле мөнәсәбәтләре чагылыш таба. Кеше, сөйләүче телдәге грамматик категорияләрнең дә үзәгендә тора. Чынбарлыкта, гомумән алганда, кеше эшчәнлеге һәм мөнәсәбәтләр өлкәсендәге аерым хәлләр, гамәлләр арасындагы бәйләнешләрне белдерү өчен телдә бик бай чаралар тупланган. Алар арасында иң беренче урында фигыльләр тора.

Фигыль – хәрәкәт, халәт яки процессны атаучы һәм бу мәгънәне төрле грамматик категорияләрдә белдерүче мөстәкыйль сүз төркеме. «Фигыльләрнең семантикасының катлаулылыгы аларны классификацияләүне кыенлаштыра, чөнки аларның һәр төркеме эчендәге аерым фигыльләр арасындагы мәгънәви бәйләнешләрнең характерын исәпкә алудан

чыгып эш итәргә тиеш. Төркемгә берләшү исә, гомумиләштерүдән гыйбарәт булып, бердәм семантик билге нигезендә гамәлгә ашырыла» [2, 37–38 б.].

Фигыль лексикасын мәгънәсе буенча төркемләү шактый катлаулы эш, чөнки фигыльнең мәгънәсе үтә гомуми, үтә киң, һәм аның нигезендә объектлар арасындагы мөнәсәбәт ята [4, 30]. Шулай булуга карамастан, фигыльләр сүз буларак өйрәнелергә тиеш, чөнки шунсыз фигыльдәге категорияләрнең мәгънәсен һәм функциясен бөтен тулылыгы һәм тирәнлеге белән аңлап булмый [5, 35 б.].

Төрки телләрдә фигыльнең мәгънә төркемчәләрен башлап өйрәнүче Н. Дмитриев була. Ул төрек, татар, башкорт һәм кайбер башка төрки телләрдәге сөйләү, фикерләү, эш һәм хәрәкәт фигыльләренең төп лексик берәмлекләрен тикшерә. 1967 елда басылып чыккан «Историческое развитие лексики тюркских языков» китабында Ә. Тенишевның «Төрки телләрдә хәрәкәт фигыльләре», Ә. Юлдашевның «Хис белән кабул итүне белдерүче фигыльләр», Н. Гаджиева һәм А. Кокляннованың «Сөйләм фигыльләре» дигән хезмәтләре урын ала. Хәрәкәт фигыльләрен төрек теле материалында В. Вещилова (1962), үзбәк телендә К. Халиков (1967), чуваш телендә Т. Васильева (1980), татар телендә Р. Лизунова (1991) өйрәнә; шулай ук кайбер хезмәтләрдә төрки телләрдәге хәрәкәт фигыльләре рус теленеке белән чагыштырып тикшерелә. Татар телендә фигыльләрне мәгънәләре буенча төркемнәргә аеру мәсьәләсендә беренче тәҗрибә Ф. Ганиев тарафыннан ясала: фигыльләр 11 тематик төркемчәгә аерыла: хәрәкәт, эш, процесс, хәл, мөнәсәбәт, үз-үзеңне тоту, яңгыраш, сөйләм, фикерләү, сиземләү һәм образ ияртемнәренә нигезләнеп ясалган фигыльләр, һәр төркемчәгә мисаллар китерелә [8, 94 б.].

Фигыльне өйрәнү рус тел белемендә бик нык үсеш ала. Бу проблема буенча Екатеринбург (Э. Кузнецова) һәм Уфада (Л. Васильев, Т. Килдебәкова, Р. Гайсина) ике үзәк барлыкка килә. Рус һәм татар телендәге фигыльләр мәгънә күләме белән, чынбарлыкның кайбер мөнәсәбәтләрен фигыль белән атау, кайберләрен грамматик форма белән белдерү ягыннан шактый аерылсалар да, рус тел белемендә тупланган тәҗрибәне исәпкә алмыйча мөмкин түгел [3, 127]. Мәсәлән, Л. Васильев фигыльләрне тикшергән һәм төркемләгән вакытта аларның функциональ тәңгәлләрен – фразеологик берәмлекләрне, перифразаларны да исәпкә ала. Татар телендә исә алар читтә кала. Ф. Ганиев фигыльләрнең 11 төркемчәсен аерып чыгара: фикерләү фигыльләрен, сөйләм фигыльләрен эш, хәл-торыш, сиземләү һ.б. фигыльләр белән беррәттән карый, Л. Васильев исә фикерләү фигыльләрен, Г. Кулиев сөйләм фигыльләрен – психик эшчәнлекне белдерүчеләр төркеменә кертәләр. Шунысын да әйтергә кирәк: фигыльнең семантик төркемчәләре үзара кисешәләр, һәм галимнәр моңа игътибар да итә [8, 95 б.]. Димәк, фигыльләрне төркемләүнең күптөрле кыенлыкларыннан берсе – бер үк фигыльнең мәгънә киңлеге аркасында төрле төркем һәм төркемчәгә керә алуы.

Татар телендә соңгы вакытта фигыльләрне, төп мәгънәләреннән чыгып, ике зур төркемгә – эш-гамәл һәм хәл-торыш фигыльләренә аералар. Өченче төркем итеп кешенең тормышында, бөтен эшчәнлегендә зур урын тоткан мөнәсәбәтләрне белдерүче фигыльләр аерыла.

Шәхесләр арасындагы мөнәсәбәтләр дип кешеләр арасында субъектив рәвештә кичерелгән үзара бәйләнешләр аңлатыла, алар бергәләп эш итү һәм аралашу процессында кешеләрнең бер-берсенә тәэсир итү характерында һәм ысулларында объектив рәвештә чагылыш таба. Мөнәсәбәтләр эмоцияләргә (хисләргә), бер кешенең шәхси сыйфатлары буенча башкаларны бәяләүгә нигезләнгән, шуңа күрә мөнәсәбәт фигыльләренең лексик-семантик төркемнәре нигездә эмоциональ-бәяләү мөнәсәбәтләре һәм аның тышкы чагылышы фигыльләрен тәшкил итә [6, 101 б.].

Татар телендә мөнәсәбәт белдерүче фигыльләрне берничә төркемгә бүлергә мөмкин:

1) Мөнәсәбәтләрнең эмоциональ чагылышын белдерүче фигыльләр:

а) уңай эмоцияләрне белдерүче фигыльләр: *аркалану, бирелү, зурлау, агалау, аллалаштыру* һ. б. *Кешегә аркаланып укыдың, кешегә аркаланып эшкә урнаштың да бит, эшли башлагач ни кылырсың икән соң син?* В. Нуруллин. *Үз агасын агаламаган кеше агасын сагалар. Мәкаль*

б) кире эмоцияләрне белдерүче фигыльләр: *ачулану, битарафлашу, боргычлау, газаплау* һ.б. *Хатыннарның берсе төкерекләрен чәчә-чәчә ачулана.* З. Хөснияр. *Ник газаплыйлар болай күкләр мине гомрем буе?* Һ. Такташ.

2) Мөнәсәбәтләрнең тышкы чагылышын белдерүче фигыльләр:

а) уңай мөнәсәбәтне белдерүче фигыльләр: *алкышлау, бәпләү, булышу, бәхилләшү* һ.б. *Әнә тамак кырып куйды һәм, алай да җавап ала алмагач, Гөлйөземнең аркасыннан бәпләп, сөйләнә-сөйләнә, үзенчә уятырга кереште.* Ф. Латыйпов. *Әгәр кеше кечкенәдән уйнап үскән, бергә укыган, эшләгән, яшәгән, бәхилләшкән дусларын, якыннарын һәм туганнарын, яңадан исән-имин җыеп, зур очрашу оештыра алса, аның бөтен биографиясе, энәсеннән җебенә чаклы, югалмыйча, әйләнеп кайтыр иде.* К. Кәримов.

б) кире мөнәсәбәтне белдерүче фигыльләр: *агулау, бозыштыру, богаулау, гаепләү* һ.б. *Эфир зарлана, шыңшый, кешеләрнең яшәвен агулый.* М. Юныс. *Җамалый агай, Галимә абыстай, сез картлар, --- сез, бәлки, ачуланырсыз да, гаепләрсез дә ---.* Һ. Такташ.

3) Контакт белдерүче фигыльләр:

а) контакт урнаштыруны белдерүче фигыльләр: *танышу, белешләнү, белешү* һ. б. *Әптерәшит белән дә белешләнсәң, бик күңелле булыр, бер дә эчеңне тишмәс.* Г.Камал. *Ярым сәгатьтән соң мин, хәлен белешеп китмәкче булып, әби янына килдем.* Ф. Әмирхан.

б) контактны өзүне белдерүче фигыльләр: *бозылышу, дошманлашу, бәхилләшү, ераклашу* һ.б. *Ни эшкә шаулаштыгыз, ни эшкә бозылыштыгыз, әллә берәр хәл булганмы?* Г. Камал. *Тик менә бәхетле булып киткән балалары аңардан, ничектер, шактый ераклаштылар шикелле.* Ә. Еники.

в) бәйләнеш тотуны белдерүче фигыльләр: *белү, алышу, аңлашу, берегү, вәгъдәләшү* һ.б. *Янәшәсендә биш кызы яшәсә дә, буш кул белән карчыкның хәлен белеп чыгудан ары узмыйлар.* Ф. Җамалетдинова. *Шул арада, бер-берсенә генә ишетелерлек, өзек-өзек шыпырт кына тавыш белән, вәгъдәләшә иделәр.* Ш. Камал.

4) Социаль мөнәсәбәтләрне белдерүче фигыльләр: *аралау, баглану, басу, бердәмләшү, буйсыну* һ.б. *Югары Авыл, Сазтамакларның һәрберсендә үз советлары бар иде. Алар сиңа [Кариле авылы советына] буйсынмый иде.* Э. Касыймов. *Кинәт дошман килеп басты, Хәйран калды бөдрә тал.* Ә. Ерикәй.

5) Кешенең әйберләргә һәм пространствога мөнәсәбәтен белдерүче фигыльләр: *бетерү, биләү, бирү, ваксыну* һ.б. *Фашизмны бетерергә булышыйк, иптәшләр, Булышыйк, иптәшләр!* Г. Гобәй. *Мәйдан ачылды яңа көчләргә: Кызыл байракны Бердәм кулга алып, Җирне биләргә...* М. Гафури.

В.В. Виноградов үзенең «Грамматическое учение о слове» дигән хезмәтендә фигыль турында болай дип язган: «фигыль – хәзерге телнең иң катлаулы семантик категориясе» [1, 131 б.]. Фигыльнең грамматик катлаулылыгы грамматик категорияләрнең шактый күптөрлелеге белән билгеләнә, ә семантик сыйдырышлылыкны үлчәү авыр, чөнки фигыльнең лексик мәгънәсе күп үлчәмле һәм катлаулы система буларак күрсәтелә.

Бу фигыльләрнең телдә ничек «эшләвен» чын-чынлап аңлау өчен, аларның белдерелешен ачыкларга кирәк. Мөнәсәбәтне белдерү өчен туры мәгънәдә кулланыла торган фигыльләр белән (*хөрмәтләү, зурлау, күралмау, ярату, кызгану, боргычлау, дошманлашу)* бергә башка семантик төркемнәргә караган фигыльләрнең күчерелмә мәгънәләре *(асрау, атылу, асылыну, бәяләү, исерү)* дә очрый. Аларның бу мәгънәләре контекстта гына ачыла. Мәсәлән:

**Аяклану** *ф. күч.* Кемгә яки нәрсәгә карата булса да каршы чыгыш ясау, кирелек эшләү, баш күтәрү. *[Габдулла] Бүген үз чорының алдынгы кешесе икәнен күрсәтте. Традициягә каршы аякланды бит ул бүген.* Ә. Фәйзи

**Егылу** *ф. күч.* Көнләшү, кызыгу; кемнеңдер уңышына эч пошу. *Иренең култыгы астында «Ядерная физика» китабы күреп егылсыннар.* А. Гыйләҗев

**Зәһәрләнү** *ф. күч.* Нык ачулану, эчтә, күңелдә ачу кайнау, шул ачудан үрсәләнү, ни эшләргә белмәү. *«Барыбер котелогыңны ватам мин синең, иптәш директор!» – дип*

*зәһәрләнсә, бернигә дә исе китмәскә өйрәтелгән кеше дә тынычсызлана,* --- *борчыла икән.* Т. Галиуллин

**Асрау** *ф. күч.* Нинди дә булса хис, уйларны саклау, хәтерендә тоту. *Ул үзе дә, кайчандыр, күңелендә Булатка каршы бер дулкын асрый иде.* Г. Ибраһимов.

Шулай ук мөнәсәбәтне белдерүдә *хәлгә керү, эче ертылу, җанга яту, җене белән бер күрү, баганага сөяү, эт кадәр дә күрмәү, кул бирү* һ.б. кебек фразеологик әйтемнәр дә кулланылырга мөмкин.

Шулай итеп, туры мәгънәдәге мөнәсәбәт фигыльләре кешеләр арасындагы конкрет гамәлләрне һәм үзара бәйләнешләрне билгеләү өчен нигез булып тора. Фигыльләрнең күчерелмә мәгънәләре аларны куллану даирәсен киңәйтә, абстракт төшенчәләрне һәм процессларны метафорик рәвештә тасвирларга мөмкинлек бирә. Фразеологизмнар да мөнәсәбәтләрне белдерү өчен тотрыклы, экспрессив формулалар булып торалар, еш кына алар эш-хәлне генә түгел, ә аның бәясен дә тапшыралар. Димәк, мөнәсәбәт фигыльләрен барлаганда, туры мәгънәле фигыльләр белән генә чикләнергә ярамый, чөнки башка семантик төркемнәргә караган фигыльләрнең дә күчерелмә мәгънәләре мөнәсәбәт белдерергә мөмкин.

**Кулланылган әдәбият**

1. Виноградов В. В. Русский язык. Грамматическое учение о слове: учеб. пособие. – 2-е изд. – М., 1972. – 720 с.

2. Дрозд А. Ф. Семантические классы глаголов – производящих баз имен деятеля в современном английском языке // Актуальные вопросы филологии, педагогики и методики преподавания иностранных языков». – 2013. – № 1. – С. 35–45.

3. Зарипова И.Ф. Семантическая и синтаксическая сочетаемость слов в татарском языке (на материале глаголов мышления // Актуальные проблемы современной татарской филологии. Сборник статей Всероссийской научно-практической конференции, посвященной 95-летию со дня рождения известного языковеда, тюрколога, доктора филологических наук, профессора, первого заведующего кафедрой татарской филологии Башкирского государственного университета Габдулхая Хурамовича Ахатова (1927 - 1986). – Уфа, 2022. – Б. 126–131.

4. Зарипова И.Ф. Хәзерге татар телендә хәрәкәт фигыльләренең лексик-семантик бәйләнешләре // Филологические науки: состояние, перспективы, новые парадигмы исследований: материалы V Международной научной конференции. – Уфа, 2022. – Б. 29–34.

5. Зарипова И.Ф. Хәрәкәт фигыльләре: өйрәнелү дәрәҗәсе, валентлыгы һәм актантлары мәсьәләсе // Филологические науки: состояние, перспективы, новые парадигмы исследований: материалы V Международной научной конференции. – Уфа, 2022. – Б. 35–45.

6. Ислакаева А.С., Зарипова И.Ф. Татар телендә мөнәсәбәт белдерүче фигыльләрнең лексик-семантик үзенчәлекләре // Актуальные проблемы теоретической и прикладной филологии: Материалы XIII Международной научной конференции. – Уфа, 2025. – Б. 100–106.

7. Кильдибекова Т.А. Глаголы действия в современном русском языке. Опыт функционально-семантического анализа. – Саратов: Изд-во Сарат. ун-та, 1985. – 157 с.

8. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2016 – Т. II. – 432 б.

© Ислакаева А.С., 2025

УДК 811.512.145

**Исмагилова А.В.,**
*студент 4 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель* – **Сагидуллина Л.Р.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*
\

# «СҮЗ» КОНЦЕПТЫН БЕЛДЕРҮЧЕ ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКНЕҢ ЭЧКЕ ФОРМАСЫН АЧУ ЮЛЛАРЫ

***Аннотация.*** *Әлеге мәкалә «сүз» концептын аның этимологиясе һәм мифологиядәге роле призмасы аша анализлауга багышлана.*
***Төрәк сүзләр:*** *лингкокультурология, татар теле, концепт, сүз, этимология, миф*

Хәзерге заман фәне турында сүз алып барганда, аның үсеш юнәлешенә йогынты ясый торган конкрет күренешләр турында әйтми үтүе мөмкин түгел. Соңгы вакытларда телне логик анализлау тенденциясе көчәеп китте. Ул фәнни теорияләр һәм гадәти аң өчен уртак булган лингвистик, логик, культурологик төшенчәләрне тикшерүне күз алдында тота. Телне логик анализлау нәтиҗәләренең берсе телдә гәүдәләнеш тапкан дөньяга караш төшенчәләренең семантик модельләрен алдан ук билгеләп куя. Телнең минималь мәгънә берәмлеге булып сүз тора. Шул сәбәпле, тел белемендә иң төп урынны да сүз һәм «сүз» концепты алып торырга тиеш дигән уйга киләбез.

Сүз – ул бары тик авазлар яки хәрефләр җыелмасы гына түгел. Ул – безнең тарихыбыз, мәдәниятебез, дөньяга карашыбызның көзгесе. Ул – безне берләштерүче, аңлашуны тәэмин итүче төп коралыбыз. Тел фәне үсеше белән беррәттән сүзләрнең килеп чыгышы, ягъни этимологиясе әһәмиятле тикшеренү объектына әверелде. «Сүз» концепты телнең төп структурасы буларак мәгънә һәм фикер җиткерүнең нигезе булып тора. Бу мәкаләдә без «сүз» лексемасының татар телендә этимологик чыганакларын, аның мәгънә үсешен һәм концептуаль аспектларын күзәтербез.

Хәзерге лингвистика өчен телгә аралашу һәм танып белү чарасы итеп кенә түгел, ә милләтнең мәдәни коды буларак карау һәм яңа юнәлештәге тикшеренүләр, фәнни мәктәпләр оешуы күзәтелә. Боларның берсе лингвокультурология термины белән билгеләнә. Лингвокультурология XX гасырның соңгы чирегендә, тел белемендә антропологик парадигма җимеше буларак барлыкка килә.

Телне мәдәният феномены буларак өйрәнү тел берәмлекләренең, аеруча сүзнең, милли мәдәни компонентына кызыксыну тудыра. Сүз, халыкның күмәкләп тупланган хәтере буларак, сүзлек мәгънәсе белән генә чикләнми, коннотацияләр, төрле милли-мәдәни аңламнар, мәгънәви һәм стилистик төсмерләрне үзенә сыйдыра. Сүзләрне когнитив лингвистикада, лигвокультурологиядә концепт рәвешендә тикшерү бүгенге көндә фәнни кулланылышка кертелгән юнәлеш [4, 5 б.].

В.Н. Телия фикеренчә, «Лингвокультурология – җәлеп итү үзәге булып мәдәният феномены торган кеше турында фәннең антропологик парадигмасы байлыгы» [2, 122 б.]. Лингвокультурологиянең бурычларына тел, мәдәният, этнос һәм халык менталитеты мөнәсәбәтләрен өйрәнү һәм тасвирлау керә [3, 28 б.].

Лингкокультурология фәненең төп терминнарының берсе булып «концепт» билгеләнә. Концепт – ул үзенең структурасы буенча кешенең үз төшенчәсеннән һәм аның турында кыйммәтле (күп очракта – образлы) күзаллаудан торган ниндидер күренеш [6, 40–43 б.].

М.В. Пименова фикеренчә, «Теге яки бу концептның тулы тасвирламасы аны күрсәтү чараларының иң тулы җыелмасын тикшергәндә генә мөмкин», чөнки «концепт аны объективлаштырып килүче тел билгеләрендә таралган» [2, 29 б.].

Бер үк концептны аның төрле лексик берәмлекләрдә реальләшү күзлегеннән анализларга мөмкин: аерым сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр; фразеологизмнар, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, әдәби текстлар һ.б. Әлеге фәнни тикшеренүдә «сүз» төшенчәсенең этимологиясе, тарихи үсеше аспектлары ягыннан коцептуаль үзенчәлекләре күзәтелә.

Татар телендә «сүз» концептын атаучы берәмлек – сүз. Татар телендә «сүз» төшенчәсе өч хәреф тышчасында яшәүче берәмлекне генә түгел, ә үз эчендә бик күп коннотацияләр булган мәгънә җыелмасын һәм, гомумән, сөйләмне дә аңлата. Бу татар мәдәниятендә сөйләмнең аерым әһәмиятенә һәм аралашуның иң мөһим чараларының берсе булып саналуга бәйле.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «сүз» берәмлегенең 11 төшенчәсе билгеләнгән [7]:

**Сүз** *и. 1) лингв. Предмет, күренеш, вакыйга, эш-хәлләр һ.б.ш.ларны белдерә торган, бер яки берничә аваздан торган иң кечкенә лексик берәмлек. 2) лингв. Сөйләмдә логик яки грамматик мөнәсәбәтләрне белдерә торган, мөстәкыйль фонетик үзлеккә ия лексик берәмлек. 3) Гыйбарә, әйтем. Борынгылар әйткән сүз. һ.б.*

Күрүебезчә, «сүз» татар телендә күпмәгънәле. Мәгънәләр бер-берсе белән бәйләнгән; һәрбер билгеләмәнең нигезендә «график билгеләрен, артикуляция аппаратын, вербаль тамгаларны кулланып, нинди дә булса уй фикер белән бүлешү» дигән мәгънә ята.

Шулай ук татар телендә «сүз»нең тамырдаш сүзләрен куллануы дә киң таралган (барлыгы 18 берәмлек): СҮЗЛӘП *рәв. Сүзләр рәвешендә; сүз итеп; һәр сүзне аерым-аерым әйтеп./* СҮЗЛӘШҮ *ф. 1) Каршы әйтү, әрепләшү. 2) Ызгышу, сүзгә килешү./* СҮЗЛЕ *с. 1) Телдә яңгыратылган, язылмаган. 2) сир. Күп сөйләшергә яратучан; сүзчән. 3) Гаугалы, тавышлы. 4) махс. Көе генә түгел, сүзләре, тексты да булган./* СҮЗЛЕК *и. 1) Сүзләрнең, тотрыклы сүзтезмәләрнең аңлатмаларын, мәгънәләрен, башка телгә тәрҗемәләрен һ.б.ш.ны җыеп, алфавит тәртибе белән яки бүтәнчә урнаштырып биргән белешмәлек, китап./* СЎЗЬЯСАГЫЧ *с. Сүз ясый торган, сүз ясау өчен хезмәт итә торган./* СЎЗЬЯСАЛЫШ *и. лингв. 1) Телнең сүз ясау чаралары нигезендә яңа сүзләр ясалышы.*

Күренә ки: «сүз» лексемасы татар телендә югары ешлыкка ия. Бу сүз икенче «миллилек» критериенә дә туры килә – ул актив җитештерүче нигезле (*сүзлек, сүзчән, сүзле* һ.б.). Бу күзәтүләр «сүз» концептын «телләштерүче» лексик берәмлекләрнең байлыгы, тамырларның тирәнлеге хакында сөйли.

Этимологик сүзлеккә мөрәҗәгать итеп, «сүз» тарихына күзәтү ясыйбыз [1, 184]. Р.Г. Әхмәтьянов фикеренчә, «сүз» гомум төрки телдән. **СҮЗ** «слово» < гом. төрки *сөз* (> алт., хак. *сөс*, себ. тат. *сөс* > *сус*, башк. *һүҙ*, як. *өс*) «сүз, сөйләм» < бор. *сөр «сөйләшү, гәп; әкият, мәзәк һ.б.ш.» (к. уйг. диал. *сөрчек*, төркм. *с!рчек* «әкият» > алт., төркм. *чөрчөк* id.), к. ш. ук чыгт. söz «рөхсәт; вәгъдә; хәлне аңлату» (Поппе 1938: 373; чаг. тат. *сүз бирү).* К. *Сөйлә-ү.* Будагов I: 645–646; ЭСТЯ VII: 315–316» [1, 184 б.].

Төрки телләрнең этимологиясен өйрәнүдә Э.В. Севортян сүзлеге зур әһәмияткә ия, чөнки ул төрки тел корылмалары һәм сүзләренең килеп чыгу юллары турында җентекле мәгълүмат бирә.

Э.В. Севортян сүзлегендә «сүз» сүзе төрки телләрендә киң таралган, аның тамыры «söz» дип билгеләнә.

**СӨЗ** турк., тур., гаг., аз., кар.к., кум., Сат. 61, бал. Шаум. 77, кир., каз., ккал., ног., уз., уз. диал. Реш. Кур. 235, Jarr.UDQ 52, уйг., уйг.диал. Мал.УНС 152, Мал.УЯ 179, Jarr. 278 (söz, súz, soz), Le Coq 92, лоб., сюг., сал. Kak. Voc. 190, Баск. Кум. 246, Р IV 585 (осм., крым., аз., чаг. вост.-тюрк., кар., тар., кир., ккир.), Буд. 1 645 (тур.), Zen. Il 525 (тур.), Pav.C. 355, ДТС 511, Мал. 422, Мал. ПМК 102, Ork. 100, An.In. 499, TT VIII 98, X 49, Caf. EUS 210, Lig.GS 191, Brock. 184, Diz. 106, Ateb. LVII, Бор.ЛТ 274, KW 224, Abú H. 93, Ettuh. 242, Из. дар 366, Tel. 323, Мел.АФ 097, Ibnü M. 63, Qutb 160, Хор.П. II 298, Надж. Мухабб. 192, Надж. ТЯДСТ 82, ЛН 157, Erg. 273, Har. 117, Çarh 3, Vám. CSpr. 297; соз' кар.т; sez, soz, söz халадж. Doerf. – Tez. 187; сос алт., Баск. Кум. 247, Баск. Туба 149, хак., хак. диал. Инк. 61, тув., ГАЯ 251, Верб. 306, Р IV 584 (уйг., алт., тел., леб., шор., саг., койб., кач.), Буд. I 645 (уйг., алт.); сез кар.г.; суз тат.,

уз.диал. Фарм. Таг. 348, Р IV 843 (казан.), Буд. I 645 (казан.); suz сал. Тен. ССЯ 490 (+ фон. варианты); сус лоб., Баск. Кум. 249, Ném.TS 197; ху баш.; соз кум. Мох. 84, кум.диал. Кер. 14, Грун. 405, Tryj. 695 (soz, soz), Hik. 41, Deny AC 70, Schütz 145; sus Ném.TS 197; suz, súz сал. Kak. Voc. 190; sus Ném.TS 197; ос як.

1. слово – во всех источниках; речь – турк., тур., гаг., аз., кар.к., кар.т., кум., кир., каз., ккал., ног., тат., баш., уз., уйг., уйг.диал.;/ 2. повествование – турк., уз., Наг.; рассказ – як.; фраза – ккал.; выражение – Qutb; текст – тув.;/ 3. разговор – турк., тур., кар.к., кум., кир., ккал., ног., тат., баш., уз., алт., возражение, аргумент – Zen.; совет – Баск. Кум.;/ 4. сведения – Ném.TS (sus); известие – як.; слухи, молва – тур., аз.; сплетня – а3.;/ 5. обещание – турк., тур., гаг., аз., ног., уз.,/ 6. право решать дело – кир.; суждение, мнение – уз.; мнение – як.;/ 7. изречение, афоризм – турк., аз., Zen.; пословица, поговорка – уйг.диал./ 8. учение – ГАЯ, Верб., Буд.; приказ – An.In., Caf. EUS;/ 10. уважение, почет – rar. [9, 365 б.].

«Сөз», генетик яктан «сөйле/ә» белән бәйле, *сө-* тамырына *-з* кушымчасы кушылып ярдәмендә барлыкка килгән; *сөз* нигезе киң таралыш табып башка фигыль һәм төшенчәләрдә очрый, дип билгели автор.

Э.В. Севортян сүзлеге мәгълүматына караганда, «сүз» сүзе төрле төрки диалектларда берничә мәгънәдә кулланылган. Ул гади генә аваз берәмлеге түгел, ә сөйләмнең, текстның лексик үзәген тәшкил итә. Мәсәлән, «сүз» – *сөйләм, ант, фикер*, хәтта *хөрмәт* дигән мәгънәдә дә очрый. Бу сүзлек мәгълүматлары буенча, «сүз» кайбер төрки телләрдә охшаш форма һәм мәгънә белән очрый: казах, үзбәк, тува телләрендә бу сүзнең төп функциясе һәм тамыры сакланган. Бу төрки телләрдә уртак этимологик чыганакның булуын раслый.

Э.В. Севортян сүзлегендәге материалны анализлаганда, «сүз» төшенчәсе төрки телләрнең төп лексик материалы буларак фикер әйтү, аралашу функцияләрен билгеләве ачык күренә. Этимологик яктан караганда, бу сүз тамыры төрки тел мәдәниятендә фикер алышуның төп берәмлеге булып формалашкан. «Сүз» – телле аралашуның нигезендә яткан, тарихи һәм лингвистик үсеш белән бәйле концепт.

Төрки телләрдә «сүз! белән !миф»ның үзара бәйләнеше – лингвистика, культурология һәм тел фәлсәфәсе тоташкан урында тикшеренүләрнең киң спектрын ача торган тема. Төрки халыклар аңында сүз аралашу чарасы булып кына тормый, кешене тарих, гореф-гадәтләр һәм табигать белән бәйләүче мифологик мәгънә йөртүче булып та кабул ителә.

Тел мифларны буыннар белән тапшыру коралы булып хезмәт итә, мәдәни тәңгәллекне саклап кала. Мифлар, үз чиратында, телне символика һәм образлар белән, дөнья турындагы күзаллаулар белән баета. Мәсәлән, татар һәм казах кебек төрки телләрдә без образлы әйтелмәләр һәм идиомаларның халык ышануларын һәм мифологик концепцияләрне ничек ассызыклавын күзәтә алабыз.

Мифның фикерләү ысулы белән кушылуы миф белән сүзнең бер-берсенә тыгыз үтеп керүе турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Сүз белән мифның барлыкка килүенең төгәл вакыты билгеле булмавы: «миф – сүздән ясалма, яки сүз – мифтан ясалма» – дигән гипотезага ике күзаллау бирә. Сүзнең мифологик подтекстын мифологик фикерләү ярдәмендә ачарга мөмкин; мондый фикерләү бәйләнешләрне мантыйк фикерләү күзәтә алмаган урында да күрә [5, 3 б.].

Төрки телле халыклар дөньясының мифологик картинасында сүзгә аерым сакраль көч бирелә. Халык зирәклеген туплаган мәкальләр бу карашны чагылдыра. Әйтик, «Жақсы сөз – жарым ырыс» («Доброе слово – половина счастья») дигән казах мәкалендә уңыш һәм иминлек китерергә сәләтле сүзнең уңай йогынтысы ассызыклана. «Тил таш жарат, тиш баш жарат» дигән кыргыз мәкалендә сүзнең икеле табигате акцентлана: ул иҗат төзүдә дә катнашырга мөмкин һәм җимерә дә ала. Тува мәдәниятендә уйланылган сөйләмнең әһәмияте белән бәйле бик күп мәкальләр бар, мәсәлән, «Дылын камны – амыдыралын камны» («Үз телеңне сакла – үз тормышыңны сакла»), бу сүзнең кеше язмышы белән бәйләнешен күрсәтә. Бу мисаллар төрки мифологиядә сүзнең аралашу чарасы гына түгел, ә чынбарлыкка йогынты ясый алырлык куәтле корал да булуын күрсәтә.

Сүзнең илаһи тылсым көче халык иҗаты әсәрләрендә бик югары күтәрелә. Һәм бу хәл, барыннан да элек, халык вәкилләренең меӊ еллар буена дәвам иткән иҗтимагый һәм көндәлек тормыш-көнкүреш хәлләрен күзәтеп бару тәҗрибәсе белән бәйле. Мәсәлән, «Балаларым төрле якта» мөнәҗәтендә түбәндәге юллар бар: *«Балаларым, сезгә Сүзем, канлы яшьле ике күзем. Языйм дисәм язып булмый, язмышлардан узып булмый. Сәламнәр әйләдем Сүздә, сәламнәрем җитсен сезгә»* [8, 81 б.].

Сүз – аерым кеше, билгеле бер коллектив һәм җәмгыять тормышында, халыкара мөнәсәбәтләрдә хәлиткеч роль уйный торган гамәли-мифологик категория. Моны халык мәкальләре белән дә дәлилләп була. «Сүз» төшенчәсе сөйләмдә ешрак үзәк мәгънәсендә кулланыла, ә «способность проникнуть» (үтеп керү сәләте) дигән бүген югалтылган эчке формасы – мәгънәсен фразеологизмнарда, мәкаль-әйтемнәрдә күзәтергә була.

Татар һәм казах телләрендәге «сүз» компонентлы мәкаль-әйтемнәре шактый күп, аларның бер өлеше: *Айтылған сөз – атылған оқ. Әйткән сүз – аткан ук./ Жақсы сөз – жан азығы. Яхшы суз – җан азыгы, яман сүз-баш казыгы./ Жанған от тәнді жылытады, жақсы сөз жанды жылытады. Янган ут тәнне җылыта, яхшы сүз – җанны./ Жаман сөз жылатады, жақсы сөз жұбатады. Яхшы сүз җанга рәхәт, Яман сүз җанга җәрәхәт./ Құлаққа кірген суық сөз – көңіліңе барып мұз болар. Колакка кергән салкын сүз йөрәккә барып боз була./ Ойнап айтсаң да ойлап айт. Уйнап әйтсәң дә уйлап әйт./ Көп сөз – күміс, аз сөз – алтын. Сүзең көмеш булса, эндәшмәвең алтын./ Өтірік сөз – өлтіреді, шын сөз – тірілтеді. Ялган сүз – яралый, дөрес сүз – дәвалый/ Сөз сүйектен өтеді. Сүз сөяк сындыра.*

Күп кенә мәкальләрнең ике телдә дә аналоглары бик якын булуы төрки халыкларның буыннан-буынга тапшырыла торган уртак кыйммәтләре һәм зирәклеге турында сөйли. Мәсәлән, «Әйтелгән сүз – аткан ук» һәм «Уйнап әйтсәң дә, уйлап әйт», – кебек мәкальләр тәңгәллегенә игътибар итәргә була.

Гомумән алганда, чагыштыру шуны күрсәтә: казак һәм татар халкы сүзнең көче һәм мәгънәсе турында охшаш күзаллауга ия, бу исә бу халыкларның уртак мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрен чагылдыра.

Тикшеренү нәтиҗәсендә ачыкланган уртаклылык һәм охшашлылыкның асылы шунда: төрки халыклар «сүз»не лексик берәмлек итеп кенә түгел, ә мифологик фикерләү ярдәмендә туган мифик герой, хәтта көчле зат итеп кабул итәләр. Борынгыдан килгән гореф-гадәтләр «сүз»нең кыйммәтен бүгенге көндә дә югары дәрәҗәдә тотарга ярдәм итәләр.

Шулай итеп, татар телендәге «сүз» төшенчәсенең этимологиясен, мифология өлкәсендә ролен өйрәнү тел йөртүчеләр дөньясының концептуаль картинасын аңлау өчен мөһим корал булып тора. Татар телендәге «сүз» концепты татар дөнья тел картинасының мөһим элементы дип әйтергә мөмкин. Аны өйрәнү татар телен яхшырак аңларга, халык тудырган милли дөнья күренешен һәм күпкырлы мәдәниятен тулырак күзалларга ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II том (М–Я). – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. – 567 б.

2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясенең нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 220 б.

3. Маслова В.А. Лингвокультурология: учеб. пособие для студентов высш. учеб. заведений. – М.: Academia, 2001. –208 с.

4. Сәгыйдуллина Л.Р. Татар лингвомәдәни концептлар сүзлеге. – Уфа: БашДУ, 2013. – 224 б.

5. Старикова И.В. Слово как носитель мифа: опыт семиотического анализа // ЭСГИ. – 2016. – №1 (9).

6. Степанов Ю.С. Константы: словарь русской культуры. – М.: 2001. – 989 с.

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: V том: С–Т. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – 908 б.

8. Урманче Т.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 3т. (С-Я). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 199 б.

9. Этимологический словарь тюркских языков. Общетюркские и межтюркские основы на буквы «Л», «М», «Н», «П», «С». – М.: Восточная литература РАН, 2003. – 446 с.

© Исмагилова А.В., 2025

УДК 821.512.145

**Исмагилова А.В.,**
*студент 4 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
**Шарипов М.С.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## ШӘРИФ КАМАЛ ПРОЗАСЫНДА ДӨНЬЯ СУРӘТЕ

***Аннотация.*** *Бу мәкаләдә Шәриф Камал прозасында дөнья картинасының үзенчәлекләре карала, авторның чынбарлыкны сурәтләүгә яңача карашы ачыклана, ул модернистик алымнар куллану белән характерлана. Тикшеренү язучы иҗатында дөньяның уникаль образын формалаштыручы төп элементларны ачыклауга һәм анализлауга юнәлдерелгән.*

***Терәк сүзләр*: *дөнья сурәте, Шәриф Камал, лейтмотив, бәхет, экзистенциаль алымнар.***

«Дөнья сурәте үзгәрү» китабында Д. Заһидуллина татар әдәбиятының күпгасырлык тарихына күз ташлап, анда яшәеш сурәтләренең ни сәбәпле һәм ни рәвешле үзгәрүен тикшерә. Әдәбиятыбызда дөнья сурәте үзгәрүендә аеруча әһәмиятле дәвер буларак XX йөз башы авторның игътибар үзәгендә тора. Д. Заһидуллина фикеренчә, бу чорда дөньяның яңа моделе формалаша, яңа тип геройлар мәйданга килә, жанрлар трансформация кичерә. Әлеге контекстта Дәрдемәнд, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Н. Думави һ.б. иҗатындагы милли дөнья сурәте чагылышын тикшереп, галимә әдәбиятыбызның классик чорына фәлсәфи ноктадан торып бәя бирә [3].

Күренекле язучы, драматург һәм публицист Шәриф Камал XX гасыр башы татар әдәбияты тарихында үзенең тирән фәлсәфи эчтәлекле, мавыктыргыч сюжетлы әсәрләре белән аерылып тора. Яңарыш дәверендә татар җәмгыяте зур социаль-сәяси һәм рухи үзгәрешләр кичерә, бу исә әдәбиятта яңа темалар, образлар һәм иҗат алымнарын эзләүгә этәрә. Ш. Камал прозасында дөнья сурәте, аның замандашларына караганда, яңачарак, модернистик рухта чагылыш таба. Ул ялгыз кеше фаҗигасенә, кеше яшәеше мәгънәсенә тирән эзләнүләргә юнәлдерелә.

Ш. Камал иҗатында дөнья рәссам палитрасы кебек күпкырлы һәм бай итеп сурәтләнә, анда тормышның ачык төсләре үрелеп бара. Аның текстлары фәлсәфи тирәнлек һәм күп мәгънәлелек белән аерылып тора, укучыны кеше хисләренең һәм кичерешләренең катлаулы дөньясына чумдыра. Гармониялек һәм бербөтен образ булдыру өчен һәрбер сүз конкрет сайланган, урынлы булмаган очраклар күзәтелми.

Ш. Камал дөнья сурәтенең үзәге булып шатлык-куанычлар, кайгы-хәсрәтләр эчендә яшәгән кеше образы тора. Һәр персонажның язмышы аша язучы мәхәббәт, югалту, тигезлек һәм иҗтимагый хокуклар өчен көрәш кебек универсаль темаларны яктырта. Бу элементлар күп дәрәҗәле композиция тудыра, анда чынбарлык һәм хис-тойгы үрелеп, әйләнә-тирә дөньяга яңа караш формалаштыра. Кешенең дөнья карашы, тормышы нинди булуы бары тик үзеннән генә торачак дигән фикер уткәрелә. Язучы әсәрләрендә күп төрле тема-мотивлар, проблемалар кузгатылса да, барсын берләштерүче ике төп тема алга чыгып тора: уяну һәм бәхет эзләү. Бәхет эзләү, бәхетле булырга омтылу – Ш. Камалның XX йөз башы чоры

иҗатына хас әйдәүче лейтмотив төсен ала. Билгеле ки, XX йөз башында фәкать Ш. Камал әсәрләрендә генә бу мотив ачыктан ачык ярылып ята иде.

Ш. Камал хикәяләрендә гомер буе изелеп, каһәрләнеп яшәүдән гаҗизләнгән, барыр кыйбласын тапмый гасабиланган, еш кына кешелеген югалту дәрәҗәсенә җиткән герой типлары үзәккә алына, шыксыз тормыш тудырган ямьсез инстинктлар алгы планга чыга.

Язучының «Муса ачуланган иде. Ачуыннан күзләре акайган, йөзе ут шикелле яна, дулкынлануыннан сүзен әйтә алмый иде...» сүзләре белән башланган «Уяну» (1909) дигән беренче хикәясе кешедәге шул ерткычлык сыйфатларын калку итеп тасвирлауга һәм явызлыкның авыр фаҗигасен өшеткеч картиналарда сурәтләүгә багышланган. Кыргыйлык, вәхшилек белән кешелек сыйфатларының кискен бәрелеше тирән кичерешләр, тетрәнүләр белән үрелеп фаҗиганең психологик аспектын тәшкил итә. Бәхетнең якында гына булып, челпәрәмә килүен исбатлый.

«Буранда» (1909) хикәясенең дә үзәгендә шул психологик конфликт ята. Солдат Мостафа кышкы буранның котыруына карамастан, өенә кайтып җитәргә һәм әнкәсе белән күрешергә ашкына. Аның әнисеннән аерылуына егерме ел икән. Ике дистә ел элек атасы әнисен куып җибәреп улын аңа каршы тәрбияләгән булган һәм хәзер ул «анасыннан бөтенләй бизгәнлеген уйлап газап чигә», аягына егылып гафу үтенергә тели. Мостафа кайчандыр әнисенә карата кылган начарлыклары, салкын мөгамәләсе өчен вөҗдан газабы кичерә, шул хис аны салкын буранда юлга чыгарга мәҗбүр итә. Ләкин аның изге ниятләре тормышка аша алмый: ул кайтып кергәндә анасының гомере инде өзелгән була. Бу очракта да бәхетнең якында гына булуын – солдат Мостафаның әнисе белән күрешү мизгелен бәхет итеп күзалласак, бу бәхетнең дә чынбарлыкта була алмавына ышанабыз.

Язучының «Козгыннар оясында» (1910) хикәясенә күз салсак, әсәр уртасында авыр көндәлектән туган бәхетсезлекне, фаҗигане күрәбез. Күмер чыгарудан тыш гомерләрен аракы сөремендә үткәреп, башкалар арасында «ташландыклар» дип хисаплана торган шул кешеләр, кара, өметсез тормышларында юаныч табу ниятеннән, бер «кызык шөгыль» уйлап табалар. Җәфа яшәүдән, исереклектән тормыш төбенә тәгәрәгән адәмнәр дөньяның иң юаш, иң оялчан бәндәсе булган Мәрьямне мыскыл итүдән тәм табарга ниятлиләр. Бу «кызык» гаять фаҗигале төгәлләнә: Мәрьям суга ташлана. Хатынның үлеме бер төркем шахтерларны сискәндерә, уйланырга мәҗбүр итә, ләкин бу инде соңарган «уяну». Шунысы да бар, бу уянуның дәвамы булмаячак, ул вакытлы гына. Мәрьям үлеме дә, билгесез тарафка китеп югалган Госман карт та «тормыш төбендәгеләрне» азга гына уйландыра, каһәрле язмышның хайвани яшәү кануннары аларны кабат үз мохитенә бөтереп ала. Хикәянең ахырында автор бу хәлне ачык күрсәтә: «Мондагы тормыш шулай ук үз юлында дәвам итә иде: ничек сәгать алты, гудок янә гадәтенчә акыра, янә кайнашу, янә җитдилек, ничек числоның башы яки унбише, янә палучка, янә кызык». Димәк, тагын җимерелгән язмышлар, фаҗига, кан, дәһшәт...

Шәриф Камал иҗатында модернизмның төп билгеләре ачык күренә. Ул традицион реалистик алымнардан читкә тайпылып, кеше эчке дөньясын, аның психологик кичерешләрен, борчуларын һәм хисләрен сурәтләүгә зур игътибар бирә. Аның хикәяләрендә еш кына ялгызлык, аңлашылмаучанлык, тормышның мәгънәсезлеге кебек экзистенциаль темалар күтәрелә.

Шәриф Камал прозасында экзистенциаль алымнарның кулланылуы аның әсәрләренә тирән фәлсәфи эчтәлек бирә. Экзистенциализм – кеше яшәвенең нигезлеген, аның иреклеген, җаваплылыгын һәм яшәү мәгънәсен эзләүне үзәккә куйган фәлсәфи юнәлеш. Ш.Камалның геройлары еш кына тормышның авыр сынаулары алдында ялгыз калалар, үзләренең авыр язмышлары белән көрәшәләр, яшәүнең максатын аңларга тырышалар.

«Экзистенциалистлар җәмгыятьтә рухи мәгънәне һәм кыйммәтләрне кире кайтарып булмаслык югалту проблемасын күтәрәләр, «дошмандай дөньяда кеше яшәешенең төп халәте – курку, ялгызлык хисе, вөҗдан газабы» дип саныйлар» [6, 319].

Экзистенциаль әдәбиятның төп темалары һәм мотивлары булып кешенең яшәеше, аның һәлакәткә дучар ителүе, шәхес язмышы, иман, тормыш мәгънәсен югалту һәм табу,

көчсезлек, ялгызлык һ.б. тора, алар XX гасыр башы татар поэмаларында да чагылыш таба. Милләт, халык язмышы турындагы тирән уйлар еш кына чарасызлык, һәлакәт, хаталар өчен түләү мотивлары белән үрелеп бара.

Билгеле булганча, «ялгыз кеше фаҗигасе» буларак каралган экзистенциализм фәлсәфәсе рационализмга һәм фикер көченә зур шик белән карый, ә шик чарасызлыкка китерә. Чарасызлыкның сәбәбе – яшәешнең камил булмавында, кешенең Галәм масштабларында үзенең әһәмиятсезлеген тоюында, Алланың бөеклеге алдында көчсезлегендә [3, 80 б.]. Мәсәлән, «Буранда» әсәрендә Мостафаның һәр сүзендә бу фикер сиземләнә. «Бала усал», дип кабатланган сүзләрендә, дустының баласын үзе белән чагыштыруы күренә. Автор аның бәләкәй чагындагы хәтирәләре аша, уй-кичерешләрен, калганнар аңлап бетмәс хис-тойгыларын аңлата. Юлда барганда кергән төшләре аны кире кайтмас балачагына, төзәтеп булмас хаталарына ишарә ясый. Бу әсәрдә «буран» – төп геройның эчке халәте, аның җанын ничә еллар буена тиргәүче-өзгәләүче зур хата образы.

Гомумән алганда, XX гасыр башында экзистенциализм фәлсәфәсе юнәлешендә иҗат ителгән татар әсәрләрендә яшәешнең вакытлы гына булуы, гомернең тиз үтүе мотивлары тормыш һәм үлем, өмет һәм өметсезлек, чарасызлык, яктылык һәм караңгылыкның бинар оппозицияләре ярдәмендә ачыла, тормыш туу белән үлем арасындагы кыска мизгел буларак кабул ителә.

Шәриф Камал прозасында дөнья сурәтен ачыклауда бинар оппозиция, шулай ук, уңышлы чагылыш таба. Хәзерге фәндә бинар оппозицияләрне өйрәнү шәхси-автор концепциясен ачыклау максатыннан сәнгать текстлары дәрәҗәсендә куела. Авторның әсәрләре традиция һәм яңалык, авыл һәм шәһәр, мораль һәм этика каршылыгы аша укучыга дөньяны аңлауда катлаулы, әмма кирәкле көрәш күрсәтә.

Шәриф Камал үзенең оппозитив фикерләвендә кеше тормышына, эшчәнлегә кагылышлы капма-каршы төшенчәләр белән актив эш итә. «Акчарлаклар» әсәрендә, мәсәлән, Ш. Камал иҗтимагый гаделсезлекне антитеза, ягъни бинар оппозиция ярдәмендә сурәтли: балык эзләүче акчарлаклар / бәхет эзләүче эшчеләр; акчарлаклар елый / акчарлаклар көлә; кырык мең табыш турында хыялланучы промысел хуҗалары / кырык сумлык хезмәт хакына өмет итүче эшчеләр; байлар йортындагы йомшкак түшәк / эшчеләрнең салам җәелгән ятагы һ.б.

Шәриф Камал әсәрләренә анализ ясау, авторның күп үлчәмле дөнья сурәтен күрсәтә, анда традицияләр һәм хәзерге заман, чынбарлык һәм фантазия үрелеп барганын ачыкларга ярдәм итә. Тормыш мәгънәсен эзләү, эчке кирелекләр белән көрәш һәм кешенең тиз үзгәрүче җәмгыятьтәге урыны кебек төп темалар аның әдәби теленең нигезе булып хезмәт итә. Язучы, үз иҗатында модернистик алымнарны оста кулланып, ялгыз кеше фаҗигасенә аерым игътибар итә. Аның хикәяләрендә без кеше күңеленең эчке дөньясына, аның борчуларына, эзләнүләренә һәм еш кына очраша торган экзистенциаль кризисларга юлыкканлыгына шаһит булабыз.

Шәриф Камалның бу юнәлештәге иҗаты XX йөз башы татар прозасы өчен зур яңалык булды. Ул вакыттагы әдәбиятта гадәттә социаль яки милли мәсьәләләргә басым ясалганда, Ш. Камал кеше шәхесенең эчке дөньясын, аның яшәү мәгънәсен эзләүләрен, ялгызлык һәм югалып калу тойгыларын проблема буларак күтәреп чыга. Экзистенциаль алымнарны куллану, ягъни кешенең барлыкка килү, азатлык, җаваплылык кебек тирән сораулар алдында торуын сурәтләү, аның прозасына яңача яңгыраш бирә.

Шулай итеп, язучының әсәрләрендә: 1) тәкъдим ителгән дөнья сурәте чынбарлыкның үзгә моделен төзи; 2) аның әсәрләрендә искелектән калган дорфа гадәтләр катгый кире кагыла, ә гомумкешелек кыйммәтләре раслана; 3) каршылыклы хәл-вакыйгалар бинар оппозиция куллану аша чагылыш таба; 4) мәхәббәт ярдәмендә бәхеткә ирешергә мөмкин дигән фикер үткәрелә; 5) психологизмның төрле алымнары кулланыла.

Шәриф Камал прозасындагы дөнья сурәте – ул бары тик тышкы вакыйгалар гына түгел, ә кеше күңеленең эчке кичерешләре, аның яшәүгә карата булган катлаулы мөнәсәбәте һәм модернистик алымнар аша ачылган ялгызлык фаҗигасе.

**Кулланылган әдәбият**

1. Җамал Вәлиди. Әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз.: Д. Абдуллина, Җ. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2010. – 624 б.
2. Закирҗанов Ә.М. Татар әдәбият белеме: традицияләр һәм үсеш тенденцияләре. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 352 б.
3. Заһидуллина Д.Ф. Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2006. – 191 б.
4. Камал Шәриф. Сайланма әсәрләр / төз., кереш сүз язучы Р. Сверигин. – Казан: Хәтер, 2006. – 495 б.
5. Литературная энциклопедия [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://gufo.me/dict/literary_encyclopedia, свободный – (23. 01.2025).
6. Мещеряков В.П, Козлов А.С, Кубарева Н.П. и др. Основы литературоведения: Учебное пособие для студентов педагогических вузов. – М.: Дрофа, 2003. – 416 с.
7. Заһидуллина Д.Ф. Милли үзаңны үстерү мәсьәләләре // Мәгариф. – 2008. – №5. – Б. 5–8.
8. Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 255 б.

© Исмагилова А.В., Шарипов М.С., 2025

УДК 821.512.145

**Исмагилова З.Р.,**
*студент 2 курса Елабужского института КФУ*
*Научный руководитель –* **Габидуллина Ф.И.,**
*доцент кафедры филологии Елабужского института КФУ,*
*г. Елабуга, Россия*

# ХИСЛӘРЕМНЕ ХИСЛӘР АЛМАШТЫРА

(Р. Харис иҗатына бер караш)

***Аннотация.*** *Ренат Харис – үзенчәлекле тавышы, кыю эзләнүләре һәм тирән фәлсәфи уйланулары белән аерылып торган күренекле татар шагыйре. Аның шигъриятендә төп урынны халык тарихы, хәзерге заман алдында гражданлык җаваплылыгы, кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре, әхлакый-рухи проблемалар алып тора. Шагыйрьнең сугыш афәтләре, туган җиргә мәхәббәт турындагы шигырьләре укучының күңеленә тирән үтеп керә, аны уйланырга һәм борчылырга мәҗбүр итә. Бу мәкаләдә Ренат Харис иҗатының төп темалары, аның шигъриятендәге образлар системасы фәнни әдәбият яктылыгында карала.*

***Терәк сүзләр:*** *Ренат Харисов, татар поэзиясе, поэзия, гражданлык лирикасы, фәлсәфи шигырьләр, тарихи хәтер, сугыш темасы, табигать һәм кеше, әхлакый проблемалар, туган җир, шигъри образлар, хәзерге заман вакыйгалары.*

Ренат Харис – 60 нчы елларның урталарында ук үзенчәлекле шигъри авазын ишеттергән, шигырьдәге кыю эзләнүләре белән шигърият сөючеләрне үзенә юнәлткән, бәхәсләр уяткан һәм шул еллардан башлап поэзия йөген җигелеп тартучы шагыйрьләребезнең берсе.

Шагыйрь үзенең шигырь һәм поэмаларында халкыбызның тарихи яшәеше, кеше шәхесенең тормыштагы урыны, җәмгыять каршындагы җаваплылыгы, буыннар дәвамлылыгы турында уйлана, заманның әхлакый, рухи, иҗтимагый күренешләренә, үзгәрешләренә үзенең фәлсәфи һәм гражданлык мөнәсәбәтләрен белдерә.

«Шагыйрь бүгенге көн, аның шатлык-борчулары турында да уйлана. Гомум кешелекнең, Җирнең әхлагындагы, кәефендәге үзгәрешләрне күреп борчыла. Күңелендә:

«Әллә инде йөрәкләрдә башландымы бөек бозлавыклар вакыты?» дигән шомлы фикерләр дә уяна. Бүгенге көндә кеше йөрәген капларлык бозлавыклар туу ихтималы турында сүзне олы итеп башлавы, мәсьәләне әнә шулай кискен итеп куюы, кешеләрнең кылган гамәлләреннән шомлануы укучыны да ваемсыз калдырмый, уйландыра һәм сискәндерә. Бу инде шагыйрьнең җирдәге авыру нокталарны укучыларның күңелләренә тәэсирле итеп җиткерә белүендә күренә» [5, 5 б.].

Хәзерге заманда кешелекне һәлакәткә сөйри торган олы куркынычның берсе – сугыш афәте. Шагыйрь әлеге шомны укучыга да җиткерерлек җегәрле сүзләр, тәэсирле буяулар эзли. Ул еллар, айларны гына түгел, сәгатьләрне, мизгелләрне тоярга өйрәтә:

Тетрәде җир, корылык узды,
Андыйларга гына түзгән, –
Җиребезне исән килеш
Кояш тирәли тагын бер
Зырылдатып әйләндердек –
Бәхетлерәк кем бар бездән?!
(«Кем бар?»)

«Китү, көтү, кайту» шигыреньдә шагыйрь «талдай буйларына котомкалар асып сугышка киткән», өйләренә кайтып «берсүзсез стеналардагы буш рамнарга кергән» унтугыз яшьлекләрнең язмышын хәтеренә төшерә. «Конфет, алма, чәчәк» шигырендә исә Саласпилс концлагеренда фашистлар тарафыннан ачтан үтерелгән җиде мең баланың язмышы турында тетрәнеп яза.

Кеше белән табигать арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турында да шагыйрь күп яза: «Коела яшел яфрак», «Яфракларың гәрәбә..», «Корылык», «Яктылык төшә», «Алтын төрән», «Көзге төн». Аның лирик герое табигатьне ярата, аның өчен «һәрбер агач, үлән – һуш китәрлек әңгәмәдәш».

Табигать, яшәү һәм матурлык чыганагы буларак, кешеләрне уйландырырлык шигырьләре дә күп. Мәсәлән, «Өянке» шигырендә тормышка омтылыштан да өстен хис юк, ул үлемнән, вәхшилектән өстен дигән фикер уздырыла:

Өскә үсмәсен әле, дип,
Баш ботагымны киссәң,
Мин бит як-якка үсәм!..
Куелыкка үсмәсен, дип,
Ябалдашымны киссәң,

Мин тамыр якка үсәм?..
Бәгыренә чабыймчы диеп,
Казып тамырыма төшсәң,
Кабрең өстендә үсәм!

Р. Харис иҗатын өйрәнүче галимә Ф. Хәсәнова: «Шагыйрь өянке образына татар халкына хас сыйфатларны сала. Татар халкының нинди генә авырлык, җәбер күрсә дә, яшәүгә ышанычын югалтмыйча, авырлыкны җиңә барганлыгын күрсәтергә тели», – дип бәяли [4, 166 б.].

Ренат Харис иҗатында Туган җир, җирне олылау хисе-иҗат итү өчен илһам чыганагы булып тора. Туган җир темасы шагыйрьдә Татарстан һәм авторның туган ягы Буа төбәге белән үрелеп тасвирлана. «Җир миндә», «Югарыга үрләгәндә», «Сусап кил» шигырьләре шул хакта.

Шагыйрьнең фәлсәфи рухтагы шигырьләрендә авторның бүгенге тормышны, кешеләрне әйбәт белүе сизелә, әмма ул күренешләрнең әхлакый сабак, олы мәгънә бирердәйләренә генә игътибар итә» [4, 164 б.]. Бер яла сүз аркасында намусның телемнәргә теленүе хакындагы «Яралар» циклы, пышылдап әйтелгән рәхмәтнең кычкырган каргыштан көчле булуын аңлаткан «Бер яшибез» шигырьләрендә кеше күңелендә булган әхлакый кыйммәтләрнең әһәмияте җиткерелә.

Ренат Харис шигырьләре укучыдан күңеленең рухи халәткә көйләнгән булуны таләп итә. Шул очракта гына укучы аның әсәрләреннән үзе өчен рухи ләззәт, матурлык ачылуын тоя.

Әйе, Ренат Харис поэзиясе – кешелек тәҗрибәсенең яңа якларны ачуы, тормыш ямен җырлавы, эзләнүләренең кыюлыгы белән хәзерге татар әдәбиятында үзенчәлекле күренеш.

**Кулланылган әдәбият**


1. Фәйзуллин Р. Заманга иш иҗат // Казан утлары. – 2001. – № 5 – Б.89.
2. Харис Р.М. Замана эзләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 255 б.
3. Харис Р.М. Сайланма әсәрләр. 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 287 б.
4. Хәсәнова Ф.Ф. Ренат Харис шигърияте // Казан утлары. – 2000. – № 5. – Б.156–166.
5. Юзеев Н. Уйлы-хисле шагыйрь, рәссам шагыйрь // Замана эзләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., – 1981. – Б. 5–10.


© Исмагилова З.Р., 2025

УДК 130.2 (575.4)

**Исмаилова Б.Т.,**
**Каримова З.С.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## «ТАБИГАТЬ» КОГНИТИВ СФЕРАСЫНА КАРАГАН ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕЛМӘЛӘР

(А. Гыйләҗев прозасы материалында)

***Аннотация.*** *Әлеге мәкалә Аяз Гыйләҗев прозасындагы фразеологик берәмлекләрнең стилистик һәм лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлана. Хезмәттә «Табигать» когнитив сферасына караган фразеологизмнар анализлана.*

***Терәк сүзләр:*** *фразеологик берәмлекләр, стилистика, когнитив сфера, концепт, лексика, компонент.*

Фразеологизмнарның компонентлары тотрыклы сүзтезмәләр төзү өчен материал буларак, аларны чагылдыру планын төзиләр. Аннары телнең озак вакытларга сузылган үсеше нәтиҗәсендә алар билгеле бер мәгънә аңлата башлыйлар. Фразеологизмнар фразео-семантик кырларга туплана. Ә бер фразеосемантик кыр составында төрле лексик берәмлекләрдән булган, бер үк төрле идеяне белдерә, дөнья тел күренешендә бер үк теманы аңлатучы фразеологизмнар берләшә. Фразеологизмнарны берләштерүгә нигез булып бу очракта аларның семантикасында телдә бер үк фикерне атаучы гомум интеграль семаның буоуы мөһим. Икенче төрле әйткәндә, фразеологизмнарга тематик-идеографик классификация тотрыклы сүзтезмәләрне аерым бер мәгънәләренә карап, билгеле бер семантик группаларга кертү күз уңында тотыла [2].

Профессор А.Г. Шәйхулов лексик берәмлекләрнең идеографик классификациясенең тәбәндәге схемасын тәкъдим итә:

1) Табигать (җанлы һәм җансыз);

2) Кеше (физиологик-биологик берәмлек буларак);

3) «Кеше (социаль берәмлек буларак)»;

4) Танып белү [3].

«Табигать» когнитив сферасына караган фразеологик әйтелмәләрне язучылар иҗатында күпләп очратырга мөмкин. Чөнки нинди генә әсәрне алсак та, аның үзәгендә кеше, ә кеше – табигать баласы. Табигать һәм аның күренешләре кешене иркәли дә, сыный да, чыныктыра да. Аяз Гыйләҗевнең кайсы гына әсәренә күз салсак та, табигать күренешләренә зур урын бирелгән, кеше язмышы табигать күренеше белән бергә үрелеп бара. Бу күренешләрне образлы итеп бирүдә, әлбәттә, фразеологик әйтелмәләрдән оста файдалану язучы иҗатының бәһасен күпкә арттыра.

«Җансыз табигать» группасына күбесенчә табигать күренешләрен белдерүче фразеологик әйтелмәләр керә һәм төп концепт булып «күк», «җир», «су», «җил», «ай», «кояш», «таң» сүзләре тора. Составына табигать күренешләре, хайваннар, үсемлекләр дөньясы белдергән исемнәр кергән фразеологик әйтелмәдә кешенең табигатьне үзләштерү процессында танып-белү тәҗрибәсе чагыла. Танып-белүнең үзәгендә кеше үзе тора, шуңа күрә кеше факторы дөнья картинасы структурасында үтәдән-үтә күренеп тора. Танып-белү – кешенең табигать шартларына яраклашуы блогына кергән фразеологик әйтелмәләрне икегә бүлеп карыйбыз: җансыз табигать, җанлы табигать [3, 5 б.]. А. Гыйләҗев илледән артык фразеологик әйтелмә куллана. Язучының «Йәгез, бер дога!» романында табигать темасына караган лексик берәмлекләр, фразеологик әйтелмәләр ифрат күп кулланыла, аларның кайберләре: *Иртә яз ике иңенә дә яңгырлар төяп килде*. Бу юнәлешкә калган *җил-давыл тыелгысыз үкерә, баш миен бораулап җәһәннәм авазлары чыгара. Башлана пәри туе! Котырына шайтан биюләре. Кара күк белән соры җир тоташа. Актасның таныш күгеннән тып та тып авыр тамчылар егыла башлады*. Бу җөмләләр гел фразеологик әйтелмәләрдән генә тора диярлек. Язучы алар ярдәмендә табигать стихиясен, аның җил-давылларын гына тасвирлап калмый, ә, бәлки, болар аша бер яктан укучыга Казахстан далаларының шактый кырыс табигатен күзалларга ярдәм итсә, икенче яктан, А. Гыйләҗев фразеологизмнар аша Актас зонасындагы тоткыннарның авыр тормышын, бу төрмәдә булган тетрәндергеч вакыйгаларны сурәтли.

«Кара күк» икән, димәк, тоткынның тормышы да, караучысы да «авыр тамчылар егыла» икән, ул укучы тарафыннан тоткын башына төшә торган авырлык сыман кабул ителә: *Дымлы җилкәләрне җил ялый, калтырата, үзәккә төшә. Беркем торып йөрми, курка-курка җирдә кәнкәеп утырган гәүдәләрне кичке җил алган, җилкәләргә суык үткән. Петр Колымада алтын юган, кыйммәтле металл белән эш итсә дә, ачлыктан чурланган, җилдә җилләнгән, суыкта куырылган*.

Табигать күренешләрен чагылдырган фразеологик әйтелмәләрне А. Гыйләҗевнең башка әсәрләреннән дә китерергә була. Мәсәлән: *Төн салкынча, күк аязган, яңгыр юган күкнең кара шәленнән йолдызлар тамарга тора*. Язучы йолдызлы аяз төннең матурлыгын аңлаткан индивидуаль фразеологик әйтелмә төзегән. Яисә: *Гомер буе кояш чыраен күрмәгән күк йөзе һаман ачылмый*. Биредә җөмлә тулысы белән фразеологик әйтелмәләрдән тора һәм ул безгә яңгырлы көнне күзалларга ярдәм итә.

Шуны да әйтергә кирәк, табигать күренешләре иң актив кулланылганы – җил образы. «Җил» концепты [1] ярдәмендә бик күп төрле фразеологизмнар ясала: *җил сызгыра, җил уйный, җил-буран уйнату, җилгә очу, җилдәй җитез, җил-яңгыр тидермәү, җил кай якка иссә, шул якка, җил кеше, җил куып йөрү, җил койрыгын тотып калу, җилдән туган бала, җилдән килеп җилгә киткән* һ.б.

Бер авторда ул табигать күренешләрен иркәләүче, тынычландыручы билге булса, икенчесендә – усаллык, ямьсезлек, шыксызлык, куркыныч янау булып тасвирлана. Табигатьтә җилне *ыжгыра, сызгыра* дип кенә характерлыйбыз. А. Гыйләҗевнең җиле

бөтенләй башка. Автор җилгә кешегә хас сыйфатлар биргән, җил белән ясалган фразеологизмнар аның әсәрләрендәге геройларны төрле яклап ачарга ярдәм итәләр.

А. Гыйләҗев әсәрләрендәге «табигать» темасына караган лексик берәмлекләр белән ясалган фразеологик әйтелмәләр күбесенчә геройларның язмышларын ачыграк чагылдырырга ярдәм итәләр, ләкин алар шул ук вакытта төрле табигать күренешләрен образлы итеп бирү өчен дә файдаланылалар. Мәсәлән: 1) караңгы төшү (кич булу): *Җил өстенә шомлы күләгә йөгерде*; 2) яңгыр яву: *Күкнең төбе тишелгән, ахры*; 3) таң ату: *Түшәктәй кабарынып-кабарынып ишелгән болытлар аркылы таң яктысы саркылды*; 4) салкын кыш: *Тәрәзәдән усал кыш патша үзенең бозлы кулларын сузганда да, карт уйнавын куймаган*; 5) җылы кыш: *Гел елак кышлар китте*; 6) кояш тотылу күренеше: *Кояш оялып кына кап-кара япмаябынып маташа*; 7) аяз көн: *Купшы күк үзенең бар булган алтын-көмешләрен таккан, япанчасына энҗе-мәрҗәннәрен сипкән, бизәнгән*.

«Җанлы табигать»кә бәйле фразеологик әйтелмәләр А. Гыйләҗевтә чагыштырмача күп түгел, компонентларында җанлы табигатьне белдергән лексик берәмлекләр белән ясалган фразеологик әйтелмәләр дә еш кына турыдан-туры табигать темасына карамыйлар, ә бәлки әсәрдәге персонажларны төрле яклап ачу, аларның характерлы сыйфатларын, портретларын күрсәтү өчен ярдәм итәләр. Шуңа күрә мондый фразеологик әйтелмәләрне икегә бүлеп карау дөрес булыр:

1) Турыдан-туры табигать күренешләрен чагылдырган фразеологик әйтелмәләр: *Кинәт аның баш очында гына тургай моңы коелды, ул күккә күтәрелеп тургайны эзләргә тотынды, күк зәңгәрле, салмак кына куерып ага, ни караса да, гүзәл кошчыкны таба алмады*: дигәндә укучы хозур табигать кочагына кереп, кошлар сайравына күмелә. Ә менә «*Һәм алар, һәммәсе шайтан таягында коллыкта*!» җөмләсендә күз алдына котырынып үскән чүп үләннәре килеп баса.

2) «Җанлы табигать»кә караган лексик берәмлекләр белән ясалып, күчерелмә мәгънә белдергән фразеологик әйтелмә. Монда фразеологик әйтелмәләрнең компонентлары булып фауна дөньясы һәм Россия территориясендә үсүче флора (урман, агач, имән, каен, юкә) керә. Ләкин алар берсе дә табигать күренешен белдермиләр, ә кешене характерлаганда гына кулланылалар. Мәсәлән: *Сул яктагы мең тармаклы карама да истә*. «Мең тармаклы карама» фразеологик әйтелмә, ул бергә күп еллар буе үсеп утырган мәһабәт карт карама агачы турында сөйли. *Мисыр күгәрчене кебек гөрләп, Бәдәр балаларын янбакчага алып чыкты* – Бәдәрнең малайларны көйләп-чөйләп, күңелләрен күрүе турында сүз бара. Яисә: *Күктау уңганарына да әкәле имән ава*! – байлык килүне белдерә; *Хатын-кызлар арасында да яшертен генә, шомлы күләгәдә каршылык агачы тамыр җибәреп ятканын миңа Дзидра сиздергән иде инде.* (дошманлашу, килешмәүчәнлек дигәнгә туры килә). *Соңыннан, байтак айлар үткәч, алар арасында шуышып йөргән кара җылан барлыгын абайладым*. Геройларның бер-берсенә карата начар мөнәсәбәттә булуын күрсәтә. Җил, күк, караңгылык, ай, пәрдә, күләгә, тургай, кояш, таң сүзләре төп концептны тәшкил итәләр.

Мисаллардан күренүенчә, җанлы табигатьне белдергән фразеологик әйтелмәләргә караганда күчерелмә мәгънәдә кулланылган фразеологик әйтелмәләрнең стилистик мөмкинлекләре күбрәк. Алар ярдәмендә автор аз сүз белән күп мәгънә аңлатып, образны күз алдына төгәл китереп бастыра.

**Әдәбият исемлеге**


1. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният. Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 350 б.
2. Хайруллина Р.Х. Фразеологическая картина мира: от мировидения к миропониманию. – Уфа: БГПУ, 2000. – 285 с.
3. Шайхулов А.Г. Структура и идеографическая традиция односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья в континууме ареальной, межтюркской и общетюркской лексики (синопсис и таксономия когнитивной сферы «Природа (живая и неживая)». – Уфа: РИО БашГУ, 2000.


© Каримова З.С., 2025

УДК 821.512.145

**Кашаева А.И.,**
*студент 3 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель* – **Сагидуллина Л.Р.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

# ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕНДӘ «ИЛ» КОНЦЕПТЫ ЧАГЫЛЫШЫ

***Аннотация.*** *Мәкалә татар телендә «ил» концептын репрезентацияләү вариантларын карауга багышланган. Шул максаттан татар теленең «ил» компоненты булган паремияләре анализлана, «ил» концепцептының төп һәм периферия мәгънәләре ачыла.*

***Терәк сүзләр:*** *лингвокультурология, дөнья тел картинасы, концепт, татар теле, «ил» компонентлы мәкальләр һәм әйтемнәр.*

Тел белән мәдәниятнең тыгыз бәйләнештә булуын тану инструменталь категорияләрнең бердәм системасын кулланып, менталитет, мәдәният һәм тел феноменнарын комплекслы өйрәнүне активлаштыра. Лингвистиканың бу юнәлешен эшләүдә билгеле бер этап булып яңа дисциплина – *лингвокультурология* барлыкка килүе тора.

Лингвокультурологиянең төп төшенчәләренә «дөнья күренеше», «дөнья тел күренеше», «концепт» керә. Аларга тукталып китү урынлы дип уйлыйбыз.

Халыкның гасырлар буе җыелган тәҗрибәсен тәшкил иткән, телнең номинатив чаралары аша белдерелгән чынбарлыкның бөтен һәм күпкырлы дөнья булып сурәтләнүен дөнья тел күренеше дип атыйлар.

Кешенең дөнья турында бөтен гомере буена тупланган белемнәре аның аңында дөнья күренеше буларак яши, кешенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен билгели, үз-үзен тоту рәвешенә, кыйммәтләр системасы, социаль яктан билгеләнгән императивлар һәм тыюлар урнашуга, кешенең субъективлыгын төшенү ысулларына йогынты ясый.

Р. Р. Җамалетдинов фикеренчә, дөнья тел күренеше төзелешен, ягъни структурасын тасвирлау ике баскычтан торырга тиеш була: «беренчесе, тел тамгаларының (билгеләренең) гомумкешелек, универсаль эчтәлеген яки инде дөнья тел күренеше компонентлары буларак, концептларны ачыклаудан, ә икенчесе, билгеле бер этномәдәният гомумилегенең дөньяны танып-белү тәҗрибәсен беркетү ысулы буларак, милли тел үзенчәлеген сыйфатлаудан гыйбарәт» [2; 25 б.].

Концептлар турындагы дискуссия бик күптәннән килә. Инглиз телендә *concept* «төшенчә»не аңлатучы философик термин буларак XIX гасырның икенче яртысыннан, рус телендә – бу мәгънәдә 1920–1970 нче елларда кулланыла.

Безнең илдә концепт табигатен иң беренчеләрдән булып анализлау омтылышын С.А. Аскольдовның «Слово и концепт» мәкаләсендә очратабыз. Ул концептка түбәндәге билгеләмәне бирә: «*Концепт* – фикер барлыкка китергән төзелмә, ул фикерләү барышында безнең өчен бер үк төрдәге күп санлы предметларны алыштыра» [1; 269 б.].

Татар телендә «ил» концептын тикшергәндә иң элек без бу концептны атаучы лексик берәмлекнең аңлатмалы сүзлектә теркәлгән мәгънәләрен, этимологиясен, дериватларын ачыкладык. «Ил» компонентлы фразеологик берәмлекләрне туплап, аларны без «Кеше» суперконцепты эчендә «кеше – җәмгыять» концептосферасы кысаларында тикшердек.

Алдагы этапта «ил» концептының үзеген һәм периферияcен киңәйтү һәм тирәнәйтү инструменты рәвешендә «ил» компонентлы мәкаль-әйтемнәрне туплауны, моның өчен паремия төшенчәсен ачыклауны максат итеп куйдык.

Хәзерге тел белеме гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләре белән бәйләнешләрен арттыра, шул рәвештә аның тикшеренү өлкәсе киңәя һәм лингвистиканың традицион өйрәнү объектларына яңача күзлектән карау мөмкинлеге туа. Мәкаль һәм әйтемнәрне инде күптәннән өйрәнү-тикшерү тәҗрибәсе булуга карамастан, соңгы вакытларда паремиологик берәмлекләрне хәзерге теоретик юнәлешләрдән чыгып өйрәнү һәм классификацияләүгә яңача караш тудыру ихтыяҗы сизелә.

Паремияләр кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр, социаль-тарихи контекст, көнкүреш, гореф-гадәтләр һәм традицияләр үзенчәлекләрен чагылдыралар. Паремияләрне өйрәнү, беренчедән, мәдәният белән билгеләнгән телдәге мәгънәләрне ачыкларга, икенчедән, аеруча мөһим мәдәни стереотипларны формалаштыруның когнитив алымнарын карарга мөмкинлек бирә.

Лингвокультурологиянең мәкаль-әйтемнәр белән кызыксынуы паремияләрнең сүздә гәүдәләндерелгән «халык аңы стереотиплары» булуы белән аңлатыла. Х. Ш. Мәхмүтов фикеренчә: «Мәкаль һәрвакыт гыйбрәт өсти, тормышның төрле очракларына ярарлык акыллы киңәшләр, үгет-нәсыйхәт бирә» [3; 43 б.].

Телнең паремиологик берәмлекләре фонды лингвокультурология өчен, һичшиксез, кызыксыну чыганагы булып тора, чөнки алар иң мөһим лингвомәдәният константаларын, халык фикере үзенчәлеген өйрәнергә мөмкинлек бирә. Халыкның гасырлар буена туплаган тәҗрибәсен һәм күзәтүләрен, гомумиләштереп, мәкальләр яшәү кагыйдәләрен төзиләр, аларны социаль яктан әһәмиятле һәм җәмгыятьчелек тарафыннан танылган закончалыклар дәрәҗәсенә күтәрәләр.

«Паремия» терминын әйткәндә, тикшеренүчеләр халык афоризмнарын, иң элек мәкаль һәм әйтемнәрне күз алдында тоталар. Алар телнең синтагма-парадигма мөнәсәбәтләренә дә катнашып китәләр [2; 129].

Мәкаль һәм әйтемнәр, гадәттә, үзенчәлекле фольклор жанры буларак өйрәнелә. Аларны хәзерге лингвистикада өйрәнүнең перспективалары бар: лингвокультурологиядә билгеле бер халыкның тарихы, көнкүреше, әхлак кагыйдәләре белән бәйләнгән мәкаль һәм әйтемнәргә игътибар юнәлтелә.

Мәкаль – җәмгыять тарафыннан үз ителеп уртак кулланылышта йөргән кыска һәм тирән мәгънәле, гадәттә насыйхәт бирә торган калыплашкан тәгъбир, тапкыр сүз [4; 319 б.]. Мәкаль гыйбарәләренең жанр үзенчәлеге тиешле структура һәм форма таләп итә, еш кына композицион кисәкләре симметрияле рәвештә урнаша.

Әйтем, мәкальдән аермалы буларак, төгәлләнгән фикер тәшкил итмәгән тотрыклы һәм, гадәттә, образлы тәгъбир.

Бүгенге лингвистикада мәкальләрне телнең фразеологик системасына кертү яки кертмәү бәхәсләре бара. В.В. Виноградов фикеренчә, мәкаль фразеологик берәмлекнең төп дүрт критериенә туры килә: образлы күчерелмә мәгънә, экспрессив байлык, фразеологик гыйбарәнең тулаем семантик алыштыру мөмкинлеге, гыйбарә составындагы бер сүзнең дә синоним белән алыштыра алмавы [2; 129 б.].

Күпчелек лингвистлар мәкальләр фразеология өлкәсенә керми дип карыйлар. В. П. Жуков фикеренчә, мәкаль һәм әйтемнәр фразеологизмнардан структур-грамматик яктан аерыла, чөнки алар тәмамланган җөмлә булалар. Шунысы мөһим: мәкальнең нигезен фразеологизмнардагы кебек төшенчә түгел, ә фикер тәшкил итә [2; 130 б.].

Паремиологик берәмлекләргә лингвокультурологик анализ ясаганда, Р. Р. Җамалетдинов түбәндәге методологик күрсәтмәләргә таяна:

- Милли телнең паремиологик фондын халыкның мәдәни тәҗрибәсен туплаучы һәм тапшыручы иң мөһим чара дип тану;
- Телнең паремиологик пространствосының концептуаль бердәмлеген дөнья милли тел күренешенең мөһим өлешләрен вербальләштерүче өлкә дип тану;
- Паремияләрнең дөнья милли тел күренешенең кыйммәти тасвирламалары үзенчәлеген ачыклаудагы әһәмиятен тану.

Югарыда китерелгән фикерләргә нигезләнеп, без «ил» компонентлы паремияләр туплау өчен Н. Исәнбәт төзегән мәкаль һәм әйтемнәр җыентыгына мөрәҗәгать иттек [5]. Тупланган 100 дән артык мәкаль һәм әйтемнәрне без семантик төркемгә бүлдек. Мәсәлән:

1. «Ил» һәм «ир» концептларының бәйләнеше (илне ил итүче – ир-егет): *Ил бай булсын, ир җай булсын; Ил барда – ир хур булмас, ир барда – ил хур булмас; Ил бетмәсә, ир бетми; ил бетсә, ир дә кирәкми; Ил – иргә, ир – илгә таяна; Ил терәгә – ир, ир терәге – хатын; Ил терәге – яучыл ир белән юньчел хатын* һ.б. [5].

2. «Ил» һәм «шәхес» бәйләнеше (ил – таяныч): *Җире байның иле бай; Җире юкның иле юк; Ил агасыз булмас, тун якасыз булмас; Ил бай булса, ярлылыгың сизелмәс; Иле иркеннең көне иркен; Иле ныкның биле нык; Иле юкның икмәге юк, икмәге юкның түшәге юк; Иле юкның җире юк, тормышының юне юк* һ.б. [5].

3. «Ил» һәм «бердәмлек» (ил көче): *Адашсаң, ил белән адаш; Бердә түгел, илдә көч; Бердәм илдә бәрәкәт бар, гаугалы илдә һәлакәт бар; Бернең көне ил белән, илнең көне җир белән; Ил өрсә, буран кубар; Аерылган ил азар, кушылган ил узар* һ.б. [5].

4. «Ил» һәм «чит як» (туган ил һәм чит ил): *Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык; Гыйбрәт аласың килсә, чит илгә бар; Илгә кушылсаң – ир буласың, илдән аерылсаң – хур буласың; Иленнән аерылганның канаты каерылган* һ.б. [5].

5. «Ил» һәм «җир» (ил – җир – байлык): *Җире юкның иле юк; Кара алтын – җир мае, аның белән ил байый; Сусыз җиргә йорт корма, утсыз җиргә ил корма; Ашлык – ил байлыгы; Ил бай булса, ярлылыгың сизелмәс* һ.б. [5].

Шулай итеп, мәкаль һәм әйтемнәрдә халыкның киң колачлы, күпкырлы тормышы, кеше эшчәнлегенең, яшәешенең бөтен катлаулыклары һәм каршылыклары чагылыш таба. «Ил» концептының сүзлек мәгънәләре бердәмлек, төрлелек, туганлык, халык, көч, байлык, туган җир, тынычлык, табигать кебек мәгънә төсмерләре белән тулыландырыла, байый. Димәк, милли дөнья тел күренешен өйрәнүдә паремияләрне тикшерү линвомәдәни әһәмияткә ия.

**Кулланылган әдәбият**


1. Аскольдов С.А. Концепт и слово // Русская словесность: антология. – М., 1997.
2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.
3. Маслова В.А. Лингвокультурология: Учеб. пособ. для студ. высш. учеб. завед. – М.: Издательский центр «Академия», 2001. – 208 с.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: IV том: Л–Р. – Казан: ТӘҺСИ, 2018. – 760 б.
5. Татар халык иҗаты: мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 592 б.


© Кашаева А.И., 2025

УДК 811.512.145

**Кашаева Г.Ф.,**
*студент 5 курса БГПУ им.М.Акмуллы*
*Научный руководитель –* **Халиуллина Н.У.,**
*доцент кафедры татарского языка и литературы БГПУ им.М.Акмуллы,*
*г. Уфа, Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «ЙӨРӘК» КОНЦЕПТЫ

***Аннотация.*** *Мәкаләдә татар халкының дөнья тел картинасында «йөрәк» концептының структурасы анализлана. Әлеге концепт татар тел дөнья картинасында формалашкан универсаль һәм милли, социаль, индивидуаль стереотиплар суммасы буларак карала.*

***Теркәк сүзләр:*** *концепт, татар теле, дөньяның тел картинасы, стереотип, менталитет.*

Дөнья реалияләре төрле халыкларның яшәү эшмәкәрлегендә яшәү рәвешенә бәйле рәвештә актуальләшә икән, гомумкешелек һәм милли үзенчәлекле дөньяны кабул итү стереотиплары барлыкка килә. Телдә ул стереотиплар бертөрле яки төрле-төрле чагылыш табарга мөмкин. Беренче очракта эквивалентлы берәмлекләр барлыкка килә. Икенчесендә милли телнең үзенчәлеге чагыла, бер үк логик-семиотик формула төрле образлар белән тулылана.

Фразеологиядә еш кына бер үк логик-семиотик формула – стереотиплы гомумкешелек фикере милли-мәдәни маркерлы компонентларны алу белән вербальләшә: Чагыштырыйк:

| татарда | руста |
|---|---|
| *йөрәккә ук* | *нож в сердце* |
| *авызыңа бал да май* | *хлеб да соль* |
| *он (камыр) итү* | *разбить в пух и прах* |
| *бәгырькәем (бавыр)* | *сердце мое!* |

Димәк, безнең дөнья турында күзаллавыбыз ул, беренчедән, җәмгыять үсешендәге гомумкешелек факторларына, үз-үзеңне тотуның социаль нормаларына, икенчедән, дөньяны милли маркерлы күрү үзенчәлекләренә һәм, ниһаять, индивидуаль факторларга бәйле. Шуңа күрә гомумән халыкның һәм аның аерым вәкилләренең тел дөньясын күрүне формалаштыруда катнашкан универсаль, милли үзенчәлекле, социаль һәм индивидуаль стереотипларны табып була.

Йөрәк һәм күңел татар халкында синонимик төшенчәләр: *бөтен йөрәгем белән – бөтен күңелем белән, чын йөрәктән – чын күңелдән.* Әмма халык күңеле – ул аның хисләре генә түгел, ә дөнья өчен борчылулары да. Һәр халыкның үзенең күңеле бар. Ә нәрсә соң ул күңел? Гомумкешелек аңламында ул хисләр, эмоцияләр, кичерешләр җыелмасы символы. *Җан, күңел* – якын төшенчәләр. Кеше аңлавында «күңел» ниндидер тотып булмый торган, иссез, төссез абстракт орган. Әмма телдә аның сыйфатлары ачык сурәтләнгән. Бу бигрәк тә фразеологиядә - кеше яшәешен образлы сурәтләүдә чагылыш тапкан.

Чагыштырыйк: фразеологик әйтелмәләрдә *җан әрни, шатлана, өзгәләнә, өлешләргә бүлгәләнә, җанны әйләндереп чыгарырга* була, аны таптарга, аңа төкерергә була, карарга мөмкин. Аның тирәнлеге бар, ул табан астына төшәргә, очарга, очарга, күкләргә күтәрелә ала. Нәрсәдер күңелгә ошамаска, кем беләндер күңел биреп сөйләшергә, бөтен күңел белән нәрсәгәдер бирелергә мөмкин. Барлык бу сыйфатларны схема рәвешендә күрсәтеп була:

үзәктә урнашкан
катлаулы төзелешле (*күңел тыкрыкларында*)
**КҮҢЕЛ** савытка ошаган (*күңелеңне ачу, күңел тирәнлегендә*)
җиңел (*күңел очты*)
аның аша кешегә тәэсир итеп була (*күңелгә төкерергә*).

*Йөрәк* сүзе туры мәгънәсендә анатомик термин буларак аңлашыла: кешенең яки хайваннарның сул күкрәк куышлыгына урнашкан, кан әйләнешен тәэмин итә торган мускуллы капчыксыман әгъза. *Шуннан Фәридә йөрәк авырулы хаста булып чыкты, гомере буе мантымады.* (А. Гыйләҗев). Күчерелмә мәгънәдә килгәндә йөрәк – кешенең һәртөрле хис, тойгы, кичерешләр җыелмасы символы. *Халык йөрәгенә иңгән шушындый җырлары булу шагыйрь өчен олы бәхет түгелмени?!* (М. Галиев). Шулай ук, ул – мәхәббәт хисләрен белдерә торгансимвол.

*Мәхәббәте булмагач соң,*
*Ничек яшәр ул йөрәк?*
*Йөрәккә бит үз дигәне,*
*Үз сөйгәне – син кирәк*! (Г. Зәйнашева).

Кешенең эчке дөньясы, күңеле дә йөрәк лексемасы аша белдерелә. Мәсәлән, *Без яшәгән илнең матурлыгын Йөрәк белән кирәк тоярга.* (С. Хәким). *Хатирәләр түреннән чыгып, Искәндәрев алдына баскан, аның йөрәген туктаусыз борчып торган сорау шушы иде.* (Ә. Еники).

Концепт буларак, йөрәк түбәндәге төшенчәләрне дә берләштерә:

– Интуиция: *Кайдадыр якында гына үлем сагалап йөргәнен йөрәге белән тоеп, бер мизгелгә үкереп җибәрәсе килсә дә, тешләрен кысып тыелып калды*. (Р. Мөхәммәтҗан).

– Кайбер сыйфатлар белән килгәндә, кешене билгеләгән эчке табигате, холкы: *Мин сине олы йөрәкле, кыю егет дип йөрсәм, син, Әнвәр, вак җанлы мещан икәнсең.* (Р. Ишморат). *Әлеге мыскыллауларга таш йөрәк тә түзмәс иде.* (Н. Гыйматдинова).

– Тәвәккәллек, кыюлык, гайрәтлелек. Телефонист: *Әгәр дә егет булсаң, командирыңа төзәп атылган дошман пулясын, күкрәгеңне куеп, килгән юлыннан туктат. Билгеле, моның өчен йөрәк кирәк.* (Ф. Кәрим). *Авыз ачып сүз дәшәргә дә йөрәге җитми.* (А. Вергазов).

– Күңел; намус, вөҗдан:

*Мин кабыздым җырда ялкын итеп*
*Йөрәгем һәм хаклык кушканны.* (М. Җәлил).

*Йөрәк кушканны тыңласаң, Акыл белән эш итсәң, Юлың һәрвакыт уң булыр.* (Ә. Хәсәнов)

– Нәрсәнең дә булса үзәге. *Сугыш башланып өлгермәде, дошман инде безнең илебезнең йөрәгенә сузыла башлады*. (И. Гази).

– Ярату хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. Иркәләү төсмере тартым формасын алганда барлыкка килә: *Кал инде, Асиякәем, йөгермә инде, кал инде, йөрәккәем!* (З. Зәйнуллин) [ТТАС, II: 733-734].

Димәк, төшенчәләр берләшмәсе буларак йөрәк концепты материаль объектны (әгъза, мускул, күкрәк, капчык), абстракт билгеләрне (үзәк, күңел), психологик күренешләрне (хис, күңел кичерешләре, кайгыру, иркәләү, холык, табигать һ.б.) сыйфатларны (тәвәккәл, кыю, гайрәтле), предикатларны (куша, яна, ярсый, көя һ.б.) берләштерә.

«Йөрәк» концептының субстанциональ, адъектив, предикатив мөнәсәбәттә торган сүзләр даирәсе дә игътибарга лаек. Монда *боз, тоз, пычак, ук, ут, ит, ишек, май, йон, мүк, таш* кебек исемнәрне атарга була. Йөрәк *ачыла, туңа, сеңдерә, тырнала,ката, җылына, кайнарлана, әрни, киселә, ярыла, чымырдый, «жу» итә* һ.б. Югарыда әйтелгәннәр халыкның дөньяны танып белүдә образлы фикер йөретүе нәтиҗәсендә туа.

**Әдәбият исемлеге**


1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.
2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
4. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 495 б.

5. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. II том. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1990. – 365 б.
6. Хайруллина Р.Х. Фразеологическая картина мира: от мировидения к миропониманию. – Уфа: Изд-во Башк. ун-та, 2000. – 285 с.
© Кашаева Г.Ф., 2025

УДК 821.512.145

**Каюмова Г.Ф.,**
*доцент кафедры татарской литературы ИФМК КФУ,*
*г. Казань, Россия*

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ҮРНӘК ПРОГРАММАЛАР АША КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУ ЮЛЛАРЫ

***Аннотация**. Бу мәкаләдә без татар әдәбиятын туган әдәбият буларак өйрәнүче укучыларда әдәби әсәрләр нигезендә коммуникатив универсаль уку гамәлләре формалаштыру мөмкинлегенә тукталдык. Дәреслекләргә кертелгән әсәрләрне өйрәнгәндә укучыда коммуникатив компетенция формалаштырырга мөмкин булуы ачыкланды.*
***Терәк сүзләр**: татар әдәбияты, коммуникатив компетенция, татар әдәбияты программалары, әдәбият укыту методикасы.*

Әдәбият дәресләрендә коммуникатив универсаль уку гамәлләрен формалаштыру турыдан-туры дәреслектәге биремнәр белән бәйле. Ягъни, әдәби әсәрләр нигезендә тәкъдим ителгән биремнәр укучының сөйләм эшчәнлегенә юнәлтелгән булырга тиеш. Мәсәлән, Ә.М. Закирҗанов, Г.Р. Габделхаковалар тарафыннан 5 нче сыйныфлар өчен тәкъдим ителүче «Әдәбият» дәреслеген карап китик. Дәреслеккә Г. Ибраһимовның «Яз башы» әсәре кертелгән. Әлеге хикәяне анализлау өчен тәкъдим ителгән биремнәрне карап, аларның кайсылары укучыда коммуникатив компетенция формалаштыруга этәргеч бирә – шуларны тикшерик. Мисал өчен, «Тимеркәй белән Апрайның үз-үзләрен тотышын бәяләгез» [1, 7 б.] дигән биремне генә алыйк. Ул турыдан-туры укучыда коммуникатив УУГ формалаштыруга юнәлтелгән. Чөнки укучы бирем шарты буенча, ике персонажга карата үз фикерләрен белдерергә тиеш була. Ә сөйләме матур һәм төгәл килеп чыксын өчен, ул тиешле сүзләр кулланып эш итәргә, әсәр тукымасыннан читкә китмичә җавап бирергә тиеш.

Хикәя буенча чираттагы бирем шундыйрак: «Салихның авылдашы Фәхри сөйләгән вакыйганы укып чыгыгыз, фикер алышыгыз» [1, 78 б.]. Бирем шарты буенча укучылар бер-берсе белән фикер алышырга тиеш. Бу очракта дискуссия оештыру да отышлы санала. Мөстәкыйль эш төрле буларак дискуссия оештыру төрле кагыйдәләргә буйсына, нindидер максат белән уздырыла һәм укучыда коммуникатив УУГ формалаштыруда мөһим роль уйный. Дискуссия вакытында укучы үз фикерләрен төгәл һәм үз-үзенә ышанып җиткерергә өйрәнә. Дискуссия формасында оештырылган эш укучының белемнәрен арттырып кына калмый, ә бәлки аны фикер йөртергә дә өйрәтә. Дискуссия процессында катнашу яки аны башлап җибәрү шулай ук осталык таләп итә. Татар әдәбиятын туган әдәбият буларак өйрәнгәндә, дискуссиядә катнашу, башкаларны тыңлау һәм ишетү – мөһим моментлардан санала һәм коммуникатив компетенция формалаштыруның барлык үзенчәлекләрен дә үз эченә ала. Димәк, Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясен анализлаганда да дискуссия коммуникатив УУГ формалаштыру чарасы буларак кулланыла ала.

Укучыларда коммуникатив УУГ формалаштыру максатыннан, татар төркемнәрендә, 9 нчы сыйныфта өйрәнелә торган Хәят» әсәрен анализлауда нindирәк эш төрләре кулланырга булуына тукталыйк. Әсәрнең төп героинясы Хәят, шуңа күрә аңа бәйле үзенчәлекләрне тулысы белән ачу төп бурычлардан санала. Бу очракта, укучыларны төркемнәргә бүлеп, аларга төрле биремнәр йөкләү дә максатка ярашлы булып тора. Мисал өчен, кызның социаль

чыгышын билгеләү, аның белем һәм тәрбия алу үзенчәлекләрен ачыклау, Хәятка бирелгән кайбер иркенлек чыганакларын характерлау кебек биремнәр формалаштырырга мөмкин. Укучылар төркем эчендә үзара киңәшләшә һәм бер фикергә килеп җавап бирә. Әдәбият дәресләрендә әсәрләрне анализлауның иң нәтиҗәле ысулларының берсе – кечкенә төркемнәрдә эшләү методын куллану. Эшнең әлеге төре укучыларның сөйләм компетенциясен үстереп һәм дәрестә вакытны нәтиҗәле кулланырга этәргеч биреп кенә калмый, ә бәлки укучыларның шәхесен сизелерлек дәрәҗәдә үстерергә, аларда командада эшләү, үзара хезмәттәшлек итү күнекмәләрен дә формалаштырырга ярдәм итә. Монда, бер яктан, тәнкыйди фикер йөртүнең мөһимлеге турында искәртеп үтсәк, икенче яктан, сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен яхшы җирлек булуын да искәртергә кирәк.

Татар әдәбияты дәресләрендә кейс-технологиядән файдалану да коммуникатив күнекмәләр булдыруда мөһим роль уйный. Кейслар, нигездә, чәчмә әсәрләр буенча төзелеп тәкъдим ителә. Кейсның иң элементар үрнәге түбәндәгечә: укучыларга әсәрдән нинди дә булса әхлакый мәсьәләне үз эченә алган өзек тәкъдим ителә. Алар алдында вакыйгаларның алга таба үсешен алдан күрү бурычы тора, ягъни алар әсәр эчтәлеге буенча алда ни булачагын күзалларга тиеш була. Мисал өчен Ф. Әмирханның «Хәят» әсәрен алыйк. Әсәр уртасында төп героиня Хәят ике ут арасында – сайлау арасында кала. Моңа татар һәм рус мәдәниятләре сәбәпче була. Шулай ук аларның рус егете белән мөнәсәбәтләре дә кызыклы гына үрелә башлый. Укучыны әсәрнең ахыргы өлеше, һичшиксез, кызыксындыра. Димәк, бу урында әңгәмә оештыру отышлы. Укучылар әсәрнең азагы ничек тәмамланачагын үзләре тәкъдим итә. Аларның фикерләре тыңланганнан соң, әсәрне уку дәвам иттерелә, ягъни сыйныфтагы укучылар әсәрнең дәвамы белән таныша. Шул ук вакытта укучы үзенең фаразларын автор фикере белән чагыштыра ала. Әсәр укылып беткәннән соң, бәхәсне дәвам итәргә дә була. Бу иҗади эш төре булып санала. Моның бердәнбер җитешсезлеге: әлеге ысул ярдәмендә роман һәм повестьлардан өзекләр яки кыска әсәрләр генә анализлана ала. Әмма шунысын әйтергә кирәк: әлеге ысул нигезендә укучыда тиешле дәрәҗәдә коммуникатив компетенция формалаштырыла. Әдәбият дәресләрендә, коммуникатив УУГ формалаштыру максатыннан, төрле катлаулылыктагы кейслар кулланыла. Шуларга тукталып китик. Беренче дәрәҗә авырлыктагы кейслар практик ситуациянең булуын һәм аны хәл итүне күз алдында тота. Укучылар әлеге ситуациянең туры килү-килмәвен яки башка вариантларын билгеләргә тиеш. Мисаллар китерик: «Сез Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә Акъәбинең балаларының әниләренә карата кылган гамәлләре белән килешәсезме?», «Сез Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәрендә операция барышында ни өчен асситентларның, шәфкать туташларының йөзендә борчылу сизелә?» һ.б. Икенче дәрәҗә авырлыктагы биремнәрдә әсәр нигезендә алынган тормыш ситуациясе аерып бирелә һәм укучыларга аны хәл итү юлларын табарга кирәк була. Мәсәлән, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәрендә «ак чәчәкләр» образы әсәр эчтәлеген ачуда нинди роль уйный? Өченче дәрәҗә авырлыктагы биремдә билгеле бер катлаулы ситауция тәкъдим ителә, укучы аны хәл итү юлларын табарга тиеш була. Мәсәлән, М. Маликованың «Чәчкә балы» әсәреннән тема һәм проблемаларны аерып чыгару кебек биремне тәкъдим итәргә мөмкин. Мондый төргә караган кейс әсәрне беренче тапкыр укып чыннан соң ук тәкъдим ителә. Кагыйдә буларак, укучыларның күбесе эчтәлек сөйли башлый. Укучыларның күпмедер өлеше әсәрдәге төп тема итеп әхлак мәсьәләләрен, туган җирне ярату кебек хисләрне аерып чыгара. Шулай итеп, кейс ситуацияләр укучыда башка күнекмәләр белән беррәттән, коммуникатив УУГ формалаштыруда да отышлы алым булып санала. Әдәби әсәрне анализлаган вакытта үстерешле укыту технологиясеннән файдалану да коммуникатив компетенция формалаштыруда максатка ярашлы санала. Моны мисал өстендә карап китик. Г. Тукайның «Өзелгән өмид» әсәре татар төркемнәрендә 9 нчы сыйныфта өйрәнелә. Укучыга үстерешле укыту технологиясенең мөһим бер этабы булган модельләштерү кебек эш төре тәкъдим ителә. Моның өчен, түбәндәге таблица бирелә һәм укучы аны тулыландырырга тиеш була. Тема, идея, композиция һ.б. Әлеге модель шул рәвешле шактый озын дәвам иттерелә ала. Иң мөһиме – укучы әлеге модель буенча һәр станциягә аерым тукталып, шуны тәфсилле

рәвештә бәян итәргә тиеш була. Димәк, шул рәвешле укучыда коммуникатив компетенция формалаштырыла.

Нинди дә булса әсәрләр буенча языла торган иншалар да коммуникатив компетенция формалашытруга зур этәргеч бирә. Инша язу барышында укучы җөмләләренең төгәллегенә, фикер эзлеклелегенә игътибар итәргә, аларны бозмаска тиеш була. Шул ук вакытта бу очракта әсәр тукымасыннан читкә китмәү дә зур таләп булып тора.

Коммуникатив компетенция формалаштыруда сорауларга җавап бирү мөһим урыннарның берсен биләп тора. Мисал өчен, Г. Кутуйның «Рәссам хикәясен» өйрәткәндә, сорауларны дифференциальләштереп тәкъдим итәргә була. Бу очракта сораулар өч төрле авырлыкта төзелә һәм өч төрле белем дәрәҗәле укучылар өчен бирелә. Беренче төркемгә әдәбият фәнен яхшы белгән укучылар туплана һәм алар өчен түбәндәге сорауны әзерләргә мөмкин: «Немец офицеры белән очрашу мизгеле сездә нинди хисләр тудырды? Ни өчен, аңлатыгыз?» Димәк, әлеге төркемдәге укучылар өчен иң катлаулы дип саналган сорауларның берсе бирелә. Бирелә әсәрдәге вакыйга буенча гына түгел, ә бәлки үз фикерләреңә нигезләнеп тә җавап бирергә кирәк. Икенче төркемгә әдәбият фәнен уртача үзләштерүчеләр туплана һәм аларга түбәндәге сорау тәкъдим ителә ала: «Рәссам нинди максат белән партизаннар отрядында кала?» Өченче төркемдәге укучылар фәнне авырданрак үзләштерә һәм аларга иң җиңел сорауларның берсе бирелә: «Шәһәр ни өчен бушап калган?» Димәк, дифференциаль биремнәр шулай ук укучыда коммуникатив УУГ формалаштыруда мөһим аспектларның берсе булып санала һәм алар укучыны төрле юнәлештә фикер йөртүгә этәрә.

Гомумиләштереп әйткәндә, әдәбият дәресләрендә төрле ысуллар аша коммуникатив компетенция формалаштырырга була. Моның өчен төрле типтагы бирем һәм авазлар тәкъдим ителә. Әдәбият фәненең турыдан-туры коммуникация эшчәнлеге белән бәйле булуын да искәртергә кирәк. Әмма шул ук вакытта дәресләрдә бертөрле бирем һәм күнегүләр куллану укучыны фәннән читләшергә дә мәҗбүр итә. Шуңа күрә эш төрләренең төптән уйланылган булуы һәм укучыларда коммуникатив УУГ формалаштыруга юнәлтелүе мөһим.

Коммуникатив УУГ формалаштыру максатыннан, әдәбият дәресләрендә түгәрәк өстәлләр оештыру да отышлы санала. Түгәрәк өстәл – актив өйрәтү методы булып тора, ул элек алган белемнәрне ныгыту, билгеле бер юнәлештәге мәгълүматны тулыландыру, проблемаларны чишү, позицияләрне ныгыту, дискуссия алып бару культурасына өйрәтүдә танып белү эшчәнлегенең оештыру формаларының берсе дип исәпләнә. Түгәрәк өстәлгә хас төп үзенчәлек тематик дискуссиянең төркем төркем эчендә алып барылуы.

Түгәрәк өстәлне үткәрүнең төп максаты – укучыларда үз фикерләрен әйтү, фикерләрен аңлату, тәкъдим ителгән карарларны нигезләү күнекмәләре булдыру. Шул ук вакытта өстәмә мәгълүмат белән баетылган материалны ныгыту һәм мөстәкыйль эшләү бергә алып барыла, шулай ук фикер алышу өчен тәкъдим ителгән проблемалар һәм сораулар да ачыклана.

Коммуникатив компетенция формалаштыру максатыннан үткәрелүче түгәрәк өстәл этаплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: әзерлек этабы; фикер алышу этабы; аналитик этап (йомгаклау).Әзерлек этабында укытучының роле максималь рәвештә бик зур: ул фикер алышу өчен материал буларак әсәрне сайлый, проблемалы мәсьәләне билгеләп куя (бәхәс тудыра торган) һәм әлеге мәсьәлә күпьяклы чишелешкә ия булырга тиеш. Нәкъ тә менә әлеге момент укучыда коммуникатив күнекмәләр булдыра. Шунысын да әйтергә кирәк: барлык әдәби әсәрләр дә күпьяклы чишелешкә ия түгел, гадәттә аларны чишү юлы бер генә була. Шуңа күрә андый әсәрләрне алу кирәкми. Шул ук вакытта укучы әсәрнең үзе белән дә каршылыкка керергә тиеш түгел. Түгәрәк өстәлдә чишеләсе мәсьәлә алдан формалаштырылган булырга тиеш. Бу түгәрәк өстәлнең дискуссия белән аермасын күрсәтә. Ягъни дискуссия вакытында сорау да, аңа карата аргументлар да дәрестә тәкъдим ителә, ә түгәрәк өстәл оештырганда, материал, ягъни әдәби әсәр тексты алдан тәкъдим ителә, шулай ук тәнкыйть мәкаләләреннән өзекләр дә бирелә ала. Аргументларны һәр укучы өйдә алдан сайлый (әлеге технология шәхси фикер йөртүгә һәм укучының шәхси коммуникатив компетенциясен үстерүгә басым ясый, бу да дискуссия белән түгәрәк өстәл арасындагы

аерманы күрсәтә). Шушы ук бу этапта укытучы түгәрәк өстәл барышының якынча тәртибен эшли. Болай итү көтелмәгән ситуацияләрдән качу чарасы буларак та бәяләнә. Түгәрәк өстәл башында укытучы кыскача кереш сүз сөйли. Ул язучы турындагы кыскача мәгълүматны, әсәрнең бастыру тарихын һ.б. үз эченә алырга мөмкин. Шулай ук әлеге этапта проблемалы сорау да бирергә була.

Рус төркемнәрендә 8 нче сыйныфта Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәре өйрәнелә. Мәсәлән, әлеге хикәяне өйрәнгәндә, түгәрәк өстәл оештырырга уйласак, «Әсәрдә пейзаж белән психологизм ни дәрәҗәдә бәйләнгән?» дигән сорауны бирергә мөмкин булыр иде. Түгәрәк өстәлнең тәртибе – укучыларны алдан әзерләү. Шуңа күрә, укучылар пейзаж белән психологизм үрелеп барган өзекләрне өйдә дә әзерләп килә ала. Мисал өчен түбәндәге өзекне генә алыйк: «Көн матур. Язгы кояш нуры минем күзләремә карый, ул, ахрысы, минем шатлыкны сизәдер, бераз елмайган кебек тоела» [2, 68 б.]. Әлеге өзек буенча тагын шундый сорау да биреп була: «Бу юллар аша Закирның күңел халәте ни дәрәҗәдә ачыла?»

Түгәрәк өстәлнең әзерлек этабын гамәлгә ашыру өчен алдан ук кул астында булырга тиешле җиһазларны барлау кирәк (аудио-, видеотехника, мультимедиа чаралары), моны алдан кайгырту зарур. Темага карап, өстәмә материалларның кәгазь яки электрон характерда булуы исәпкә алына. Шушы этапта укучыларга үз фикерләрен төгәл һәм дөрес итеп җиткерү өчен төрле киңәшләр бирелә. Фикер алышу этабы түбәндәгеләрне үз эченә ала: укытучының кереш сүзе; − әңгәмәнең гомуми кагыйдәләре турында мәгълүмат бирү (гомуми фразалардан, дәлилсез әйтелгән сүзләрдән читтә тору; башкаларны тыңлый белү; әңгәмә вакытында актив булу; фикереңне төгәл һәм кыска итеп җиткерү; тәнкыйди фикерләр әйтү; әңгәмәдәшеңне кимсетмәү); проблемалы сорауны яңгырату; билгеле бер эзлеклелеккә корылган җавапларны тыңлау, аларны билгеле бер фактларга, әсәр эчтәлегенә бәйле булуы мөһим; укытучы укучыларның җавапларына, әйтелгән фикерләренә нәтиҗәләр ясый: фикер алыша торган проблемалы мәсьәлә буенча каршылыкларның сәбәпләре һәм характерлары ачыклана. Йомгаклау этабы укытучының нәтиҗә ясап әйтелгән фикерләрен үз эченә ала.

Түгәрәк өстәл түбәндәгеләрне күз уңында тота: укучыларның проблеманы чишү юлларын билгеләү максаты белән фикер алышуга әзерлеге, теоретик белем һәм тәҗрибә булу.

Әдәби әсәрләрне чагыштырма планда өйрәнү шулай ук укучыда коммуникатив УУГ формалаштыруда зур роль уйный. Мисал өчен 11 сыйныфта Ә. Еникинең «Мәк чәчәге» һәм «Бер генә сәгатькә» әсәрләрен чагыштырып өйрәнергә була. Чөнки алар икесе дә бер үк тематикага – сугыш вакыйгаларына багышлана. Шушы юнәлештә укытучы укучыларга берничә эш төре тәкъдим итә ала.

Авторларның әсәрләренә кереш сүз сыйфатында, мәкальләрдән файдалану да бик отышлы. Чөнки мәкальне укып, аның мәгънәсен аңлату укучыдан зур тырышлык сорый. Мисал өчен, 6 нчы сыйныфта Һ. Такташның «Мокамай» әсәре өйрәнелә. Моның алдыннан, «Дуслык» темасына кыска проектлар да эшләп алырга мөмкин. Проектлар эшчәнлегенең шулай ук коммуникатив компетенция формалаштырудагы ролен ассызыклап үтәргә кирәк.

Укучыда коммуникатив УУГ формалаштыру эш төрләре белән тыгыз бәйләнештә тора. Дискуссия, сорауларга җавап бирү, дифференциаль эш төрләре, түгәрәк өстәл, үстерешле укыту технологиясенең бер өлеше буларак модельләштерү һ.б. укучыда коммуникатив компетенция формалаштыруга зур этәргеч бирә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Закирҗанов Ә.М., Габделхакова Г.Р. Татар әдәбияты. 5 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 207 б.

2. Хәбибуллина З.Н., Фәрдиева Ф.Г., Хисмәтова Л.К. Татар әдәбияты. 8 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 246 б.

© Каюмова Г.Ф., 2025

УДК 811.512.142

**Кетенчиев М.Б.,**
*профессор, заведующий кафедрой карачаево-балкарской филологии КБГУ,*
*г. Нальчик, Россия*

# КОНСТРУКЦИИ С ОБРАЩЕНИЯМИ В ПОЭЗИИ САИДА ШАХМУРЗАЕВА

***Аннотация***. *Статья посвящена творчеству известного карачаево-балкарского поэта С. Шахмурзаева. В ней рассматриваются обращения, употребляемые автором. Выявляются и описываются их структурно-семантические особенности, функциональный потенциал, а также эмоционально-ценностные интенции поэта.*

***Ключевые слова:*** *карачаево-балкарский язык, литература, С. Шахмурзаев, поэзия, обращение, структура, функция, семантика.*

Начав свою творческую деятельность в 1910-е годы, С. Шахмурзаев приложил много усилий для формирования и дальнейшего развития современной карачаево-балкарской литературы. Проблемы, которые актуализированы в его поэзии, не потеряли свою значимость и для современной духовной культуры, в частности для лингвокультурологии. К ним, например, можно отнести целый ряд вопросов, поднимаемых в специальных научно-теоретических работах: проблемы этнической идентичности [1], выявление и описание этнокультурно маркированной архаической лексики [2] и фразеологии [7], концептуальных понятий [3, с. 4] и др. Ниже остановимся на функционально-семантическом потенциале обращений, которые нашли нишу в поэтических текстах автора [6].

Обращение в языке обычно рассматривается в рамках синтаксиса. Карачаево-балкарские языковеды, как и другие тюркологи, интерпретируют данный феномен как конституент синтаксической конструкции, который является распространителем его предикативной основы. Применительно к предмету нашего исследования важным представляется мнение И.И. Ковтуновой о том, что «обращение к предмету речи – естественная черта языка лирики, органически ему присущая» [5, с. 93].

В поэтической речи карачаево-балкарских авторов лексическая наполняемость позиций обращения относительно свободная, но у каждого поэта в этом отношении наблюдается своя специфика. Так, у основоположника балкарской поэзии К. Мечиева имеют место обращения поэта к самому себе, выраженные именем собственным, чего нельзя сказать относительно С. Шахмурзаева. У него обращения к лицам представлены в большей степени номинациями детей и школьников, работников сельского хозяйства: *Школчула, сабийле, // Биз кетейик наныкъгъа* «Школьники, дети, // Пойдем собирать малину мы»; *Колхозчула, совхозла, // Биченни кёп этейик* «Колхозники, совхозы, // Сена заготовим много». Наряду с такими встречаются и конструкции, в которых вокативы гендерно маркированы: *Жашчыкъла эм къызчыкъла, // Турма салып къарайыкъ* «Мальчики и девочки, // Будем редиску сажать».

Хоть и не так часто, можно заметить употребление обращений, выраженных антропонимами, которыми наречены персонажи некоторых произведений: *Сау къал, Шамил, мен башха шофер табарма* «Шамил, до свидания, я другого шофера найду»; *Унутулмазса, Азрет!* «Не будешь забыт, Азрет!»; *Хыйны этгенсе, Зухра, манга, // Къул болдум ахыр санга* «Одурманила, Зухра, меня, // Стал рабом я для тебя»; *Дертлиме, Тахир, ийнан, // Сенсе жаныма дарман* «В мечтах я, Тахир, поверь, // Ты лекарство для души моей».

Для автора характерно употребление обращений с уменьшительно-ласкательным аффиксом *-чыкъ/-чик*, что обусловлено адресованностью поэтической речи к детям, привлечением их внимания к выполнению общественно полезного труда: *Сабийчикле, келигиз, // Бахчалагъа барайыкъ* «Подходите, детки, // Пойдем на огороды»; *Ариу жашла, къызчыкъла, // Тереклени салайыкъ* «Красивые ребята и девчата, // Посадим мы деревья».

В рассмотренных выше синтаксических конструкциях обращения являются простыми, однословными. Однако они могут и распространяться за счет междометных лексем и адъективов: *Эслеп аша, эй жашчыкъ, // Аман кючлю турмады* «Осторожно ешь, эй мальчик, // Очень редька уж горька»; *Ариу-ариу сабийле, // Ариу, айбат кийигиз* «Красивые-красивые дети, // Чисто и нарядно одевайтесь»; *Къоз терекле салыгъыз, // Малкъар къыз эм малкъар жаш!* «Ореховые деревья сажайте, // Девушка-балкарка и парень-балкарец!». В них адъективные атрибуты формально являются факультативными, но их невозможно элиминировать без смыслового ущерба.

Рамки обращения автором расширяются и за счет других языковых единиц, например, благодаря причастным оборотам, сравнительным дескрипциям и т.д.: *Жаным сюйген жан нанықъ, // Сабийлеге жомакъса* «Душой любимая малина, // Сказка ты для ребятни»; *Жаным кибик жан хораз, // Кёзлеринг маржан хораз, // Бек эртелеп тураса, // Жукъларгъа нек къоймайса?* «Словно душа моя петух, // С коралловыми глазами петух, // Очень рано ты встаешь, // Почему спать не даешь?».

Значительными функциональными возможностями у С. Шахмурзаева отмечены обращения, позиции которых замещаются субстантивными нарицательными лексемами, обозначающими объекты флоры и фауны, которые наличествуют в стихотворениях для детей о мире животных и растений: *Сау келигиз, зурнукларым!* «Добро пожаловать, мои журавли!»; *Ой, жумукъул, жумукъул, // Къаялада битесе* «О костяника, костяника, // В горах ты растешь».

Ср. конструкции *Нанықъ-нанықъ, ой нанықъ, // Къызыл алтын токъмакъса* «Малина-малина, ой малина, // Из красна золота бубенчик»; *Герге-герге, гергечик, // Ариу назик гитчечик* «Жаворонок-жаворонок, жавороненок, // Красивая, стройная и маленькая». В них налицо употребление такого стилистического приема, как повтор, который усиливает выразительность поэтической речи и способствует ее эмоциональной окрашенности.

В этом плане примечательно произведение автора «Саулукъ» («Здоровье»), представляющее собой стихотворение-обращение, воспевающее здоровье. В нем налицо авторское эмоционально-ценностное отношение к нему поэта:

*Саулукъ, сенсе жарыкъ дунья атасы,*
*Саулукъ, сенсе жашауланы къаласы,*
*Саулукъ, сенсе кёзюбюзню инжиси,*
*Саулукъ, сенсе ариулукъну гинжиси,*
*Саулукъ, сенсе хазналаны ачхычы,*
*Саулукъ, сенсе узун ёмюр басхычы,*
*Саулукъ, сенсе насыплыны жарыгъы,*
*Саулукъ, сенсе игиликни чырагъы,*
*Саулукъ, сенсе жашауланы баш-башы,*
*Саулукъ, сенсе къууанчлыкъны байрагъы,*
*Саулукъ, сенсе жюреклени ийнагъы.*

Подстрочный перевод:

Здоровье, ты светлого мира отец,
Здоровье, ты жизней крепость,
Здоровье, ты жемчуг наших глаз,
Здоровье, ты кукла красоты,
Здоровье, ты ключ от многих кладов,
Здоровье, ты долголетия ступень,
Здоровье, ты счастливого отрада,
Здоровье, ты доброты светило,
Здоровье, ты вершина жизни,

Здоровье, ты радости знамя,
Здоровье, ты любовь сердец.

В поэзии С. Шахмурзаева часто встречаются обращения, которые характеризуют адресата, чему в первую очередь способствуют обособленные причастные и деепричастные обороты:

*Ой, жугъутур, жугъутур,*
*Тауда кырдык отлаучу,*
*Сакъалынгы жер тарай,*
*Ёхтем-ёхтем атлаучу.*

Подстрочный перевод:

Ой, тур, тур,
В горах пасущийся,
Бороду твою ветер развевая,
Гордо-гордо шагающий.

Небезынтересна и роль фразеологических единиц в составе стихотворных рядов с обращениями. При этом фразеологизмы носят релятивный характер и способствуют репрезентации положительной оценки адресата. По количеству компонентов они в основном подразделяются «на двухкомпонентные, трехкомпонентные и многокомпонентные, которые представлены различными моделями» [7, с. 261]. Приведем примеры: *Туугъан тилим, сенсе мени жарыгъым, // Ана тилим – жан тамырым, чырагъым* «Родной язык мой, ты мой свет, // Язык матери моей – сосуд души моей, мой светоч» и др.

Автором регулярно употребляются присущие для карачаево-балкарского этикета обращения, которые выражаются лексемами с аффиксами принадлежности:

*Жюйюсханым, сыйлы, уллу ханыбыз,*
*Не айтаса, не этейим, ёлейим?*
*Нек чакъырдынг, айтчы, жаным, жарсыуунг?*
*Буйругъунгу сен айтханча этейим.*

Подстрочный перевод:

Господин мой, почитаемый, великий хан,
Что ты скажешь, что мне делать, умереть?
Зачем позвал, скажи, душа моя,
Приказ твой выполню, как ты сказал.

Посредством подобных и иных обращений С. Шахмурзаеву удается отразить культурные реалии карачаево-балкарского этноса. Они отмечены значительным функционально-семантическим потенциалом. Для них присуще многообразие грамматических форм, а также широкий спектр значений, что дает возможность ему, с одной стороны, отразить различные стороны карачаево-балкарского языкового сознания, с другой – собственно авторское мировосприятие.

**Список литературы**

1. Базиева Г.Д., Узденова Ф.Т. Карачаево-балкарская литература и проблемы этнической идентичности // Полилингвиальность и транскультурные практики. – 2019. – Т. 16. – № 3. – С. 358–365.

2. Кетенчиев М.Б., Ахматова М.А., Додуева А.Т. Архаическая лексика в карачаево-балкарских паремиях // Полилингвиальность и транскультурные практики. – 2022. – Т. 19. – № 2. – С. 297–307.

3. Кетенчиев М.Б., Додуева А.Т., Ахматова М.А. Полиаспектный анализ названий дней недели в карачаево-балкарском языке // Балтийский гуманитарный журнал. – 2019. – Т. 8. – № 2 (27). – С. 248–251.

4. Кетенчиев М.Б., Додуева А.Т., Хуболов С.М. Названия месяцев в карачаево-балкарском языке // Вестник Череповецкого государственного университета. – 2019. – № 6 (93). – С. 109–118.

5. Ковтунова И.И. Поэтический синтаксис. – М.: Наука, 1986. – 206 с.

6. Саид Шахмырза Назму чыгъармалары. – Нальчик: Эльбрус, 2006. – 360 б.

7. Хуболов С.М. Семантические разряды компаративных фразеологизмов в карачаево-балкарском языке // Известия Кабардино-Балкарского научного центра РАН. – 2015. – № 1 (63). – С. 290–294.

© Кетенчиев М.Б., 2025

УДК 81'373

**Киселева Л.А.,**
*профессор Самарского национального исследовательского университета имени академика С.П. Королёва,*
*г. Самара, Россия*

## МЕТАФОРИЗАЦИЯ ЭМОЦИЙ В СОВРЕМЕННОМ МЕДИАДИСКУРСЕ

***Аннотация.*** *Статья посвящена систематизирующему описанию наиболее продуктивных метафорических моделей, которые лежат в основе языковой интерпретации эмоций в рамках современного русскоязычного медиадискурса. Выявлено, что метафорические номинации в основном используются для описания негативных эмоций, таких как страх, возмущение и т.д. Высокая степень продуктивности характерна для метафорических моделей, которые в образной форме описывают эмоции путём их ассоциирования с предметными и природными реалиями.*

**«Тулпар» журналындагы кайбер материалларга тукталып үтик**. Журналда иң актив «әңгәмәдәш» – М. Вафин. Ул – журналист та, шагыйрь дә, тәнкыйтче дә. Шуңа күрә аның әңгәмәдәшләре һәрвакыт иҗади кешеләр: шагыйрьләр, язучылар, журналистлар. Әйтергә кирәк, М. Вафин үз әңгәмәләренә татар әдипләре генә түгел, башкорт һәм рус авторларын да чакыра.

Егерме елдан артык вакыт эчендә М. Вафин журнал битләрендә Р. Идиятуллин, М. Кабиров, М. Салимов, М. Кәримов, З. Зәйнуллин, Р. Зиязетдинов, Р. Чурагулов, М. Абделмәнов, Ә. Кәшфуллин, Д. Булгакова, Р. Гаташ, М. Кәрим, Н. Асанбаев, Д. Морзакаева, Н. Гаетбаев, Л. Соколов һ.б. белән әңгәмәләшкән. Бу елларда аңа кайбер әдипләрдән берничә тапкыр интервью алырга да туры килгән.

Бу әдәби тәнкыйть жанрында Д. Булатова, Л. Сәгыйдуллина, И. Фазлетдинов һ.б. эшләре дә бар. Игътибар итик: А. Зәкиевнең интервьюсы кызыклы һәм оригиналь – бу «үзе белән үзеңә әңгәмә». Анда автор бер яктан «үткен теле» журналист буларак, икенче яктан – язучы, прозаик буларак чыгыш ясый. Биредә журналист һәм язучы иҗат табигате, әдәби процесс турында сөйләшәләр.

Әдәби әңгәмәләрнең исемнәре дә шигъри характерда икәнен искәртергә кирәк: «Җирдә Кояш илчесе», «Әдәбият – йөрәк эше», «Шигърият чишмәсе корыр дип курыкмыйм», «Халык шагыйре – Сүз пәйгамбәре ул..», «Мин – ирекле кеше», «Шигъри күңелле тарихчы», «Тамырларым – туган җирдә», «Бу гомрем тәгәл бер көн кебек» һ.б. Эчтәлек ягыннан бу әңгәмәләр бик кызыклы, аларда шагыйрь һәм язучыларның фикерләре белән танышырга, аларның гомумән иҗатка, аерым коллегалар мирасына, республикабыз әдәби процессына, туган тел һәм мәдәниятькә, шулай ук тормыш принципларына мөнәсәбәтен аңларга мөмкинлек бирә.

Әдипләр арасында үз әсәрләре җыентыкларына коллегалары, галимнәр яки журналистларның кереш сүзләрен кертү традициягә әйләнгән. Әдәби тәнкыйттә мондый мәкаләләрне аерым жанрга аерып карыйлар. Башкортостанда татар телендә чыккан китапларның күбесендә мондый кереш сүзләр яки сүз башлары бар.

Мисал өчен кайбер эшләргә тукталып үтик. XX гасырның 90 нчы еллар башында Башкортстанда татар телендә басылган беренче китапларның берсе С. Рәхмәтулланың «Уяну» шигырьләр җыентыгы булды. Китап Башкортстан татар әдәбияты өчен зур әһәмияткә ия, беренчедән, билгеле булуынча, ул беренче «самиздат» китапларның берсе, икенчедән, җыентык тирән символлы, шигъри исемгә ия. «Уяну» сүзе Башкортстан татар әдәбиятының, төрле сәбәпләр аркасында шактый еллар «йокы» халәтендә булганлыгын, гомуми торышын бик тәгәл характерлый. Моңа сүзбаш авторы М. Вафин да игътибар итә, ул бу халәтнең әһәмиятен, шулай ук бу китапның Башкортстан әдәби мәйданындагы ролен ассызыклар өчен хәтта «уяну» сүзен берничә тапкыр кабатлый [6].

Кайбер китапларда үзенчәлекле кереш сүз форматы тәкъдим ителә: биредә авторның стиле, шигъри образлар, ачылулар, гомумән иҗатының индивидуаль хассияте турында шагыйрь, язучы, галимнәрнең кыска язмалары урын алган. Мисал өчен М. Вафинның «Тынлык моңы» китабын алыйк. Җыентыкта авторның иҗаты турында шагыйрь һәм язучы, галимнәр Ә. Атнабаев, М. Кәримов, И. Юзиев, Ә. Баянов, С. Поварисов, К. Дәүләтшин, Ә. Мәхмүтов, М. Мөлеков, Л. Сәгыйдуллина, С. Рәхмәтулла, М. Кәбировның кызыклы фикерләрен укырга мөмкин. Әлбәттә, бу язмаларның барысы да диярлек тулы вариантта массакүләм мәгълүмат чараларында басылган, бу китапта алар кыскартылып, бергә тәкъдим ителә [7].

Әдәби тәнкыйть жанрлары төрле, әмма татар әдәбият белемендә алар әлегә җентекләп тикшерелмәгән дияргә була. Башкортстанның хәзерге татар әдәби процессында түбәндәге әдәби тәнкыйть жанрлары күзәтелә: рецензияләр, ике формататта: китап яки билгеле бер әсәр буенча; китап яки шагыйрь-язучы иҗаты буенча уйлану-фикерләр; юбилей мәкаләләре; әдәби диспут (бәхәс); әдәби конкурс нәтиҗәләре буенча күзәтү; түгәрәк өстәл; әдәби әңгәмәләр (шагыйрьләр, язучылар һәм галимнәр белән интервьюлар). Барлык жанрлар да бик актив, аларның берсе дә игътибарсыз калган, дип әйтеп булмый.

Башкортстанда тәнкыйтьче-авторлар булып югары уку йортлары укытучылары һәм галимнәре К.С. Дәүләтшин, С.Х. Хафизов, Р.К. Әмиров, С.Г. Сафуанов, Л.Р. Сәгыйдуллина, И.К. Фазлетдинов, А.Г. Хәлиуллина, Р. Сөләйманов; язучы-шагыйрьләр М. Вафин, М. Кәбиров; журналистлар Ф. Фәткуллин, Л. Кәшфи, шулай ук мәктәп укытучылары һәм укучылары, югары уку йортлары студентлары, укучылар саналалар.

Башкортстанда татар телендәге әдәби тәнкыйть «Кызыл таң», «Өмет» гәзитләрендә, «Тулпар», «Башкортстан укытучысы» журналларында һәм башка шәхси массакүләм чараларда, шулай ук тәнкыйди эшләр җыентыкларында, уку әсбапларында басылган. Безнең тарафтан Башкортостан татар әдәбияты буенча әдәби-тәнкыйди эшләрнең шактый зур (500

дән артык) библиографиясе төзелде. Әлбәттә, барлык әдәби-тәнкыйди эшләрне кечкенә бер хезмәт кысаларында анализлап бетерү мөмкин түгел.

**Кулланылган әдәбият**

1. Амиров Р.К. О развити татарской литературы Башкортостана// Башкортостанда татар теле һәм әдәбиятын укытуда региональ компонент: фәнни-методик мәкаләләр җыентыгы / И.Е. Карпухинның гомуми редакциясендә; җаваплы ред. И.С. Насипов // Республика фәнни-практик конференциясе 4 апрель 2000 ел. – Стәрлетамак: Стәрлетамак дәүләт педогогия институты, 2001. – Б. 4–14.

2. Бәхәс тәмам // Тулпар. – 2007. – № 6. – Б. 36-37.

3. История русской литературной критики: учеб. Пособие для студ. высш. пед. учеб. заведений / [В.В.Прозоров, Е.Г. Елина, Е. Е. Захаров и др.]; под ред. В.В. Прозорова. 2-е изд., испр. и доп. – М.: Издательский центр «Академия», 2009. – 432 с.

4. Фазлетдинов И.К. Тәнкыйтьтә Башкортстандагы хәзерге татар поэзиясе // Tatarica. – 2016. – № 2 (7). – Б. 64–72.

5. Вафин М., Хафизов С. Туган җир музасы (Башкортстанда яшәүче татар телле шагыйрьләр иҗаты турында «кырлы» өстәл) // Тулпар. – 2001. – № 1. – Б. 23–30; Идиятуллин Р. Бу гомерем төгәл бер көн кебе... Әдәби кунакханә // Тулпар. – 2016. – № 3. – Б. 50–53; Фазлетдинов И. Хыял яшәешкә шундый якын. Әдәби кунакханә // Тулпар. – 2017. – № 1. – Б. 32–35; Вафин М. «Язучылык – күңел таләбем». Әдәби кунакханә // Тулпар. – 2019. – № 1. – Б. 72–73; Кәримов М. «Мин бервакытта да яраклашмадым». Әдәби кунакханә. Әңгәмәдәш М. Вафин // Тулпар. – 2022. – № 1. – Б. 2–4.

6. Вафин М. Соңгы сүз // Салават Рәхмәтулла. Уяну: шигырьләр, җырлар, поэмалар. – Уфа, 1993. – Б.195–199.

7. Вафин М. Тынлык моңы: шигырьләр. – Уфа: Китап, 2011. – 150 б.

© Мансуров И.С., 2025

УДК 821.512.145

**Мансурова З.Я.,**
*учитель МБОУ Каранская СОШ МР Буздякский район РБ,*
*с. Ураново, Россия*

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА АТ ОБРАЗЫ

***Аннотация***. *Әлеге мәкаләдә хәзерге татар әдәбиятында ат образының бирелеше карала. Шулай ук Х. Исмәгыйлев һәм А. Әхмәтгалиева әсәрләрендәге геройларның үсешендә һәм формалашуында атның ролен һәм әһәмиятен өйрәнү мәсьәләләре дә күтәрелде.*

***Терәк сүзләр***: *образлар; типиклаштыру; эпик хикәяләү; психологизм; системалылык.*

Ат – безнең төрки халкыбызның тугры юлдашы, гомумән, безнең яшәешебез аның белән аерылгысыз бәйләнгән. Ат образы, ат культы кардәш төрки халыкларның да рухи мәдәниятләрендә үзәк урын биләп тора. Ат борынгыдан килгән төрки дастаннарда төп каһарманның аерылгысыз юлдашы. Бәйгеләр, бәйрәмнәр, йолалар атсыз узмаган. Ат белән бәйле күп төрле ышанулар, йолалар татар тормышында зур урын тоткан. Борын-борыннан халкыбыз атка изге хайван дип караган, аны үзенең иң якын дусты, уң канаты дип санаган. Европа илләрендә ат иң бай кешеләрдә булса гына, безнең төрки бабаларыбызның ул тормыш таләбе булган. Көнкүреш – яшәешне атсыз күз алдына китерергә дә мөмкин түгел. Кырда, өйдә, төрле күңел ачу бәйрәмнәрендә дә ат мөһим рольне уйнаган

Татар әдәбиятына килгәндә, Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе, Г. Тукайның «Пар ат» поэмасы, И. Юзеевның «Йолдыз кашка турында баллада»сы, М. Галиевнең «Ат

рухы», А. Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәрләре дә язучыларыбыз бу образга битараф булмаулары хакында сөйли. Күз алдыбызга иксез-чиксез болыннарда утлап йөргән атлар, шул атларны кичкырын сакларга чыккан малайлар, янып торган учак күз алдына килә. Ул гына түгел, ирексездән, авыз эченнән генә «ниләр генә күрми бу дөньяда ир-егеткәй белән ат башы», дип көйли башлыйсың. Бу әсәрләр үткән гасырда калса да, алар атка мәдхия җыры булып яңгырый. Ат образының, башка образлар белән янәшә караганда, «әхлакый-эстетик бирелеше, эмоциональ көчергәнеше» [7, 648 б.] шактый көчле.

XX гасыр азагы–XXI гасыр башында ат образы традицион героик-романтик яссылыкта буыннар, шәхес язмышы белән бәйләнештә ачылу белән бергә фәнни-техник революция тудырган рухи-әхлакый югалтулар яссылыгында яңача сурәтләнә башлады. Ат язмышы ил язмышы символына әверелде. Ат һәм башка йорт-кура малы үзләрендә халык язмышын, кеше һәм табигать мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерде [1; 33 б.].

Татар язучысы өчен кешелек һәм табигать дөньясының бәйләнеше аерылгысыз. Язучылык эшенә соң гына керешүеннән карамастан, бүгенге көн татар әдәбияты мәйданында үз урынын тапкан, үз аудиториясын булдырган Хисаметдин Исмәгыйлев иҗатына күз салсак, югарыда әйтеп киткән фикерләрем бик урынлы. Беренче тапкыр Хисаметдин Исмәгыйлевның иҗаты белән танышуым «Тулпар» журналы аша, «Ат һәм без» повесте булды. Эчтәлеге буенча, автор үзе билгеләмәсә дә, әсәр автобиографик повесть жанрына карый. «Ат...Ике хәрефтән генә торган гап-гади сүз. Барлыгы ике хәреф. Һәм бу сүз берничә төрле мәгънәгә ия», – дип башлый автор үзенең әсәрен [5; 4 б.]. Повестьта Х. Исмәгыйлев ат сүзенә иң беренче чиратта тирән мәгънә салып куя. Авыл хуҗалыгында хайваннар күп булуына карамастан, ул «Миңа ат кадерлерәк», – ди [5; 4 б.].

Төп герой (автор үзе) безне 60нчы елларга алып китә. Авыл һәм урман хуҗалыгында барган вакыйгалар безне төрле кешеләр белән очраштыра. Геройның әтисе Шәрәфи авыл Советы рәисе булып эшли. Бик итагатьле, тырыш һәм кешелекле кеше. Бервакыт урманда рөхсәтсез агачлар киселә. Акт төзиләр, акт буенча берникадәр штраф тиеш була. Тик икейөзле кешеләр актны үзгәртеп, биш төп урынына унбиш төп дип үзгәртеп куялар. Урман түрәсе үзе үк урман кистереп, барча булган гаепне күрше колхоз рәисе өстенә тагарга уйлаган була. Шәрәфинең үткенлеге һәм игътибарлылыгы аркасында, кеше гомере сакланып кала. Ләкин шушы кешлеклеге аны һәм аның гаиләсен бик озак эзәрлекләп бара, автор үзе әйтмешли «нужа күрүләре» яңа гына башлана [5; 7 б.].

Авыл җирендә мал азыгы әзерләсәң дә, чүп түгәргәме, яки күрше авылга барып килүме – иң мөһим транспорт булып ат санала. Шәрәфи дә беркөнне аксак булса да ат алып кайта. «Чатанласа да ат, ат инде» [5; 9 б.]. Автор авыл җирендә яшәвенең бөтен матурылыгын да, авырлыгын да шушы ат образы аша безгә китереп җиткерә алган. «Татра» кушаматлы ат машинадан да кадерлерәк була ул вакытта. Ул кушаматны да юкка гына бирмиләр, «атның галәмәт көчле һәм акыллы булуын (безнең бригадта андый гәүдәле һәм көчле ат юк та иде әле) исәпкә алып, «Татра» дип исем куштык» [5; 10 б.]. Бу кушаматта ниндидер яшерен мәгънә дә салынган кебек. Әгәр хәрефләрнең урынын алыштырсак, Татар дигән исем килеп чыга. Бу халкыбызның ат кебек эшчән, тугры, тырыш кебек сыйфатларны үз эченә алган символик образ булып тора.

Атлы кешенең эше күбәйсә дә, дөнья көтүе дә бераз җиңеләя. Урман аланында төп геройның әтисе белән бергәләп печән чабу мизгелләре, печән чабуның тәме, тирә-яктагы кошлар сайравының моңы, үлән арасында сибелеп калган кып-кызыл җир җиләкләре дә, әлбәттә, ат белән бәйле. Чөнки авыл агаеның авыр хезмәтенә нигезләнгән яхшы, мул, имин тормышны, бәхетле тормышны да аттан башка күз алдына китереп булмый. Печән чабулар, атка утырып җырлы-җырлый кайтулар, кичен ат саклаулар, атлы кешедән авылдашларының көнләшүе – барысы да әсәрдә чагылыш таба. Беркөнне атлары Шәрәфиләрнең югала. Эзли торгач, күрше авылда казакъларда табалар. Алар «чегәннәр урлап китеп барганда, ташлап калдырдылар», – дип алдаша. Еллар үткәч кенә урман кисеп байый алмаган урман хуҗасының үч алу нияте белән эшләнгән икәне билгеле була.

Әсәрдә ат образы янындагы барган вакыйгалар безгә гореф-гадәтләрне генә түгел, шул чорда барган совет хакимиятенең гади халыкка булган мөнәсәбәтләрен, налог җыюлар, гади халык ничек булса да рәхәт яшәмәсен дигән кебек, мал исәбен алулар, артык булса, колхоз абзарына төшерүләр тасвирланган. «Шәрәфи законсыз ат асрый. Атын гомум хуҗалык файдасына тартып алырга» дигән карар чыгарып, эзәрлекләүләрен дәвам итәләр. Сугыш ветераны булган, инвалид Шәрәфи гаепсезгә гаепле булып, авыр вакытлар кичерә. Һәр җыелышта куркыныч җинаятьче кебек эшен тикшерәләр, янәсе «законсыз ат асрый». Атын бирмәгән өчен «Шәрәфигә баллонлы газ бирмәскә», «электр чыбыгын өзергә», «морҗа төбенә кадәр тикшерәләр» [5; 13 б.]. Шәрәфи абыйга «партбилетыңны өстәлгә куй» дигәндә дә ул үзенең тугры дусыннан ваз кичми. Шушы юлларны укыганда сорау туа: ни өчен шулкадәр эзәрлекләүләргә дә түзеп, атыннан баш тартмый ул? Чөнки аты башка бик күп татар халкының тамагын туйдыручы, эшчәнлек, җаваплылык, тугрылык кебек сыйфатларны булдыручы. Шәрәфи карт та, аның улы да (автор үзе) атның кадерен белә. Әсәрдән күрүебезчә, кешелек дөньясы бер генә түгел, икейөзлеләргә дә, намуслы кешеләргә бүленгән. Алар арасында һәрвакыт көрәш. Шушы әсәр аша үзенең идеалларына ышанган Шәрәфи карт кара эчле кешеләр алдында көчле булуын, балаларын да дөрес итеп тәрбияләвендә күрәбез. Автор ачынып, «Соңгы вакытларда ат асраучылар бетте. Яшьләр ялкауланды. Яшьләр авылда калмый», – дип яза. Димәк, ат образы – ул безнең үткәнебез һәм бүгенгесе белән бәйләнеш. Автор үзенең этисе һәм аты «Татра» белән ул халкыбызның аянычлы хәленә, авылыбызның бетүенә ишарә ясый.

Ат образы Айгөл Әхмәтгалиеваның «Ул югалмады» хикәсендә икенче яссылыкта ачыла. Аның әсәрләрен укый башласаң, җырлап торган сөйләме үзенә тарта. Аның әдәби телендә Фатих Хөсни аһәңнәре яңгырап китә. Әмма бу – лиро-эпик тел, нәсер, шигъри проза теле түгел. Матур әдәби телне заманча хәрәкәттәге тормыш вакыйгаларын тергезү белән куша алган эпик хикәяләү бу. Урынлы һәм уйлап сайланган һәр сүз тирәлекнең матур сурәтен тудыра, шул сурәт күз алдына килеп, сине олы җанлы, матур күңелле кешеләр дөньясына алып кереп тә китә. «Ул әле югалмады» хикәясе бүгенге тормышка хас булган актуаль проблемаларны үз эченә алып тасвирлаган әсәрләрнең берсе. Гаилә кыйммәтләре, эчкечелек, хатын-кызның гаиләдәге роле, ана һәм бала мөнәсәбәләре бик ачык чагылган. Язучы әсәрдә дөньяда булган вакыйгаларны гомумиләштереп, образларны типиклаштырып, геройларга исем дә бирмәгән. Без бары тик тормышны сөйрәргә тырышкан этине, исерек әнине һәм кечкенә генә булуына карамастан, дөньяның ачысын-төчесен татыган малайны күрәбез. Малайның тугры дусты аның аты – Карлыгач. Бөтен уйларын, кайгы-хәсрәтләрен, мәктәптәге хәлләрне атына сөйли малай. «Әле дә син бар, Карлыгач», – дип әйтеп куя малай [2; 198 б.]. Аты Карлыгач, малайны кызганудан: «Мин нишли алам?» – дигән сыман күзләрен тутырып карый гына ала [2; 197 б.]. Айгөл Әхмәтвәлиева бала күңеленең ниләр кичергәнен ат образы аша китереп җиткерә. Шушы юлларны укыганда, шундый сабые була торып, ана булган кешенең тормыш баткаклыгына тәгәрәвенең сәбәбен эзлисең, йөрәкнең иң нечкә кылларына ук кагылып, баланың киләчәктә бәхетеле булуын, ананың туры юлга басуын тели башлыйсың.

Автор милләтебезнең йөзек кашы булган Сабантуй бәйрәмен дә читтә калдырмый, ат образы булган әсәрдә ул һичшиксез булырга тиеш итеп кабул итәлә. Малайның «Әни, син эчмә! Әни, китмә!», – дип өзгәләнүләре ат чабышы вакытында Карлыгачның тояк тавышларына үрелеп бара. Малайның тырышуы бушка китми, әнисенә вәгъдә иткән бүләген дә ота. Ләкин әнисе генә һаман эчкелек баткаклыгыннан чыгу юлын тапмый. Кешенең табигате шундыйдыр күрәсең, үлем белән йөзгә йөз очрашмыйча, аның якынлыгын тоймыйча, ал-ялны белми ялган кыйммәтләргә табынып яшәүдән тартынмаган ана кешене менә шул кискен фаҗига генә айнытып җибәрә. Улы үлемнән калгач кына, әни кеше акылына килә.

Бу әсәрдә малай үзенең тирә-ягында кешеләргә ышанычын югалтканда табигать җаны – атта таба. Язучы биредә образларны янәшә куеп, бик уңышлы сурәткә ирешкән дип әйтә алабыз.

Айгөлнең Әхмәтгалиеваның сөйләм теле шулкадәр йөгерек һәм сыгылмалы – кызганудан күзләрдән яшьләр килә, кеше күңеленең олылыгына карата горурлык уяна – хисләр бәйләме кичерәсең. Әмма, тормыш нинди генә авырлыклар китерсә дә, бәхетле, шөкер итеп яшәгән кешеләр тарихының ышандыру көче зур түгел. Әкиятләрдәгечә уңай һәм тискәрегә аерылган геройлар, шушы ак һәм карага бүлеп бәяләнгән дөнья схематик тоела. Нәтиҗәдә, төп геройларга карата кулланылган психологизм, укучыны көчле кичерешләргә дучар итә. Психологизм да, фәлсәфә дә, иҗтимагый-сәяси бәя дә бер үремтәдә килеп, әсәрне көчле бер әдәби яңгырашка алып чыга: аны кат-кат укырлык әсәр ясый.

Сүзне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: XX гасырның икенче яртысында башланган техник революция атның тормышыбыздагы ролен бик нык үзгәртте. Ат хәзер безнең тормышта бер экзотик җан иясе дәрәҗәсенә төште. Хәзер атны авылларда да бер күрергә зар булырсың. Дөресен әйткәндә, без үзебезне кеше иткән тарихи юлдашыбызны ташладык. Ләкин менә югарыда әйтеп үткән язучыларыбызның әсәрләре шуны исбат итә: ат образы яңадан үзенең ролен үти башлады, аңа рухи халәтебезнең үзеннән килеп чыккан яңа мәгънә салынды.

**Кулланылган әдәбият**


1. Әмиров Р.К. «Җиктереп пар ат...» Тукай иҗаты һәм Башкортстандагы татар шигърияте // Тулпар. – 2012. – № 6. – Б.32-35.
2. Әхмәтгалиева А.Г. Кичке таң: повестьлар, хикәяләр. – Казан: Идел-Пресс, 2020. – 224 б.
3. Булатова Д. Язучының күңел дәфтәреннән // Тулпар. – 2019. – № 6. – Б.22-25.
4. Заһидуллина Д. Ак читек // http://www.xn--80aaa0anjn0apj6g.xn--p1ai/news/jehet-tenkyjt/ajgol-ehmetgalieva-ak-chitek
5. Исмәгыйлев Х.Ш. Ат һәм без // Тулпар. – 2018. – № 2. – Б.4–23.
6. Сәгыйдуллина Л.Р. Мифны җимерүче роман // Тулпар. – 2018. – №5. – Б. 32–33.
7. Садриева Р. Р., Халиуллина А.Г. Нравственно-эстетический анализ образа-персонажа на уроках татарской литературы в общеобразовательной школе // Система непрерывного филологического образования: школа – колледж – вуз. Современные подходы к преподаванию дисциплин филологического цикла в условиях полилингвального образования: Сборник научных трудов по материалам XXV Всероссийской (с международным участием) научно-практической конференции, Уфа, 24–26 апреля 2025 года. – Уфа: БГПУ им. М. Акмуллы, 2025. – С. 647-651. – EDN CKCWZW.


© Мансурова З.Я., 2025

УДК 811.512

**Миннуллина Э.Р.,**
*студент Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель* – **Гайнуллина Г.У.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИНГЛИЗ АЛЫНМАЛАРЫ

***Аннотация.*** *Бу мәкаләдә татар телендәге инглиз алынмалары карала, шулай ук аларның тематик классификациясе бирелә.*

***Терәк сүзләр:*** *лексика, сүз мәгънәсе, англицизмнар, алынмалар, глобальләшү.*

Тел үзара бәйләнеше процессы-закончалыклы һәм һәр җирдә була торган күренеш. Татар теле, күпмәдәни дөньяның бер өлеше буларак, башка телләрнең, шул исәптән инглиз

теленең дә йогынтысыннан котыла алмаган. Инглиз алынмалары татар теленең төп сүз катламын тәшкил итмәсәләр дә, аларның булуы тарихи һәм мәдәни багланышлар турында сөйли, шулай ук глобальләшүнең хәзерге тенденцияләрен чагылдыра.

Инглиз сүзләренең татар теленә беренче, аз санлы үтеп керүен Россия белән Великобритания арасында сәүдә мөнәсәбәтләренең XVIII–XIX гасырларда активлашу чорына кертергә мөмкин. Әмма бу процесс эпизодик характерда булды һәм лексик составка сизелерлек йогынты ясамады. Рус-инглиз сәүдәсе һәм Рус-Инглиз дипломатиясе тарихы башланды, ә инглизләр эзләгән сату базары ярдәмендә ныклы сәүдә мөнәсәбәтләре башланды. Ул вакытта үлчәүләр, акча берәмлекләре фунт, шиллинг тамгалары алынды, ә төрле хисапларда, илчеләрнең эшчәнлеге турында сэр, лорд, мистер һ.б. кебек сүзләрне очратырга мөмкин иде.

Инглиз алынмаларының артуы XX гасырның икенче яртысында башлана. Бу чор халыкара багланышларның киңәюе, фән һәм техниканың үсеше, көнбатыш мәдәниятенең кино, музыка һәм әдәбият аша таралуы белән характерлана. Яңа төшенчәләрне һәм күренешләрне белдерүче күп кенә инглиз сүзләре, рус телендәге ассимиляция стадиясен читләтеп, татар теленә үтеп керә башладылар.

Татар теленә инглизчәлек агымы XX гасыр ахырына кадәр зәгыйфь булып кала. Барысы да микропроцессор уйлап табу белән үзгәрде, ул мәгълүмати технологияләр өлкәсен актив үстерүгә этәргеч бирде. Татар телендә компьютер техникасына (дисплей, браузер, сайт, джойстик, курсор) караган инглизчәләр барлыкка килде. Илләр арасында мәдәни алмашу көчәйде, Инглиз теле халыкара аралашу теленә әверелде, ә инглиз телендә сөйләшүче илләрнең берләшкән милләтләр оешмасын төзүе инглиз теленең күтәрелүенә һәм таралуына ярдәм итте. Татар сүзлек запасына күп санлы икътисади һәм финанс терминнары (кредит, маркетинг, брокер, бизнес, импорт), косметик терминнар (консилер, мейкап), ашамлык исемнәре (гамбургер, чизбургер, коктейль, кекс) үтеп кергән.

Шулай ук нглизчәлекнең татар теленә киртәсез кереп китүенең бер сәбәбе: поп-мәдәниятне популярлаштыру тора. Россия Британия һәм Америка музыкасы, кинофильмнар, рәсем сәнгате белән кызыксына. Яңа сүзләр халыкның күпчелеге тарафыннан кулланыла башлады (анимация, аниме, блог, видеоклип, дизайн, имидж, кавер, комикс, вестерн, һ.б.)

Социаль яңалыкларның телләргә йогынтысы аларның статусына һәм, димәк, таралуына бәйле. Сөйләүчеләре күп булган телләр (кытай, инглиз, рус, немец телләре) әдәбиятта, массакүләм мәгълүмат чараларында киңрәк кулланыла һәм сөйләүчеләре аз булган телләргә караганда (татар, башкорт, угро-фин телләре) зуррак аудиторияләрне колачлый. Социаль факторлар һәм, нәтиҗә буларак, телнең статусы аның функциональ үсешенә һәм таралышына турыдан-туры йогынты ясый. Сөйләүчеләре күп булган һәм статусы югары булган телләр төрле өлкәләрдә үсеш һәм куллану өчен күбрәк мөмкинлекләргә ия, шул ук вакытта сөйләүчеләре азрак булган һәм статусы түбәнрәк булган телләр үсешләрендә һәм кулланылышында чикләнгән.

Хәзерге этап инглизчәлекләрнең интенсив үтеп керүе белән характерлана, бигрәк тә мәгълүмати технологияләр, бизнес, мода һәм спорт өлкәләренә. Интернетны һәм социаль челтәрләрне актив куллану Инглиз сүзләренең тиз таралуына ярдәм итә, еш кына татар теленең фонетик һәм грамматик нормаларына яраклашмый. Бу тел чисталыгын саклау һәм алынмалар процессын җайга салу кирәклеге турында бәхәсләр тудыра. Гомумән алганда, Инглиз алынмалары, теләсә нинди чит тел элементлары кебек үк, җентекләп өйрәнүне һәм аңлауны таләп итә торган катлаулы һәм бер мәгънәле булмаган феномен булып тора.

Сүзләрне алынмау алынма телнең лексик-семантик системасының үсеш дәрәҗәсенә, анда чыганактагы теге яисә бу төшенчәләрне, мәгънәләрне, мәгънә төсмерләрен билгеләү өчен кирәкле сүзләрнең булу-булмавына турыдан-туры бәйле була. Кыскасы, ул алынма тел системасында җитешмәгән элементларны тулыландыру зарурлыгы белән бәйле.

Җитешмәгән звенолар түбәндәге дүрт очракта аеруча ачык күренәләр:

1) Чит телдәге сүзне үз телеңнең бертигез мәгънәле сүзенә алмаштырып булмый, ә бары тик тасвирлап кына тапшырырга мөмкинлек булганда (интервью, круиз, рейтинг, стресс һ.б.);

2) Чит тел сүзе үз телендә шактый якын синонимик тәңгәллекләргә ия булса да, бу тәңгәллекләр өлешчә, тулы булмаган, контекст ягыннан үзгәрүчән булганда (мәгълүмат, спикер һ.б.);

3) Чит телдәге сүзнең кайбер мәгънәләре үз теленең тиешле сүзләре белән тапшырылганда, ә башкалары алынма сүз белән белдерелгәндә (практика);

4) Чит телдәге сүз нindидер бер мәгънәдә генә алынса, ә аның башка мәгънәләрен тапшыру өчен үз телендәге сүзләр булса [1].

Инглиз алынмаларының татар теленә арадашчы тел аша, бу очракта рус теле аша күчүен исәпкә алып. Практик өлеш өчен Т.В. Егоровның 2014 елгы «Словарь иностранных слов современного русского языка»сы тикшерелде. Барлыгы англицизм булган 900 артык сүз саналган. Барлык сүзләр дә рус телендә актив кулланылмый. Куллану өлкәсе буенча сүзләрне төркемнәргә бүлеп була:

– Спорт терминнары: *аэробика, армрестлинг, бадминтон, баскетбол, бодибилдинг, бокс, волейбол, дайвинг, джиу-джитсу, нокаут, раунд, ринг, старт, тайм-аут, футбол, хоккей һ.б.*

– Икътисадый терминнар*: адвертайзинг, бартер, бизнес, билборд, импорт, инвестиция, инсайд, консалтинг һ.б.*

– Техника һәм IT белән бәйле терминнар: *браузер, веб, веб-сайт, диск (дискета, компакт-диск, DVD), джойстик, интернет, компьютер, программа, курсор, кэш, лаг, логин, модем, процессор, скан, слайд, спам, трафик, файл.*

– Һөнәр исемнәре: *аниматор, астронавт, байер, бизнесмен, блогер, брокер, букмекер, диспетчер, коуч, тренер, программист, репортёр һ.б.*

– Музыкаль мәдәният, массакүләм мәдәният терминнары: *анимация, аниме, бестселлер, блог, видеоклип, интервью, кавер, комикс, креатив, вестерн, саундтрек, мюзикл, перфоманс, пиар, ремейк, ремикс, рок-н-ролл, рэп, трибьют һ.б.*

– Физика, информатика һәм фән белән бәйле терминнар: *акр, байт, бит, бойлер, вентилятор, ватт, дренаж, жироскоп, конвейер, конвертер, пиксель, реактор, метан, терабайт, транзистор һ.б.*

– Сленг*: анбоксинг, андеграунд, апргрейд, бедлам, блеф, гаджет, глэм, инет, кринж, лайфхах, мем, мерч, пранк, респект, рофл, стрим, трэш, фейк, флешмоб, форс, хейтер, экшн һ.б*.

– Азык белән бәйле терминнар: барбекю, бекон, бифштекс, гамбургер, гипермаркет, грейпфрут, кекс, коктейль, крекер, грог, йогурт, попкорн, пунш, фаст-фуд һ.б.

– Кием һәм мода белән бәйле терминнар*: бренд, бриджи, джемпер, джинсы, кардиган, кашемир, смокинг, секонд хенд, һ.б.*

– Транспорт белән бәйле терминнар: *автобус, байк, грейдер, танк, трактор, трамвай, троллейбус, хетчбэк, һ.б.*

– Сәяси термин: *саммит, митинг,*

– Медицина белән бәйле терминнар: *акупунктура, аутотренинг, бихевиоризм, гайморит, геном, дальтонизм, инсулин һ.б.*

– Абстракт терминнар: *дискомфорт, комфорт һ.б*.

Тематик классификация нигезендә безгә рус теленә килгән инглизчәләрнең күбесе исем булып тора һәм яңа предметлар, һөнәрләр, хезмәтләр исемнәре буларак алынды, дигән нәтиҗә ясарга була.

Алынмаларның татар теленә йогынтысы-тарихи контекстны җентекләп анализлауны һәм тирәнтен аңлауны таләп итә торган катлаулы һәм күпкырлы процесс. Бер яктан, алынмалар телнең сүзлек запасын баета, аңа яңа чынбарлыкка җайлашырга һәм яңа

концепцияләрне белдерергә мөмкинлек бирә. Икенче яктан, алынма сүзләр белән артык мавыгу татар теленә генә хас булган үзенчәлеген югалтуга китерергә мөмкин.

**Кулланылган әдәбият**


1. Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Алма-Ата, 1967. – 58 с.
2. Егорова Т.В. Словарь иностранных слов современного русского языка – М.: «Аделант», 2014. – 800 с.


© Миннуллина Э.Р., 2025

УДК 821.512.145

**Мукимова Г.Ф.,**
*студент 3 курса Елабужского института КФУ*
*Научный руководитель* – **Габидуллина Ф.И.,**
*доцент кафедры филологии Елабужского института КФУ,*
*г. Елабуга, Россия*

## ШАГЫЙРЬ ХӘСӘН ТУФАН ПОЭЗИЯСЕНДӘ КӨЧЛЕ ЛИРИЗМ, ПСИХОЛОГИЗМ ЧАГЫЛЫШЫ

***Аннотация***. *Әлеге мәкалә XX гасырның күренекле татар шагыйре Хәсән Туфан шигърриятенә көчле лиризм һәм психологизм чагылышында анализ ясауга багышлана. Хезмәттә әдипнең шигъри стиль үзенчәлекләре, шәхеснең эчке дөньясы, мәхәббәт, газаплар һәм истәлекләр кебек төп темалар һәм мотивлар карала. Хәсән Туфан шигырьләренең психологик аспектларын тикшерүгә аерым игътибар бирелә, аларда эмоциональ кичерешләр һәм тирән эчке халәт ачык чагыла. Шагыйрьнең лирик образларының байлыгын һәм шигъри сүзенең психологик тирәнлеген чагылдырган иҗат мисаллары анализлана. Мәкалә Х. Туфан поэзиясенең кешенең эчке дөньясын һәм аның рухи кичерешләрен, шулай ук милли поэзия формалашуда лиризм һәм психологизмның ролен аңларга ничек ярдәм итүен күрсәтә.*

***Терәк сүзләр:*** *Хәсән Туфан, татар поэзиясе, лиризм, психологизм, эчке дөнья, эмоциональ кичерешләр, мәхәббәт, истәлекләр, шигъри образ.*

Хәсән Фәхрулла улы Туфан (Хисбулла Фахриевич Гулзизин) – XX гасыр татар шигърияте үсешендә үзенчәлекле урын алучы, тирән лиризм һәм психологизм белән билгеле шагыйрь. Аның шигъриятендә шәхеснең эчке дөньясы, хис-кичерешләре, мәхәббәт һәм үткәннәр белән бәйле психологик халәтләр тирән һәм нәфис сурәтләнә.

Хәсән Фәхриевич Туфан 1900 елның 9 декабрендә Татарстанның Аксубай районы, Иске Кармәт авылында крестьян гаиләсендә туган. Ул әтисеннән укырга һәм язарга өйрәнгән, ә авылда мәктәп ачылгач, шунда белем алган.

Үзенең иҗади эшчәнлеген ул башта шигъри эшчәнлек белән башлап, кыска вакыт эчендә танылган шагыйрьгә әверелгән. Хисбулла Хәсән Туфанга шагыйрь булгач кына әйләнә. Күп еллар татарларга хас булмаган Гөлзизин фамилиясен йөртергә туры килә. Ул бу турыда менә нәрсә дип язган булган: «Безнең нәсел качкын крестьяннардан, соңыннан чукындырылган һәм христиан булып саналганнардан килеп чыккан. Әмма алар чиркәүгә барып никахлашмаган, балаларын чукындырмаган, шуңа күрә аларның балалары «законсыз» булып саналган һәм гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгән. Фамилияләр дә әниләрнең исемнәреннән бирелгән…» [5; 1 б.]. 1905 елгы инкыйлабтан соң ул үз документларын «Хәзрәтов» исеменә үзгәртә. Аннан соң, Аклар армиясенә алынмас өчен, Хәсән Кусинов исемле казакъ дустының документларын куллана. Шул рәвешле, Х. Туфан үз фамилиясен дүрт тапкыр алыштырырга мәҗбүр була.

Һөнәр ягыннан ул төрле эшләрдә эшләгән: Урал шахталарында, металлургия заводында токарь булып, сәгатьләр төзәтеп. Шулай ук ул Урта Азия һәм Кавказ якларына сәяхәт иткән, бу аның тормышында зур тәҗрибә һәм илһам чыганагы булган.

Хәсән Туфан 1981 елның 10 июнендә вафат булган. Аның иҗаты татар әдәбиятында зур урын алып тора, ул милли аңны уятып, милләт үсешенә зур өлеш керткән шагыйрь.

Бу хезмәттә без аның шигырьләрендә көчле лиризм һәм психологизм чагылышларын анализлыйбыз, аерым әсәрләрдән мисаллар китереп, аларның эчтәлеген ачыклыйбыз.

Хәсән Туфан шигъриятендә лиризм – төп элемент. Аның шигырьләрендә абстракт символика яки реаль тормыштан аерылган дини-мифологик образлар очрамый. Ул үзенең хис-кичерешләрен, сагыну, туган илгә мәхәббәт кебек хисләрне нәфис һәм тирән лирик стиль белән сурәтли. Аның шигырьләре еш кына кыска, ләкин тирән мәгънәле була һәм музыкаль ритмнар, образлар белән баетыла.

Соңгы елларында иҗат ителгән шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы шигъри шедеврга әверелә, анда төп урын яраткан хатынын сагыну хисенә, аның матурлыгы белән соклануга, аның тугрылыгына һәм мәхәббәтенә ышануга бирелә. Мәсәлән, Х. Туфанның «Ромашкалар» шигыренең юлларында:

«...Искә төште бергә чакларым;
Көтә микән, сагына микән, дип,
Канатларын йолкам аларның...» [4; 1 б.]

лирик герой үткән вакытларны искә төшерә, кайгыра, сагына һәм ромашкаларның канатларын йолкып, аларга карап, үзенең эчке халәтен чагылдыра. Шулай ук мондый әсәрләргә «Үзеңә бүләк итәсе иде», «Алга барышлый», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Чәчәк сибелә җилдә», «Моабитны күрдем төшемдә», «Агыла да болыт агыла», «Сиңа», «Иртәләр җитте исә», «Тамчылар ни диләр», «Әйткән идең», «Иртәләрем-кичләрем», «Кая шулай ашыгасың, йөрәк?» һ.б. керә. Туфанның мәхәббәт лирикасына хисләрнең сафлыгы, оригинальлек һәм тирән сагыш хас. Бу шигырьләрнең лирик герое үзенең тирән кичерешләренә, сөйгәнен сагынуына чумган.

Утызынчы елларда шагыйрь иҗатында күзәтелгән лирик-философик юнәлеш һәм сәнгатьчә гади һәм табигыйлеккә омтылу тенденциясе елдан-ел ныгып, яңа поэтик сыйфатлар белән баетылып, кырыкынчы-илленче елларда көчле, тирән хисләр һәм уй-фикерләр белән тулган поэзиягә әверелә [1; 105 б.].

Х. Туфан шигъриятенең үзәгендә конкрет шәхес образы тора, аның индивидуаль, милли, социаль, конкрет-тарихи үзенчәлекләре белән. Х. Туфан иҗатының төп чыганагы – авторның үз шәхесе, аның тормышка карашы, аның уйлары һәм кичерешләре.

1960 – 1970 елларда Х. Туфан үз иҗатында лирик геройның психологик һәм рухи халәтен сүрәтләүне беренче урынга куя.

Мисал итеп, Х. Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырен китерергә була.

«Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы?
– Бәйлисе бар йөрәкне...» [4; 1 б.].

Әлеге куплет геройның тормышта күп авырлыклар кичерүен, шул ук вакытта, үз-үзендә көч табуын күрсәтә. «Бирде дөнья кирәкне» юлында автор тормышта күп авырлыклар, сынаулар белән очрашуын күрсәтә, ләкин шул ук вакытта «Еламаска өйрәтте» юлы геройның рухи яктан көчле булуын белдерә.

Гомумән, бу строфада кешенең тормыштагы кыенлыклар белән көрәшүе, мәхәббәт һәм җылы хисләрнең геройга рухи көч бирүе турында психологик фикерләр чагыла.

Хәсән Туфан поэзиясендә көчле лиризм һәм психологизм – бер-берсен тулыландырып тора. Аның шигырьләрендә мәхәббәт, сагыну, үткәннәр белән көрәш – барысы да тирән психологик һәм лирик чагылышлар аша сурәтләнә. Алар укучыга шәхеснең эчке дөньясына кереп, хис-кичерешләрнең тирәнлеген аңларга мөмкинлек бирә. Туфанның шигырьләре –

шәхеснең рухи халәтен, эчке дөньясын аңларга ярдәм итүче, нәфис һәм тирән психологиягә бай әсәрләр җыелмасы.

**Кулланылган әдәбият**


1. Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: биобиблиографик белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б.
2. Мостафин Р. Остаз шагыйребез газаплары: Хәсән Туфанның сөрген чоры // Мәдәни җомга. – 2018. – № 27. – Б. 8–9.
3. Сабиров Р. Татар әдәбияты тарихы (1920-1930 еллар): «Филолог» белгечлеге буенча белем алучы студентлар өчен методик кулланма. – Казан: Ихлас, 2010. – 60 б.
4. Хәсән Туфан шигырьләр җыентыгы. – URL:https://shigriyat.ru/authors/tufan/page1?ysclid=mgkn1ikx65120012647; (мөрәҗәгать итү вакыты: 09.10.25).
5. Мифтахова С. Тиргәмиләр Кармәт гөлләре // Ватаным Татарстан. – URL:https://vatantat.ru/2025/09/181902/?ysclid=mgjb6642p0225339740; (мөрәҗәгать итү вакыты: 09.10.25).


© Мукимова Г.Ф., 2025

УДК 811.512.145

**Мурзина Ю.М.,**
*студент 6 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель* – **Зарипова И.Ф.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры,*
*г. Уфа, Россия*

## ФРАЗЕОЛОГИЗИРОВАННЫЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

***Аннотация.*** *В данной статье описываются структурные и семантические особенности фразеологизированных предложений в современном татарском языке.*

***Ключевые слова:*** *татарский язык, лексикология, фразеологизмы, предложение, контекст.*

Фразеологизмы обогащают речь, придавая ей образность и выразительность. Они широко представлены в художественной литературе, повседневной речи и татарском фольклоре. Фразеологические единицы не просто называют явления, предметы или действия, но и несут в себе оценочный смысл. Каждый язык формирует свою уникальную фразеологическую картину мира, отражая наиболее значимые для носителей аспекты реальности. Не каждое явление или действие может стать фразеологизмом. В культурном плане фразеологизмы аккумулируют ценную информацию, позволяя выражать множество значений при минимальных языковых средствах [4, 62 с.].

Сбор фразеологизмов в татарском языке стартовал в начале XX века. Народная речь и литературный язык оказались богаты на краткие и разнообразные выражения. Именно тогда, в начале XX века, фразеологические единицы были признаны самостоятельным и важным разделом языкознания и стилистики [5, 134 с.]. В 1940-е годы эти исследования получили дальнейшее развитие: они расширились, углубились и оформились в новое направление языкознания. Фразеологизмы активно собирались, изучались и сравнивались с единицами других языков. Аналогичные процессы происходили и в родственных тюркских языках. Так, словари фразеологизмов были изданы в казахском, узбекском, башкирском и азербайджанском языках [7, 192 с.].

Среди выдающихся татарских языковедов, внесших значительный вклад в изучение фразеологии, следует отметить Л. Джаляя, Ш. Рамазанова, Л. Махмутову, Н. Бурханову, В. Хакова, К. Сабирова, Г. Ахунзянова, Х. Курбатова, Ф.С. Сафиуллину и других. Актуальность изучения фразеологизмов сохраняется и по сей день, поскольку они широко представлены как в художественной литературе, так и в живой речи.

По своей структуре фразеологизмы не всегда представляют собой словосочетание, но могут также выражаться целым предложением. Лингвистическая классификация простых предложений может быть применена и к фразеологизированным конструкциям [6, 213 с.].

В татарском языке существуют фразеологизированные предложения, которые по цели высказывания относятся к повествовательным. Например: *авыз ачарга (да) ирек бирми; адымын санап атлый; карындыгын башына киеп туган; абуз өстендә арыш суга; адәм рәтенә кермәгән; бишкә алып бергә саткан; диңгездән кичеп инешкә баткан; ике азан әйтмиләр; карандыгын башына киеп туган* и другие.

Фразеологизированные вопросительные предложения встречаются редко, например: *валлаһи дип әйттимме соң?*

В зависимости от того, подтверждается или опровергается явление действительности, предложения фразеологизированного типа делятся на утвердительные и отрицательные. Например: фразеологизированные отрицательные предложения: *ишегенә аю мае сөртмәгән; дары исе иснәмәгән; алды арты киселмәгән; ирененд ә ана сөте кипмәгән; йомырка сарысы кипмәгән; килер юлыма ботак үсмәгән* и т.д.

Фразеологизированные предложения, подтверждающие реальность, противопоставляются отрицательным предложениям: *акча өчен иманын саткан; алтын бишектән төшкән; балык башы ашаган; артына чуан чыккан; ата сакалы авызына җиткән; борыны ташка тиеп үскән; исәнлеккә ис киткән* һ.б.

В зависимости от наличия второстепенных членов фразеологизированные предложения могут быть распространёнными и нераспространёнными. Например, к ряду нераспространённых предложений, состоящих лишь из главных членов, относятся следующие примеры: *кан кызу; йомырка сарысы кипмәгән; карыш каткан; бабасыр кергән; йөрәге бетләгән; йөрәк кайнау* и т.д.

Также в татарском языке довольно часто встречаются и распространённые предложения фразеологизированного типа, в составе которых имеются как главные члены, так и второстепенные: *ит белән кайнап сөяккә сеңгән; бала акылы кергән; аннан артына кояш чыкмас; акылын кәҗә ашаган; бер чөе ычкынган; кашын песи ашаган; китап җене кагылган; артыннан җир капкан; зур күтәреп бәләкәй суккан; буранга очраган күркә кебек корышкан, бер тиен кергән* и т.д.

В зависимости от количества грамматических основ фразеологизированные предложения могут быть односоставными и двусоставными. Большинство односоставных предложений представляют собой неопределённо-личные предложения. Например: *керпе кебек йонын тырпайткан; абуз өстендә арыш суга; алдына килгән бәхеттән колак каккан; елан аягын кискән; гарешкә күзен терәгән; балык башы ашаган; баскан җиреннән ут чыгара; йөзлеген битенә киеп туган* и т.д.

Существуют также двусоставные предложения, включающие и подлежащее, и сказуемое. Например: *колагына тычкан оялаган; кендеге эченә ябышкан; бер тиен кергән; алмалары суга туенган; базар көнне ике тиен тормый; башка тай типмәгән; казлар Рим коткарган* и т.д.

Фразеологизированные предложения, как и обычные, делятся на простые и сложные в зависимости от количества грамматических основ. Простые предложения составляют подавляющее большинство (около 90%) практического материала [3, 97 с.]. Все приведённые выше примеры являются именно такими – простыми предложениями.

Такие простые предложения как *бүрегә алып куянга тидергән; бакчасына тиен кергән; бала акылы кергән; башында җил уйный; борыны гына утырып калган; араларыннан чебен дә очмый* противопоставляются сложным предложениям с двумя или несколькими

грамматическими основами. Например: *аллар бетеп гөлләр үскән; ат-хан җиткән җир; башы өзелсә култык астына кыстырып йөгерер; егылсаң җир күтәрер; без өйләнгәч төн кыскарды; йоны коелган яман эт; ите бетеп сөяккә калган, баш ярылып күз чыкмаган* и т.д.

Таким образом, фразеологизмы, обладающие такими чертами, как единство, нерасчленимость и целостность, могут проявляться не только в виде словосочетаний, но и как самостоятельные предложения. Эти предложения фразеологизированного типа подразделяются на типы в зависимости от различных критериев.

Так, по цели высказывания они бывают повествовательными и вопросительными, по отношению к действительности – утвердительными и отрицательными, по наличию второстепенных членов – распространёнными и нераспространёнными. Кроме того, их можно делить на односоставные и двусоставные, а также на простые и сложные, исходя из количества грамматических основ.

Среди всех видов фразеологизированных предложений наиболее распространены повествовательные, односоставные и двусоставные. Вопросительные же предложения встречаются относительно редко.

**Список литературы**

1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан, 1980. – 174 б.

2. Җәләй Л., Борһанова Н., Мәхмүтова Л. Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. – Казан: Татар. кит нәшр., 1957. – 247 б.

3. Зарипова И.Ф. Специфика структуры и смысла синтаксических фразеологизмов в татарском языке // Восток – Запад: теоретические и прикладные аспекты преподавания европейских и восточных языков: Материалы VIII Международной научно-практической конференции. – Новосибирск, 2025. – С. 92–98.

4. Зарипова И.Ф. Структурно-семантические особенности фразеологизированных предложений в татарском языке // Лингводидактика и лингвокультурология в контексте современного образовательного дискурса: Сборник научно-методических статей по материалам V Международной научно-практической конференции, посвященной 45-летию кафедры теории языка и методики его преподавания. – Уфа, 2023. – С. 61–65.

5. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. I том. – Казан, 1989. – 495 б.

6. Мурзина Ю.М., Зарипова И.Ф. Татар телендә фразеологик җөмләләр // Актуальные проблемы современной татарской филологии: Сборник статей Всероссийской научно-практической конференции, посвященной 95-летию со дня рождения известного языковеда, тюрколога, доктора филологических наук, профессора, первого заведующего кафедрой татарской филологии Башкирского государственного университета Габдулхая Хурамовича Ахатова (1927 – 1986). – Уфа, 2022. – С. 211–214.

7. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.

7. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). – Казан: «Хәтер», 1999. – 288 б.

8. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015 – Т. I. – 352 б.

9. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – Т.1 (А – Й). – 476 б.

© Мурзина Ю.М.,2025

УДК 821.512.145

**Муртазин И.И.,**
*магистрант 1 г.о. Высшей школы отечественной филологии Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ,*
**Шарипов М.С.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ, г. Уфа, Россия*

# ТАТАР СҮЗ СӘНГАТЕНДӘ ӘДӘБИ ШАРТЛЫЛЫК МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

***Аннотация***. *Бу мәкаләдә татар сүз сәнгатендәге әдәби шартлылыкка анализ ясала. Әдәби алымнарның һәм образларның әдәби шартлылыгы белән бәйле үзенчәлекләре ачыклана.*

***Терәк сүзләр:*** *татар әдәбияты, әдәби шартлылык, модернизм, драматургия, символизм.*

Шартлылык – татар сүз сәнгатенең борынгы чорларыннан ук актив кулланылып килгән мөһим әдәби алым. Татар әдәбиятының беренче ядкярләре – шартлылыкны куллануның үрнәк мисаллары булып тора. Әле XIII гасырның беренче яртысында Кол Гали тарафыннан кыйсса жанрында иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасында, Алтын Урда чоры әдипләре Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында, Хисам Кятибнең «Җөмҗемә солтан» поэмасында шартлылык күренешләре ачык чагыла.

Шартлылык ярдәмендә авторлар чынбарлыкка охшамаган тормыш сурәтен тудыра. Моның өчен төрле шартлы алымнар: фантастик деформацияләү, мифологик сюжетлар һәм образлар, символ, парадокс, гротеск, аллегория һәм башка алым һәм чаралар кулланыла. Соңгы еллардагы тикшеренүләр күрсәткәнчә, XX йөз башы сүз сәнгатендә модернизм әдәби юнәлеш булып формалашып җитми, шулай да татар әдипләре аның аерым элементларын шактый тулы үзләштерәләр. Шундый элементларның берсе – яңа чорда шактый трансформация кичергән шартлылык.

Шартлылык әдәбият гыйлемендә чагыштырмача яңа термин булып санала. Ул бары тик XX гасырда гына әдәбиятта, сәнгатьтә рәсми рәвештә танылу ала. Чөнки «чынбарлык поэтикасы» реализм белән генә канәгатьләнә алмый – әкренләп башка төр тенденцияләргә юл ача. Әдәбият теориясендә дә шартлылык категориясе әһәмиятле роль уйный башлый.

Бүгенеге көнгә кадәр шартлылыкның асылын төшендерүдә төрле карашләр яшәп килә. Берәүләр аны тормышның антиподы, формализм, схематизм, фальш буларак аңлаталар. Бу караш тарафдарлары идеологиягә корылган совет сәнгатен тулысынча шартлылыктан арындыруга өндиләр, аны көнбатыштан килгән абстракционизм йогынтысыннан саклап алып калырга чакыралар. Д. Осипов, П. Масленников кебек галимнәр сәнгатьнең киләчәген «я реализм, я шартлылык» дип сайларга тәкъдим итәләр. Икенче яктан, Н. Охлопков, В. Турбин кебек галимнәр сәнгатьнең киләчәген шартлы формаларсыз күз алдына китерә алмыйлар һәм аны бертөрлелектән, натурализмнан котылу чарасы, чынбарлыкны чагылдыруның үзенчәлекле формасы буларак күрәләр. Өченче караш вәкилләре – В. Зименко, Н. Видинеев – шартлылыкны танып, мәсьәләгә сак киләләр һәм шартлы формаларны куллануда чама хисен белүне таләп итәләр.

Ниһаять, җитмешенче еллар башында әдәбият белгечләре уртак фикергә килә алалар һәм Т.А. Аскаров, А.С. Михайлова, Е.Н. Дмитриев кебек галимнәрнең нигезле теоретик хезмәтләре бәхәскә ачыклык кертә. Алар арасында А.С. Михайлованың «О художественной условности» дигән монографиясе аеруча игътибарга лаек, чөнки ул сәнгатьчә гомумиләштерү һәм образлылык принципларыннан чыгып, шартлылык төшенчәсен аңлатуга якын килә. Е.Н. Дмитриевнең әдәби шартлылыкка багышланган монографиясе дә бу өлкәдә яңа хезмәт булып тора, ул сәнгатьчә шартлылыкны һәм тормышчанлыкны янәшә куеп, шартлылыкның дөньяны аңлату өчен генә түгел, ә аны үзгәртер өчен дә кирәклеген исбатлый. Шартлылыкны

ул реалистик һәм модернистик төрләргә бүлеп, беренчесенең тормышчанлыктан читләшкән хәлдә дә, хакыйкатьне тулырак ачарга ярдәм итүен исбатлый. Әлеге фикерләрен рус классиклары А. Пушкин, Н. Гоголь, И. Тургенев һ.б. әсәрләре нигезендә раслый.

Шул рәвешле, шартлылык төшенчәсе үзенә күпмедер дәрәҗәдә яшәү хокукы яулады, шартлылык әдәби үсешнең характерлы сыйфаты төсендә танылды һәм, нәтиҗәдә, әдәби җәмәгатьчелек, тәнкыйть фикере шартлылыкка карашын үзгәртте.Узган гасырның алтмышынчы елларында шартлылык совет әдәбиятында гомум бер тенденция буларак кулланыла башлады һәм дәүләт цензурасы кысымында язучылар үзләренең тәнкыйди фикерләрен яшерү өчен эпос теленә, шартлы детальләргә таяндылар.

Сәнгать чарасы буларак шартлылыкка билгеләмә XX гасырның 40 нчы елларында гына бирелә. Беренче билгеләмәләрдә шартлылыкны кабул итмәү, аның асылын аңламау, реализмга капма-каршы күренеш буларак ачарга тырышу белән очрашабыз. Мәсәлән, Н.Д. Ушаков редакциясендә төзелгән аңлатмалы сүзлектә шартлылыкка түбәндәге билгеләмә бирелә: «чынбарлыкны реалистик кабул итүдән баш тарту, үзенең символик юнәлешенә охшатып алмаштыру» [8, 165 б.]. Шартлылыкны реализмның антиподы итеп тану XX гасырның 60 нчы елларында кире кагыла. Шартлылыкны реализмның асылын ачучы сәнгать чарасы буларак тану да нәкъ шул елларга туры килә. Бу уңайдан В.А. Разумный белдергән фикер дә игътибарга лаек: «Аерым сәнгать алынмаларын аңлату өчен шартлылык термины кулланыла» [5, 13 б.].

В.Е. Хализевнең «Әдәбият теориясе» хезмәтендә шартлылык болай аңлатыла: «Авторның сурәт тудырудагы бербөтенлек булмауга акцент ясавы, яисә чынбарлык формасы белән сурәтләүнең капма-каршылыгы» [3, 105 б.]. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә түбәндәге билгеләмә бирелә: «Шартлылык – 1. Шартлы булу. 2. Чиклелек, чикләнгән, аерым шартлар, таләпләр куелган булу» [6, 494 б.]. Т. Галиуллин фикеренчә, «шартлылык кеше белән табигатьне соң чиккәчә якынлаштыру, күпертү, арттыру, тормышны, яшәешне, кеше рухын яңача сурәтләргә, иңләбрәк күрергә мөмкинлек ача» [1, 143 б.].

Язучы, шәхси тәҗрибәсенә таянып, тормышны кабул итү, аны аңлау дәрәҗәсенә нигезләнеп, чынбарлыкка охшаш яңа реаль сурәт тудыра. Сүз сәнгате тормышның копиясен, аның тәңгәл күчерелмәсен бирү максатын куймый. Каләм әһеле тормышны никадәр үз формасында сурәтләргә омтылмасын, образ сурәтләнгән предметка тәңгәл килми. Ягъни сәнгать тормышның нәкъ үзе түгел, ә образлы гәүдәләнеше, сүз сәнгатендәге шартлы күчерелмәсе. Әдәбият гыйлемендә моны «беренчел шартлылык» дип атыйлар. Мәсәлән, Ю. Манн, А. Михайлова хезмәтләрендә шундый фикерләрне очратырга мөмкин.

Татар әдәбияты белемендә дә беренче шартлылыкка тулы билгеләмәләр бар. Мәсәлән: «Чынбарлыкның әдәбиятта һәм сәнгатьнең башка төрләрендәге сурәтләнеше белән туры килмәве беренчел шартлылык дип атала. Моңа махсус кагыйдәләрдән оешкан сәнгатьле сөйләм һәм геройлар образы аша яшәешне чагылдыру керә» [6, 29 б.].

Әдәби әсәрләрдәге шартлылык, табигый күренешләрдән аерылмый торган бер хәл итеп кабул ителә. Әсәрне укыганда, без аны табигатьнең гадәти бер өлеше буларак кабул итәбез. Шартлы образларга салынган эстетик мәгънәләрне, әсәрнең үз контекстында гына аңлыйбыз. Бу категорияләргә символлар, ассоциацияләр һәм кинаяләр керә.

Беренчел шартлылык тибына мисал рәвешендә Шәриф Камалның «Акчарлаклар» повестендагы акчарлаклар образын китерергә мөмкин. Биредә диңгез өстендә бөтерелүче акчарлакларга бәйле күренешләр табигать манзарасы, яшәешнең табигый агышы төсендә кабул ителә. Әмма әлеге тасвир-сурәтләр артында тирән фәлсәфә ята.

«Шартлылык» термины киң мәгънәдә генә түгел, ә билгеле бер эчтәлеккә ия булганда да кулланыла. Бу термин сурәтләү чарасы һәм гомумиләштерү алымы буларак та кулланылырга мөмкин. Мондый очракта, яшәеш чынлыгы бозылып күрсәтелә һәм тормышчанлыкка каршы килә. Мисалларга Н. Гогольнең «Җен», «Шайтан», «Борын» образлары, А. Чеховның «Кара монах»ы, Г. Тукайның «Су анасы» һәм «Шүрәле»се керә. Бу образлар, гадәти булмаган, шартлы һәм символик мәгънәләргә ия булып, әдәби әсәрләрдә тормышның бер өлешен чагылдыру өчен кулланыла.

7. Чувашско-русский и русско-чувашский словарь / Скворцов М.И., Скворцова А.В.; – Изд. 4-е, стереотип. – Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 2007. – 432 с.
8. Чăваш халăх пултарулăхĕ: ваттисен сăмахĕсем / [пухса хатĕрленĕ О.Н. Терентьева]. – Шупашкар: Чăваш кĕн. изд-ви, 2007. – 493 с.


© Никитина О.В., Коротаева Л.В. 2025

УДК 821.512.145

**Нурисламова З.Г.,**
*учитель татарского языка и литературы МАОУ школа-интернат СОО с углубленным изучением отдельных предметов № 1 г. Туймазы,*
*г. Туймазы, Россия,*

## КҮПТЕЛЛЕ МОХИТТӘ БАЛАЛАРНЫҢ СӘЛӘТЕН ҮСТЕРҮ

***Аннотация****. Мәкаләдә индивидуальләштерү принципларына, мәдәниятләр диалогына, интегратив якын килү принципларына нигезләнгән икетелле һәм күпмәдәни мәктәпләрдә күпмәдәни белем бирү шартларында укучыларның сәләтен формалаштыру һәм үстерү мәсьәләләре карала. Әлеге нигездә укыту һәм тәрбияләү процессы телләр һәм мәдәниятләрнең үзара бәйләнеше идеясенә нигезләнергә тиеш. Укучыда үз мәдәнияте белән кызыксыну, аның кыйммәтләрен башка мәдәниятләр кыйммәтләре белән чагыштыру ихтыяҗын формалаштыру формаларының берсе буларак, татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадаларга әзерләнүгә игътибар бирелә. Грамматик конструкцияләрне генә түгел, тулаем тел күренешләрен һәм традицияләрен чагыштыру да әзерләүдә төп метод булырга тиеш. Тәкъдим ителгән материал мондый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: туган телне өйрәнгәндә укучыларның рус яки чит телне өйрәнү барышында алган лингвистик тәҗрибәсенә, шулай ук гомуми белемнәргә таяну максатка ярашлы.*

***Терәк сүзләр:*** *сәләтле бала, туган тел, олимпиада, икетелле белем бирү, күптелле белем бирү мохите, мәдәниятләр диалогы, үстерә торган белем бирү принциплары, туган телгә таяну, мәдәниятара аралашу, аралашу чарасы.*

Бүгенге көндә икетеллелек һәм күптеллелек төшенчәләре бик киң таралды. Татар халкы өчен бу ят, яңа күренеш түгел: милләтебезнең укымышлы зыялылары элек тә, татар теле белән беррәттән, рус, гарәп, фарсы һәм башка телләрне яхшы белгән.

Күптеллелек, беренчедән, илебездә төрле милләт вәкилләренең бергә яшәве белән бәйле. Аларның һәркайсы өчен рус теле үзара аралашу чарасы булып, үз ана телләрен дә

саклау бурычы тора. Шулай ук халыкларның ил эчендә генә түгел, бер илдән икенче илгә күченеп йөрүе дә бар. Өстәвенә, бөтен дөнья буйлап инглиз теле белән кызыксыну да арта бара. Димәк, яшь буынга, ким дигәндә, өч телдә аралаша белү мәҗбүри шарт булып тора.

Тикшеренүчеләр билгеләвенчә, икетелле (яисә күптелле) баланың баш мие сәламәт, көчле һәм активрак була икән. Билингваль балалар иң яхшы күрсәткечләргә ирешәләр: бертелле яшьтәшләренә карата акыл дәрәҗәсе күпкә югары булып, куелган бурычларны чишүдә яңача, иҗади фикер йөртә. Димәк, күп тел белү – заман таләбе [6, 37 б.]

Күптелле яисә полилингваль шәхес кем ул? Күптелле (полилингваль) шәхес ул-милли үзаңы югары дәрәҗәдә анык оешкан, мәдәниятара компетенцияләре ныклы үсешкән, кимендә ике-өч тел белгән, толерантлы һәм гомумхалык кыйммәтләренә тартылган кеше [6, 11 б.].

Рус телендә аралашып, туган телен начар белгән, хәтта бөтенләй сөйләшмәгән балалар белән ничек эшләргә? Туган теле белән кызыксыну,аңа сөю хисләре ничек тәрбияләргә? Һәм киресенчә, туган телендә ирекле аралашып, тел мохитендә тәрбияләнгән баланың сәләтен тагын да үстереп, чагу йолдыз итеп балкырлык дәрәҗәгә җиткерү өчен нишләргә? Шушы вазгыятьтән чыгып, уку-укыту процессын уңай якка үзгәртү, балаларны кызыксындыру, сәләтен үстерү максатыннан, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә һәм дәрестән тыш чараларда традицион булмаган алымнар куллану бик уңай нәтиҗәләр бирә.

Сәләтле бала – зур байлык. Бу эшчәнлектә ике юнәлеш булуы мөмкин: беренчесе-баланың телгә сәләтле икәнен вакытында күреп, аны үстерүгә ярдәм итү, тиешле шартлар тудыру; икенчесе-сәләтле икәнен күреп тә, аның белән эшләүче, ярдәм итүче, үстерүче шартларның булмавы. Соңгысы уйланырга мәҗбүр итә. Ни кызганыч, зур шәһәр мәктәбе кысаларында күпчелек баланың телгә сәләте ачылмый кала. Ә замана мәктәбе баланың табигать тарафыннан бирелгән сәләтен үстереп, аны иҗади шәхес итеп тәрбияләүне ассызыклый.

Бу форсаттан, сәләтле балаларны күрү, аларга тиешле ярдәм күрсәтү, шәхесен ачу татар теле һәм әдәбияты укытучысының һөнәри осталыгына бәйле, шуңа күрә бу эш зур җаваплылык һәм укытучы тарафыннан фидакарьлек, иҗади караш сорый [4, 37 б.]

Сәләтле балалар белән эшләүнең бер юнәлеше булып олимпиадалар тора. Күп еллар инде укучыларны татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларга әзерлим. Югарыда әйтеп үтелгән эшчәнлек- күптеллелек шартларында гаять катлаулы, әмма мөмкин булмаслык әйбер түгел.

Туган тел дәресләренә бирелгән сәгать саны аз булуы, кайбер ата-аналарның туган телгә карата кире мөнәсәбәте, баланың күптеллелек шартларында туган тел үзенчәлекләрен аңлап бетермәве, гомумән, туган тел дәресләренә караш шәһәр җирендә генә түгел, саф татар авыл мәктәпләрендә дә укытучыдан зур түземлелек сорый. Сәләтле укучыларда үз фәнеңә карата кызыксыну уяту, туган телебезне, әдәбиятыбызны тирәнтен өйрәнүгә ихтыяҗ булдыру да укытучының үз фәнен яратуына, тирәнтен белүенә һәм шәхесенә нигезләнә. Монда укучы, аның әти-әнисе белән һәрдаим аралашу, «бер дулкында булу» да – мөһим шарт. Олимпиада – баланың танып белү активлыгын камилләштерү һәм үстерерү, өстәмә әдәбият белән җентекләп эшли белү генә түгел, асылда, аның «мин-минлеген» тою, тирә-якта үз урынын табу, үзенең хезмәтеннән ләззәт кичереп, рәхәтләнеп эшләү, үз нәтиҗәләре белән лаеклы горурлану хисләре булдыру өчен иң уңышлы эшчәнлекләрнең берсе. Шуңа күрә олимпиадага әзерләнү зур җаваплылык таләп итә.

Эшне нәрсәдән башларга? Әлбәттә, һәр уку елы башында эш планы төзелә, сәләтле балалар исемлеге булдырыла, «юл картасы» төзелә. Башта фәнни-методик әдәбият, практик биремнәр, интернет-программалар тупланмасы булдырылып, системалы рәвештә тулыландырыла. Олимпиадага әзерлек иң беренче чиратта, укытучыдан белемнәре үз фәне кысалары белән генә чикләнмичә, күпкырлы иҗади фикер йөртүне таләп итә. Мөгаллим күп укырга, тел белемендәге яңалыклар белән таныш, укучы камил аралашкан телнең нечкәлекләрендә хәбәрдар булырга тиеш.

Дөресен әйткәндә, олимпиадага әзерләнергә укучыларның буш вакытын табу бик кыен, әмма баланың кызыксынуын, үсәргә теләвен күрү – барысын да хәл итә: ял көннәрендә интернет челтәрендә булдырылган махсус кушымталар аша укучылар белән онлайн әзерләнергә туры килә. Шул ук укучыларны төрле иҗади чараларда катнаштыру, тел белеме дәрәҗәсен арттыру да бик мөһим. Бу чараларны тормышка ашыру максатыннан, әзерләнүчеләр белән аерым төркем булдырыла. Тел белеме, татар мәдәнияте, халык тарихы буенча чыккан яңа басмалар, яңалыкларны шул төркемгә сала барам, чөнки бер сәгать ярым эчендә генә барлык мәгълүмат белән танышып бетеп булмый, укучылар үзаллы фикер йөртергә дә өйрәнергә тиеш. Мәкалә, әдәби әсәрләне уку да, иҗади фикерләүне үстерә, олимпиаданың иҗади өлешен үтәүдә зур ярдәм күрсәтә. Аерым бер тема эчендә әңгәмәләр, фикер алышулар, яңа чыккан фәнни китаплар, методик кулланмалар белән танышып, өйрәнеп бару зур әһәмияткә ия. Әлбәттә, болар барысы да балага аңлаешлырак булган рус һәм башка халыклар әдәбияты, тарихына таянып, андагы мисаллар белән үрелеп барылса, бигрәк тә отышлы. Олимпиада биремнәрен башкару юлында, мәсәлән, татар әдәбиятыннан җавапларның дәреслек материалына һәм тәнкыйди язмаларга таянган булуы, аларга үз шәхси бәяне бирергә кирәклеген, фикерләү дәрәҗәсен чагылдырырга тиешлеген укучыга җиткерергә кирәк.

Һәр дәреснең бер өлешен укучыларның сәләтләрен үстерүгә юнәлдерелелгән, шәхси якын килеп эшләнгән биремнәр, тестлар, өстәмә әдәбият, интернет-ресурслар белән эшкә багышлыйм. Еш кына укучыга дәрестә ниндидер тел мәсьәләсен башкаларга аңлатучы (консультант) вазифасын йөкләтәм. Бу алым да баланың белем дәрәҗәсен үстерергә ярдәм итә: ул өстәмә мәгълүмат таба, үзенчә эшкәртә, нәтиҗә ясый.

Шушы әзерлекнең ачык дәлиле – укучыларымның район,республика, регионара, халыкара олимпиадаларында ирешкән уңышлары. Күп еллар дәвамында күптеллелек мохитендә тәрбияләнгән, максатчан әзерлекле укучыларыбыз – Бәдретдинова Диләрә, Салихова Гүзәл, Суфиянов Тимур, Галина Гүзәл, Габитова Гөлшат, Бәдретдинова Эльзана, Маннанова Асылъяр, Салихова Элина, Халикова Алина – республикада гына түгел, башка дәрәҗәле олимпиадаларда призёрлар һәм җиңүчеләр булып киләләр. Төрле елларда татар теленнән халыкара олимпиада призёрлары, җиңүчеләре дә – минем укучыларым. Регионара олимпиаданың Гран-при иясе Галина Гүзәл, Бәдретдинова Эльзана булса, халыкара олимпиаданың Гран-при иясе Суфиянов Тимур булды.

Шунысы куанычлы: бу укучылар мәдәниятара дуслыкта тәрбияләнгән, күптелле вазгыятьтә аралашучы, чын милләт балалары. Алдагы тормышларын татар теле, әдәбияты белән бәйләмәсәләр дә, туган телләренә тугрылыклы, Туган илебезне чын күңелдән сөюче, милләтпәрвәр шәхесләр булып кала.

**Кулланылган әдәбият**


1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: Раннур, 2000
2. Савенков А.И. Одаренные дети: особенности психического развития. – М., 2010.
3. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогик технологилар. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2008.
4. Шумакова Н.Б. Одаренный ребенок: особенности обучения. – М.: Просвещение, 2010.
5. Юсупов Р.А. Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү. – Казан. Татар. кит. нәшр., 1983.
6. Полилингилизм и поликультурность в эпоху постграмотности. Материалы международного научного форума. – Екатеринбург, УрФУ. 2019.
7. Полилингвальное образование в школах России // Сборник материалов всероссийской научно-практической конференции. – Саранск, 2021.


© Нурисламова З.Г., 2025

УДК 811.512.145

**Нурмухаметова Р.С.,**
*доцент кафедры общего языкознания и тюркологии ИФМК КФУ*
**Саттарова М.Р.,**
*доцент кафедры общего языкознания и тюркологии ИФМК КФУ,*
*г. Казань, Россия*

## ЛИНГВОМӘДӘНИ МӘГЪЛҮМАТ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЭТНОМӘДӘНИ СҮЗЕКЛӘРЕ

***Аннотация**. Хәзерге татар ликографиясе татар телен милли-мәдәни аспектта өйрәнү өчен бай материал бирә. Мәкаләдә татар теленең уникаль икетелле этномәдәни сүзлекләре кыскача тасвирлана, аларның һәрберсендә әһәмиятле лингвомәдәни компонент бар.*

***Терәк сүзләр**: татар теле, лингвокультура, этномәдәни сүзлекләр.*

Яңа гасыр Россиянең һәм дөньядагы күпчелек илләрнең сәяси, икътисадый, мәгълүмати, мәдәни, рухи тормышында даими үзгәрешләр белән характерлана. Мондый шартларда төрле этносларның үзенчәлекләрен саклап калу, халык холкындагы үзенчәлекләрен ачыклау максатында аларның рухи һәм матди тормышын өйрәнү зарурлыгы туа. Бу вакытта телдә чагылыш тапкан этник мәдәният элементларын өйрәнүгә аерым урын бирелә.

Этномәдәни берәмлекләргә аерым бер телдә сөйләшүчеләр яшәгән өлкәгә хас табигать күренешләре атамалары, матди һәм рухи мәдәният лексикасы керә. Бу катламга караган лексиканы өйрәнү тел үсешенең һәр чорында тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итә. Әлеге хезмәт, татар халкының, аның мәдәниятенең уникальлеген ачыклау максатында, татар телендәге табигать күренешләре атамаларын өйрәнүгә багышлана. Этник мәдәниятнең төп функциясе – халыкның үзаңын саклау һәм тапшыру булганлыктан, бу берәмлекләр этник бергәлекнең үзенә күрә мәдәни коды, алар тарих, формалашу этаплары, яшәү һәм эшчәнлек шартлары һ.б. турында мәгълүматны саклый, чөнки табигать лексикасы телдә үзенчәлекле һәм серле бер катламны тәшкил итә.

Мәгълүм ки, лексика, тел системасының иң мөһим дәрәҗәсе буларак, милли дөньяны кабул итү үзенчәлекләре турындагы мәгълүматны буыннан-буынга саклый һәм тапшыра. Сүзләр мәдәни традицияләренең дәвамлылыгын һәм бердәмлеген сакларга ярдәм итә. Өйрәнү өчен алынган катлам шулай ук халыкның үзенчәлеген, кабатланмас булуын чагылдыра.

Татар теленең этномәдәни лексикасын сүзлекләргә туплап бирү тарихы әллә ни зур түгел, телнең бу бай катламына караган аерым тематик төркемнәрен лексикографик тасвирлауга багышланган беренче хезмәтләр XXI гасыр башында гына пәйда була.

2003 елда татар теленең беренче махсус этнокультура сүзлек-белешмәлеге басылып чыкты (төзүче – Р.Р.Җамалетдинов). Бу хезмәт моңа кадәр басылган сүзлекләрдән аерылып тора. Татар теленең этнокультура сүзлеге татар лексикографиясендә моңарчы күрелмәгән яңа тип сүзлек: монда аерым лексик берәмлекне теркәп, аңлатып бирү түгел, ә шул тел берәмлеге аша тел һәм мәдәниятнең үзара бәйләнешен дәлилләү максат итеп куелды. Сүзлек мәкаләләре милли-мәдәни үзенчәлекләрне ачык чагылдырган, өстәмә мәгълүматка бай, халыкның тарихы һәм матди көнкүреше белән тыгыз бәйләнгән, һәр татар кешесенә кечкенәдән таныш булган берәмлекләргә багышланды. Болар белән беррәттән, халык хәтереннән югала барган, әмма кайчандыр мөһим урын тоткан төшенчәләргә дә игътибар ителде.

Әлеге уңышлы тәҗрибә 2012 елда Казан федераль унверситетында башкарылган «Татар теленең этнокультура сүзлеге: матди мәдәният лексикасы», «Татар теленең этнокультура сүзлеге: рухи мәдәният лексикасы» хезмәтләрендә дәвам иттерелде.

2015–2017 елларда «2014–2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы» кысаларында, алдагы еллар тәҗрибәсен дәвам итеп, өч томда «Татар теленең этномәдәният сүзлеге» дөнья күрде. Әйтеп үтелгән сүзлекләрдән аермалы буларак, бу хезмәтләрдә материал татар һәм инглиз телләрендә бирелде. Сүзлекнең өч томы да Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты укытучы-галимнәре тарафыннан әзерләнде. Алар фикеренчә, рухи һәм матди мәдәниятнең кисешү ноктасы булган ризык һәм аны әзерләү белән бәйле, киенү культурасына караган, халыкның милли холкын ачык чагылдырган берәмлекләрне әлеге юнәлештә өйрәнү – тел белемендә соңгы елларда көчәеп барган лингвокультурология фәненә кертелгән зур өлеш.

Сүзлек мәкаләләренең төзелеше түбәндәгечә: баш сүздән соң аның килеп чыгышы турында мәгълүмат китерелә, әгәр сүз гарәп яки фарсы телләреннән кергән булса, чыганак телдәге мәгънәсе бирелә. Сүзлек мәкаләсенең алдагы өлешләре татар теленең төрле сүзлекләре буенча сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен, сүзьясалыш потенциалын ачыклауны күздә тота. Алга таба әлеге сүз белдергән күренеш турында өстәмә мәгълүматлар китерелә. Шуннан соң лексик берәмлекнең фразеологизмнар, мәкальләр составында реальләшүе яктыртыла. Татар җырларында, язучыларның әсәрләрендә кулланылышын барлап, сүзнең лексикографик чыганакларда теркәлмәгән яңа семантик, стилистик үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкин.

Телне мәдәни күренеш буларак өйрәнү юлында бер тәҗрибә булган тәрҗемәле этномәдәни сүзлекләрнең беренче томы 2015 нче елда дөнья күрде һәм анда татар телендәге ризык һәм аны әзерләү белән бәйле төшенчәләрне белдергән 40 сүз каралды: *азык, әйрән, бавырсак, бәлеш, ботка, бөккән, гөбәдия, гөбе, дучмак, җәймә, иләк, кабартма, казан, казы (казылык), каймак, каклаган каз, катык, кашык, коймак, кош теле, күмәч, кымыз, кыстыбый, мичкә, өчпочмак, пәрәмәч, пилмән, пычак, самавыр, сумса, таба, табак, табикмәк, токмач, умач, чәй, чәкчәк, чүлмәк, ширбәт, шулпа.* Бу берәмлекләр татар халкы формалашуга нисбәтле мөһим иҗтимагый-тарихи төшенчәләрне тәшкил итәләр. Аларның төрле чыганакларда урын алуы халыкның көнкүреше, мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм тел үзара тыгыз бәйләнгән булуны күрсәтә.

Этномәдәният сүзлегенең икенче томы 2016 нчы елда басылып чыкты һәм ул киемсалым, тукымалар һәм бизәнү атамаларына караган 45 берәмлекне яктыртты: *алка, алъяпкыч, балак, балдак, башмак, беләзек, билбау, бишмәт, бияләй, бүрек, ефәк, җиң, итәк, итек (киез итек), йөзек, каеш, калфак, ката, кәләпүш, кесә, кием, киндер, куныч, күлмәк, күн, муенса, оек /оекбаш, олтан, толып, тун, түбәтәй, ука, хәситә, чабата, чалбар, чалма, чапан, чикмән, читек, чулпы, шәл, ыштан, эшләпә, яка, яулык*.

III том 2017 нче елда «Татар теленең этномәдәният сүзлеге: кешенең интеллектуаль һәм әхлак дөньясы лексикасы» дигән исем белән басылды. Бу басмада татар халкының кыйммәтләр системасын һәм менталитет үзенчәлекләрен чагылдырган, югары дәрәҗәдәге эмоциональлеккә ия булган һәм ассоциатив кырлары бай 30 сүзлек мәкаләсе урын алды: *абруйлы, акыллы, атаклы, батыр, бәхетле, дуамал, елак, җитез, җор, зирәк, изге, ихлас, көнче, куркак, мактанчык, мәрхәмәтле, моңлы, намуслы, оялчан, оятсыз, сабыр, саран, тиле, хәйләкәр, хыялый, шаян, юмарт, явыз, ягымлы, ялагай.*

Шул рәвешчә, сүзлекнең бу томында милли тел шәхесен сыйфатлый торган кайбер лексик берәмлекләр бирелде. Кешегә генә хас булган хис-кичерешләр, билгеләр, тасвирлаулар тулы бер милләт, халык турында мәдәни-лингвомәдәни күзаллау булдырырга, үзенчәлеген тирәнрәк ачарга ярдәм итә. Шулай ук кешене дөньяның үзәгендә тора торган зат буларак сыйфатларга, аның уй-фикер рәвешен күзалларга булыша.

Этномәдәни берәмлекләрне сүзлек рәвешендә туплап җәмәгатьчелеккә тарату эше, мәгълүм сәбәпләргә бәйле, берничә ел өзелеп торды. Инде менә 2024 елда авторлар коллективы этномәдәни сүзлекнең тагын бер томын тәкъдим итәргә булды. Ул татар телендәге туганлык атамаларына багышлана.

Сайланган тематик төркем һәр телдә актив лексик берәмлекләрне тәшкил итә һәм төп сүзлек фондының иң борынгы катламына карый. Кешеләр гаиләләр төзеп яши башлаган көннән алып, гаилә эчендәге затларны атау ихтыяҗы барлыкка килгән. Башка тематик төркемнәрдән аермалы буларак, кардәшлек-ырулык атамалары гаять тотрыклы, алар күп гасырлар дәвамында үзгәрмичә, буыннан-буынга күчеп киләләр.

Әлбәттә, җәмгыятьтә барган үзгәрешләр аның бер өлеше булган гаиләдә дә үз эзләрен калдыралар, шунлыктан кайбер затларны атаучы берәмлекләрнең мәгънәләре киңәергә, яисә тараерга мөмкин, ә аерым берәмлекләр җирле төбәкләрдә генә дә сакланып кала. Менә шушы үзенчәлекләрне тел материалында күзәтү максатында, этномәдәни сүзлекнең чираттагы томы «Татар теленең этномәдәни сүзлеге: рухи мәдәният лексикасы (гаилә һәм туганлык мөнәсәбәтләре атамалары)» исеме белән тупланды.

Туганлык-кардәшлек атамалары галимнәрнең игътибарын күптәннән җәлеп итеп килгән. Аларны төрле аспектларда өйрәнүгә багышланган хезмәтләр рус тел белемендә дә, төрки тел белемендә дә шактый. Бу тикшеренүләр туганлык атамалары системасын тулаем барлаудан алып, әлеге берәмлекләрнең килеп чыгышын, таралышын, морфологик билгеләрен ачыклау, башка кардәш һәм кардәш булмаган телләр белән чагыштыруны да күздә тоталар.

Тәкъдим ителә торган хезмәттә авторлар гаилә һәм туганлык мөнәсәбәтләрен чагылдырган 25 берәмлекне (*абый /абзый, ана / әни, апа, ата / әти, әби, бабай, баҗа / баҗай, бала, балдыз, бәби, гаилә, җизнә / җизни, җиңги / җиңгә, ир, каене (каениш) / каенага // каенсеңел / каенигәч, кайната / каената // кайнана / каенана, килен, кияү, кода / кодагый / кодача, кыз (кыз бала), оныкь, сеңел / эне, туган / кардәш, үги ана, ул (ир бала), хатын*) этномәдәни материаллар ярдәмендә тасвирлауны, һәр сүзлек мәкаләсендә әлеге атаманың мәгънә үзенчәлекләрен һәм кулланылыш функцияләрен киңрәк күзалларга мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар белән баетып бирүне максат итеп куялар.

Төрки телләрдәге табигать күренешләрнең атамалары лингвистлар, фольклорчылар, этнологлар өчен аеруча кызыклы. Бу проблематика белән бәйле хезмәтләрдә актуаль бурычларның берсе – төрки халыклар дөньясының тел сурәтен (яки аның аерым фрагментларын) модельләштерү тәҗрибәсе. Бу яктан табигать күренешләрен белдергән атамаларны өйрәнү аеруча нәтиҗәле булып күренә, чөнки, бер яктан, абстракт төшенчәләрнең атамалары (конкрет лексика белән чагыштырганда) халык фикерләве үзенчәлекләрен турыдан-туры тасвирлый, икенче яктан, табигать күренешләрнең атамалары борынгылыклары һәм күп гасырлар дәвамында тотрыклылык саклаулары, шулай ук лексикографик чыганакларда җитәрлек дәрәҗәдә чагылыш табулары белән аерылып тора.

Төрки халыклар, аерым алганда татарлар да, яшәү, көнкүреш үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, табигатькә гаять якын булганнар, аннан аерылмаганнар һәм бөтен яшәешләре нәкъ менә табигатькә, андагы шартларга бәйле булган. Шунлыктан алар табигать күренешләрен үзләренчә анализлый, төрле фаразлар кыла, гомумән алганда, табигатьне бөтен нечкәлекләре белән тоя алганнар. Сүзлек мәкаләләрендә туплап бирелгән фразеологик гыйбарәләр, мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар әнә шул хакта сөйли. Татар халык һәм автор җырлары да, язучылар әсәрләреннән өземтәләр дә бу фикерне тагын бер кат дәлилли.

5 нче том итеп әзерләнгән сүзлектә (Татар теленең этномәдәният сүзлеге: табигать күренешләре атамалары / Төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова. – Казан, 2025) мәдәни яктан бай, халык тормышыннан аерылгысыз 28 табигать күренеше атамасына этномәдәни тасвирлама бирелде: *аҗаган, ай, бәс / сыкы / зыкы, боз, болын, болыт, буран, дала, елга / инеш, җил, җир, йолдыз, кар, кояш, күк (йөзе), кырау, офык, рәшә, салават күпере, таң, тау, таш, томан, урман, чишмә, чык, яңгыр, яшен.* Алар белән танышу бу хезмәтне кулларына алган һәркемгә кызыклы һәм файдалы булыр дип уйлыйбыз.

Шул рәвешле татар теленең сүзлекләргә тупланган этномәдәни лексикасы башка төрки телләр мисалында шундый хезмәтләр төзү өчен үрнәк булыр һәм киләчәктә алар барлык төрки телләрнең мәдәниятен лексикографик тасвирлауга өлеш кертер дип ышанабыз.

**Кулланылган әдәбият**

1. Татар теленең этномәдәният сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (ризык һәм савыт-саба атамалары) / Төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Ә.Ш. Юсупова Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Г.Н. Хөснуллина / Тәрҗемәчеләр: А.Х. Әшрапова, Л.Р. Мөхәммәтҗанова, Л.Р. Мөхәрләмова, Л.Х. Шәяхмәтова. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2015. – 280 б.

2. Татар теленең этномәдәният сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (кием-салым, тукымалар һәм бизәнү әйберләре атамалары) / Төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Ә.Ш. Юсупова Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, И.И. Фазлыева, З.Г. Ханова / Тәрҗемәчеләр: А.Х. Әшрәпова, Л.Р. Мөхәммәтҗанова, Л.Р. Мөхәрләмова, Л.Х. Шәяхмәтова. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2016. – 288 б.

3. Татар теленең этномәдәният сүзлеге: кешенең интеллектуаль һәм әхлак дөньясы лексикасы / Төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Ф.Р. Сибгаева / Тәрҗемәчеләр: А. Х. Әшрәпова, Л.Р. Мөхәрләмова. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2017. – 188 б.

4. Татар теленең этномәдәният сүзлеге: рухи мәдәният лексикасы (гаилә һәм туганлык мөнәсәбәтләре атамалары) / Төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Г.Ф. Җамалетдинова, Д.Г. Гайсина, Р.С. Нурмөхәммәтова, А. Ф. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Д.И. Саттарова / Тәрҗемәчеләр: А.Х. Әшрәпова, И.М. Макаров. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2024. – 216 б.

© Нурмухаметова Р.С., Саттарова М.Р., 2025

УДК 1751

**Олимова Г.Т.,**
*студент 2 курса факультета английской филологии и переводоведения Самаркандского государственного института иностранных языков, г. Самарканд, Узбекситан*
**Зияева М.Ф.,**
*доцент кафедры узбекского и иностраных языков Джизакского политехнического института, г. Джизак, Узбекистан*

# ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ ПОДХОД В ОБУЧЕНИИ ИНОСТРАННОМУ ЯЗЫКУ

***Аннотация.*** *Лингвокультурологический подход в обучении заключается в построении процесса овладения иностранным языком с учетом взаимосвязи и взаимодействия культуры и языка в процессе их функционирования и изучение этого взаимодействия в единой системной целостности. Данный подход позволяет сформировать достаточно полную картину иноязычной действительности через изучение как языкового, так и внеязыкового материала, отражающего различные сферы культуры. Таким образом, суть обучения иностранному языку в рамках лингвокультурологии заключается в том, что язык теснейшим образом связан с культурой, при этой связи происходит приобщение к культуре и овладение новых социокультурных навыков. А также в статье рассматривается проблема выбора учебного материала по русскому языку, подбора и систематизации тематики, речевых ситуаций, вопросы преподавания русского языка в технических ВУЗах на начальном этапе.*

***Ключевые слова:*** *лингвокультурологический подход, учебный материал, этап, слушатель, коммуникация, теоритический аспект, описание, повествование, рассуждение и доказательство.*

Лингвокультурология – это комплексная научная дисциплина, изучающая взаимосвязь и взаимодействие культуры и языка в его функционировании и отражающая этот процесс как целостную структуру единиц в единстве их языкового и неязыкового (культурного) содержания при помощи системных методов и с ориентацией на современные приоритеты и культурные установления (система норм и общечеловеческих ценностей). Принцип диалога культур является основополагающим в теории иноязычного образования. Использование лингвокультурологического подхода, основанного на принципе диалога культур, направлено на развитие у обучающихся умений успешно осуществлять межкультурное взаимодействие в современном мире. Наравне с принципом диалога культур важное значение при реализации лингвокультурологического подхода в обучении иностранному языку имеет принцип культуросообразности. Данный принцип определяет отбор лингвокультурологического материала при разработке культуроведческого содержания учебного материала. Его применение способствует развитию навыков межкультурного общения путем сопоставления фактов родной и иностранной культур.

Целью иноязычного образования является формирование у школьников понимания важности владения иностранным языком в современном мире и потребности пользоваться им как средством общения, познания, самореализации и социальной адаптации; развитие национального самосознания,готовности отстаивать национальные и общечеловеческие ценности, свою позицию гражданина и патриота своей страны; стремления к лучшему пониманию культуры своего народа и готовности содействовать ознакомлению с ней представителей других стран; стремления к взаимопониманию между людьми разных стран, уважительном и дружелюбном отношения к культуре других народов, позволяющем участвовать в диалоге культур.

Преподавание языка должно как можно раньше приобщить их к коммуникации, знакомить со спецификой разговорной речи. Для студентов-нефилологов русский язык – не профилирующий предмет, он не является объектом специализации, а является лишь средством ее приобретения. И перед нами встает вопрос: к какой профессиональной коммуникации будем приобщать слушателя? Ведь в одной группе иногда в других странах можно встретить студентов с разной профессиональной ориентацией: строителя, экономиста, технолога, инженера, агронома, архитектора и просто педагога.

Объектом изучения должна стать речевая деятельность, сам же язык воспринимается как объективная основа речевой деятельности. Методические разработки учебных материалов по русскому языку, прежде всего, должны отражать коммуникативную направленность обучения. Студенты должны приобрести способность участвовать в языковой коммуникации на русском языке, особенно в главных видах речевой деятельности языкового общения, имеется в виду слушание, чтение, говорение и письмо. Объективной основной данной коммуникации является субъязык изучаемой области, представленной определенной тематикой, определенными ситуациями и определенным набором языковых средств.

Чтобы начать работу над учебным материалом, прежде всего и обязательно, авторы должны определить: *что является предпосылкой для правильного определения содержания учебного материала?*

Основой правильного определения содержания учебного материала являются:

1. подбор и систематизация тематики;
2. речевые ситуации, типичные для этой тематики;
3. типы языковых сообщений;
4. типы соответствующих языковых средств.

Подготовка учебного материала по русскому языку для иностранной аудитории имеет еще и свои трудности. Надо помнить, что дисциплину «русский язык» надо рассматривать как практическую, и ее теоретический аспект подчинен практическим целям. Другими словами, основной целью является активизация навыков речевого общения в устной форме на основе изученного материала. Для выполнения этой цели дополнительные трудности

создает, прежде всего, отсутствие языковой среды, а также то, что все преподаватели ведут занятия по другим предметам на родном языке студентов, и это вполне нормально. Таким образом, студент может практически использовать свои знания в устной разговорной речи только на занятиях по русскому языку.

Все вышеизложенное еще раз говорит о том, насколько сложна и ответственна подготовка учебного материала по русскому языку для иностранной аудитории. Можно представить, какую огромную роль играет на занятиях по развитию речи на иностранном языке учебный материал. Он не только должен способствовать созданию атмосферы естественной языковой среды, что является необходимостью. Учебный материал является также основой организации всей работы со студентами.

Как уже было сказано выше, контингент слушателей в иностранной аудитории очень разный, поэтому преподаватель всегда должен ставить перед собой два вопроса при подготовке учебного материала.

1. Учим ли мы студентов русскому языку в целом?
2. Можно ли, овладев только определенным стилем речи, пользоваться русским языком в других сферах общения?

Всем нам известно, что в разновидностях литературного языка по-разному проявляются система значений слова, реальная сочетаемость лексем, окружение синтаксических конструкций, система форм в пределах грамматической категории, стилистические возможности языковых средств и многое другое. Все это говорит о том, что при составлении учебного материала по русскому языку необходимо находить разумные пропорции в привлечении материала. Количество не определяет качество.

И чтобы справиться с вышеизложенными задачами, которые необходимо учитывать при подготовке учебного материала по русскому языку, уместно сказать и об авторе.

Автор прежде всего должен правильно определить тематику будущей работы. Качество ее во многом будет зависеть и от того, насколько правильно будет подобран материал, насколько методически целесообразно будет он изложен, насколько правильно будет отобран лексический и грамматический материал и насколько правильно будет построена система упражнений. Только учет всех этих требований при составлении учебного материала будет способствовать активизации речи учащихся, практическому владению языком.

Ясно здесь одно: чтобы подготовить учебный материал с учетом вышеназванных требований, необходимо быть прежде всего квалифицированным специалистом по русскому языку, а также знать основы методических и дидактических принципов в педагогической деятельности, знать психологию.

При определении тематики учебного материала встает не менее сложный вопрос: как должна решаться проблема отбора текстов.

Прежде всего надо сказать, что сам текст является и должен быть объектом изучения. Почти традиционным сейчас стало деление текста на четыре основных типа: описание, повествование, рассуждение и доказательство. Основанием такого различия является прежде всего логическая структура текста, представленная определенным набором грамматических средств. Анализ самого текста отмечает связь между логическим построением и выбором грамматических средств.

При определении учебного материала и подбора текстов для иностранной аудитории, на наш взгляд, необходимо привлечь и самих студентов, т.е. мы должны услышать мнение студентов. Только тогда преподаватель может учитывать интерес студентов. Если же они имеют некоторые знания по русскому языку, то в этом случае в какой-то степени можно определить и знание грамматического материала, а также лексический запас слушателей. В иностранной аудитории особенно важно методически правильно организовать материал: тексты должны отбираться именно по тематическому принципу, так как это способствует прежде всего накоплению лексики. Грамматический же материал здесь можно подавать свободно, ибо тексты различны по грамматической наполняемости. Последовательность

подачи грамматического материала в этом случае также определяет сам текст. И грамматика в силу этого отрабатывается «по мере встречаемости» в тексте, что не способствует системности в подаче грамматических явлений. Основные требования к тексту:

1. текст должен вызвать интерес учащихся;
2. текст должен представлять определенную коммуникативную ценность;
3. текст должен отражать основные стилистические особенности языка;
4. текст должен нести основную информацию, стилевую принадлежность, логическую четкость.

Каждый преподаватель в процессе обучения должен научить студентов различать типы текстов, узнавать его структуру, видеть связь языковых форм и смысловых категорий. Все это влияет на глубину понимания и воспроизведения.

Особо хотим остановиться на монологической речи. В условиях иностранной аудитории прежде всего должны учить студентов формированию навыков построения связного монологического высказывания. Умение построить монологическое высказывание необходимо для того, чтобы студенты могли участвовать в беседах, дискуссиях и т.д. То есть коммуникативные задачи, стоящие перед студентами, могут быть реализованы главным образом на уровне монологического высказывания.

Изучение особенностей синтаксиса языка является центральной задачей при определении содержания обучения. Поэтому весь учебный материал представляется на синтаксической основе. Это позволяет постигать язык и его систему через основную коммуникативную единицу – предложение.

На наш взгляд, на основе интегративного подхода к иностранным языкам не только укреплять межпредметные связи в чтении, интегрировать знания, полученные по разным предметам, собирать информацию по различным предметам, формировать у учащихся компетентность получать необходимую информацию из различных предметов, использовать ее в соответствующих ситуациях, но и интегрировать речевая деятельность – слушание и понимание, говорение, чтение и письмо и прилагает важные усилия. Исходя из предположения о различных высказанных мнениях, мы руководствуемся тем, что пришли к идее, обобщение знаний, навыков, приобретенных на основе различных дисциплин. Организация введения русского языка на основе интегративного подхода дает возможность усилить междисциплинарные распределения, собирать информацию по различным темам учащихся, получать необходимую информацию из предметов, формировать компетенцию их использования в соответствии с конкретной ситуацией. Повышая эффективность этого образовательного процесса, поощряя практическое применение знаний, полученных из различных дисциплин, проявляет особый интерес к формированию профессиональных компетенций учащихся.

При этом следует подчеркнуть, что инновационный подход к изучению русского языка важен не только как важный фактор получения компетенции и предоставления информации в области науки, но и одновременно развивать факторы как, формирования умения слушать, понимать, говорить, читать и писать. Таким образом, развитие коммуникативной компетентности является важным аспектом личностного роста и успеха в жизни. Это может помочь личности эффективнее общаться, лучше понимать и адаптироваться к различным ситуациям, и строить продуктивные отношения.

В заключение отметим, что изучать иностранный язык вдвойне сложнее, так ли это на самом деле. В настоящее время в нашей стране создается множество учебников, учебных программ и различных пособий для внедрения иностранных языков в образование. Следует отметить, что большинство населения Узбекистана выбирает русский язык в качестве второго иностранного.

И преподаватели так должны строить свои занятия, чтобы у студентов появилась потребность (или необходимость) в развернутом монологическом высказывании. Или, выражаясь другими словами, высказывания на уровне предложения должны перейти на более крупную единицу – текст. Необходимо всегда помнить, что при восприятии чужого

иноязычного высказывания и оформлении своего, кроме знаний лексики и грамматических правил, следует осознать программу построения речевого высказывания, постичь его структурно-смысловую организацию. Умению составлять и реализовывать такие программы надо специально учить.

## Список литературы

1. Абдувахобова Д. Э. Познавательные мотивы подростка в процессе обучения // Молодой учёный. – 2015. – № 7. – 614 с.

2. Абдувахобова Д. Э., Эргашев У.Э. Формирование умений и навыков в учебной работе // Молодой учёный. – 2014. – № 3. – С. 762–763.

3. Абдувахобова Д.Э. Использование ИКТ в образовании – важный фактор развития информационного общества // Экономика и социум. – 2023. – № 2. – С. 386–388.

4. Абдувахобова, Д. Э. Психологические особенности обучения в процессе образования / Д.Э. Абдувахобова, М. К. Кадырова, Ш. Н. Эрназарова // Молодой ученый. – 2014. – № 8 (67). – С. 912-914. – URL: https://moluch.ru/archive/67/11268.

5. Апресян Ю.Д. Образ человека по данным языка: попытка системного описания // Вопросы языкознания. – 1995. – № 1. – С. 37–67.

6. Выготский Л.С. Мышление и речь. – М.: Директ-Медиа, 2014. – 570 с.

7. Дубровская О.Г. Русские и английские пословицы как культурологические единицы.– Тюмень, 2002. – 164 с.

8. Жуков В.П. Словарь русских пословиц и поговорок. – М.: Русский язык, 1991. – 534 с.

9. Калдыкозова С.Е. Формирование у учащихся представлений об изучение языка // Gospodarka I innowacje. – 2024. – № 3. – С. 122-128.

10. Ким Н.В. Психологичекие закономерности процесса обучения // Экономика и социум. – 2023. – № 12. – С. 879–882.

11. Теория обучения иностранным языкам. Теория обучения иностранным языкам. Лингводидактика и методика: учеб. пособие для студ. учреждений высш. проф. образования / Н.Д. Гальскова, Н.И. Гез. – 7-е изд., стер. – М.: Издательский центр «Академия», 2013 – 336 с.

12. Эргашев У.Э. Мотивы учения в подростковом возрасте / У.Э. Эргашев, Ш. А. Муртазаева, Ф. Б. Эшонкулова // Молодой ученый. – 2015. – № 7(87). – С. 702–707.

© Олимова Г.Т., Зияева М.Ф., 2025

УДК 821.512.145

**Рамазанова А.Р.,**
*студент 4 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Халиуллина А.Г.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## ДИЛӘ БУЛГАКОВЫНЫҢ «ҮРМӘКҮЧ» ХИКӘЯСЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ / АНА ОБРАЗЫ

***Аннотация***. *Мәкаләдә Д. Булгакованың «Үрмәкүч» хикәясендә катлаулы һәм күпкырлы хатын-кыз образы тикшерелә, тормыштагы шактый четерекле шартларда ана образы карала.*

***Терәк сүзләр:*** *татар әдәбияты, хатын-кыз образлары, ана образы, татар хатын-кызы, төрмә прозасы.*

Хатын-кызның кешелек тормышында, яшәешебездә аерым урыны бар. Бу турыда төрле фикерләр яши. Әдәбият тормышны чагылдыручы көзге ролен үтәгәнгә, әдәби әсәрләрдә бәхетле аналар да, балаларын бер күрергә зар-интизар булып торганнары да, үги аналар да, сабыйларын язмыш кочагына ташлап китүчеләре дә бар. Әниләр турында халык күп, төрле жанрларда иҗат иткән. Җырлар, шигырьләр, поэма, баллада, әкият, хикәя, повестьлар... Иң үтемлесе – проза әсәрләре. Чөнки әниләр, балалар турында, алар арасында була торган бәйләнешләр хакында сөйләп бетерү мөмкин түгел. Күп очракта сүз аналарының кадерен белмәгән балаларына кайтып кала.

Иҗтимагый чынбарлык, заман әверелешләре язучы иҗатына көчле йогынты ясый. Ул үзгәрешләрнең кешеләр тормышына, аларның психологиясенә йогынтысын язучы геройлар язмышы аша сурәтли, аларга үз мөнәсәбәтен ачыклый. Әдәбиятның мөһим темаларының берсе булган хатын-кыз язмышы мәсьәләсенең татар әдәбиятында үсеш-үзгәрешен күзәтүдә бу ачык күренә.

Әдәбиятчы А. Ганиева билгеләвенчә, «Татар әдәбиятында анага ихтирамлы мөнәсәбәт борынгы әдәбияттан ук килә. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында үсеш алган татар реалистик прозасы да үзенең башлангыч чорында ук гаиләне иң мөһим кыйммәт дип билгели. Шул ук вакытта мәдәни күтәрелешне тәэмин иткән мәгърифәтчеләр төп игътибарны, милли кыйммәтләрне алдагы буынга тапшыручы буларак, хатын-кызга, аерым алганда, ана образына юнәлтәләр» [4, 62 б.].

Әдәбият тормышны чагылдыручы көзге ролен үтәгәнгә, әдәби әсәрләрдә бәхетле аналар да, балаларын бер күрергә зар-интизар булып торганнары да, үги аналар да, сабыйларын язмыш кочагына ташлап китүчеләре дә бар. Инде алда әйтеп киткәнебезчә, мәгърифәтчелек әдәбиятында татар хатын-кызлары образына зур урын бирелә. Бу тема хәзерге көннәрдә дә үзенең актуальлеген югалтмаган. Татар әдәбиятында хатын-кыз темасына мөрәҗәгатъ итмәгән бер генә шагыйрь дә, бер генә язучы да юктыр. Шагыйрьләр һәм әдипләр озак гасырлар дәвамында хатын-кыз матурлыгына дан җырлаганнар, гүзәллегенә таң калганнар. Аларның һәрберсе хатын-кызны бәхетле итү уе белән язганнар. Хатын-кыз бәхете, аның иреге мәсьәләсе бүгенге тормышта милли проблема кебек үк, иң үткеннәрнең берсе булып тора, чөнки кешене физик яктан да, рухи яктан да хатын-кыз тудыра һәм үстерә. Табигать һәм кешелек җәмгыяте тарафыннан хатын-кызга әнә шундый иң бөек вазифа йөкләнгән. Кызганыч, шагыйрьләр һәм язучылар аларның бәхетен кайгыртып ни генә язмасыннар, сүз ярдәмендә ничек кенә көрәшмәсеннәр, алар барыбер тормыш ачысын татып, аның авыр йөген тартып яши биргәннәр.

Башкортстанда яшәп иҗат итүче Дилә Булгаковының «Үрмәкүч» әсәрендә хатын-кызлар образын карасак, кызыклы нәтиҗәләргә килергә мөмкин. Гомумән, «Үрмәкүч» әсәре Дилә Булгакованың «төрмә» циклына керә, димәк әлеге цикл әсәрләрендә зинданда утырган кеше гомере тасвирлана. «Бу персонажларны «абсолют явызлыкны» гәүдәләндерәләр дип атарга кыен, һәм бу фонда каршылыклар геройларның гамәлләре һәм рухи кичерешләре арасында безне чолгап алган реаль дөньяга чакыру буларак чыгыш ясыйлар. Автор позициясе ике төрле аңлатыла: реаль дөньяда кешенең социаль ирексезлеге һәм кайгы, авыр кичерешләр белән тулы экзистенциаль, һәм әхлакый кешелек йөзе, халыкның гуманистик кыйммәтләре һәм әхлакый традицияләре аша чагыла» [12, 1808 б.]

Хикәя үзәгендә ике хатын-кыз образы бирелә. Беренчесе – Суфия, төп геройларның берсе, икенчесе – Суфиянең ак әбисе. Аның исеме телгә алынмаса да, геройлар тормышындагы урыны тоемлана, ак әби ике балага ана булып, тәрбия бирә: «*Ак әбисе Суфияның үзен дә, улын да тәрбияләде. Әни дә, әти дә булды ул алар өчен*» [2, 33 б.].

Татар әдәбиятында Акъәби, Акбабай образлары еш кулланыла. Аларны милләт гаделлек, аклык билгесе буларак күрергә күнеккән.

Мәрхәмәтле, олы җанлы аналар каршында һәркем тигез бурычлы: яңа туган сабый да, үсмер егет һәм кыз да, олыгаеп килүче шагыйрь дә... Аналарга багышланган җырлар, романнар, повестьлар, поэмаларда аларга бурычлы булуыбызны кабатлап туя алмыйбыз.

Дилә Булгаковының «Үрмәкүч» әсәрендәге төп герой Суфия, яшьли кайгыга күмелеп үскән җан. Авторның бу геройга аерылып торган мөнәсәббәте сизелә. Исем биргәндә үк, ул аны Суфия дип исемли. Суфия – чыгышы белән гарәп исеме, хатын-кыз исеме. Исемнең мәгънәсе – «начар эшләргә бармаучы, суфи, гыйбадәтчел, тәкъва» [6, 166 б.]. Димәк, язучы бу образга өмет баглый, геройны фәрештәгә тиң образ итеп сурәтли.

Тормыш аның юлына гади кеше үтеп чыга алмаслык авырлыклар ташлый. Бала чагыннан аны үги әтисе тарафыннан мәсхәрәләнә: «*Хәсрәтнең иң олысы төшкән иде шул Суфиянең башкаена. Аны үги әтисе, исерек Әнәс абыйсы көчләде»* [2, 36 б.]. Суфия балага узган була һәм якты дөньяга Мөслим исемле малай алып кайта. Мөслим үзенең туу тарихын белгәч, үз атасын үтерә: «*Әнисен мәсхәрәләгән өчен дә, әтисез үскән еллары өчен дә үч алган – кулын әтисенең каны белән юган...»* [2, 38 б.]. Җинаяте өчен егетне төрмәгә ябалар. Суфия дүрт ел улын күрү хыялы белән яши һәм аңа мондый мөмкинлек бирелә, ул улы янына төрмәгә бара. Алма агачыннан ерак төшми, ди халык әйтеме. Атасының юлын кабатлап, Мөслим үз әнкәсенә кагылырга да чирканмый: *Йөрәгендә еллар буе җыела килгән, назлы сүзләрен түгеп, тилерә-тилерә төне буе Суфияны назлады, шашына-шашына анасын төрлечә кыландырып, ботарлап ташлардай булып сөйде* [2, 39 б.]. Бу вакыйгадан соң төп геройның язмышы икегә бүленә һәм ул башкача бәхетле тормышка өмет бagламый: *Шул көннән соң Суфия күршеләренә дә кермәс, балкып урамга да чыкмас булды. Кояш баегач та күтәрмәгә чыгып утыра да бер ноктага карап тик тора. Шулай елларны сүтә-сүтә акрын гына сүнә барды Суфия* [2, 42 б.].

Суфиянең фаҗигале язмышы язучы тарафыннан «градация алымы ярдәмендә ачыклана һәм киеренке ноктага җиткерелә» [10, 268]. Героинягә башта үги атасы, ә аннары үз улы тарафыннан ясалган хурлык, психологик һәм рухи җәзаны арттыру өчен кулланылган әдәби алым булып тора. Автор көчергәнешле нокта итеп, корбанны һәм җафалаучыны бер көнкүреш ситуациясенә урнаштыра: *Көндезләрен «әнкәй!» дип дәшсә, төннәрен «бергенәм, кадерлем!» дип тилерде, яратты* [2, 46 б.] дигән сүзләр өстәп, Суфиянең мәсхәрә ителүе арасындагы каршылык китерелә. Бу контраст аның тормышындагы иң олы изелүне – янындагы кеше тарафыннан рухи җимерелүне символлаштыра. Шулай итеп, автор хатын-кызның гаилә һәм җәмгыятьтәге хәленә тәнкыйди караш ташлаудан бигрәк, җәмгыятьтәге социаль нормаларның җимерелү фаҗигасен күпертеп күрсәтә.

Бу вакыйгалардан соң Суфия озак яшәми, кызганыч, ләкин үлеме аның тормышындагы хурлыктан котылуның бер юлы булып тора: *Суфиянең тынычлап калган йөзенә, аккоштай ак күлмәк кигән сылу гәүдәсенә карап, байтак вакыт авыр тын алдылар»* [2, 49 б.].

Чыннан да, бүгенге тормышта, нык күбәеп, көчәеп киткән эреле-ваклы әшәкелек ташкынына каршы тора алу, шундый мохиттә яшәп тә, буялмый, пычранмый калу – үзе бик тә зур батырлык, ныклык сорый шул. Баласы тоткынлыкта чакта да, аннан соң да үзе дә тоткынлыкта яшәүче, сынган, сыгылган бу образ нинди генә заманда, нинди генә шартларда яшәсә дә Ана булып калганлыгын гәүдәләндергән. Язучы әсәрләре хакында фикер алып барганда, «Туган як әдипләре» китабының авторлары белән килешми мөмкин түгел. Алар фикеренчә, «Геройлар характерына салынган үзгәлек вакыты-вакыты белән типиклык кануннарыннан читләшүгә дә алып килә» [13, 106 б.].

Автор Суфия образы аша зур фәлсәфи сорау күтәрә: пычыраклыкны түзеп яшәү һәм моны үзгәртүгә көч салмау изгелек билгесе микән? Суфиянең яшәешендә үсеш күзәтелми. Аны татар хатын-кызының типик образы дию дә дөрес булмый. Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять», Ш. Хөсәеновнең «Әни килде», А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» әсәрләрендә тасвирланган олы җанлы аналардан аерыла, Муса Җәлилнең «Алтынчәч» поэма-либреттосындагы тугыз баһадирны үстергән Тугзак-анадан ерак тора. Фронтовик-шагыйрьнең «ананы, хатын-кызны тереклек чишмәсе итеп тасвирлаучы Көнчыгыш әдәбияты традицияләренә мөрәҗәгать иткән» [3, 6 б.] «Ана бәйрәме»ндәге ана сыйфатлары да күренми.

Әдәбиятчы А. Хәлиуллина әдәбиятта типиклаштыру күренеше хакында фикер йөртеп, Д. Булгакованың «Үрмәкүч» әсәренә карата түбәндәге юлларны яза: «Хикәянең нигезенә җан

өшеткеч вакыйга алынган: тоткынның үз әнисе белән төрмә камерасында җенси мөнәсәбәткә керүе һәм иреккә чыкканнан соң да шул хәлләрнең дәвам итүе. Һәм бу җир йөзендәге әшәкелекләрнең берсе буларак тасвирланган. Сүз дә юк, ана зур тетрәнү кичерә, бу минуттан аның язмышы бөтенләй башка төсмер ала: бер төндә чәче агара, ахирәтләре, күршеләре белән аралашмый башлый, үз-үзенә бикләнә. Ә менә тормыштагы бу факт хикәядә художестволы факт дәрәҗәсенә күтәрелә аламы соң? Әлеге вакыйга ананың, аның улының характерын ачарга, бер-берсенә булган мөнәсәбәтен чагылдырырга, я булмаса башка якка үзгәрергә ярдәм итәме соң? Һич югында кешеләр арасындагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, әхлакый кануннарны үзгәртергә этәргеч ясыймы?» [10, 49 б.]. Әдәбият белгече тарафыннан куелган сорауларга «Әлбәттә, юк! [11, 49 б.], – дигән җавап бирә. Әйткәннәрен куәтләп, әсәрне тикшерүче ягыннан түбәндәге нәтиҗә ясала: «Язучы ана кеше баласының нинди генә гөнаһларын гафу итми дип әйтергә теләгәндер, бәлки. Ләкин хикәя андый идея яңгырашы бирерлек дәрәҗәдәге материалга нигезләнмәгән» [11, 49 б.].

Суфия – язмыш корбаны, аның гәүдәләнешендә автор бик мөһим, бүгенге көндә дә актуаль социаль пролеманы ачыклый, ул да булса: яшьли балага узып, алып кайткан балаларына тиешле тәрбия бирә алмаган аналар. Кешене кеше итеп тәрбияләү өчен, беренче чиратта үзеңә формалашып беткән шәхес булырга кирәк.

Шулай итеп, бүгенге татар прозасында хатын-кызлар образлары аша язучы мөһим иҗтимагый сорауларны күтәрә. Ул да булса намауслы хәләл җефет булу, балага яхшы тәрбия бирердәй ана булу. Хатын-кыз тормышын бер мизгелдә юкка чыгарып булганлыгын да автор ассызыклый. Димәк, һәрдаим нечкә, хәтта артык нәзберек итеп сурәтләнгән гүзәл затлар, Дилә Булгакованың әсәрендә дә үзгәрешсез кала. Язучы бәхет өчен кеше гомере буе көрәшергә тиеш, бирешергә ярамый, яшәешнең максаты булырга тиеш дигән фикерне дә күтәрә.

**Кулланылган әдәбият**


1. Ахунов Г. Язучы һәм заман // Казан утлары. – 1988. – № 1. – Б. 119–126.
2. Булгакова Д. Паутина = Үрмәкүч: рассказы: хикәяләр. Под ред. Д. Мурзакаева. – Уфа: Китап, 2001.
3. Вәлиев М. Гамәл дәфтәре: Әдәбият һәм тормыш турында уйланулар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 447 б.
4. Ганиева А.Ф. Татар әдәбиятында милли асылны саклаучы ана образы // Фәнни Татарстан. – 2021. – № 4 (32). – Р. 61–70. – EDN SEAZUN.
5. Маннапов С. Хәтер https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/1982-5/khter-1666254820
6. Саттаров Г.Ф.. Татар исемнәре сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 256 б.
7. Сафуанов С. Рухи күперләр. – Уфа: Китап, 2006. – 376 б.
8. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60–90 еллар әдәбияты. – Казан: «Раннур» нәшр., 2001. – 544 б.
9. Фазлетдинов И.К., Хәлиуллина А.Г., Сөләйманова Д.Д., Сайфулина Ф.С. Татарстаннан читтә иҗат ителгән әдәбиятта татар мотивлары (Башкортстан һәм Себердәге әдәбият) // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р. Ф. Рахмани]. – 8 т.: 2001 – 2020 еллар]. Казан: Фолиант 2021. – Б. 612–689.
10. Халиуллина А. Г. Дилә Булгакова хикәяләрдә геройларны гәүдәләндерү чаралары // Вопросы языковых контактов и литературных взаимосвязей в полилингвальном и поликультурном образовательном пространстве: Сборник материалов Всероссийского научно-методического семинара, посвященного 60-летию доктора филологических наук, профессора Илшата Сахиятулловича Насипова. Уфа, 2025. С. 362-371. – EDN QMGRZG.
11. Халиуллина А.Г. Заман һәм герой. – Уфа: БГПУ им. М. Акмуллы, 2007. – 206 с. – EDN VVVCOZ.

12. Халиуллина А.Г. Художественное осмысление темы «неволи» в рассказах Дили Булгаковой // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – 2022. – Т. 15. – № 6. – С. 1807–1811. – DOI 10.30853/phil20220335. – EDN JNGKHA.

13. Халиуллина А. Г., Сулейманова Д. Д. Туган як әдипләре: Башкортстанда хәзерге татар прозасы: шәхес, иҗат, тәнкыйть. – Уфа: Китап, 2013. – 320 с. – ISBN 978-5-295-05884-4. – EDN VVVCOP.

© Рамазанова А.Р., 2025

УДК 811.512.145

**Рамазанова Г.Р.,**
*студент 6 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*

# КУЛЛАНЫЛЫШЫ ЧИКЛӘНГӘН ЛЕКСИКА БУЛАРАК ХӘРБИ ТЕРМИННАР

***Аннотация.*** *Мәкаләдә татар телендә кулланылышы чикләнгән лексика буларак хәрби өлкәгә караган сүзләрне өйрәнү тарихы тасвирлана. Аларның тематик төркемнәре, актив һәм пассив лексиканы үз эченә алган системалы классификация бирелә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, лексикология, хәрби лексика, семантика, классификация, термин*

Татар телендәге хәрби лексика озак вакытлар очраклы күзәтүләр һәм фрагменталь тикшеренүләр предметы булып торды. Бары тик XX гасыр ахырында гына татар теленең бу мөһим өлешен тирәнрәк аңлау һәм өйрәнү башлана. Мондый артта калуның сәбәпләре тулаем шартлар комплексында ята, алар арасында сәяси вәзгыятьне, тикшеренү инструментларының җитәрлек дәрәҗәдә эшләнмәгәнлеген һәм квалификацияле кадрларның булмавын билгеләп үтәргә кирәк.

Алга таба, тел белемендә билгеле булганча һәм Р.Т. Сәфаровның «Татар телендә хәрби сүзләр» дип исемләнгән диссертация нигезендә, хәрби лексиканы өйрәнүнең чорларын билгеләп үтәбез.

Төрки телләрнең хәрби лексикасы галимнәрнең өйрәнү объектына чагыштырмача күптән түгел генә әйләнде. Барлык төрки телләрдән дә хәрби лексика махсус өлкә сыйфатында монографияләрдә җентекләп өйрәнелде һәм төрек теле сүзлекләрендә эшләнде. Беренче рус-төрек сүзлекләре XIX гасырда ук басылып чыга, соңрак тагын берничә сүзлек чыгарыла.

Хәрби лексика бүгенге көндә дә өйрәнелде һәм өйрәнелә, хәрби терминнарның махсус сүзлекләре төзелә. Бу теманы өйрәнүче галимнәр: М.А. Гамазов, П.С. Бочкарев, Л.П. Бочкарев, Б.М. Хохлов.

Башка төрки телләргә килгәндә исә, аларның күпчелегендә хәрби лексика искерә, кулланыштан чыга, кирәк булмау сәбәпле эшләнми. Гражданнар сугышы чорында милли төбәкләрдән чакырылган сугышчылар рус теленең хәрби лексикасын түгел, бәлки үз милли телләрен белгән, чөнки һәр төрки халыкның хәрбиләре сугышчан төшенчәләрне һәм күренешләрне билгеләгәндә үз туган телләрен кулланганнар. Командалар һәм боерыклар шулай ук милли телләрдә бирелде. Әмма бердәм армия барлыкка килү һәм республикалар СССРда берләшү белән, барлык милли командование унификацияләнә, бердәнбер милләтара аралашу теле һәм армия теле рус теле була. Шулай итеп, һәрбер аерым төрки халыкның халык авыз иҗатында сакланып калган уникаль хәрби лексикасы әкренләп онытыла башлады. СССР таркалганнан соң суверен булган һәм эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә, шул исәптән хәрби өлкәдә дә, туган телләренә күчә башлаган республексикаларда вәзгыять бераз башкачарак күзәтелә [4, 54 б.].

Ю.А. Яковлевның «Пути развития и способы образования турецкой военной терминологии» (1969) диссертация хезмәтендә төрек хәрби терминнарының генетик килеп чыгышы нигезендә сүз ясалышы үзенчәлекләре, ягъни төрек теле чаралары ярдәмендә, башка телләрдән алыну юлы белән, катнаш юл белән хәрби терминнар ясалуы карала. Чыганаклар сыйфатында автор хәрби сүзлекләрне һәм сөйләм китапларын, шулай ук хәрби лексиканы үз эченә алган гомуми сүзлекләрне куллана, яхшы һәм кимчелекләрен күрсәтеп, бу чыганакларны җентекләп тасвирлый [4, 34 б.].

Хәрби лексика тюркологиядә шактый җентекләп эшләнгән. Бу юнәлештә алып барылган эш, нигездә, чагыштырма яктылыкта лексиканы өйрәнүнең кыйммәтле чыганагы булган тарихи яки махсус әдәбиятта, дәреслекләрдә һәм сүзлекләрдә булган терминнарны гади теркәүдән гыйбарәт.

Шулай итеп, хәрби лексика тюркологиядә чагылыш тапкан. Элек тә, бүген дә тармак терминологиясен сүзлекләрдә җыю һәм теркәү буенча зур эш алып барыла.

Татар тел белемендә хәрби лексика лексикологик аспектта әлегә кадәр иң аз яктыртылган проблемаларның берсе булып тора. Махсус монографик тикшеренү объекты буларак, әлеге тема әлегә аз өйрәнелгән булып кала бирә. Лингвистлар, әдәбият белгечләре, тарихчылар хезмәтләрендә хәрби лексикага кагылышлы аерым мәсьәләләр генә каралган.

Р.Г. Әхмәтьянов хезмәтләрендә хәрби лексикага зур игътибар бирелә. Аның «Урта Идел буе халыкларының материаль мәдәниятенең гомуми лексикасы» (1988) монографиясендә бер бүлек хәрби оешмага һәм коралларуга багышланган. Автор башка төрки, фин-угор, монгол һ.б. телләрдән бик күп паралельләр китерә.

«Татар терминологиясенең тарих чыганаклары» (2003) монографиясендә Р.Г. Әхмәтьянов шулай ук хәрби лексикага туктала. Ул хәзерге татарларның ата-бабаларының хәрби оештыру һәм кораллану сүзләрен җентекләп тасвирлый, этимологиясе турында кыскача мәгълүмат бирә, я төрле чорларда кулланылган, я билгеле бер семантик аерымлыклары булган билгеле бер терминнарның тулы бер синонимик рәтләрен китерә.

Р.Т. Сәфәров үзенең «Татар телендә хәрби лексика» дигән диссертация хезмәтендә хәрби терминологиянең үзенчәлеген һәм аның татар теле структурасындагы ролен өйрәнә. Тикшеренүнең түбәндәге аспектларына төп игътибар бирелә: хәрби лексиканың килеп чыгышы һәм үсеше, хәрби лексиканың семантик кыры, хәрби лексиканың структур үзенчәлекләре, хәзерге татар телендә хәрби лексиканы куллану, хәрби лексиканың этномәдәни үзенчәлеге.

Рус теленә күз салсак, аның тарихи үсешендә хәрби лексиканың өйрәнү проблемаларына күп кенә тикшеренүчеләрнең хезмәтләрен билгеләп үтергә мөмкин, ләкин, әйтүебезчә, татар телендә бу сферу әле өйрәнү дәрәҗәсендә генә.

Борынгы рус чорының хәрби лексикасы күбрәк өйрәнелгән. Әйтик, А.С. Львов Киев гаскәрләренең хәрби атамалары тарихын һәм аларның «вакытлы повестьлар»да кулланылуын күзәтә. Хәрби лексика эволюциясенең факторларын П.Я. Черных билгеләргә омтыла. Б.А. Ларин элеке рус чорының хәрби лексикасы тарихы, аның барлыкка килүе һәм семантикасы буенча кыйммәтле кисәтүләр ясый.

Ф.П. Сороколетов «XI–XVII гасыр рус телендә хәрби лексика тарихы» фундаменталь хезмәтендә «хәрби сүзләрнең төгәллеген һәм тотрыклылыгын, аларның хәрби эшкә хезмәт күрсәтүче төшенчәләрнең һәм идеяләрнең семантик бәйләнешен билгеләргә мөмкин, ягъни терминнарга һәм терминология системаларына, безнең очракта – хәрби терминологик лексика системасына караган билгеләр булуны билгеләргә мөмкин» [6, 27 б.], ди.

Соңгы унъеллыкта тарихи-лингвистик һәм этимология өлкәсендә аерым хәрби лексемаларын өйрәнүгә багышланган эшләр барлыкка килде.

Хәрби лексика өлкәсендә тикшеренүләр елдан ел артып бара. Информатиканың һәм компьютер технологияләренең алга таба үсеше мәгълүматларны цифрлы эшкәртү, электрон сүзлекләр төзү һәм текстны автоматлаштырылган анализлау өчен яңа офыклар ача. Челтәр ресурсларын һәм платформаларын булдыру, белем туплау темпларын тизләтеп һәм анализ

методларын камилләштереп, төрле регионнардан һәм илләрдән тикшеренүчеләрнең тырышлыгын берләштерергә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, татар телендә хәрби лексиканы өйрәнү беренче күзәтүләрдән алып бербөтен фәнни дисциплина булдыруга кадәр озын юл үтте. Алга таба перспективалар тикшеренү методларын камилләштерү, белгечләр әзерләү дәрәҗәсен күтәрү һәм халыкара кооперацияне көчәйтүдән гыйбарәт.

Мисал өчен, билгеле филология фәннәре кандидаты Р.Т. Сәфаров нәкъ «Татар телендә хәрби сүзләр» дигән темага диссертация һәм 2012 елны аны яклый. 2015 елны 196 битлек монография бастырып чыгара. Шулай ук Р.Т. Сәфәровның «Татар-рус хәрби лексика сүзлеге» дә 2017 елны дөнья күрде.

«Татар телендә хәрби лексика» темасының актуальлеге: хәрби лексика барлык телләрдә дә аерым урын алып тора, чөнки ул тарихи вакыйгаларны, хәрби эшчәнлекне һәм халыкның милли гореф-гадәтләрен чагылдыра. Татар теле очрагында әлеге тема берничә сәбәп аркасында аеруча актуальләшә.

Тарихи әһәмияте – татар халкының Алтын Урдадан алып Бөек Ватан сугышында һәм аннан соңгы конфликтларда катнашуына кадәр бай хәрби тарихы бар. Хәрби лексика татар халкының тәҗрибәсен һәм каһарманлыгын чагылдыра, шулай ук халыкның менталитетына һәм дөньяга карашына йогынты ясый. Хәрби лексиканы өйрәнү милли рухны һәм хәрби мәсьәләләргә мөнәсәбәтне тирәнрәк аңларга ярдәм итә; фәнни-тикшеренү кыйммәте – хәрби лексиканы фәнни өйрәнү татар теленең килеп чыгышы һәм эволюциясе турындагы белемнәрне тирәнәйтергә мөмкинлек бирәчәк. Хәрби лексика халыкның тарихы һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнгәнлектән, аңа анализ ясау татар халкының этник психологиясен һәм кыйммәтләрен аңлауга мөһим ачкычлар бирә. Мәдәни мирасны саклау – хәрби лексика еш кына халык әкиятләре, риваятьләр һәм мәкальләр аша буыннан-буынга тапшырыла. Аны фиксацияләү һәм анализлау мәдәни мирасны саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру өчен мөһим; бүгенге көн вәзгыяте – кулланылыш даирәсе буенча аерым бер төркемне хасил итүче хәрби лексика татар телендә гасырлар дәвамында формалашып, үсеш-үзгәреш кичергән хәлдә, бербөтен система буларак, бүгенгәчә килеп җиткән.

Лексик системаның бөтенлеге аның бертөрле булуы дигән сүз түгел, сүзлек составының тулылыгы һәм системалылыгы аның төрле формаларда һәм төрле иҗтимагый һәм территориаль катлам вәкилләре сөйләмендә татар теленең табигыйлеген, байлыгын һәм функциональ мөмкинлеген тулысынча файдаланып яшәвендә чагылыш таба.

Хәрби лексика хәрби тормышның барлык өлкәләрен: төрле корал һәм техника атамаларыннан алып шәхси кирәк-ярак предметларына кадәр, шулай ук хәрби хезмәткәрләр арасында аралашу үзенчәлекләрен дә үз эченә ала [2, 235 б.]. Хәрби тормыш өлкәсе бер урында гына тормыйча, даими үсештә булган кебек, хәрби лексика да шулай: үзгәреп тора.

Татар телендә хәрби лексиканы лексик-семантик үзенчәлекләре буенча түбәндәге тематик төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин. Мәсәлән:

**1. Гаскәрләрнең, отрядларның, бүлекчәләрнең атамалары:** *ләшкер, военкомат, черчет, сак, арт ил, бүлҗәр, берләшмә, галиб, ыстан, лава, шеренга, резерв, тыл, мар, каравылханә, нәүбәт, армия, артиллерия, әләмән, әрме, әшкәр, ополчение, лагерь, фланг, фронт, часть, чәри, гарнизон, гаскәр, йортавыл, җәяүле, кавалерия, канат, саф, сипаһ.*

**2. Хәрби исемнәрнең, вазыйфаларның һәм һөнәрләрнең атамалары:** *җиңелүче, бунтчы, болачы, бөгәвел, башлык, башыбозык, восстанияче, гуардин, гренадер, герой, генералиссимус, гази, забит, чавыш, йөзбаш, чура, чин.*

**3. Хәрби һәм саклагыч кием, хәрби трофей атамалары:** *броня, амуниция, алпак, алдамиян, бакрач, битлек, борынча, бәрең, бәйдәнә, зирәһ, шлем, шаң, шайман, шай, дулга, дөлмән, панцирь, сакалдырык, савыт, сөмәк, саравыч, кыяу, калкан, кабаи аһәнин, тубыка, тигәләй, тубылдырык, турка, түбәтәй, ялау, кирәүкә, көбә, корал-ярак, куяк.*

**4. Коралларның (корал өлешләренең), кораллы бәрелешләрдә кулланыла торган предметларның атамалары:** *берданка, кабызгыч, дары, кубыр, һәдәф, прицел, мәрәй, айбалта, айпычак, аләт, алтатар, алтыколак, амбразура, арсенал, аткы.*

**5. Сугыш вакытында барган процесслар һәм гамәлләр, урыннар:** *җиңеш, галәбәлек, зафәр, бола, инкыйлаб, алыш, атака, атыш, баскынчылык, барымта, бастион, блокада, буталыш, бунтарьлык, бунт, болганыш, баз, бәрелеш, восстание, газават.*

**6. Дошманнан саклану, күзәтү һәм корал өчен төрле корылма атамалары:** *блиндаж, бөреҗ, башня, вал, шәрәфә, хисн, хәндәкъ, сырган, кальга, каланча, тура, таран, урай, ур, колып, кирмән, кәнт, катау, касыр, курган, кремль, крепость, ныгытма, күшек, сап, коралханә.*

**7. Тоткынлык белән бәйле сүзләр:** *әсир, тоткын, туснак, тел, тоснак, ясир, качкын, заложник ,рәһен, әсирлек, плен, полын, качкынлык, гауптвахта, саугa, саугат, аманәт.*

**8. Ризык атамалары:** *азык, азык-төлек, провизия, ризык, төлек.*

**9. Хәрбиләрнең төрле сыйфатларын белдерүче сүзләр:** *пәһлеванлык, баһадиранә, каһарманлык, азамат, геройлык, бәрмә, гаскәрилек, галәбәдар, дошманчылык, сугышчанлык, мәргәнлек, баһадирлык, батырлык, җан дошманы, кас, гадү, гавер, хәсым.*

Моннан тыш хәрби лексикага караган сүзләр кулланылыш активлыгы ягыннан да барлык пластларны да алып торалар. Шуңа күрә аларны кулланалыш активлыгы ягыннан да анализарга мөмкин.

Актив лексикага түбәндәге сүзләрдән гыйбарәт: военкомат, берләшмә, гаубица, резерв, тыл, армия, артиллерия, ополчение, лагерь, гарнизон, гаскәр, гауптвахта, җәяүле, кавалерия, канат, полк, дивизион, дивизия, рота, команда, разряд, отделение, отряд, генералитет, взвод, батальон, батарея, авангард, Ватан, җиңелүче, җиңүче, бунтчы.

Ләкин, татар телендә тагын бик күп пассив лексикага карый торган хәрби сүзләр бар.

Мисал өчен:

1) Тарихи сүзләр: алпак (металлдан эшләнгән хәрби баш киеме, тимер башлык), ятаган(кылыч белән чәнчеп-кискән һәм чәнчеп-кискән салкын корал, бер җөйле озын, ике тапкыр бөгелешле кылыч; кылыч белән такта арасында ниндидер урталык бар), ук-садак (корал, кораллану, уклар сала торган капчык), капка сакчысы (капка төбендә басып торган сакчы), арканчы (лассо белән коралланган сугышчы).

2) Архаизмнар: ярак – амуниция, яу – сугыш, ихтилалчы – революционер, әрме – армия, янарал – генерал, галиб – җиңүче.

3) Неологизмнар. Соңгы елларда хәрби сферага караган бик күп сүзләр барлыкка килде һәм актив кулланышка кереп тә китте. Кайбер неологизмнар бик кыска вакыт эчендә актив лексика катламына керделәр. Әйтеп үтәргә кирәк, барыбер дә неологизмнарны күбрәк рус сүзләре тәшкил итә һәм алар тәрҗемә ителми, димәк турыдан-туры рус сүзе белән татар теленә керә. Ясалыш ысулы буенча, бик күп аббревиацияләр, шулай ук тезмә, ясалма, кушма һәм парлы сүзләр дә бар. Мәсәлән, МХО (Махсус хәрби операция), БПЛА (Пилотсыз очу аппараты), груз-300 (МХОда яраланган яучы), мобилизация (кораллы көчләрне һәм дәүләт инфраструктурасын хәрби әзерлеккә китерүгә юнәлдерелгән чаралар җыелмасы), Zа победу (лозунг).

Лепестки (хәрби хәрәкәтләр зонасында ВСУ куллана торган пехотага каршы миналар), FPV-дрон (оператор үз тәненең хәрәкәтләре белән идарә итә торган квадрокоптер), «ФАБы» (фугаслы авиабомбалар), ЧВК – шәхси хәрби компания, «Открытка» – юк итү куркынычы аркасында хәрәкәт итәргә ярамый торган ачык урын.

Бу темага мөрәҗәгать итү хәрби лексиканың хезмәтләрдә билгеле бер өлеше генә анализлануына бәйле, күбесенчә аның нинди дә булса текст кысаларында билгеле бер чорны чагылдыруда стилистик вазыйфасына игътибар итәләр. Әмма, безнең фикеребезчә, хәрби лексика җыелмасы этимологик, тарихи, семантик, структур күзлектән анализлана ала торган киң мәгълүматка ия, бу исә лексиканың әлеге катламын киңрәк һәм җентекле карау кирәклеге турында дәлилли.

**Кулланылган әдәбият**

1. Әхтәмов М.Х. Хәҙерге башҡорт теле. – Өфө, 1986. – 138 б.

2. Рамазанова Г.Р., Зарипова И.Ф. Татар теленең лексик составында хәрби лексика // актуальные проблемы современной татарской филологии: Сборник статей Всероссийской научно-практической конференции, посвященной 95-летию со дня рождения известного языковеда, тюрколога, доктора филологических наук, профессора, первого заведующего кафедрой татарской филологии Башкирского государственного университета Габдулхая Хурамовича Ахатова (1927 – 1986). – Уфа, 2022. – С. 233–236.

3. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан, 2002. – 407 б.

4. Сәфәров Р.Т. Татар теленең хәрби лексикасы. – Казан, 2015. – 196 б.

5. Сәфәров Р.Т. Татар-рус хәрби лексика сүзлеге. – Казан, 2017. – 111 б.

6. Сороколетов Ф.П. История военной лексики в русском языке (XIXVII вв.). – М.: ЛИБРОКОМ, 2009.

7. Татар лексикологиясе. 1 том. – Казан, 2015. – 351 б.

8. Татар лексикологиясе. 2 том. – Казан, 2016. – 391 б.

© Рамазанова Г.Р., 2025

УДК 372.881.1

**Сагдиева Р.К.,**
*доцент кафедры татарского языкознания ИФМК КФУ,*
*г. Казань, Россия*

## ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮ КОРАЛЫ БУЛАРАК ӘДӘБИ ТЕКСТ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация***. *Укучыларның сөйләмен үстерү татар теленә өйрәтүнең мөһим бурычы булып тора. Мәкаләдә укучыларны укыту һәм тәрбияләү процессында әдәби текстларның әһәмияте карала. Әдәби әсәрләр укучыларның сүзлек запасын баетуга, аларның коммуникатив күнекмәләрен үстерүгә һәм дөньяны эстетик яктан кабул итүне формалаштыруга ярдәм итә. Мәкаләдә шулай ук укучыларның сөйләмен үстерү өчен әдәби әсәрләр белән эшләүнең конкрет методларына мисаллар китерелә. Аларны укытучылар укытуның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен куллана ала.*

***Терәк сүзләр***: *әдәби текст, татар теле, монолог, диалог, сөйләм.*

Һәрбер предмет укытучысы үз дәресендә текст белән эш итә. Яңартылган ФДББС таләпләре буенча һәр дәрестә сөйләм, язу, таңлап аңлау һәм уку күнекмәләрен булдыру зарури. Бүгенге көндә туган тел (татар теле) дәресләренең төп максаты – укучыларның грамоталылыгын, сөйләм һәм тел компетенцияләрен үстерү. Бу максатларны тормышка ашыру өчен, ярдәмгә текстлар килә. Шуңа күрә хәзерге заман яңа буын дәреслекләрендә аерым биремнәрне башкару өчен микротекстлар тәкъдим ителә. Бер дәрес кысалары эчендә төрле жанрларны файдалану да үз ролен башкара. Дәреслекләрдә бер теманы аңлату һәм кабатлаттыру, ныгыту өчен, билгеле бер лексик тема һәм тәрбияви максат белән чәчмә әсәрләрдән өзек, шигъри әсәрләр, мәкаль-әйтемнәр, укучылар өчен кызык булган аерым мәгълүматлар урын ала. Моннан тыш теге яки бу дәрестә, аеруча аерым темаларны кабатлаттыру дәресләрендә, билгеле бер язучының бер әсәрен аерым күнегүләргә таркатып бүлеп бирү дә соңы елларда актуальләшә башлады [2, 149 б.].

Туган тел (татар теле) дәресләрендә аерым текстлар белән эшләүнең максаты – укучыларны телнең фонетик, морфологик, синтаксик, стилистик, орфографик мөмкинлекләре белән таныштыру, теге яки бу язучы, шагыйрь иҗаты белән кызыксындыру, тәрбияләү, фикерләргә һәм нәтиҗә ясарга өйрәтү һ.б. Иҗади фикерли торган яшьләрне тәрбияләүнең мөһимлеге, әлбәттә, бүгенге көндә бәхәс тудырмый. Теге яки бу теоретик

материалны ятлау, истә калдыру гына түгел, ә иҗади фикерләргә өйрәнү, өйрәнгәннәрне гамәлдә дөрес куллана белү – бүгенге көн таләбе. Шул рәвешле әдәби әсәр татар теле дәресләрендә телне өйрәтү материалы гына түгел, ә укучыны тәрбияләү, иҗат белән таныштыру, аралашырга өйрәтү коралы да булып тора. Беркемгә дә сер түгел: бүгенге көндә китап укуга теләк тудыру, әсәр укырга кызыксыну уяту актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора [1, 456 б.].

5 сыйныфта фонетика һәм лексикологиядән үткән теоретик материалны кабатлаттыру максатыннан, укучыларга Фәнис Яруллинның «Урман әкияте» әсәре тәкъдим ителә. Дәрес текстның өзеген укыттыру белән башланып китә:

Бервакыт усак ботагында эленеп торган бер әйбергә Куянның күзе төшкән. Аның нәрсә икәнлегенә төшенмәгәч, хәйләкәр Төлкедән сорап карарга булган.

– Менә бер әкәмәт нәрсә таптым. Шуның ни икәнен һич белә алмыйм. Төлке дус, син кара әле, эчендә берәр тәм-том юкмы? – дигән Куян.

– Һи, юләр Куян, – дигән Төлке мыскыллап, – бигрәк надан инде син. Үзең егерме беренче гасырда яшисең. Бу бит – телевизор.

– Усак ботагына каян килеп эләккән соң ул? – дип сораган беркатлы Куян.

– Мин беләм. Монда кичә бер көтү яшьләр килгән иде. Шулар онытып калдырган, – дигән Тиен, агач башында сикеренгәләп.

– Озакламый Аю абзыйның туган көне җитә. Аңа бүләк итәрбез без бу телевизорны, – дигән Төлке [3, 112 б.].

Әлеге өзекне укыттырганнан соң, укучылар рус теленнән кергән алынма сүзне укырга, фразеологизмны табарга, аның мәгънәсен аңлатырга тиеш. Тексттагы сүзләрнең синонимнарын искә төшерәләр. Аерып бирелгән җөмләдәге сүзләрне иҗекләргә бүлеп язалар, юлдан-юлга күчереп була торган вариантларны күрсәтәләр.

Икенче күнегүдә әсәрнең икенче бер өзегенең җөмләләренең урыннары бутап бирелә:

• Бу – барлык җәнлекләрне мәҗлескә чакыру булган.

• Аланда мәҗлес башланган.

• Ниһаять, көтелгән көн килеп җиткән.

• Кайсы сыртына сыер боты салып, кайсы кәрәзле бал күтәреп, кайсы-берсе кесәсенә чикләвек тутырып, урман аланына мәҗлескә йөгергән.

• Кунаклар ашаганнар, эчкәннәр, җырлаганнар, биегәннәр.

• Ала карга, урмандагы иң биек агач башына кунып, өч тапкыр каркылдаган.

• Һәркем үз бүләген беренче булып Аю абзыйга тапшырырга теләгән.

• Шушы чакырудан соң, бөтен урман хәрәкәткә килгән.

• Аю абзый, дәү агач төбен өстәл итеп, үзенә китергән күчтәнәчләрне шунда өя барган [3, 113 б.].

Укучылар җөмләләрне тиешле тәртипкә куеп, текстның дәвамын укыйлар. Ахырдан укытучы электрон дәреслектә бирелгән аудиоязманы тыңлаттыра, һәм укучылар үз җавапларын тикшерәләр, нәтиҗә ясыйлар. Ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне дә уку таләп ителә.

Алдагы күнегүдә мнемотехнология методы алгы планга чыга: дәреслектә 4 төрле рәсем бирелә: 1) төлке аюга телевизор бирә; 2) куян белән төлке телевизор каршында басып торалар, ә телевизорда җилкәсенә мылтык аскан аучы белән аның зур эте урманда йөриләр; 3) куян белән төлке телевизор каршында басып торалар, телевизорда «Ну, погоди!» мультфильмы күрсәтелә; 4) экранда футбол уены бара [3, 113 б.].

Укучылар, әлеге рәсемнәргә карап, текстның дәвамын сөйләргә һәм электрон дәреслектәге аудиоязманы тыңлап, үз җавапларын тикшерергә тиешләр. Мондый төр биремнәр дә укучыны уйларга, фикерләргә этәрә. Шунысы да мөһим: бу очракта укучылар аерым җөмләләр генә кулланмасыннар, ә һәр рәсем буенча аерым кечкенә генә текст төзесеннәр. Шул рәвешле балаларда сөйләм күнекмәсен дә булдыруга ирешеп була.

Чираттагы бирем һөнәрчелек лексикасын кабатлаттыру максатыннан тәкъдим ителә. Тексттан читкәрәк китеп, укучылар белән футбол уены турында да сөйләшеп китү урынлы

булачак. Күнегү эчендә мат, кәшәкә, капка, туп, арбитр, капкачы, штанга, гол, штраф, сары карточка кебек сүзләр урын ала. Укучылар футбол уены, аның тәртибе, уен шартлары турында бер берсе белән диалог төзеп сөйләшергә тиеш булалар [3, 114 б.].

Дәрестә язу күнекмәсен булдыру максатыннан, алга таба укучылар нокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп, текстның дәвамын күчереп язалар:

Шулвакыт капкага туп килеп к..ргән. Бу тамашаны карарга җы..лган халык сызгырырга, кычк..рырга тот..нган. Бөт..н урман гөжләп торган. Аю экранга кыз..ксынып карап т..рган. Тора-бара урмандагы җәнлек..әр бу уенны ярата башлаган..ар. Һәрберсенең яраткан к..мандасы барлыкка килгән. У..н б..ткәч, урманны яңгыратып бәхәсләшә торган булган..ар. Капкага т..п керткән саен, Аю б..тен көч..нә «Го-ол!» дип акыра икән [3, 114 б.].

Моннан тыш алынма һәм һөнәрчелек сүзләрен дә таптыру соралар.

Әлеге биремне башкарганнан соң, укучылар яңадан аудиоязманы тыңлыйлар һәм җәяләр эчендәге тиешле сүзне сайлап алып, текстның дәвамын укыйлар:

(Радио/Телевизор/Ноутбук) табылганнан бирле, урмандагы барлык тәртипләр үзгәргән. Бер җәнлек тә үзенең (анасын/атасын/баласын) вакытында (йокларга/ашарга/укырга) яткыра алмаган. Бер яктан ата-аналары бәбиләрен (эссе/кайнар/җылы) түшәккә куып торганнар, икенче яктан балалары (сикерешеп/әйләнеп/чүгәләп) торып, телевизор (күрергә/карарга/тыңларга) утырган. Аю, Бүре, Төлке, Куяннарның (аугa/кунакка/эшкә) йөрүләре дә туктаган.

Әмма көннәрдән бер көнне (учакта/телевизорда/экранда) ут сүнгән. Тегеләй борып, болай баскалап караганнар, тик хикмәтле тартмага җан кермәгән [3, 114-115 б.].

Укучыларны тәрбияләү максатыннан, аларга: «Син телевизор яисә компьютер каршында күпме вакытыңны уздырасың? Телефон уеннарын уйныйсыңмы? Урман җәнлекләренә нинди киңәшләр бирер идең?» – дигән сораулар бирелә.

Алга таба дәреслектә текстның эчтәлеге белән бәйле рәсем урын ала: урман җәнлекләре үзләре футбол уйныйлар, аю капкада басып тора. Укучылар, рәсемне карап, нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп, текстның дәвамын укыйлар:

– Инде нишлибез? – дигәннәр Төлкегә. Төлке җавап бирә алмаган.

– Үзебезгә уйнарга кирәк бу туплы уенны. Җитәр инде, кешеләргә күп кызыктык, – дигән Керпе. – Аюны ... куярбыз. Бүреләр төп ... булыр. Куяннар – ... . ... читкә тәгәрәгән ... китереп торырлар. [3, 115 б.].

Моннан тыш укучылар хәреф белән аваз саны туры килмәгән сүзләрне әйтергә, басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзлрне табарга һәм ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне укырга тиеш булалар.

Иң соңгы бирем итеп төрле тәртиптә килгән җөмләләрне тиешле тәртипкә куеп, текстның ахыры укыттырыла:

• Аюга танытмас өчен, җәен-кышын кием алыштырып йөри башлаганнар.

• Тилгән түгәрәк чуер таш тапкан.

• Үз капкасына бер туп та керттермәгән бердәнбер капкачы булуы белән ул бик бәхетле икән.

• Таш тупка типкән җәнлекләр аксап беткән.

• Ә Аю, ике агач арасында басып, һаман аларны көтә, ди.

• Җәнлекләр: «Без хәзер өс-башыбызны гына алыштырып киләбез», – дигәннәр дә, Аюдан качып, урманга таралганнар [3, 116 б.].

Дәрес ахырында укучылар бер-берсенә текст белән бәйле сораулар бирәләр. Шул рәвешле текстны тагын бер кат искә төшерү, ныгыту белән бергә сөйләм күнекмәсе дә булдырыла.

Нәтиҗәдә бер дәрес кысасында укучылар алдагы дәресләрдә алган теоретик белемнәрне дә, билгеле бер язучы яисә шагыйрь иҗатын да кабатлыйлар. Мондый төр дәресләр укучыларда укырга теләк уята, аларны һәрьяктан тәрбияли, иҗатка һәм эзләнү эшләренә тарта.

**Кулланылган әдәбият**

1. Корнеева Т.А. Интегрированные уроки русского языка и литературы в 10 классе // Татьянин день: Сборник статей и материалов девятой республиканской научно-практической конференции «Литературоведение и эстетика в XXI веке» («Татьянин день»), посв. памяти Т.А. Геллер (25–27 января 2012 г., Казань). – Казань: Нижний Новгород, 2013. – Вып. 9. – С.456–461.

3. Сагдиева Р.К., Галиуллина А.И. Интеграль дәрес шартларында текст белән эш // В.А. Богородицкий и современная лингвистика. Труды и материалы Международной научной конференции: в 2 т. – Казань, 2024. – С. 149–151.

2. Сәгъдиева Р.К., Фәйзрахманова К.Ф. Туган тел (татар теле). 5 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). [рәссамы Ф.Ризаева]. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2023. – 136 б.

© Сагдиева Р.К., 2025

УДК 811.512.145

**Сагидуллина Л.Р.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## М. ВАФИННЫҢ ИҖАДИ ПОРТРЕТЫ ӨЧЕН ЭСКИЗЛАР

***Аннотация**. Мәкалә шагыйрь Мөнир Вафинга хас булган иҗади алымнарга анализ ясауга багышланган. Авторның беренче китабында эпиклык, маргинальлек, минорлык кебек үзенчәлекләрне ачу аша шагыйрьнең үсеш тенденциясе билгеләнә.*

***Терәк сүзләр:** татар әдәбияты, М. Вафин, дөнья әдәби картинасы, шигъри текст, шигъри алымнар*

Билгеле булуынча, текст, коммуникатив һәм психолингвистик күзлектән караганда, һәрвакыт «кем өчендер» төзелә. Әдәби текстны вербаль характердагы, аралашуга юнәлдерелгән һәм текстны кабул итү барышында ачыкланган эстетик кыйммәткә ия әсәр дип билгеләп була [2, 15 б.]. Сәнгатьле текст чынбарлыкның шәхси интерпретациясен чагылдыра. Автор тудырган дөнья күренешенең аерым чалымнарын тасвирлау, аның иҗатына хас индивидуаль-стилистик үзенчәлекләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

Мөнир Вафин иҗатының башлангыч чорын чагылдырган «Сүзләр чәчтем» [1] дигән җыентыгы шагыйрьгә хас төп поэтик алымнарны барларга мөмкинлек бирә.

М. Вафин шигырьләренә *эпиклык* хас. Шигырь һәм эпос иҗат елгасының капма-каршы ярларында яшиләр төсле. Әмма М. Вафин, шул ике каршылыкны берләштереп, яңа бөтенлек барлыкка китерә алган. Монда эпос шигырь ярыннан, шигырь эпос ярыннан башлана, ахры. Күңелдә әллә күпме боҗралар тудыра торган реаль тормыш картинасы, яшәү тарихы калку детальләр ярдәмендә, телисеңме-теләмисеңме, үз эченә алып керә, шул картиналарга авазадашлык уята.

Менә «Детдом» шигыре: *«Рәшәткәле (!) койма ярыгыннан (!)»* карап торучы *«гарип курчак (!) тоткан гөнаһсыз кыз»* язмышы. Берничә деталь ярдәмендә баланың үткәне, бүгенгесе, киләчәге күзаллана. Тик бу күзаллау аның аша гына түгел, ә йөрәк аша туа. Бәлки, шагыйрь *«иң яхшы сүзләрне иң яхшы тәртиптә»* (В. Маяковский) куя алу бәхетенә ирешкәнгә күрә шулайдыр бу? Шуңа сүзләр җанда эмоциональ шартлау тудыручы көчкә әйләнгәндер дә.

«*Тәмам җиргә сеңгән*» агач өйдә иң зур җиһаз – тынып калган күкеле сәгать. Бу йортта *«вакыт төшенчәсе күптән үлгән», «ләхет суыклыгы иңгән өйдә»* намазлык та кәфенне хәтерләтә. Әлбәттә, шигырь картлык фаҗигасе, гомумән – тормыш фаҗигасенең күңелгә уелып керердәй образын тудыра. Шул ук шагыйрь төшергән рәсем-сурәт тирәнрәк уйларга да этәрә. Вакыт төшенчәсе киләчәге булганнар өчен кешеләр тарафыннан уйлап

чыгарылган. Мәңгеләккә якынайган саен аның кирәклеге бетә бара, күрәсең. *«Шәүлә кебек (!) карчык»* вакыттан арынган инде, ул Мәңгелек тупсасында.

«Гыйнвар ае…», «Театрда», «Елый-елый ишек шыгырдады», «Каз өмәсе», «Ялгыз миләш» һ.б. минем күңелдә хис-тойгы уяткан шигырьләрнең күбесенә вакыйгалылык, эпиклык аша хиссиятле кичерешләр тудыру хас. Бәлки, мондый характердагы шигырьләрне «реалистик шигырь» дип тә атап буладыр. Беренче карашка, аларда гомумиләштерү, фәлсәфи тирәнлек күзәтелми. Ләкин конкретлыгы, сурәтнең чагу детальләрдән торуы белән, күңел күзе белән күрелми үтелгән күренешләрне ача белүе белән укучыны шигырь рамкаларыннан чыгып уйланырга этәрә дә инде бу шигырьләр.

Әйтергә кирәк, миңа, укучы буларак, икенче характердагы шигырьләр якынрак, ягъни бер агач артында урман күргән шигырьләр. Әмма китапка беренче укыганда ук күңел кабул иткән шигырьләрнең күбесе шул мин «эпиклык хас» дигән шигырьләр. «Яхшы шигырьнең яхшылыгын мин шигырьне укыганда тәннең һәр квадрат сантиметрында калкып чыккан каз тиресе бөртекләренең саны белән исәплим», – диюче бер шагыйрь белән тулысынча килешәм. Гадәттә сюжетлы шигырьләрдән әллә ни зур ләззәт алмаган укучы булуга карамастан, бу шигырьләр мине ышандырды, лирик герой кичерешләрен үз итеп кабул итүгә китерде.

М. Вафин шигырьләренең беренче юлларына игътибар итсәк, алар я вакытны ачыклаудан: «Яз да җитте», «Кышкы иртә иде», «Җәйге иртә иде», «Көзге бер көн иде», «Гыйнвар ае...», я урынны ачыклаудан: «Детдом», «Өй буенда ялгыз миләш үсә», «Иске сарай» һ.б. белән башлана, ягъни хикәяләр тибындагы текстларга хас үзенчлекләрнең берсе күзгә ташлана.

М. Вафин иҗат иткән сәнгати вакыт һәм ара (художественное время, художественное пространство) әдәбият белемендә М.М. Бахтин аерып чыгарган хронотоплар белән аваздашлык таба. Аеруча ике вакыт тибы күзгә бәрелә: «идиллик вакыт» (идиллическое время) һәм «авантюр вакыт» (авантюрное время). Бу ике вакыт тибы ике төрле урын-ара (пространство) белән бәйләнгән. «Идиллик вакыт «лирик герой өчен – «югалган оҗмах», ә «авантюра вакыты» – сынаулар, кичерешләр, югалтулар, эзләнүләр чоры.

Вакыт белән ара төшенчәсенең аерылгысыз бердәмлеге «Бала чагым шулай истә... « дип башланган шигырьдә 5 строфа эчендә бик ачык сурәтләнә. Лирик «мин «нең балалыктан малайлыкка, аннан үсмер, егетлек чоры аша ир корына керү хронологиясен берничә деталь ярдәмендә бик кыска һәм үтемле итеп тасвирлый шагыйрь: «*бәллү – тәрәзә – ихата – койма ярыгы – басу капкасы – материк – җир кендеге»*.

Әдәбият белемендә поэзия белән эпос арасында торган жанрларны лиро-эпик жанрлар дип атап йөртәләр (лирик поэма, баллада һ.б.). М. Вафинның мондый шигырьләрен дә, бәлки, мини-поэма дип атарга мөмкиндер. Хәер, ничек атау мөһим микән? Поэтик образ-сурәтнең хис-тойгыга тәэсир итәр дәрәҗәгә җиткән булуы әһәмиятлерәк түгелме?

«М. Вафин шигъриятенә эпиклык хас», дигән фикергә тагын бер дәлил. Эпик жанрлар эчендә каралган новелланың кайбер алымнарын да куллана шагыйрь. Мәсәлән, көтелмәгәнлек, вакыйгаларның кискен рәвештә, хәтта парадоксаль рәвештә тәмамлау күзәтелә («Су ташыйлар яшь киленнәр», «Атлар халкы», «Каз өмәсе» һ.б.).

М. Вафин шигъриятенең тагын бер үзенчәлеге – *маргинальлек*. Маргинальлек төшенчәсе бик киң. Бу мәсьәлә буенча социология, этнология, психология, лингвистика һ.б. өлкәләрнең һәрберсендә үз аңламы бар. Дөрес, ни өчендер бу терминның кире (негатив) төсмере киңрәк билгеле. Җәмгыятьтән, халыктан, милләттән, тормыштан читтәрәк торучыларны кертәләр маргиналларга: бомжлар, эшсезләр, җилкуарлар, наркоманнар, манкортлар. Татарлыктан тартынган, урыслыкка тартылганнар да шушы төркемдә. Чөнки алар татар мәдәниятен үзләштермәгән (үзләштерсә – читләшмәс тә иде, бәлки), рус культурасына да – җир белән күк арасы ераклыкта, бик читтә.

Бу яктан караганда, маргинальлек Л. Гумилевның «субпассионарий» төшенчәсенә якыная, минемчә. Аларны кисәү башлары белән чагыштырырга буладыр. Кайчандыр, бәлки, янганнардыр, җылылык һәм яктылык биргәннәрдер. Ә бүген исә ни янмый, ни сүнми

пыскып, төтенләп, тирә-юньне яслап яталар. Л. Гумилев «Этногенез и биосфера Земли» хезмәтендә субпассинарийларның саны үскән саен, илнең, милләтнең яшәү сәгатьләре кыскара, кими бара, дип дәлилли . Хәер, бу – аерым тема.

«М. Вафин иҗатына маргинальлек хас» дибез икән, иң беренче чиратта аның чиктәшлек сыйфатына игътибар итәбез. Дөрес, чик – һәрвакыт экстрималь зона (А. һәм Б. Стругацкийлар – А. Тарковкий Зонасы кебек!). Монда вакыйгалар, кичерешләр кискен, калку, көчергәнешле төс ала. Шуңа да Шагыйрь – язмышлар кисешкән зонада. Ул – Сталкер.

«Безнеңчә, «Сүзләр чәчтем» китабының иң уңышлы өлеше – беренче бүлек. Җанга аваздаш шигырьләрнең күбесе шул бүлектә. Ул *«Кыяфәтем бәлки шәһәрчәдер, ә йөрәгем һаман авылча»* дип атала. Социаль һәм рухи маргинальлекнең – чиктәшлекнең девиз-символы, дип атарга була бу юлларны» [3, 66 б.]. *«Мин – «деревня». Городской түгел. Дистә еллар монда яшәп тә.»* Әйе, авыл малае бар булмышы белән авылга тартыла. Авыл – балачак, яшьлек, туган туфрак, йорт, ата-ана. Авыл – өмет, хыял, омтылыш... *«Шул авыллык мине яшәтә»,* – ди шагыйрь. Әйе, чөнки тамырлар – авылда. Шәһәр исә – ботаклар, яфраклар, чәчәкләр, хәтта җимешләр. Тик аларның берсе дә тамырдан башка мөмкин түгел. «*Бу шәһәр – бигрәк зәһәр. Кешелек юк. Кечелек юк. Тартылдык (!) ник яшәргә дип?»* «Тартылдык» сүзе бу очракта нәкъ үз урынында. Өзелер дәрәҗәгә җитеп һәр мускул, кан тамырлары, хәтта сөякләр ике якка тартылган. Бу тартылуга түзәсең, түзмәсәң – өзеләсең... Ассоциатив рәвештә Сальвадор Далиның «Предчувствие гражданской войны» дигән картинасы искә төшә – авылдан шәһәргә тартылучыларда да «эчке гражданнар сугышы» тою яшидер ул. Шагыйрь исә – аеруча! Тамырларын калдырып шәһәргә күчкәннәргә шагыйрь мөһере аяусыз. *«Без юләрбез!..»*

Тумышы һәм булмышы белән авылда калган, тормышы белән шәһәрне сайлаган *«буранда адашкан»* йөз меңнәр язмышын, кичерешләрен чагылдыра шагыйрь. Ике арада бәргәләнә: авыл – кала, кала – авыл... *«Шыксыз димәс идем шәһәрне дә»,* – дип шәһәрне дә якын итмәкче була. Ләкин бу очракта да икмәк комбинаты ягыннан искән, авылны хәтерләткән «татлы җиле» булганга шәһәр җиле белән килешеп була икән. Авылның исә туфракка чумган тавыкларын да *«һич түгелдер сөеп туймалы». «Бәхетлеләр алар. / Ихатасы. Җиме. Кетәклек. / Ихатасыз, җимсез бер мескеннең /Бер атнасы җиде китаплык».*

Шушы бәргәләнүләр әдәбиятка 7 генә түгел, 77 китап китергәндер. М. Мәһдиевның «Бәхилләшү»ен генә алыйк: нинди трагик шигърият үрнәге. Һәр язучы, шагыйрь иҗатында күзәтелә бу өзгәләнүләр. Авылдан китеп бетә алмау, шәһәргә «килеп җитә алмау»... М. Вафинда тагын ничә китаплык калгандыр, билгесез, ә әлегесендә шактый. Һәм ышандырырлык көчкә ия бу кичерешләр нәтиҗәсе.

Маргинальлекне шигъри «мин»нең авыллык белән шәһәрлек арасында каршылыклы бәрелешенә генә кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Вафин акыл белән хис, тән һәм җан, туу һәм үлү, яшьлек һәм картлык, елау һәм елмаю арасында яши; шул каршы ярларга үзен чиктәш итеп тоя (Бәлки, шагыйрьлек – агым-елга булып шул чикләрне тоташтыручыдадыр?!). Икенең берсен генә сайламый ул, дөресе – сайлап ала алмыйдыр. Чөнки антитезик каршылыкта яткан бу күренешләр арасында бихисап мөмкинлекләр дөньясы ята. Шагыйрь – шунда. *«Илеңдәге илсезлек – / Шулдыр зур тигезсезлек»* – кыска гына әйтелгән бу кырыс юлларда шулай ук чикләр чигендә яшәүченең тавышы. Башкортстан татарына әйләнеп баручы татар улының җан авазы.

Мәхәббәткә багышланган шигырьләрдә дә күзәтелә бу ике якка тартылыш. Бер чиктә: *«Мин сине Ходайга тиңләдем», «Мәҗнүндәй югалттым башымны...», «Һәм шундый биеккә күтәрдем хыялым канатында...».* Икенче чиктә – *«түгәрәк ирен, түгәрәк күкрәк, түгәрәкләп тик өрәсең...» һәм «урыннар исерек кала мәхәббәт хисен татып...»* Лирик герой шушы ике мөмкинлек арасында таба, югалта, үкенә, үпкәли, ышана.

Маргинальлек турында сүзне шушы урында туктату урынлы, чөнки, уйлый башласаң, аның бик киң һәм тирән күренеш икәне ачыклана бара. Татар поэзиясенең (гомумән, поэзиянең) олы бер өлеше шушы татлы-газаплы бәргәләнүләр җимешедер, дигән уй килә

башка. Аеруча модернизм һәм постмодернизм юнәлешләрендә иҗат итүчеләргә хас, ахры, бу үзенчәлек: реаль чынбарлык һәм мистика, физик һәм рухи халәт, Җир һәм Күк, бүгенге яшәеш һәм мифлар, фотографик төгәллек һәм символлар һ.б.

М.Вафин шигъриятендә *минор* тональлекнең өстенлек итүе күзгә бәрелә. Үлем, картлык, ятимлек, ярлылык, ялгызлык... һәр шигырьдә диярлек яши бу темалар. Алар китапка трагик яңгыраш бирә. Менә 38–41нче битләрдән мисаллар: «Бүгенгенең туар көне кара...», «Көз», «Бу дөньяга тууыма күптән...», «Эзләремә басып берәү килә». Чынлап та, «тормыш – фаҗига» – дип килешәсе килә башлый шагыйрь белән (аның кара буяулардан гына тормаганын белсәк тә!). Бу тональлекнең тотальлеген аңлап-аңлатып була, безнеңчә. Бәхет ташып торганда берәү дә кулга каләм алмый, *«сагышка, моңга, газапка»* манып, шигырь иҗат итми, бәхет мизгелендә ул бәхетнең үзен иҗат итә Ә аны кәгазьгә теркәү бәхетләнең башына да кереп чыкмый. Соңыннан гына килә бу теләк, югалтканны эзләгәндә.

Ә үлем темасы шагыйрьне генә түгел, һәр кешене кызыксындыра, уйландыра, төн йокыларын качыра торган күренеш. Чөнки дөньга килүдә без турыдын-туры катнашмаганбыз, аны бездән башка хәл иткәннәр. Беренче көннән үк без үлемгә юл алабыз, аңа якынаябыз. Кеше акылы китү, югалу белән килешә алмый, ахры. Шуңа да аннан качуның, аны кичектерүнең төрле юлларын эзли (мәсәлән, дин), бу серне аңларга тырыша, аңламаса да аңлатырга тырыша.

Яшәү фәлсәфәсе ни кадәр ныграк кызыксындыра шагыйрьне, үлем фәлсәфәсе дә шул дәрәҗәдә (хәтта көчлерәк тә) кызыксындыра ала. М. Вафин да юкка гына үлем һәм картлыкка шулкадәр урын бирмәгәндер. Картлык – икенче дөнья ишегенең тоткасын тоткан чор, үлемнең (мәңгелекнең) сулышын тойган чор. Без ничек ачарбыз ул ишекне? Аңлы рәвештәме? Аңсызмы? Әзер булырбызмы мәңгелек белән очрашырга? Шагыйрьне дә, безне – укучыны да борчый бу сорау. Ничә яшьтә булсак та.

Ялгызлык темасы – китапның кызыл җебе, дисәк бераз арттыру булмас микән? Шулай да чынлыкка бик якын тәгъбир бу. «Ялгыз миләш», «Йолдызларга рәхәт», «Еламыйм ул...», «Ялгызлык» һ.б. шигырьләр шуңа мисал. Иҗат – ялгызлык җимеше генә була алганлыктан шулайдыр, бәлки. Ыгы-зыгы, әйтеш-төртеш тулы җирдә иҗатка урын бар микән? Юктыр, чөнки Иҗатчы Илаһият белән интим мөнәсәбәткә керә. Өченчеләрнең шәм тотып, өйрәтеп торулары битабигый хәл булыр иде. Шуңа да шигърияттә ялгызлык темасының аеруча көчле булуы гаҗәп түгел. М. Вафин шушы гомуми тенденция эченә керә, минемчә. Бер караганда, сүз көнкүреш ялгызлыгы турында гына бара кебек: *«Бик еш барып серләремне сөйлим туңып торган ялгыз каенга»,* – ди шагыйрь, *«я мәче балаларына...»*

Еламый ул «*салкын мендәр кочып, салкын тәндә салкын җан өши*» (шәп бит ә!). Киткәч тә «*кешеләрне белмим. Әмма этләр искә алган саен еларлар...».* Әйе, бу көндәлек ялгызлык, бәндәләр арасында үз кешеңне таба алмау. Ә кешегә (аеруча иҗади шәхескә) җиһани ялгызлык салынган. Тагын капма-каршылык белән очраша шагыйрь: бер яктан – ялгызлыктан бичара булу, аңардан азат булырга омтылу, икенче яктан – бары тынлыкта, ялгызлыкта гына үзең белән үзең очрашырга, тирәнлеккә-биеклеккә күз салырга мөмкинлек ачыла. Бу – шагыйрьнең бәхетле бәхетсезлеге.

Мөнир Вафин шигърияте турындагы бу күзәтүләр тулылыкка да, бөтенлеккә дә дәгъвә итми. Бәлки, бу язмаларны «портрет өчен эскизлар», – дип карарга буладыр. Ләкин М. Вафин портреты өчен генәме икән? Ничек кенә булмасын, М. Вафин китабы шигырь – шагыйрь – шигърият турында уйлану өчен, шул уйларны әйтү өчен бер сәбәп-этәргеч булды, ахры. Бу – бик мөһим, чөнки һәр шигъри җыентык та андый мөмкинлек бирми.

Без яңа китап, яңа автор, яңа әсәрне кулыбызга алабыз икән, иң беренче, Л.Н. Толстойча әйтсәк, «Син кем? Син нинди? Сине нәрсә борчый?» һ.б. шундый сораулар куябыз аның алдына, шуларга җавап эзлибез. Шулай да, миңа калса, безне «Мин кем? Синдә мин бармы?» дигән сорау ныграк борчый. Шул проблемаларны хәл итәргә омтылыш безне башка кешегә, аның тормыш-тәҗрибәсен өйрәнергә этәрә, эзләндерә, кабат-кабат укырга мәҗбүр итә. Мин дә М. Вафин шигырендә үземне эзләдем, әлбәттә. Гомер буе үзеңне эзләү, үзеңне табу (һәм таба алмау!) иҗатның нигезедер. Язучыны да, укучыны да үзе, үз булмышы

кызыксындыра. Бөтен тирә-якта, тормышта, башкаларда, сәнгатьтә ул үзен эзли, бербөтен итеп җыя, нур туплый. Берәүдә ул үзенә охшаш чалымнарын таба, берәүдә – юк. Тагын эзләргә.

И. Бродскийның *«Поэзия – телнең иң югары яшәү формасы ул»* дигән фикеренә таянып һәм кушылып, шигырьнең телнең генә түгел, ә шәхеснең дә, табигать баласының да югары яшәү формасыдыр ул, дип өстисе килә. Чөнки кеше (шагыйрьме ул, түгелме!) шул формага омтыла. Редакция хезмәткәрләренең әйтүенә караганда, ун хатның тугызында – шигырьләр. Дөрес, алардагы шигъри көлтәләр төрле сыйфатта, орлыклары өлгермәгәннәре дә, коелганнары да, күгәргәннәре дә бардыр. Әмма шигырь авторы өчен бу әнә шул югары нокта-формага – илаһилыкка омтылу түгелме соң?!

Әйе, бар шигырь дә телнең югары чагылышы, дип әйтеп булмый. *«Шигырь эзлим шигырь урманында. Аһ, бу күңелләрнең талымлыгы!..»* Ә шулай да шигъри урманда М. Вафинның үз уйдыгы бар, дип уйларга урын бар. Андагы үсентеләрне чүп басмаса, таптап узмасалар – зур урман булыр, иншалла!

М. Вафинның башлангыч чор иҗатын күзәтү нигезендә, гомумиләштереп, шуны әйтергә була: шагыйрь чынбарлыкның үзенә яхшы таныш өлешләрен тасвирлый; үзенә якын һәм аңлашылган фикер-карашларны үстерә, куәтли; тел берәмлекләрен һәм үзе өчен мөһим шәхси мәгънә белән тулыландырылган метафораларын куллана. Алга таба шундый нигезләмәне әйтергә кирәк: сәнгатьле текстта чагылган дөнья картинасы, автор тарафыннан струтуралаштырылган һәм вербальләштерелгән шәхси дөнья картинасы буларак аңлана һәм кабул ителә.

**Кулланылган әдәбият**


1. Вафин М. Сүзләр чәчтем // Биш кыллы саз. – Уфа: Китап, 2001. – Б. 3–111.
2. Маслова В.А. Поэт и культура: Концептосфера Марины Цветаевой. – М.: Флинта: Наука, 2004. – 256 с.
3. Сагидуллина Л.Р. Текст. Язык. Литература. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2023. – 120 с.


© Сагидуллина Л.Р., 2025

УДК 374.3

**Сайфулина Ф.С.,**
*профессор, заведующий кафедрой татарской литертуры ИФМК КФУ,*
*г. Казань, Россия*

## И. БИККОЛОВНЫҢ БАЛАЛАРНЫҢ ТАНЫП-БЕЛҮ СӘЛӘТЕН ҮСТЕРҮ ЮНӘЛЕШЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Аннотация***. *Әлеге мәкалә XX гасыр башы журналисты, публицисты, җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Биккуловның балаларда дөнья турында фәнни күзаллауны үстерүгә багышланган мәкаләләр циклын анализлауга багышланган. Яңа гасыр башында чыккан «Ак юк» исемле танылган балалар журналында басылган «Күк дөньясы» дигән фәнни-популяр мәкалә балалар һәм яшүсмерләрнең танып белү эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән. Фәнни-популяр мәкалә укучының игътибарын тел образлылыгы, әдәби-публицистик язу стиле белән җәлеп итә.*

***Терәк сүзләр:*** *Ибраһим Биккулов, «Ак юл» балалар журналы, фәнни-танып белү мәкаләсе.*

XX гасыр башы вакытлы матбугатында еш басылган, татар мәдәнияте, татар милләтенең гомуми үсеше, танылган шәхесләр, җәмгыятьтәге замана үзгәреше, сәяси хәлләр турында саллы мәкаләләре белән танылган Ибраһим Биккол(-ов) [1, 340-352; 2: 272-276]

гасыр башы балалар журналы «Ак юл»да да шактый мәкаләләр белән чыгыш ясый. Казанда 1913–1916 елларда чыккан балалар өчен рәсемле (иллюстрацияле) әдәби журнал – «Ак юл»ның басылу вакыты да, мәгълум ки, шул замандагы күпсанлы гәзит-журналлар кебек үк, берничә ел белән чикләнә. Әлеге балаларга багышлангын басма турында бирелгән мәгълуматта журналда язышкан күпсанлы замана татар зыялылары арасында, кызганыч ки, Ибраһим Бикколов исеме күрсәтелмәгән. «Балалар һәм яшүсмерләр өчен «Ак юл» журналы айга ике тапкыр чыга, барлыгы 74 номер дөнья күрде. Аңлаешлы җиңел теле, бай эчтәлеге һәм яхшы техникасы буенча, шул заман матбугатында күренекле урын биләгән. Аның эшендә яңа таныла башлаган яшь язучылар катнаша. Иң актив катнашучыларга исә Габделбари Баттал, Фәхрелислам Агиев, Фатих Сәйфи-Казанлы, Садри Җәлал, Г. Рәфикый, Хөсни Кәрим, Шәһит Әхмәдиев, Г. Шәрәф, И. Биккол, Нәкый Исәнбәт, Х. Әбелхан, Сәгыйть Сүнчәләй, Зыя Ярмәки, Шәйхулла Алкин һ.б. кертергә мөмкин» [3, 399 б.].

1916 елда «Аң» журналында басылган мәкаләсендә гасыр башында дөнья күргән дистәләрчә вә дистәләрчә милли вакытлы матбугат басмалары турында фикер йөрткәндә, И.Бикколов, әлбәттә, «Ак юл» турында да телгә ала, аның балалар журналы буларак кыйммәтен ача [4, 393–396 б.].

Хезмәт журналист, публицист И. Бикколовның «Ак юл» (1914) журналыгың берничә санында дөнья күргән «Күк дөньясы» мәкаләсен анализлауга, аның максат-бурычын ачыклауга багышланган [5, 1914, № 23: 8–10; № 24: 3–5 б.].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы мәгърифәтчеләре, бертуган абыйсы Касым Бикколовлар традицияләрен дәвам иттереп, И. Бикколов журналның укучы даирәсен искә алып, мәкаләсен балаларны әйләнә-тирә табигать, күк йөзендәге җисемнәр хакында фәнни-популяр язма рәвешендә тәкъдим иткән. Язма 4 бүлекчәдән тора. Башта ук язманың балаларны кызыксындырырлык хикәяләү ысулы белән язылган булуына игътибар ителә. «...безнең җиребезне чолгап алган күклек – очсыз, кырыйсыз бушлык ул. Ул бушлыкның очы да, кырые да юк һәм аның очын вә чиген белүче дә юк. Аны Аллаһы бер үзе генә beләдер. ... Көндез бөтен җир йөзен нурландырып инсаннарга, бөтен хайваннарга вә бөтен үлән вә агачларга үзенең якынлыгы һәм җылылыгы белән җан бирә торган «кояш»ны күрәбез. Ул түм-түгәрәк көенчә күк йөзендә тәгәрәп безне җылыта, безгә яктылык бирә, шулар белән безгә җан вә азык бирәдер. Мин кояшны безгә җан бирә, дидем, сез тагын бу сүзгә гаҗәпләнмәгез. Чыннан да шулай. Әгәр кояш булмаса иде, яки ул бүгеннән әллә кая югалса иде, без җир йөзендә яши алмас идек. Сез сынар өчен генә идән асты шикелле кояш нуры тими торган җирдә үскән үләнне карагыз. Ул бичара ап-ак булып бераз гына үсә дә, аннан соң үлә. Ул җимеш бирә алмый, орлык калдыра алмыйдыр. Ә аның ук бертуган карендәшләре кояш нурында ямь-яшел, таза вә матур булып үсәләр. Менә кешеләр дә, хайваннар да шулай ук кояштан башка яши вә тора алмыйлар».

Шул рәвешле, мәгълумат бирү белән бергә, мәкалә авторы укучылар күз алдында соклангыч табигать сурәтен дә тудыра, балаларның күзаллавын, фантазиясен дә үстерүгә юнәлтелгән әлеге язма, әдәби әсәр кебек укыла, образлы теле белән укучыгың игътибарын җәлеп итә: «Сез аяз көннәрне кич белән күккә карагыз. Бигрәк тә матур вә аяз җәй көннәрендә. Әгәр аяз гына көнне күккә карасаң, күктә хисапсыз күп кечкентәй генә нур – яктылыклар җем-җем итеп торалар. Алар шулкадәр матурлар, шулкадәр күңелле ләр ки, күккә бер караганнан соң, алардан бөтенләй күзне аласы килми! Аларның араларында аерым яктырып торганнары бар, кечерәкләре бар, кайсыберләре бергәләшеп, өешеп торалар, кайсыберләре бер-бер артлы тезелешеп торалар. Без ул вак яктылыкларны «йолдыз»лар, – дибез».

Мәкалә авторы башта шул рәвешчә укучының игътибарын күк йөзенә юнәлтә, кояш, ай, йолдызлар хакында башлангыч мәгълуматлар бирә.

Икенче бүлектә автор үзенең балачак хәтирәләре, иксез-чиксез күк йөзенең үзенә ничек тәэсир итүе хакында искә ала. «Мин кечкенә вакытта кайчакларда шулай җәй көннәрне кич белән үзебезнең бакчага чыгып, бик озак вакытлар күккә карап тора торган идем. Кич белән күктәге шушы матурлыктан һич күземне ала алмый, карап туя алмый торган идем. Ул

бөтен күк йөзенә үзенең җәүһәр шикелле нурларын чәчеп, мөлдерәп торган тулы ай, гүя бөтен йолдызларның падишаһы вә аларның хуҗасы! Үзе әллә кая таба бик ашыгып барган, тәгәрәгән кебек күренә, ул күктәге хисапсыз күп йолдызлар җем-җем итеп торалар...». Бүлек укучыларны шушы күк йөзенең серлелеге белән танышу теләге тудыру, аның өчен күпсанлы китаплар укырга кирәклеге кебек кызыксындыру белән дәвам иттерелә, үзенең дә бераз олыгаеп, мәдрәсәдә белем ала башлагач кына, балалык хыялларын тормышка ашыруы, шулар турында белем туплавы, хәзер исә шул белемнәре белән журнал укучы балалар белән бүлешергә теләве турында да өсти. Шул рәвешле, мәкалә балаларның кызыксыну һәм дөнья турында күбрәк белергә омтылышларын искә алып язылган. Язма җиңел, рәхәт укылуы ягыннан да яшүсмерләрнең игътибарын җәлеп итәрлек эшләнгән.

Өченче бүлек авторның укучыларга мөрәҗәгате, кызыксынуларын үстерү белән дәвам иттерелә: «Бу заманда инде дөньядагы һәммә нәрсәләрне белергә мөмкин. Дөньяда төрле нәрсәләр никадәр күп булса, аларны өйрәнеп белер өчен шул кадәр күп гыйлемлекләр дә бар. Менә шушы гыйлемлекләр арасыннан берсе «күк дөньясы»н өйрәтә торган гыйлем. Галимнәр бу гыйлемгә «һәйәт» гыйлеме дип исем биргәннәр».

И. Бикколов әлеге юнәлештәге гыйлемнәрне өйрәнү өчен галимнәрнең никадәр вакыт сарыф итүен, дөнья серләренә төшенү өчен зур тырышлыклар куярга кирәк булуын да искәртә. Ягъни, әлеге мәкалә, мәгълүмат-информация бирүдән бигрәк, журнал укучы балаларга гыйлем алуның никадәр кызыклы шөгыль, ләкин, шул ук вакытта, аның җиңел эш булмавын да искәртә. Укучыларны кызыксынучан, зирәк булырга өнди, мәгълуматны да кызыклы итеп җиткерергә омтыла.

Галимнәргә карата «...аларны хөрмәтләргә вә аларны олугларга тиешбез, чөнки алар һәммә гыйлемлекне язылган китаплардан гына укып белмәгәннәр, бәлки күп гыйлемләрне үзләре эзләп тапканнар, үзләре тырышып, үз заманнарына кадәр кешеләргә мәгълүм булмаган нәрсәләрне мәгълүм итеп ачып биргәннәр. Үзләренең шул тырышлыклары аркасында безнең заманда «фән» дип аталган гыйлемлекләрнең күбесендә эз салып калдырганнар».

Алга таба автор күк йөзенә карап, фикер йөрткән кешеләрнең ялгышлары да, зур ачышлары да булуын искәртә, күк йөзенә бәйле күпсанлы ышанулар, фәнни булмаган фаразлауларның да булуын әйтеп үтә.

Дүртенче бүлектә исә, язучы галимнәрнең әкренләп иске ышануларны кире кагып, яңа белемнәргә нигез салулары хакында яза. «зур галимнәр чыгып, «күк дөньясы» хакындагы иске гыйлемлекләрне җимереп, моның хакында бөтенләй яңа фикерләр тудырганнар. Мәсәлән, алар йолдызлар белән бәхет вә бәхетсезлекләр һәм бәла вә казалар арасында һичбер мөнәсәбәт юклыгы, дөньяның мәркәзе – уртасы җир булмыйча, кояш булганлыгын, йолдызларның һәм җирнең кояш тирәсендә әйләнеп йөргәннәрен сөйләгәннәр вә язганнар. ...Италия галимнәреннән Галилей, инглиз галимнәреннән Ньютон, тагын Коперник исемле галимнәр шушы юлда чиксез күп җәзалар күргәннәр. Халык аларны гакылдан язган тилеләр дип уйлаган...».

Шул рәвешле, анализлана торган мәкалә И. Бикколов тарафыннан балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларның кызыксынуын үстерү, аерым галимнәр исемнәре, хезмәтләре турында мәгълумат бирү максатын истә тотып язылган. Гасыр башы яшүсмерләрен, укучы шәкертләрне җәдитчелек идеяләре белән кызыксындыру юлын сайлап, мәкалә авторы бу хезмәте белән дә үзенең төп эше – милләтне тәрәккый иттерү, гыйлемле, алдынгы карашлы булуына ирешү юнәлешендәге эшен дәвам итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Сайфулина Ф.С. Отражение социально-культурной жизни начала XX века в публицистике Ибрагима Биккулова // Тюркский мир и исламская цивилизация: проблемы языка, литературы, истории и религии. IX Международная тюркологическая конференция. Ответственный редактор Р.Б. Камаева. 2018. – С. 349–352.

2. Сайфулина Ф.С. «Сибирия» (Томск) гәзитендә Г. Тукай исеме: Ибраһим Биккол(-ов) язмасы // Занкиевские чтения: интеграция науки и практики в современном образовательном пространстве: традиции и инновации. сборник тезисов докладов VIII Международной научно-практической конференции. – Киров, 2024. – С. 272–276.
3. Исмәгыйль Рәмиев, Рәис Даутов. «Ак юл» // Әдәби сүзлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – Б. 399.
4. Сайфулина Ф.С. Ибрагим Биккулов о периодической печати начала XX века // Тюркский мир в современных реалиях: проблемы языка, литературы, истории и культуры. Материалы XII Международной тюркологической конференции. Казань, 2024. С. 393-396.
5. Биккулов И. Күк дөньясы // Ак юл. – 1914. – № 23. – Б. 8–10; № 24. – Б.3–5.

© Сайфулина Ф.С., 2025

УДК 316.4

**Сафин Ф.Г.,**
*главный научный сотрудник отдела этнополитологии ИЭИ УФИЦ РАН,*
*г. Уфа, Россия*

## ЯЗЫКОВАЯ КОМПЕТЕНЦИЯ И ЯЗЫКОВОЕ ПОВЕДЕНИЕ МОЛОДЕЖИ В ПОЛИЭТНИЧЕСКОМ РЕГИОНЕ

***Аннотация.*** *В данной статье на основе этносоциологического исследования анализируются языковая компетенция и языковое поведение молодежи в полиэтничном Башкортостане. В ходе опроса были выявлены определенные расхождения между данными переписи населения и результатами этносоциологического опроса. Установлено, что, несмотря на относительно высокий уровень признания родного языка своей национальности, речевая практика татарской и башкирской молодежи преимущественно ориентирована на использование русского языка. Установлено, что более половины татар и четверть башкир указали, что первым языком, на котором они начали разговаривать был русский. Это свидетельствует о доминирующей роли русского языка в языковой социализации молодежи обеих этнических групп. Речевое поведение башкирской и татарской молодежи в зависимости от ситуации имеет тенденцию меняться. Так, в повседневной жизни, например в семейном кругу при общении с родителями или же старшим поколением, молодые люди больше используют национальный язык. Однако при общении со сверстниками или близкими друзьями речевая практика переходит на русский язык. Анализ данных показывает, что в повседневной жизни молодежь обеих национальностей преимущественно использует русский язык. Языковые ориентации молодежи в перспективе также ориентированы на русскоязычное общение, что свидетельствует о значительном влиянии русскоязычной среды на формирование языковой идентичности молодого поколения в Башкортостане.*

***Ключевые слова:*** *молодежь, языковая компетенция, языковое поведение, родной язык, русский язык, татары, башкиры, этнические группы*

Проведенные нами этносоциологические исследования [1] демонстрируют, что среди татарской молодежи лишь 69,4 % респондентов указали татарский язык в качестве родного. В то же время, среди башкирской молодежи этот показатель значительно выше и составляет 89,2 %. Следует отметить, что данные Всероссийской переписи населения 2020 года свидетельствуют о более высоких уровнях признания родным языка своей национальности, как среди татар, так и среди башкир по сравнению с результатами наших опросов [2].

Однако, необходимо также подчеркнуть, что показатели владения родным языком, полученные в ходе переписи, существенно ниже, чем доля респондентов, указавших этот язык в качестве родного. Иными словами, данные переписи демонстрируют значительное

расхождение между признанием языка своей национальности в качестве родного и фактическим владением этим языком. Эта тенденция характерна не только для татар и башкир, но и для представителей других этнических групп, и, что особенно важно, она проявляется в других регионах, т.е. индивиды в качестве родного отмечают язык своей национальности, при этом не владея им [2].

Анализ данных социологического опроса выявил интересную тенденцию: лишь 44,3 % татарской и 72,4 % башкирской молодежи указали родной язык своей национальности в качестве первого языка, который они освоили. В то же время, значительная часть респондентов, а именно 50,5 % татарской и 24 % башкирской молодежи, отметили русский язык как первый язык, на котором они начали разговаривать. Эти данные свидетельствуют о доминировании русского языка в процессе первичной языковой социализации среди молодежи обеих этнических групп.

Следует отметить, что доля татарской молодежи, указавшей башкирский язык в качестве первого освоенного, оказалась крайне низкой. Аналогично, лишь небольшая часть башкирской молодежи выбрала татарский язык в качестве первого.

Этносоциологические исследования демонстрируют, что уровень языковой компетенции татарской и башкирской молодежи в родном языке постепенно снижается. Это явление можно объяснить, прежде всего, переходом на русский язык обучения в образовательных учреждениях, т.к. в большинстве школ Республики Башкортостан преподавание ведется исключительно на русском языке, а родной язык изучается лишь как предмет и в объеме около двух часов в неделю. Следующий момент – это доминирование русского языка в сфере домашнего общения. В многонациональных городских условиях, в которых доминирует русская речь основным средством общения снова выступает русский язык, будь это в образовательных учреждениях, рабочих коллективах, в общественных местах и социальных сетях.

Примечательно, что данная тенденция наблюдается не только в полиэтнических, но и в моноэтнических населенных пунктах, где проживают преимущественно представители одной национальности. Использование русского языка при общении дома с родителями больше характерна для молодежи. Это свидетельствует о том, что процессы языковой ассимиляции и культурной интеграции являются системными и не ограничиваются географическими или демографическими рамками.

Высокий удельный вес смешанных межнациональных браков оказывает значительное влияние на процесс языковой социализации индивида. В таких семьях ребенок, как правило, выбирает язык одного из родителей, чаще всего матери, или же в семье доминирует русский язык, что приводит к его преобладанию в повседневном общении. Однако, для определенной, хотя и незначительной, части молодежи, как татарской, так и башкирской, характерно признание в равной степени русско-башкирского (1,9 %) или русско-татарского (3,1 %) варианта освоения первого языка.

Таким образом, независимо от национальной принадлежности, языковая компетенция современной молодежи на уровне семьи, образовательного учреждения и общественной среды преимущественно ориентирована на использование русского языка.

В контексте лингвистического анализа языковой компетенции этнических меньшинств, проживающих в Башкортостане, следует отметить, что представители марийцев, удмуртов и чувашей демонстрируют схожие тенденции в развитии своих языковых навыков. Несмотря на то, что значительная часть представителей указанных этносов проживает в сельской местности, их языковая практика также характеризуется доминирующим использованием русского языка.

Данное явление можно объяснить комплексом факторов, включая исторические, социальные и культурные аспекты. В частности, процессы урбанизации, миграция населения и глобализация оказывают значительное влияние на языковые предпочтения этнических меньшинств. В условиях многоязычия, характерного для Башкортостана, русский язык

выступает в качестве лингва франка, обеспечивая коммуникативную доступность и способствуя социальной интеграции.

Почти 90 % башкирской молодежи считают башкирский язык родным, однако в повседневном общении, например, с отцом, его используют лишь 67,1 %. Среди татарской молодежи только 37,4 % предпочитают татарский язык в разговорах с отцом дома. Половина татарской (53 %) и четверть башкирской (24,8 %) молодежи говорят с отцом исключительно на русском языке. При этом каждый десятый татарин и вдвое меньше башкир используют русско-национальный вариант речи в общении с отцом.

Ситуация с использованием родного языка при разговоре с матерью практически не отличается, но есть некоторые изменения. У татарской молодежи до 13 % используют русско-татарский вариант речи, а у башкирской – 7 % применяют русско-башкирский. Небольшая часть башкир (2 %) прибегает к татарской речи в разговорах с матерью, и почти столько же татар используют башкирский или русско-башкирский вариант.

В общении с бабушкой по линии отца или матери заметно возрастает использование родного языка, при этом употребление русского языка снижается.

Однако наиболее показательным и точно отражающим речевое поведение является общение с самым близким другом или подругой. Результаты этносоциологического исследования показали, что около 70 % татарской и немногим менее половины (46 %) башкирской молодежи общаются на русском языке при разговоре с близким другом. При этом функции национальных языков существенно сокращаются. Каждый второй башкирский респондент (42 %) и лишь каждый пятый татарский (20 %) указали, что при общении с близким другом используют язык своей национальности. Аналогичная тенденция наблюдается среди чувашской, марийской и удмуртской молодежи.

В контексте исследования языковой компетенции среди молодежи необходимо отметить, что 75,2 % респондентов башкирской национальности указали на свободное владение башкирским языком, в то время как 85,4 % заявили о свободном владении русским языком. При этом лишь 22 % опрошенных отметили, что их мыслительный процесс преимущественно осуществляется на русском языке, в то время как на родном башкирском языке этот показатель составил всего лишь 11,5 %.

У татарской молодежи уровень свободного владения татарским языком значительно ниже по сравнению с башкирской молодежью. Согласно результатам опроса, доля респондентов, свободно владеющих татарским языком, составила немногим более половины (57 %). В то же время, 94 % татар подтвердили свое свободное владение русским языком.

Опрос показал, что подавляющее большинство башкирской (80 %) и половина татарской (49 %) молодёжи поддерживают идею преподавания башкирского языка во всех школах Башкортостана. Тем не менее, когда речь заходит о конкретных предметах, таких как изучение языка, культуры и истории башкирского народа, мнения башкирской молодёжи значительно расходятся. Более 85 % из них считают, что необходимо преподавать только историю и культуру башкирского народа, в то время как лишь 8 % выступают за изучение башкирского языка.

С этим мнением согласны более половины русской молодёжи и две трети татарской, которые считают, что можно обойтись без изучения языка, поскольку дети и так перегружены, или затрудняются ответить на этот вопрос.

Позиция молодежи в отношении выбора языка обучения для будущих детей в школе приобретает все более категоричный характер. Анализ данных показывает, что лишь 2,5 % башкирской и татарской молодежи готовы поддержать идею монолингвального образования на национальном языке.

Большинство башкирской молодежи (71 %) выступает за двуязычное образование, включающее башкирский и русский языки. В то же время среди татарской молодежи доля сторонников двуязычного обучения значительно ниже и составляет 35,7 %. Каждая пятая татарская молодежь ориентирована исключительно на обучение на русском языке.

В контексте текущей этноязыковой ситуации можно констатировать, что независимо от этнической принадлежности, молодежь демонстрирует низкую мотивацию к повышению уровня владения башкирским языком. Это свидетельствует о наличии определенных факторов, препятствующих формированию устойчивой языковой идентичности и развитию билингвизма среди молодого поколения.

Результаты исследования подчёркивают важность тщательного изучения причин и последствий текущих тенденций в языковой политике и образовательных подходах. Также необходимо разработать эффективные стратегии для сохранения и развития национальных языков в многоязычном обществе.

**Список литературы**

1. Этносоциологический опрос по исследовательскому проекту «Современные этнокультурные и этноконфессиональные процессы в Башкортостане: этничность, идентичность, язык».

2. Всероссийская перепись населения 2020 г. Том 5, табл. 6. Население по родному языку. https://rosstat.gov.ru/vpn_popul (Дата обращения. 08.11. 2025).

© Сафин Ф.Г., 2025

УДК 811.512.145

**Сираева Дж. М.,**
*студент 2 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
**Сагидуллина Л.Р.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «ЧӘЧӘКЛӘР» ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ТӨРКЕМЕ

***Аннотация***. *Әлеге мәкалә татар телендәге «чәчәкләр» лексик-семантик төркемен тикшерүгә багышланган. Аның структур һәм семантик характеристикалары карала, компонент һәм этимологик анализ үткәрелә, шулай ук хәзерге татар теленең актив һәм пассив лексик запасында төсләр атамаларының урыны билгеләнә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, лексикология, лексик-семантик төркем, тематик төркем, сема, лексема, этимология, компонентлы анализ, төсләрнең атамалары.*

Татар теленең лексик системасын өйрәнүдә тематик һәм лексик-семантик төркемнәрнең роле зур. Алар телнең сүзлек составының тәртиплелеген һәм системалылыгын ачыклый [4]. «Чәчәкләр» тематик төркеме табигатькә бәйле лексиканың борынгы катламнарыннан санала һәм лингвистик, мәдәни һәм тарихи аспектларда кызыксыну уята мәдәни һәм тарихи аспектларда кызыксыну уята. Хәзерге татар телендә флора белән бәйле лексиканы өйрәнүгә багышланган хезмәтләр булуга карамастан, «чәчәкләр» аерым тематик төркем буларак хәзерге көнгә кадәр системалы тикшерү объекты булмаган.

Бу теманың актуальлеге татар теленең лексик байлыгын тирәнрәк аңлау һәм милли-мәдәни мирасны саклау ихтыяҗы белән бәйле. Тикшерүнең төп максаты – татар телендәге «чәчәк» атамаларының тематик һәм лексик-семантик үзенчәлекләрен ачыклау.

Тикшерүдә түбәндәге методлар кулланылды: теоретик материалны өйрәнү, чәчәк атамаларын сайлап алу (җыю, туплау), сүзләрне лексик-семантик, этимологик яктан тикшерү, тасвирлама метод (тупланган материалны төркемләү һәм гомумиләштерү). Эшнең методологик нигезен В.В. Виноградов, Т.Р. Галиуллин, Г.Р. Галиуллина, М.З. Закиев, Ф.С. Сафиуллина, Р.Н. Сәгъдиева, А.А. Уфимцева, Ф.П. Филин, Г.Ш. Фәезханова, Г.Х. Хәйруллина хезмәтләре тәшкил итә.

Лексикологиядә тематик төркемнәр (ТТ) бер үк тематик кыр белән бәйле сүзләр җыелмасын тәшкил итә. Алар предметларның чынбарлыктагы бәйләнешләренә нигезләнә [5]. «Чәчәкләр» төркеме дә ТТ-гә үрнәк булып тора.

Лексик-семантик төркемнәр (ЛСТ) семантик яклар (мәгънә үзара бәйләнеше) буенча берләшкән сүзләрдән тора. Алар парадигматик мөнәсәбәтләр (синонимнар, антонимнар, гипонимнар) аша формалаша һәм лексиканы системалы бәйләнешләр аша ача. ТТ чынбарлыкны чагылдыра, ә ЛСТ тел эчендәге семантик структураны күрсәтә. Икесе дә лексикографиядә, лексиканы тарихи һәм лингвокультурологик аспектларда өйрәнүдә кирәкле методологик кораллар булып тора.

Тикшерүнең тәҗрибәи өлешендә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән [7] «ботаника» билгесе белән билгеләнгән 29 чәчәк атамасы сайлап алынды: *азалия, андыз, аралия, арчан, аюколак, әрем гөле, гладиолус, глоксиния, гөлбаба, гөлбадран, гөлҗимеш, гөлчәчәк, дәлия, ирис, кактус, кашкарый, космея, кыяк гөл, лалә, лотос, сөмбел, чалмалы гөл, чалмачәчәк, яз гөле, ясмин, яушан, яфракча, җилдәк, һиндыба.*

Материалны тирәнрәк өйрәнү өчен компонентлы анализ ысулы кулланылды, бу сүзнең мәгънәсен элементар семантик компонентларга – семаларга таркатуны күздә тота [3]. Сема – эчтәлек планының минималь чик берәмлеге, семеманың (лексеманың бер мәгънәсе) төп элементы. Чәчәк атамаларын семаларга таркату үрнәге: *азалия – үсемлек, көньякта үсә, куаклы; андыз – үсемлек, киң яфраклы, сары чәчәкле; гөлҗимеш – чәнечкеле куак үсемлек, ал яки ак чәчәкле, җимеш бирә торган; чалмачәчәк – декоратив үлән яисә куак үсемлек, кызыл, алсу яки ак, эре чәчәкле.* Бу ысул һәрбер лексеманың үзенчәлекле семантик структурасын ачыкларга, алар арасындагы уртаклыкны һәм аермалыкны билгеләргә ярдәм итә.

Тупланган 29 лексема төрле принциплар буенча төркемләргә бүленде. <u>Тематик нигездә төркемләү:</u> чәчәкләр һәм гөлләр (*әрем гөле, гөлчәчәк, дәлия, кыяк гөл, яз гөле*); чәчәкле үсемлекләр (*андыз, ирис, космея, лотос, чалмалы гөл, яушан, җилдәк, һиндыба)*; куак үсемлекләр (*азалия, аралия, арчан, гөлбаба, гөлҗимеш, чалмачәчәк, ясмин*); декоратив үсемлекләр (*кашкарый, глоксиния, ясмин, чалмачәчәк*); чәчәкле үлән үсемлек (*гладиолус, сөмбел, чалмалы гөл, яушан*); үлән (*аюколак, яфракча*); яфраксыз үсемлек (*кактус*). <u>Ботаник семьялык (гаилә) нигезендә төркемләү:</u> чәчәкләр 16 ботаник семьялыкка бүленде, мәсәлән, оешма чәчәклеләр (*андыз, әрем гөле, гөлбаба, гөлбадран, дәлия, кашкарый, космея, һиндыба*); арчанчалар (*азалия, арчан*); розачалар (*гөлҗимеш, гөлчәчәк*); лаләчәләр (*лалә, сөмбел*); чалмабашчалар (*чалмачәчәк*); зәйтүнчәләр (*ясмин*). Бу классификация лексик берәмлекләрнең номенклатура характерын һәм фәнни-терминологик бәйләнешләрен ачыклый.

Этимологик тикшерү сүзләрнең килеп чыгышын аңлау, телнең тарихи үсешен күзәтү өчен мөһим. Р. Г. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге» [2] буенча кайбер атамаларның килеп чыгышы: *андыз* – кыпчак телләреннән (уйг., үзб. *андыз*), борынгы төрки *anduz, аңды-у* («аңкыту») сүзеннән килеп чыккан, чөнки андыз исе әрвахларны туендыра дип саналган; *яушан* – кыпчак телләреннән (каз., кырг. *җуушан*), *ябыш-у* сүзеннән килеп чыккан; *җилдәк – җил* («җил») сүзе белән бәйле булырга мөмкин; *гөлҗимеш* – татар телендә үзе ясалган кушма сүз: *гөл + җимеш*; *ясмин* – гарәп теленнән, фарсы теле аша халыкара таралган сүз. Этимологик анализ күрсәткәнчә, чәчәк атамалары төрки, гарәп-фарсы, грек-латин чыганакларыннан килеп, татар телендә үзгәртеп ясалганнан алып, тумыштан ук кушма сүзләр булып барлыкка килгәнче, киң спектрны тәшкил итә.

Тикшерү барышында чәчәк атамаларының сөйләмдәге ешлыгы да анализланды. Актив лексикага керүче атамалар көндәлек сөйләмдә киң кулланыла һәм күпчелек тел йөртүчеләргә билгеле: *азалия, гөлчәчәк, лалә, ясмин, гөлҗимеш, дәлия, ирис, космея, лотос, кактус, чалмачәчәк, җилдәк һ.б.* Пассив лексикага түбәндәге сәбәпләр аркасында керүче атамалар санала: архаизмнар / искергән сүзләр (*кашкарый, һиндыба*); диалектизмнар / фәнни терминнар (*андыз, аралия, аюколак, әрем гөле, гөлбадран, кыяк гөл, яз гөле, яушан, яфракча*); алынмаларның русча формасы өстенлек итү (*гладиолус, глоксиния*). Бу күренеш татар теленең

яшәеш мәйданы тараюуына һәм рус теленең йогынтысы көчәюенә бәйле социаль-лингвистик процессларны күрсәтә.

Әлеге тикшерү нәтиҗәсендә татар телендәге «чәчәкләр» лексик-семантик төркеменең төп үзенчәлекләре ачыкланды. Төркемне тәшкил итүче 29 лексема тематик, ботаник һәм семантик принциплар буенча төркемләнә ала. Компонентлы анализ ысулы һәрбер атаманың үзенчәлекле семантик структурасын ачуга ярдәм итте. Этимологик тикшерү атамаларның килеп чыгышының төрлелеген (төрки, гарәп-фарсы, халыкара, ясалма) раслый. Атамаларның яртысыннан күбесе хәзерге телнең актив лексикасына керә, ә калганнары пассив запаска күчү процессы белән сыйфатлана, бу телдәге үзгәрешләрне күрсәтә. Эшнең фәнни әһәмияте «чәчәкләр» тематик төркеменә аерым тикшерү объекты буларак карау мөмкинлеген, ә практик әһәмияте татар теле дәресләренә материал тәкъдим итүдә, шулай ук татар халыкының тел һәм мәдәни мирасын саклауда ярдәм итүдә. Киләчәктә бу юнәлештәге тикшеренүләрне татар диалектларындагы чәчәк атамаларын өйрәнү, төрки телләрдә флора терминологиясен чагыштыру, шулай ук чәчәк атамаларының татар милли дөнья картинасындагы урынын ачу кебек проблемаларны үз эченә алу файдалы булыр.

**Кулланылган әдәбият**


1. Виноградов В.В. Основные типы лексических значений слов // Избранные труды. Лексикология и лексикография. – М.: Наука, 1977.
2. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015.
3. Галиуллина Г.Р. Татар телендәге үсемлекләр атамаларының үзенчәлекләре // Филология һәм мәдәният. – 2016. – № 3.
4. Закиев М.З., Галиуллина Г.Р. Татар лексикологиясе: өч томда. – Казан: ТӘҺСИ, 2015. – Т. I.
5. Нуриева Ф.Ш. Лексико-семантическая группа «Растения» в татарском языке // Ученые записки Казанского университета. – 2012. – Т. 154.
6. Саберова Г.Г. Татарча-русча-латинча үсемлек атамалары. – Казань: Фикер, 2002.
7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда / төз. Ф.Ә. Ганиев [һ.б.]. – Казан: ТӘһСИ, 2015 – 2021.


© Сираева Дж.М., Сагидуллина Л.Р., 2025

УДК 821.512.145

**Субаева З.Р.,**
*магистрант 2 г.о. Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
**Каримова З.С.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ПРОЗАСЫНДАГЫ СИНОНИМ ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕЛМӘЛӘРНЕҢ СТИЛИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация**. Мәкаләдә М. Мәһдиев прозасындагы синоним фразеологизмнар һәм аларның стилистик үзенчәлекләре анализлана.*

***Терәк сүзләр:** фразеология, фразеологизмнар, синоним фразеологизмнар, лексема, стилистика, семантика, лексик-грамматик форма, морфема.*

Фразеология составы эчендә лексик-грамматик төзелеше төрлечә булып, төрле лексик берәмлекләр белән белдерелеп тә, мәгънә үзенчәлекләре белән бер-берсенә бик якын торган, предмет, күренешләрне танып-белүдә, стилистик кулланылышында ниндидер билгеләре белән генә бер-берсеннән теге яки бу төсмерләре ягыннан гына аерылган конструкцияләр бар

[3; 75]. Боларны фразеологик синонимнар дип атарга мөмкин. Алар образ тудыру өчен кулланылалар. Фразеологик синонимнар турында рус галиме Н.М. Шанский да әйткән сүзләре шуңа кайтып кала: «Синонимические обороты могут, в частности, дифференцироваться друг от друга оттенками в семантике, стилистической окраской, сферой употребления, словесными связями и т.д.» [5; 95 б.]. Синоним буенча язылган хезмәтләрнең авторлары нигездә фразеологик синонимнарның төп билгеләре итеп түбәндәгеләрне күрсәтәләр: 1) Бертөрле төшенчәне аңлату үзенчәлеге; 2) Семантик стилистик мәгънә төсмерләренең булуы [1; 15 б.].

Фразеологик синонимнар әдәби әсәрләрдә фәкать образ тудыру өчен генә кулланылалар. Алар, төрле лексик-грамматик форма ярдәмендә ясалып, бер үк төрле мәгънә белдерсәләр дә, һәрберсенең стилистик-семантик аерымлыгы да бар [3; 21 б.]. Синонимия телнең бөтен сфераларына да үтеп керә: морфемаларга да, сүзләргә дә, җөмләләргә дә. Синонимия фразеологизмнарга да хас, монда инде алар функциональ яктан сүзләргә якын торалар [4; 78 б.]. Язучы М. Мәһдиев фразеологик синонимнарны бик мул кулланган язучыларның берсе. Язучының теле үзенең осталыгы, тел- сурәтләү чараларына бай булуы ягыннан аерылып тора. Мәсәлән: иза чигү – җәфа чигү – газап чигү, тәпи сузу – җан бирү, йөрәк әрнү – йөрәк чәнчү – йөрәк сукылдау, җиңел сулау – өстеннән авыр йөк төшкәндәй булу, тынсыз калу – телсез калу – телен калдыру – телсез-авызсыз калу, дөнья күрү – дөньяны күп гизү, гәп кору – гәпләшү, юл сабу – юл тоту. Дөнья селкетү – дулау, күздән югалу – юк булу, күз явын алырлык – күз чагылырлык, күңел өзгәләнү – күңел тыпырчыну, җан рәхәте – рәхәт чигү, шәрран яру-шау итү, өнсез итү – югалып калу, йөрәк чәнчү – йөрәк сикерү – йөрәк яну, ил-җир күргән – дөнья күргән, күзгә төтен җибәрү – шыттырып җибәрү – күз буяу, күңел тетрәү – йөрәк тетрәү, йокыга тарта башлау – күзне йокы басу, кан-яшь җылау – зар елау, «ә» дигәнче – күз ачып йомганчы,баш вату – баш миен черетү, дөньядан китү – шәһит китү, көн итү – гомер кичерү башка китү – баш шаулау. Җан каһәрләү – үзәккә үтү, йөрәк төшеп китү – йөрәк үзенә урын тапмау – йөрәк урыныннан кузгалу – йөрәк беркайчан да тигез типмәү – йөрәк дөп- дөп килү – йөрәк жу итү – йөрәк какшау – чыгырыннан чыгу – йөрәк бозу – йөрәкккә кан саву – йөрәк кагу, дөнья чуалу – зилзилә башлану, дөнья күчерү – дөнья кубу. Дөнья кую – җан бирү, рәт китү – рәт булмау, кош теледәй – тырнак очы кадәр, эчтән сызу – эчтән көю, егәр китү – тотлыгу, ярага тоз салу – йөрәккә тоз салу, яшь түктерү – җәфа-хәсрәт чигү һ.б. Болар барысы ла язучы ижатында образ тудыручы сурәтләү чаралары булып торалар.

Мәсәлән, кешенең матур, итәгатьле сөйләшүен М. Мәһдиев менә ничек сурәтли: «Безнең якның кызлары-егетләре бик тәмле теллеләр. Менә шулай кичке уенның башыннан ахырынача яшьләрнең теленән энҗе коела» [2; 41 б.]. Мисаллардан күренүенчә, язучының теле шулкадәр бай, бер фразеологизмның күпме синонимын куллана белгән! Биредә китерелгән мисалларда бу фразеологик синонимнар кешенең эчке тирән психологик кичерешләрен, уй-хисләрен ачык тасвирлау өчен дә кулланылалар. Кайбер очракта, стиль таләп итү буенча, язучы фразеологик синонимны чагыштыру конструкциясе формасында да бирә: өстеннән авыр йөк төшкәндәй булу, кош теледәй, тырнак очы кадәр һ.б. Фразеологик синонимнар әсәрнең бер үк битендә килеп, яки бер-берсенә шактый якын торсалар да, икенче урында исә башка парлар бер-берсеннән шактый ерак торалар, ләкин язучы бер фразеологик әйтелмәне ике тапкыр кабатламаска, аның төшенчәсен ничек тә башка лексик-грамматик чаралар белән бирергә тырыша. Кешенең иң эчке, тирән кичерешләрен М. Мәһдиев үз йөрәге аша үткәргән төсле, геройларның психологизмы аның иң нечкә хисләренә кагылып узган кебек. «Бу иптәшнең бер көнне йөрәге чәнчи, икенче көнне ашказаны авырта, өченче көнне – башы чатный. Син килеп кергәч тә йөрәгем сикергән иде…» [2; 55 б.], [2; 61 б.]. Шул ук әсәрдән тагын бер мисал карыйк. Автор персонажларның характерын, хәл-әхвәлен төрле яклап ачыкларга омтылган: «Дөньяда диңгез, флот күргән матрос кадәр шыттырган, ягъни күзгә төтен җибәрә алган бүтән бер кеше дә юктыр. Әнә, үзәк матбугатны карап барабыз, моңарчы хәрби журналистлар күз буядылар, хәзер аңа – нокта! «[2; 77 б.]. «Миләр катып калган, аларны кузгатмаганга өч-дүрт ай. Шул минутта ул үзенең баш миен бик сыек хәлдә

итеп күз алдына китерде. Баш мие шулпаланган» [2; 145 б.]. Түбәндәге җөмләләрнең фразеологизмнары бер үк мәгънәгә ия, алар синоним булып киләләр. Язучы фразеологик әйтелмәләрнең синонимик вариантларын кулланып, укучы алдына мәгънәле картиналар китереп бастыра. «Без – кырык беренче ел балалары» әсәрендә укучыларның немец теленә өйрәнүләрен менә ничек итеп тасвирлый ул : «Шул арада бу сүзләр барысы вак кисәкләр кебек оча башлыйлар. Аларның һәрберсе бер кисәк йокы икән. Алар күзгә килеп керәләр, башны авырайталар. Баш тула. Шуңа күрә сүзе авыр, һәр җөмләсе баш миенә чүкеч белән суккан күк. «Син ничә тел белсәң, шуның кадәр әйбәт кеше… фәлән-төгән» дип йөрәкне боза, һәр сүзе – ярага тоз сала. Миләр кабара, баш шаулый. Гомердә онытылырлык итмәдең узган дәрестә, һәр сүзен хор белән әйттереп. Җаныбызны каһәрләдең «Нох айн маль, нох айн маль» дип, җелегебезне суырдың» [2; 120 б.]. Бу өзектә язучы никадәр синонимик фразеологик әйтелмәләр кулланган. Алар күбесе бер-бер артлы килеп, әйтеләсе мәгънәне тагы да көчәйтеп җибәрәләр. Тормыш кору, дөнья көтү, яшәү һәм үлем төшенчәләрен белдерә торган фразеологизмнар да күп очрый: авыр сулау, йөрәк урыныннан кубып алу, дөньядан китү, һ.б.

Язучы халык телендәге фразеологик синонимнарның барсын да кулланырга тырыша. Борчылу, кайгы, сагыш төшенчәләрен белдергән фразеологик синонимнары да күп: тынсыз калу, телсез калу, күңел өзгәләнү, күңел тыпырчану, йөрәк чәнчү, күңел тетрәү, зар елау, җан каһәрләү, үзәккә үтү, йөрәк әрнү һ.б. «Поездларда йөргәндә сезнең як халкының рус сүзләрен сытып сөйләшүенә минем йөрәгем әрни» [2; 100 б.].

Болардан тыш тагын бик күп төрле синонимик оя тәшкил итүче фразеологик әйтелмәләрдән файдалана М. Мәһдиев. Курку, борчылу, хәсрәтләнү, сыкрану, көю, әрнү төшенчәләрен белдергән фразеологик синонимнарын язучы гадәттә «йөрәк» лексемасы белән дә ачык күрсәткән: йөрәк әрнү, йөрәк чәнчү, йөрәк сулкылдау, йөрәк сикерү, йөрәк яну, йөрәк төшеп китү, йөрәк үзенә урын тапмау, йөрәк урыныннан кузгалу, йөрәк дөп-дөп килү, йөрәк бозу, йөрәккә кан саву, йөрәк кагу һ.б.

М. Мәһдиев прозасындагы фразеологик синонимнар искиткеч күп, аларның барысын да анализлау бер мәкалә кысаларында тикшерү мөмкин дә түгел. Һәрберсенең язучының үзенә генә хас стилистик үзенчәлеге бар.

**Кулланылган әдәбият**


1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 177 б.

2. Мәһдиев, Мөхәммәт Сөнгат улы. Әсәрләр: ун томда / Мөхәммәт Мәһдиев; [төзүче Г. Хәсәнова]. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2019.

3. Поварисов С.Ш. Тел – күңелнең көзгесе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 158 б.

4. Жуков В.П. Семантика фразеологических оборотов. – М.: Просвещение, 1978. – 160 с.

5. Шанский Н.М. Фразеология современного русского языка. – М., Высшая школа, 1963. – 156 с.


© Субаева З.Р., Каримова З.С., 2025

УДК 81'255

**Сулейманова Д.Д.,**
*ассистент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

# КИҢКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМӘТ ЧАРАЛАРЫ ТЕКСТЛАРЫНДА РУСЧАДАН ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘЛӘРДӘ ТИПИК ХАТАЛАР

***Аннотация**. Татар-рус икетеллелеге актив яшәп килгән шартларда массакүләм мәгълүмат чараларында язма тәрҗемә сыйфаты проблемасы аеруча әһәмияткә ия була. Бу ике төрле тел системасының үзара тәэсир итешүе һәм милли мәдәният үзенчәлекләрен адекват тапшыруның катлаулылыгы белән аңлатыла. Башкортстан Республикасының татар телендәге район вакытлы матбугатының беренче битләрен анализлап, берничә типик тәрҗемә хатасын ачыкларга мөмкин: калькалаштырылган конструкцияләр, изафета әйләнешләрендә грамматик килешүчәнлек бозылу, тартым аффиксларын дөрес кулланмау, антропонимнарны дөрес транскрибировать итмәү һәм башка күренешләр.*

*Автор, ачыклаган хаталарның системалы характерда булуы, рус тел системасының татар теленә интерференцияле йогынтысы белән бәйле булырга мөмкин дигән нәтиҗәгә килә. Хәлне яхшыртуга мәдәниятара аралашу өлкәсендә белгеч-тәрҗемәчеләр әзерләү юлы белән ирешеп булыр иде.*

***Терәк сүзләр**: язма тәрҗемә, ММЧ, тәрҗемә хаталары, калькалы конструкцияләр, изафета әйләнмәләре.*

Интернет технологияләр, мәгълүмат ташкыны илләр, телләр һәм мәдәниятләр арасындагы бәйләнешләрне көннән-көн үстерә, тирәнәйтә. Шулай булгач, тел гыйлемендә дә тәрҗемә иң әһәмиятле юнәлешләрнең берсе булып кала. Мәсәлән, Башкортстан шартларында урысчадан татарчага тәрҗемә милли матбугатта аеруча еш кулланыла.

Бүген һәр журналист, мөхәррир яисә укытучы тәрҗемә эше белән турыдан-туры очраша. Тематик биремнәр, матбугат релизлары, мәгълүмат чыганаклары, кагыйдә буларак, барысы да урыс телендә. Һәм мондый шартларда гәзит хезмәткәренә яисә укытучыга тәрҗемәче функцияләрен дә үтәргә туры килә. Биредә, әлбәттә инде, аның белеме, тәҗрибәсе, интуициясе, телне сиземләве ярдәмгә килә.

Шул ук вакытта фәнне эшкә җигү тәрҗемә эшен шактый ук җиңеләйтә ала. Тәрҗемә теориясе һәм аның практик мәсьәләләре тел галимнәре тарафыннан яхшы ук өйрәнелгән, тикшерелгән. Татар тел белемендә тәрҗемә мәсьәләләре буенча И.М. Низамов, Р.А. Йосыпов [3; 5 б.] һәм башкаларның хезмәтләре әһәмияткә ия.

2022 ел ахырында Башкортстанның Матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат чаралары агентлыгы үткәргән семинарда чыгыш ясау өчен 17 район гәзитенең беренче битләренә анализ ясарга туры килгән иде. Урыс теленнән тәрҗемә ителүе ачык беленеп торган мәкаләләрдән лексик, грамматик, синтаксик, стилистик һәм лингвомәдәни яктан кытыршы тоелган мисаллар тупланды. Гадәттә рәсми хәбәрләр бирелә торган беренче бит моның өчен шактый уңайлы булып чыкты.

**Калькалаштыру**, ягъни сүзмә-сүз тәрҗемә тел белемендә лексика һәм синтаксис белгечләре тарафыннан өйрәнелә. Тәрҗемә иткәндә киткән хаталар теге яки бу сүзне төгәл тәрҗемә итмәүдә күренергә мөмкин. Мәсәлән, *районның иртәгәсе*, дөресрәге – *киләчәге; район намусын яклады*, дөресрәге – *район данын яклады.*

Калькалаштыру процессында иң кызыклысы – сүзтезмәләр. Бу рәвешчә, татар теленә урысчадан байтак сүзтезмәләр күчә. Мәсәлән, урысча «*черное золото»* дигән гыйбәрә татарча «*кара алтын»* булып кереп киткән. Республика матбугаты («Кызыл таң») «*пожарный извещатель»* сүзтезмәсен «*янгын хәбәрчесе»* дип тәрҗемә итә. Ә «Туймазы хәбәрләре» гәзите аны «*янгынкисәткеч»* дип яза. Татарстан матбугатында бу сүз аерым языла. Туймазы гәзите

варианты уңышлырак тоела. Октябрьский шәһәре гәзитендә «*чисталама ремонт*» дигән сүз очрый, бу мисал тәрҗемәченең тирән белеме, сүзлекләр белән эш итүе турында сөйли.

Гомумән, урысчадан тәрҗемәдә сүзтезмәләргә игътибар таләп ителә. Мәсәлән, «*творческая энергия*» – «*иҗади энергия*»дән бигрәк, «*иҗат дәрте*», горячая линия – «*кызу линия*»дән бигрәк, «*кайнар элемтә*».

Гәзитләрнең берсендә «*Алар килеп җиткәндә өй ачык ялкын белән янган булган*» дигән җөмлә кызыклы. Биредәге «*ачык ялкын*» сүзтезмәсе – урысчадан («*открытое пламя»*) калька, әлбәттә. *Алар килеп җиткәндә өй дөрләп янган булган* дисәк, татарчарак булыр иде. Янә бер охшаш мисал: *Советлар Союзына һөҗүм планнарын корган Төркия һәм Япония көтү позициясен ала* – монда урысча «*занимают выжидательную позицию*» сүзтезмәсе чалымлана. *Советлар Союзына һөҗүм планнарын корган Төркия һәм Япония көтеп торырга карар итә*, дип язарга мөмкин булыр иде.

Урыс телендәге ***«по»* предлогы** белән сүзтезмәләрне татар теленә тәрҗемә иткәндә «*буенча*» бәйлеген куллану, Г. Ә. Нәбиуллина, Р. Р. Сабирова билгеләвенчә, урыс теленнән калька дип санала. Ягъни «*мәсьәләләре буенча киңәшмә*» дигән сүзтезмәне галимнәр «*мәсьәләләрен яктырткан киңәшмә*», «*мәсьәләләре хакындагы киңәшмә*» дип үзгәртүне хуплый [2, 123 б.].

Башкортстан район гәзитләрендә дә андый мисаллар очрый. Мәсәлән, урысча «*по телефону*» дигән сүзтезмә гәзитләрдә, гадәттә, «*телефоны буенча*» дип тәрҗемә ителә. Дөресрәге: «*телефонына*» булыр иде. Яисә «*... түләү норматив буенча башкарылган*» урынына – «*... нормативка ярашлы түләнгән*» уңышлырак яңгырый. Әмма бу бәйлек шулкадәр күп һәм еш кулланыла ки, мөгаен, бу күренеш нормага үк әйләнеп китәр, мөгаен.

Кайчакта гәзитләрдә интернациональ лексика яисә урыс сүзләре тәрҗемә итмичә кулланыла: *стереотип (катып калган караш); путевка (юллама), массажист (массаж ясаучы)*. Төрки фамилияләрне **урысча транслитерация**дә бирү еш очрый: *Садиков (Садыйков), Әхмәдеев (Әхмәдиев), Нафиков (Нәфыйков)*. Бишбүләк гәзитендә якташ батырыбызның исеме «*Минегали Шәйморатов*» дип бирелгән. Татарстан матбугаты *Миңлегали* дип язса, «Кызыл таң» фонетик ассимиляцияшкән вариантны (*Миңнегали)* ала. Дөресрәге, әлбәттә, *Миңлегали* булыр иде.

Урыс теленнән татар теленә тәрҗемәдә төрки, шулай ук гарәп, фарсы һәм фиг-угыр телләренә хас булган **изафет конструкцияләре**н (ике исем ярашу) еш кулланыла. Мисалга Р. Т. Шәрәфетдинова 2нче тип изафетның Татарстан матбугатында аеруча еш күзәтелүен билгели [4, 171 б.].

Башкортстандагы район гәзитләре материалында да бу тип сүзтезмәләр еш очрый. Хаталарга килгәндә, тартым кушымчасының төшеп калу очраклары ачыклана: «*Янда булу» проект* (дөресе – *проект**ы***) *чикләрендә»*.

Изафетның өченче тибын кулланганда иялек килеш кушымчасы төшеп калгалый: «*Дан ордены тулы кавалеры*», дөресе – «*Дан ордены**ның** тулы кавалеры*».

Гәзитләрдә системалы хаталарның иң күзгә ташланганы – **изафет сүзтезмәләр алдыннан аергыч куллану**. Мондый очракларда изафетның өченче тибына мөрәҗәгать итү мантыйкка ярашлы. Мисалга:

*ару-талу белмәс ана хезмәте* (дөресе – *аналарның ару-талу белмәс хезмәте*);

*сизелерлек дәүләт ярдәменнән* (дөресе – *дәүләтнең сизелерлек ярдәменнән*);

*зур булмаган разведчиклар төркеме белән* (дөресе – *разведчикларның зур булмаган төркеме белән*);

*ел ярымлык терлек азыгы хәзерләнде* (дөресе – *ел ярымга җитәрлек терлек азыгы хәзерләнде*) һәм башкалар.

Шулай ук **тартым кушымчасы**н куллануда башка төгәлсезлекләр дә очрый: «*Алар күп балалы гаиләләргә ярдәм иткән* (*дөресе – иткәне, итүе*) *өчен дәүләткә бик рәхмәтле*».

Тартым кушымчалары булган сүзләр бергә килсә, сүзтезмәне аңлау авырлаша: «*авыл хуҗалыгы җитештерүе дәрәҗәсен үстерү*», дөресе – «*авыл хуҗалыгында җитештерү дәрәҗәсен үстерү*», «*авыл хуҗалыгында җитештерүне үстерү*».

Яисә: *«Балалар легендар кавалерия дивизиясе сугышчысы – Советлар Союзы Герое Әмирҗан Сөләйман улы Хәйдәров һәм аның данлы сугышчан юлы белән таныште».* Бу очракта җөмләне бүлү отышлырак: «*Балалар Әмирҗан Сөләйман улы Хәйдәровның данлы сугышчан юлы белән таныште. Ул Советлар Союзы Герое булган һәм легендар кавалерия дивизиясендә сугышкан».*

Шул рәвешчә, урысчадан тәрҗемә иткәндә, **сүз тәртибе**н үзгәртү, ягъни трансформация алымы отышлы була ала. Гомумән, сүз тәртибенә игътибарлы булу мөһим: *«Башлана 11 сәгатьтә»* урынына *«11 сәгатьтә башлана»* дөресрәк.

Тәрҗемә эшендә тарихи, **лингвомәдәни алшартлар**ны да искә тотмый булмый. Мисалга, «*Ана көне»* түгел – «*Әниләр көне*», «*алла боерса»* түгел – *«Аллаһы боерса». «Алиһә»* сүзен куллану бөтенләй урынсыз. Грек мифологиясе – рухыбызга ят нәрсә, аның элементларына тәрҗемә эквивалентлары табу – читен хәл. Шулай ук *«илаһи», «изге»* кебек сүзләрне бик сак куллану кирәк.

Дөрес, машина тәрҗемәсе, ягъни автомат тәрҗемә технологияләре барлыкка килү тәрҗемәчеләрнең эшен яхшы ук җиңеләйтте. Аларның алгоритмнарын камилләштерү дәвам итә. Тәҗрибә күрсәткәнчә, Татарстан Фәннәр академиясенең Семиотика институты тәкъдим иткән «Татсофт» (https://translate.tatar/), Яндекс-тәрҗемәче (https://translate.yandex.ru/?ysclid=mbsuzsrp8i395707178&source_lang=ru&target_lang=tt) сайтлары – арада иң уңышлылары. Тәрҗемәчеләр өчен «Сүзлекләрнең электрон фонды» сайты (https://suzlek.antat.ru/) шулай ук бик файдалы.

Әмма ләкин татар укучысының күңеленә үтеп керергә телибез икән, нәкъ менә татар теленә генә хас нечкәлекләрне, сүзтезмәләрне, фразеологик әйләнмәләрне кулланымый булмый. Бу очракта инде үзебезнең тел байлыгын эшкә җигәргә туры килә.

Йомгаклап әйткәндә, Башкортстан районнарында татар телендә нәшер ителүче гәзитләрдә тәрҗемәнең, нигездә, канәгатьләнерлек булуын, Әлшәй, Краснокама, Тәтешле, Туймазы, Октябрьский, Аскын, Ярмәкәй, Бишбүләк район гәзитләрендә чагыштырмача яхшы башкарылуын билгеләргә мөмкин. Ачыклануынча, төп җитешсезлекләр урыс теленнән калькалаштыру очракларына, изафет конструкцияләрен, тартым кушымчаларын дөрес куллануга, сүз тәртибенә кагыла. Дөрес, болар тупас хата булып исәпләнми, әзерлексез укучы аларны тоймаска да мөмкин. Икенче яктан, бу күренешләрнең еш күзәтелүе рус теленең татар теленә интерферент йогынтысы нәтиҗәсе була ала.

Гомумән, тел гыйлемендә кабул ителгән таләпләргә ярашлы, тәрҗемәнең максаты – текстларның мәгънә ягыннан мөмкин кадәр тәңгәллегенә ирешү [1, 214 б.]. Мәгънәдән кала, бер үк вакытта оригиналның һәм тәрҗемәнең лексик, грамматик, синтаксик, стилистик яктан да мөмкин кадәр тәңгәл булуы кирәк. Нәкъ шушы сәбәпле тәрҗемә авыр һәм катлаулы эш булып санала да инде. Югары сыйфатлы тәрҗемәгә ирешү өчен тәрҗемәче теоретик һәм гамәли яктан югары әзерлеккә ия булырга, һәр ике халыкның тарихын, әдәбиятын, мәдәниятен дә белергә тиеш. И. М. Низамов билгеләгәнчә, «татарча текстта фикернең табигый агышына татарча чаралар белән генә ирешеп була» [5, 103 б.]. Башкортстандагы татар филологиясе бүлекләрендә «Тәрҗемә белеменә кереш» яисә «Тәрҗемә эше» дигән махсус курслар булдыру һич тә зыян итмәс иде.

**Кулланылган әдәбият**


1. Гарбовский Н. К. Теория перевода: Учебник. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 2007. – 544 с.

2. Набиуллина Г. А., Сабирова Р. Р. Особенности перевода словосочетаний в переводных текстах на сайте *tatar-inform.ru* // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2014. – № 12 (42): в 3-х ч. – Ч. II. – С. 122–124.

3. Низамов И. М. Татарча әдәби редакцияләү: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Казан (Идел буе) федераль университеты нәшрияты, 2012. – 159 б.

4. Шарафутдинова Р. Т. Изафетные конструкции татарского языка на материале СМИ // Современная наука: актуальные проблемы теории и практики. Серия «Гуманитарные науки». – 2019. – № 6 (июнь). – С. 170–172.

5. Юсупов Р. А. Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2005. – 383 с.

© Сулейманова Д.Д., 2025

УДК 811.512.145

**Тазетдинова И.Р.,**
*студент 6 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Зарипова И.Ф.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА ДЕНДРОНИМНАРНЫҢ СИМВОЛИКАСЫ

***Аннотация.*** *Бу мәкалә татар халык җырларында дендронимнарның кулланылыш үзенчәлекләренә багышлана. Анда агач атамаларының символик мәгънәләре, халык аңында аларның урыны, шулай ук җырларның милли колоритын һәм эстетик кыйммәтен арттырудагы әһәмияте ачыклана. Дендронимнарның татар халкының табигатькә карашын, гореф-гадәтләрен һәм рухи дөньясын чагылдыручы мөһим элемент булуы ассызыклана.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, татар халкы, фольклор, халык җырлары, дендронимнар*

Татар халкы – элек-электән үк җырга-моңга бай халык. Шатлыкларын, сагышларын да җырга сала. Бишектән үк һәм соңгы көннәребезгә хәтле халык җырлары безнең җаныбызда һәм яныбызда. Әйтерсең, халык җырларында бөтен үткән татар халкының күңелен нечкәртеп, җанына рәхәтлек бирүче аһәң булып яңгырый, аның йөрәгенә барып җитә дә күңелендәге изге хисләрне уята, тетрәндерә [5].

Халык җырлары – бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале мирастыр. Халык җырларының җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле булуы өчен аларга зур әһәмият бирү мөһим. Аларны кадерләргә, югалтмаска, буыннан-буынга тапшырырга кирәк. Халык җыры, халык көе – ул халык авазы, халык тойгысы һәм фикеренең турыдан-туры чагылышы, аның музыкаль теле.

Күзәтүебезчә, татар халык җырларында күп кенә темалар чагыла: мәхәббәт, сагыш, югалту, аерылу, кавышу, шатлык, дуслык һәм башкалар. Әлбәттә, элек-электән кеше табигать белән бик тыгыз элемтәдә, аның кочагында яшәгән. Хәтта ул аңа уй-кичерешләрен белдергән, аның белән сокланган, аннан ярдәм сораган. «Халык иҗатын белми торып, хезмәт халкының чын тарихын белеп булмый», – дигән бөек рус язучысы М. Горький. Шуңа күрә әлеге мәкаләбезне татар халык җырларына, аларда чагылган дендронимнарның кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклауга багышладык.

Безнең тарафтан анализланган мисалларда каен, имән, чыршы, бадъян агачы, тирәк, тал, зәйтүн агачы, шомырт, алмагач, хөрмә, чия, миләш һәм усак кебек агач атамалары һәм карлыган, кура җиләге кебек куак атамалары очрады. Алар арасында иң киң таралган агач атамасы – тал. Ул 29 җырда кулланыла: *«Бәгырем диярмен», «Ярлы егет», «Сайра, сайра син, сандугач», «Абау, бәгърем», «Сабый кияү», «Су өсләрендә бөдрә тал», «Күз яшьләрем», «Әллүки, сарымсак», «Җирән атлар», «Курай уйный кызлар», «Кузырлакай чана», «Җаек буе», «Җәзек бил», «Мәдинәкәй», «Тәзкирә», «Күк күгәрчен», «Зая үтә гомер», «Печәнче җыры», «Иш буе», «Җилфер-җилфер», «Дим буе», «Сандугачлар килгән», «Оныталмыйм», «Яшәсен, яшәсен», «Бер-беребездән бизмиек», «Авыл көе», «Сандугачым-былбылым», «Тоткыннар җыры», «Талы-талы», «Ай, Бибкәй, елама», «Ай, йолдызым».*

Тал агачы татарларда гына түгел, башка халыкларда да сагыш, сагыну, юксыну, хәсрәт белән күзаллана. Мәсәлән:

***Тал*** *тибрәтсәм, тала беләгем*

*Исемә төшсә, яна йөрәгем.* («Кузырлыкай чана»)

Ул кайгыдан сыгылып төшкән кешене хәтерләтә, ә яфракларыннан, әйтерсең, яшь тама. Тал гадәттәгечә су буенда үсә, менә кеше дә үз кайгыларын суларга сала. Чыннан да, «тал» сүзе кулланылган күп кенә җырларыбыз тематик яктан сагышлы, моңсу эчтәлекле.

*Җаек та буе, әй, сары* ***тал,***
*Ир балалар күрсә, ат итәр.*
*Күп еллардан бирле күргәнем юк,*
*Инде күрсә дә мине ят итәр.* («Җаек буе»)

*Үз алмагач кынам булса иде,*
*Таянмас та, таянмас та идем* ***талларга.***
*Үз сөйгәнем янда булса иде,*
*Ялынмас ла, ялынмас ла идем ятларга.* («Үз сөйгәнем янда булса»)

***Талдан*** *талга кунып сайрый микән*
*Таң алдыннан сандугач?*
*Сандугачлар тавышы моңлы икән,*
*Сөйгәнеңне өзелеп сагынгач.* («Бөдрә тал»)

Тал – татар халкының күңелендә тирән урын алган образ. Ул тынычлык, назлылык, хәтта берникадәр моңсулык белән дә бәйле. Җырларда сандугач еш кына талларга куна, шунда утырып, тирбәлеп, үзенең моңлы көйләрен башкара. Сабый бала да әнисенең назлы җырларын тыңлап, тал бишектә йокыга тала. Мәсәлән, халык җыры «Мәдинәкәй»дәге соңгы юлларны алыйк. Кызның әйткән сүзләре күңелгә тынычлык салырдай җылы, назлы, таллар тибрәтерлек моңлы.

*...Шикәрләрдән тәмле, балдан татлы,*
*Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,*
***Тал*** *тибрәтеп әйткән сүзләрең.* («Мәдинәкәй»)

Тал – татар халкының рухи дөньясында мөһим урын алып торган символ.

Белүебезчә, талның ботаклары бик нык, аларны сындырыр өчен көч кирәк. Чын дуслыкны да җиңел генә бозып булмый. Бәлки, шуңадыр татар халкы талның шушы сыйфатларына таянып, аны дуслык образы буларак җырга салган:

*Сезнең белән безнең арада*
*Суырылып үскән чуклы* ***тал;***
*Чуклы талның чугын өзмиек*
*Бер-беребездән, дуслар, бизмиек.* («Бер-беребездән бизмиек»)

Тал атамасы татар халык җырларында башка мәгънәдә дә кулланыла. Бу агач нәзек һәм зифа. Аны еш кына яшь матур кызлар белән дә чагыштыралар:

*Ай, дускаем, буең зифа,*
***Тал*** *кебек бөгеләсең.*
*Таллар кебек бөгеләсең,*
*Кем өчен өзеләсен.* («Ай йолдызым»)

Шулай ук татар халык җырларында «тал тирәк», «тал-тирәк» дигән дендроним да еш очрый. Бу атама талсыман агачлар, төрле тал агачларын җыйма мәгънәдә белдерү өчен кулланыла.

*Су буена төшкән идем,*
*Яфрак ярган* ***тал-тирәк*** *шул.*
*Яна дисәң, ялкыны юк,*
*Ялкынсыз яна йөрәк.* («Тәзкирә»)

Татар халык авыз иҗатында, бигрәк тә җырларда, алмагач һәм каен агачлары еш кына төрле хис-тойгыларны чагылдыру өчен кулланыла [1, 40 б.]. Каен еш кына сагыну, ялгызлык кебек моңсу кичерешләр белән бәйле булса, алмагач мәхәббәт, өмет һәм туган якка булган назлы хисләрне символлаштыра. Мәсәлән:

*Безнең каршыбызда* ***алмагачлар,***
*Бер ботагы алты алмалы.*
*Егет, алыр булсаң ал тизрәк,*
*Урамга чыгарлыгым калмады.* («Алырмын, җаныем, алырмын»)

Бу юлларда алмагачның муллыгы, җимешле булуы сөйгән ярга булган хисләрнең ныклыгын күрсәтә.

*Шәрүкның башында камчат бүрек,*
***Алмагачка*** *кунган кош кебек.*
*Самат илләрендә йөргән чагым,*
*Төн йокымда күргән төш кебек.* («Шәрүк беглый»)

Бу мисалда алмагач, кош кебек, ирекне, хыялларны символлаштыра.

Ә каен агачы, киресенчә, еш кына кайгы-хәсрәт, ялгызлык темаларына бәйле. Мәсәлән:

***Каен*** *гына агач тал булмас,*
*Каен суы койган май булмас.*
*Кайгырмасана, газиз башым,*
*Кайгы йөрәкләргә ял булмас.* («Күз яшьләрем»)

Бу юлларда каенның ялгызлыгы, аның ярдәмсезлеге кеше кайгысы белән чагыштырыла. Тагын бер мисалда каенның ялгызлык символы булуы ачык күренә:

*Ялгыз* ***каен*** *булмый, диләр,*
*Ялгыз каен кырларда.*
*Ялгыз каеннардан ялгыз,*
*Мин бүгенге көннәрдә.* («Ялгыз каен»)

Бу җырда каенның ялгызлыгы, кешенең үзенең ялгызлыгын тойган хәленә туры килә.

Шулай итеп, алмагач һәм каен агачлары, үзләренең табигый үзенчәлекләре аркасында, халык җырларында төрле хис-кичерешләрне, уй-фикерләрне гәүдәләндерү өчен мөһим образларга әверелгән.

Балан – ачы җимешле агач. Шуңа да күп кенә татар халык җырларында тирән мәгънә йөртүче символ булып тора. Аның ачылыгы еш кына тормышның катлаулы юлларына, авыр язмышларга бәйләнә. Шуңа күрә дә заманча җырларда да еш кына: «Балан – ачы язмыш», «Балам – балан», «Балан ашама, балам» дигән юлларны очратырга була. Бу юллар аша без бала өчен борчылу, аның язмышын кайгырту, хәтта ятимлек мотивларының татар халык иҗатында никадәр нык тамыр җәйгәнен күрәбез. Мәсәлән, «И, дуслар» җырындагы өзеккә игътибар итик:

*Озын юлкайларда малина күп,*
*Извозчиклар әйтә* ***балан*** *дип.*
*Унөч-үндүрт яшьтән хезмәт бирәм, и, дуслар,*
*Һичберсе әйтми балам дип.* («И, дуслар»)

Бу юллар аша без кеше язмышын күрәбез. Ул бик иртә, унөч-үндүрт яшеннән үк хезмәткә алынган. Аның өчен «малина» (кура җиләге) кебек татлы, җиңел тормыш түгел, ә «балан» кебек ачы, катлаулы юллар язылган. Извозчикларның аны «балан» дип атавы – аның язмышының ачылыгын, авырлыгын күрсәтә. Ә иң аянычы – аның өчен беркемнең дә «балам» дип борчылмавы, кайгырмавы. Бу, әлбәттә, ятимлек, яклаучысызлык, яшьли үк тормыш авырлыкларын татырга мәҗбүр булу хәлен ассызыклый.

Шулай итеп, балан җимеше һәм аның белән бәйле образлар татар халык җырларында кеше язмышының төрле якларын, аеруча ачы, катлаулы мизгелләрен чагылдыру өчен кулланыла.

Кешеләр мәхәббәтне бик татлы, хәтта бал кебек тәмле бер хис дип атыйлар. Шуңадырмы, җырларда да еш кына кызларның матурлыгын тулысынча пешкән җиләк-җимешләргә тиңлиләр. Мәсәлән:

***Карлыганнан*** *кара, ай, кашларың,*
*Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч...* («Мәдинәкәй»)

Татар халкы һәрвакыт үзенең нечкә күңеле, моңы белән аерылып тора. Хәзерге вакытта да татар халык иҗаты онытылмаган. Мәктәптә дә, балалар бакчасында да, төрле бәйрәмнәрдә дә, иҗатта да, көнкүрештә дә без шушы гүзәл җәүһәрләрдән еш файдаланабыз.

Халык җырлары – бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле мирас. Шуңа күрә аларга зур әһәмият бирергә, киләчәктә дә истән чыгармаска кирәк.

Татар халкының бай һәм тирән мәдәниятендә табигатькә карашы, гореф-гадәтләре һәм рухи дөньясы аеруча зур урын алып тора. Бу кыйммәтләрне аңлауда дендронимнар мөһим роль уйный. Алар безгә борынгы бабаларыбызның табигать белән тыгыз бәйләнешен, аның серләренә тирән хөрмәт белән каравын күрсәтә.

Һәр агач исеме – ул бер хикәя, бер риваять. Кайберләре агачның тышкы кыяфәтен, үзенчәлекләрен чагылдырса, икенчеләре аның файдалы якларын, халык хуҗалыгында кулланылышын искә төшерә. Мәсәлән, «имән» сүзе ныклык, көч символы булса, «юкә» – йомшаклык, ягымлылык, ә «нарат» – салкыннарны җиңеп чыгу, чыдамлык билгесе.

Дендронимнар шулай ук татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары белән дә тыгыз бәйле. Борынгы заманнарда агачларны изге дип санаганнар, алар янында төрле бәйрәмнәр үткәргәннәр, теләкләр теләгәннәр. Кайбер агачларны сихри көчкә ия дип уйлаганнар, аларны төрле бәла-казалардан саклаучы дип белгәннәр. Мәсәлән, «чыршы» – язгы яңарту, яшәеш символы буларак каралган.

Рухи дөньябызны аңлауда да дендронимнарның әһәмияте зур. Алар безгә табигатьнең бер бөтенлеген, аның тылсымлы дөньясын күрсәтә. Агачларны ата-бабаларыбызның рухы белән бәйләп карау да еш очрый. Аларны саклау, хөрмәтләү – ул безнең тамырларыбызны, милли үзаңны саклау дигән сүз.

Шулай итеп, татар халык җырларында кулланылган дендронимнар – ул бары тик агач исемнәре генә түгел, ә татар халкының табигатькә карашын, гореф-гадәтләрен һәм рухи дөньясын чагылдыручы, аларны киләчәк буыннарга җиткерүче мөһим элемент булып тора. Аларны өйрәнү – безнең тарихыбызны, мәдәниятебезне тирәнрәк аңлау юлында бер адым.

**Кулланылган әдәбият**

1. Ахунова И.Р., Зарипова И.Ф. Татар халык җырларында флоронимнар // Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей X Всероссийской научно-практической конференции (9 декабря 2022 г.) / отв. ред. И.Ф.Зарипова; И.К. Фазлутдинов. – Уфа: РИЦ УУНиТ, 2022. – Б. 40.

2. Габдрахманов Н. Халык традицияләре җирлегендә // Мәгариф. – № 1. – 1998. – Б. 5–7.

3. Галимов Ф. Халык җырлары – олы мирасыбыз // Мәгариф. – 2000. – № 3. – Б. 32–47.

4. Сез яраткан җырлар. – Казан, 1994. – Б. 25–451.

5. Татар җырлары. – Казан: Татар. кит. Нәшр., 2015.

6. Татар халык җырлары – иң кадерле мирас. – URL: https://infourok.ru/konspekt-uroka-tatar-halik-irlari-i-kaderle-miras-656675.html (мөрәҗәгать итү вакыты: 26.10.2025)

© Тазетдинова И.Р., 2025

ДК 821.512.145

**Талыпова Л.Н.,**
*студент КФУ*
*Научный руководитель* – **Габидуллина Ф.И.,**
*доцент кафедры филологии Елабужского института КФУ,*
*г. Елабуга, Россия*

# ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИННЫҢ «АНА КОРТ» ПОВЕСТЕНДА ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫ

***Аннотация**. Бу мәкаләдә Тәлгать Галиуллинның «Ана корт» повестендагы хатын-кыз образлары тикшерелә. Тәлгать Галиуллин – танылган татар язучысы, прозаик һәм драматург, аның иҗаты хәзерге татар әдәбиятында мөһим урын алып тора. Анализ үзәгендә ике төп героиня – Нәфисә һәм Регина тора, аларның язмышлары һәм характерлары повестьның үзәк метафорасы – «ана корт» аша ачыла. Көчле, ихтыярлы, гадел хатын-кыз лидер буларак күрсәтелгән Нәфисә образына аерым игътибар бирелә. Аның капма-каршысы булып гаилә таянычы һәм әхлакый ориентирлары булмаган ятим Регина тора, бу аны зәгыйфьләндерә һәм тормыш фаҗигаләренә китерә. Бу образларны чагыштырып анализлау аша повесть шәхес формалашуда гаиләнең, ана тәрбиясенең һәм ныклы әхлакый принципларның мөһимлеген ассызыклый.*

***Терәк сүзләр:** татар әдәбияты, проза, повесть, хатын-кыз образлары, чагыштырма анализ, гаилә, тәрбия, әхлак, ана булу, ятимлек, әхлакый принциплар, шәхес, тормыш сайлавы.*

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм язучы Тәлгат Нәби улы Галиуллин 1938 елның 20 июлендә Татарстанның Нурлат районы Кычытканлы авылында туа. Авылдагы сигезьеллык, аннан күрше Әлмәт (Яңа Әлмәт) авылындагы унъеллык мәктәпне тәмамлаган. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң, 1961-1962 елларда татар теле кафедрасында ассистент булып эшли. 1962-1965 елларда СССР Фәннәр академиясенең академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече гыйльми хезмәткәр булып эшләгән [2; 126].

1965 елда Т. Галиуллинны Алабуга педагогика институтында эшли. Анда ул татар һәм рус әдәбиятлары буенча лекцияләр укый. Укыту белән бергә 1967 елдан 1971 елга кадәр институтның укыту һәм фәнни эшләр буенча проректор хезмәтен дә башкара. 1970 елда «Хәзерге татар поэзиясе һәм халык иҗаты» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклаганнан соң, аңа доцент дәрәҗәсе бирелә. 1971–1986 елларда Тәлгат Галиуллин – Алабуга педагогика институтының ректоры [2; 126].

Тәнкыйтьче буларак, Т. Галиуллинның исеме матбугатта узган гасырның 60 нчы еллар уртасында күренә башлый. Аның «Казан утлары» журналында басылган беренче мәкаләләре Сибгат Хәким поэзиясендәге халык иҗаты традицияләренә багышланган. Соңрак шул ук журнал битләрендә бер-бер артлы «Балладаларыбыз турында», «Поэманың барыр юллары», «Шигъри ачышлар һәм югалтулар аша» кебек теоретик күзәтүләргә бай мәкаләләре дөнья күрә. 60 нчы еллар һәм 70 нче еллар башы татар поэзиясенең төп үсеш тенденцияләрен өйрәнүгә багышланган бу тикшеренүләр соңыннан тәнкыйтьченең «Яңа үрләр яулаганда» (1972) һәм «Еллар юлга чакыра» (1975) дигән аерым җыентыкларында басыла [2; 126].

Тәлгат Галиуллинның «Ана корт» әсәрендә хатын-кыз образлары калку сурәтләнә. Хатын-кыз, бигрәк тә Ана вазифасындагы хатын-кызның тормыштагы роле үтә югары булуын язучы табигать законнарына, бөҗәкләр тормышында хакимлек иткән кануннарга таянып та аңлата: «Нәфисәне аеруча үзенә каратканы, күңеленә хуш килгәне, һәрвакыт Хакыйкать яклы Ана корт иде. Ул шундый зур көч – балалары, оныклары белән оста дирижер шикелле җитәкчелек итә. Ялкауларны әрли, чеметеп тә ала, уңганнарны хуплау гамәлен дә таба. Нәфисәнең дә менә шулай күп балалы ана корт буласы килде. Әмма Ана корт

«вазифасын» үтәү ифрат катлулы вә четерекле булып чыкты» [1; 73]. Димәк, Нәфисә образы әнә шул ана корт образы белән янәшә куеп анализланырга тиеш, дип уйлыйбыз.

Умартачылык курсларында укыганда, районнан тикшерүче килеп, нәкъ менә Нәфисәгә ымсынуы, аны үзенеке итү теләген белдерүе, Нәфисәнең аны алдап авылга кайтып китүе, героиняның матур гына түгел, кызлык намусын саклый белүче, тапкыр буларак та сыйфатларын ача.

Олы һәм саф йөрәкле хатын-кыз булуга карамастан, Нәфисә кырыслык та күрсәтә ала. Бу яктан ул умарталыктагы, көчтәге ялкау, булдыксыз яисә гаепләре булган кортларны чеметеп тә ала торган Ана кортка охшап кала. Бу сыйфатлар анда яшьлектә үк булып, тормыш тәҗрибәсе арткан саен, үсә генә бара. Инде яше утыздан узган, беркадәр тормыш сабаклары алган хатын-кыз булып Регинага якты йөз күрсәткәндә дә ул җавап рәвешендә алдашмау, тырышлык, йөзгә кызыллык китермәүне таләп итә.

Нәфисә – яхшы тәрбия алып, тормыш сабаклары да алып, гадел, бераз кырыс, әмма мохтаҗларны беркайчан да ярдәменнән калдырмас «Ана корт» булып җитешә. Инде ничә көн ашханә янында кемнедер эзләгән кыяфәттә йөрүче яшь кыз аңа бик кызганыч булып тоела, ул аңа ярдәмгә ташлана, аның төрле фаҗигаләрдән йолып кала.

Әсәрдә аталган образлардан ата-ана образлары да әһәмияткә ия. Иң авыр вакытта, югарырак аталган тикшерүче дә, умарта хуҗалыгы мөдире дә Нәфисәне «юл уңае» белән тикшерүченең машинасына утырырга күндергәндә, кыз әнисенең сүзләрен искә төшерә: «Берәр явызы куркытыпмы, әллә ялган вәгъдәләргә күмепме, бәйләнсә, карышып, бәхәсләшеп, вакыт уздырма, әнә теге якта соңгы йортны яисә юан имән агачын күрәсеңме, шунда көтеп тор (тик килермен сүзен әйтмә, чигенергә ара калдыр) дип вәгъдә бир дә, үзең икенче якка шыл. Тәнең үзеңнеке, сатып алган, урлаган әйберең түгел. Беркем дәгъва белдерә алмый, дигән иде әнисе» [1; 73 – 74]. Гомумән, образны ачканда, Тәлгат Галиуллин аның тәрбиясенә, бала чагына игътибарын тиешле дәрәҗәдә бирә, Нәфисәнең тулы гаиләдә, ата-анасының сөекле баласы булып үсүен дә, кечкенәдән хезмәткә өйрәнүен дә ассызыклый.

Ә менә Регина, ятимә кыз, ул биш яшьтә булганда, ата-анасы юл һәлакәтенә таралар, кызны ун яшенә кадәр әбисе тәрбияли, әмма инде ул үлгәч, кыз балалар йортына озатыла. Бирелә ул ана тәрбиясе, анадан гомерлеккә отып калырлык тормыш сабакларыннан да, хәтта газиз исеменнән дә аерыла. Документлар тутырганда, язуы артык авыр дип, Рәһбар исемен Регина дип үзгәртәләр. Гаилә тәрбиясен дә, балалар йорты тәрбиясен дә күргән Регина каршылыклы шәхес булып җитешә, анда Нәфисәгә хас булган бөтенлек юк. Бер яктан, ул самими, яхшы күңелле, бер күрмәгән кешесенә акчасын да, алтын балдагын да, фатир документларын да тоттырып җибәрә. Икенче яктан, нәфесле, үзенә ярдәм иткән Нәфисәгә әйтеп тә тормыйча, «Социаль ашханәдә»н китә һәм хезмәт хакын өч тапкыр күбрәк итеп түләргә вәгъдә биргән «Шашлычная»га урнаша. Ә инде «Шашлычная»да эшләүче азгын әзербайҗан егете Лачынның мәхәббәт корбаны булгач, киңәш сорап, яңадан Нәфисә янына килә. Нәфисә белән Регинаны тасвирлаганда, язучы чагыштыру алымына да мөрәҗәгать итә, икесен бер үк ситуациягә куеп карый. Регина Лачынның капкынына тиз эләгә, аның бүләк-чәчәкләре, матур сүзләре, атакка өстерәмәве егет турында яхшы фикер калдыра. Лачын кызны үз өенә кунакка чакыргач, ошаса, шунда бергә тора башларбыз, дигән вәгъдәләре аны канатландыра. Ул, чыннан да, Лачынның өенә бара, нигәдер бөкесе инде ачылган булган шәмпан шәрәбеннән авыз итә, ә инде дару тәэсирендә йоклап китеп, иртән уянганда, ал анадан тума шәрә һәм канга буялган була. Мәхәббәт әкияте шушы мизгелдә тәмамлана. Нәфисәгә дә Лачын кайчандыр капкын корган булган. Әмма Нәфисә хәйләкәррәк була, «алсу иренеңнән үбәсем килә» дигән тәкъдимгә:

– Шул гынамы? Аның өчен сүз боткасы куертып, кеше көлдереп торасы да юк», – дип җавап кайтара [1; 82]. Ә инде кызның шундый тиз риза булуы бәхетеннән шашкан егет, үбер өчен битен якынайткач, кыз аның борынын бар көченә тешләп, йөгереп китә.

Нәфисә ана буларак үзе өчен чит булган Регина, барлык татар кызлары өчен генә түгел, үзенең баласы Рафик өчен дә тырыша. Ул улын ялгызы тәрбияли, әмма улы башка балалардан ким яшәми, түгәрәкләргә дә йөри, рәсем ясау белән мавыга. Әхлакый

сыйфатларга килгәндә, Нәфисә аның йөрәгенә дөрес, файдалы орлыклар салган, дип әйтергә җирлек бар. Кайчандыр, иреннән аерылып өч ел чамасы узганда, ул да чак кына Лачынның мәхәббәтенә ышанмый кала. Әмма нәкъ менә шушы көннәрдә улы аңа иң дөрес сүзләрне сайлап әйтә: пычранмаска киңәш итә. Баланың хаклы булуы Регина вакыйгасыннан соң аеруча төгәл аңлашыла.

Әсәрдә уңай образ буларак Нәфисә тәкъдим ителә. Ул үзен ана корт буларак позицияли һәм әсәрнең көчле урыннарында – исемендә, ахырында бу атама кулланылып, героиняның ана корт дәрәҗәсенә ирешүе ассызыклана. Регина күпмедер дәрәҗәдә чагыштырма рәвештә тасвирлана, әмма ул мәхәббәт сынавын лаеклы үтә алмый. Шулай да ятимә бу кызга карата автор мәрхәмәтле, ул исән кала, Гаваз исемле гади егеттә бәхетен таба.

**Әдәбият әдәбият**


1. Галиуллин Т. Ана корт // Казан утлары. – № 7. – 2020. – Б. 66–95.
2. Галиуллин Т.Н. Яктылык:әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Тәлгат Галиуллин [кереш сүз авт. Д. Заһидуллина]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 126–128.
3. Рамазанов Г. Поэзиядә заман сулышы // Казан утлары. – № 6. – 1980. – Б. 185–187.


© Талыпова Л.Н., 2025

УДК 821.512.145

**Уразбахтина А.И.,**
*магистрант 1 г. о.Стерлитамакского филиала УУНиТ*
*Научный руководитель* – **Мансуров И.С.,**
*доцент кафедры татарской и чувашской филологии Стерлитамакского филиала УУНиТ,*
*г. Стерлитамак, Россия*

## БАШКОРТСТАН ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЕНДӘ САЛАВАТ РӘХМӘТУЛЛА ИҖАТЫ

***Аннотация***. *Бу мәкаләдә М. Вафин, Л. Кәшфи, Р. Миңнуллин, С. Хафизовның Башкортстанның татар шагыйре Салават Рәхмәтулла иҗатына багышланган әдәби-тәнкыйди мәкаләләре анализлана. Мәкалә авторы укучының игътибарын шагыйрь әсәрләренең иҗади һәм стиль үзенчәлекләренә тәнкыйтьчеләрнең бәя бирүенә юнәлтә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар әдәбияты, Башкортстан әдәбияты, әдәби тәнкыйть, Салават Рәхмәтулла иҗаты.*

Салават Ибраһим улы Рәхмәтулла – заманча шагыйрь, аның иҗаты укучыларда да, әдәби тәнкыйтьчеләрдә дә зур кызыксыну уята. Аның тирән фәлсәфи эчтәлеккә һәм уникаль стильгә бай әсәрләре хәзерге татар лирикасында аерым урын алып тора. Әлеге мәкаләдә без аның иҗатының төп аспектларын әдәби тәнкыйть призмасы аша карарга омтылабыз, шулай ук аның шигырьләре ни өчен шулкадәр киң аудиториядә җавап табуын аңларга тырышабыз.

Л. Кәшфи [4], С. Хафизов (Лашманчы) [5; 10], Р. Миңнуллин [6], К. Дәүләтшин [3], Ф. Сәлимова [7], Ф. Фәткуллин [8; 9] кебек тәнкыйтьче галимнәр һәм журналистлар Салават Рәхмәтулланың иҗатын югары бәялиләр, аның әсәрләрен хәзерге татар әдәбияты үсешенә керткән өлешен билгеләп үтәләр.

Салават Рәхмәтулла иҗатының үзенчәлекләре сыйфатларыннан берсе булып аның кабатланмас стиле тора. Л. Кәшфи һәм Р. Миңнуллин аның иҗатын Тукай, Бабич, Ибраһимов, Юзеев белән бер баскычка куялар. Ул шигырьләрендә бөек шагыйрьләр фәлсәфәсенә таяна, әммә аның иҗатында заманча сулыш та тоела.

С. Хафизов С. Рәхмәтулла стилен бик тиз танып була ди, хәтта аның «бу-мин!» дип тора торган, аңа гына хас булган тезмәләре бар. Шагыйрь үзенең иҗатында сүзләрне, аерым фигыльләрне янәшә куеп көчәйтергә ярата: «Әнкәй, түз бер, түз ике; Яумаса... миннән торамы, торамы, торамы синнән генә?! Әнкәсе, чәй куй, куй аш!; Бәлеш итеп пешереп бир, пәрәмәч итеп пешер; Төеп пешер, пешер ярып... Бу җикеренү – ник әле? Ник йөрү кызып-кызып?; Давылларны кочтым, җилләрне кочтым, әлләниләр, әллә кемнәрне; Җиңелгән дә, җиңелгән дә юк әле, Туйган да юк әле көрәштән; Лениннарсыз яшәп була, булмый Сәйдәшләрсез, Гафуриларсыз!» [10]

М. Вафин С. Рәхмәтулланың шигырьләрен язу стилен Х. Такташ белән чагыштыра [1]: чөнки Х. Такташ белән бары тик С. Рәхмәтулла гына шулкадәр «эх» ымлыклар куллана:

«Иң дөрес!» дигән юл да бит
Башыннан башлап... яган...
Эх!
«Минем арттан!» – дип, үземчә
Кылыч болгыйсы калган!
**«Күченү»**
Эх... Җиңелгән чаклар...
....................................
Эх!
Гел җиңгән чаклар!
«Эх.......»
«Бәхетле киләчәк» – алда,
Аны да күрелмәгән
Эх...
Муеннан бурычларым –
Тиен дә бирелмәгән...
**«Ак биләү».**

М. Вафин Салават Рәхмәтулланы «Җәяле» шагыйрь дип та таный. Чөнки аның «Уяну» һәм «Сулар үргә акса да..» китапларында гына 213 шигырь, һәм беренче җыентыгында «җәя»ле – 122 җөмлә, яки сүз, икенчесендә – 149 [2].

Күрәбез, С. Рәхмәтулла сүз белән генә түгел, ә тыныш билгеләре белән дә бик еш уйный. Һәм бу аның шигыренә кабатланмас ритм һәм стиль булып тора.

Л. Кәшфи Салават Рәхмәтулланы күп төрле жанрларда иҗат итүче шагыйрь итеп күрә: «Бер урында таптанмый, ялыктырмый. Әле бер шәлкем лирик-патриотик, әле балалар шигыре, әле поэма, әле пародия-миниатюралар яки көлке әсәрләре алып килә ул. Сыйфат – югары, шуңа да тиз дөньяга чыга алар» [4].

Шагыйрь балалар өчен бик күп яза. Ул балаларның психологиясен бик якшы аңллый һәм бала кебек уйлый белә. Шуңа күрә аның балалар өчен язылган шигырьләре бик кызыклы һәм якты, самими, заманча булып чыга. Л. Шәех болай ди Салават абый турында: «Шагыйрь баланы өлкәннәргә хөрмәт белән карарга, табигатькә сак мөнәсәбәттә булырга, хезмәтне сөяргә өйрәтә. Үзенчәлекле табышмаклары, шарадалары, сүз уйнатулары аша сабыйларны зирәклектә сыный» [11].

Салаватның шигырьләре гади һәм аңлаешлы, фәлсәфи карашы ачык, фикере тыгыз, теле җор. Аның геройларына социаль-сәяси ясалмалылык хас түгел. Алар тормышның үзе кебек кырыс һәм туры сүзле. Андый геройларны, билгеле, дөреслекне маңгаена бәреп әйтердәй туры сүзле, кыю шагыйрьләр генә тудыра ала.

Роберт Миңнуллин Салават Рәхмәтулла иҗаты турында булай ди: «Кайбер шагыйрьләрнең язганнары күңелнең бер генә кылын да селкетми, хисләреңә һич кенә дә тәэсир итми, классик шигъриятне, бөек шагыйрьләребезнең берсен дә хәтерләтми. Чөнки ул «шигырьләр» – буш сүзтезмәләр генә, тозсыз, төссез, сүз боткасы гына. Ә чын шигырь ул синең 48 күңелеңнең кайсыдыр кылларын чиртеп, җаныңның кайсыдыр җирен чеметеп алырга тиеш. Ул үткен бер тема, матур рифма, сүз уйнату, канатлы, тапкыр сүз һәм башкалар

булырга мөмкин. Шуларсыз шигырь була алмый. Ә Салаватның иҗатыннан боларның барысын да табып була. Шигырьләрне укый-укый, аның кемнәрдән өйрәнгәнен, кайсы шагыйрьләрне яратканын, кемнәрнең шәкерте икәнен бик тиз төсмерлисең. Ә өйрәнүнең бер ояты да юк аның. Иң мөһиме, кемнән өйрәнәсең, кемгә ияләсең бит! Мин инде биредә әллә нинди яңалык ачмыйм. Алар өстә үк ярылып ята: ул иң элек, әлбәттә, такташлык, атнабайлык... Димәк, халыкчанлык, авылчанлык, гадилек һәм галилек... Атнабайдан килгән шигъри алымнар гына түгел, Гамил Афзалга хас сатира да, Илдар Юзеевка тартым лирик фәлсәфә дә, Наҗар Нәҗми шикелле тирән поэтик фикерләр дә чагылып-чагылып китә анда... Әгәр дә инде шигырьләрен игътибар белән укып чыксаң, анда Тукай чалымнарын да табарга булыр иде. Тукайдан аермалы буларак, ул күбрәк йомшак әйтеп катыга утыртырга ярата. Миңа калса, безнең чорда анысы да бик ярап тора» [6].

Кыскача әйткәндә, Салават Рәхмәтулла иҗаты хәзерге әдәбиятта уникаль күренеш. Аның тирән мәгънә һәм уникаль стиль шигырьләре төрле яшьтәге укучыларны мавыктыра. Ул шигъри традицияләрне саклаучы, шул ук вакытта новатор да булып тора.

**Әдәбият әдәбият**

1. Вафин М. Соңгы сүз // Салават Рәхмәтулла. Уяну: шигырьләр, җырлар, поэмалар. – Уфа, 1993. – Б. 195–199.

2. Вафин М. «Җәяле» Салават // Тулпар. – 2007. – №1. – Б. 22-24.

3. Дәүләтшин К. Гомер буе шагыйрь «эзләнә...» / Тулпар. – 2002. – №1. – Б. 44–47.

4. Кәшфи Л. Сабыйларга бүләге зур: С. Рәхмәтулланың балалар өчен язылган поэмаларына бер караш // Кызыл таң. – 2015. – 12 сент.

5. Лашманчы С. Кояш артыннан йөгерүче шагыйрь // Кызыл таң. – 2009. – 13 ноябрь.

6. Миңнуллин Р. Шагыйрь дигән исем күтәрде...: [Салават Рәхмәтулла иҗаты тур.] // Кызыл таң. – Уфа. – 2012. – 1 февраль.

7. Сәлимова Ф. Әдәбият нурлары сүнмәсен // Кызыл таң. – 2000. – 6 сентябрь.

8. Фәткуллин Ф. Үзенчә – нәкъ Салаватча! // Рәхмәтулла С. Сулар үргә акса да.. – Уфа, 2001. – Б. 5-13.

9. Фәткуллин Ф. Аны «Кызыл таң» шагыйрь итте // Кызыл таң – 2001. – 23 гыйнвар.

10. Хафизов С. Салават Рәхмәтулла стиле // Хафизов С. Очмыйча син түзеп кара...: (Башкортстанда татар шигърияте) // Казан утлары. – 2002. – №7. – Б. 138-139.

11. Шәех Л. Үзебезнең Салават абый // Кызыл таң. – 2010. – 20 июль.

© Уразбахтина А.И., 2025

УДК 821.512.145.09

**Фазлутдинов И.К.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## САТИРА МАР. САЛИМА В КОНТЕКСТЕ БАШКИРО-ТАТАРСКИХ ЛИТЕРАТУРНЫХ ВЗАИМОСВЯЗЕЙ

***Аннотация.*** *В статье рассматривается художественное своеобразие сатирических произведений Мар. Салима (Марселя Салимова) в контексте межкультурных и межлитературных взаимодействий в Урало-Поволжском этнокультурном пространстве.*

***Ключевые слова:*** *поэт, творчество, сатира, юмор, сборник, лирический герой, басня, афоризм.*

Наверное, в Башкортостане нет человека, который не знал бы Марселя Салимова. Какую бы газету ни открыл, на какой бы канал ни переключил телевизор, на чей бы сайт ни

заходил в Интернете, тебя обязательно встретит новость о том, что «башкирский сатирик Мар. Салим победил на таком-то престижном конкурсе» или «был удостоен международной премии имени того-то». Только для того, чтобы перечислить литературные премии, присужденные Марсель-агаю, или награды, которые он получил, потребовалась бы большая статья. Но моя цель в другом – привлечь внимание читателей к поэтическим сборникам Мар. Салима «Чорына күрә җыры» («По времени и песня») и «Мар. Сәлим чыбыркысы» («Кнут Мар. Салим»), изданным в последние годы в Казани. Это весьма примечательные сборники, составляющие определенный этап в творчестве Народного писателя Республики Башкортостан.

Во-первых, издать книгу для любого писателя – большое счастье. А вот издание своих книг в государственных издательствах соседней республики – это двойное-тройное счастье, о котором многие даже и не мечтали! Впрочем, Марсель-агая таким «счастьем» не удивишь. Он – автор 45 книг, изданных в Уфе, Москве, Казани, Чебоксарах, Симферополе и даже Лондоне на башкирском, русском, татарском, чувашском, болгарском и английском языках. Для татарских читателей это книги «Көлсәң – көл…» («Смеясь – смейся», 1998), «Үзебезнең агай-эне» («Свои люди», 2007), «Бергәләп көлик!» («Посмеёмся вместе», 2003), «Мәхәббәтле каләм» («Любовное перо», 2005), «Мәңгелек мәхәббәт» («Вечная любовь», 2008), изданные в Казани, и «Майлап-җайлап» («Кнутом и пряником», 1995), «Тормыш көзгесе» («Зеркало жизни», 2008), опубликованные в Уфе. При этом новые книги имеют одну выдающуюся особенность, выгодно отличающую их от вышеперечисленных сборников. Дело в том, что здесь собраны стихи, написанные на татарском языке, а не переводные!

Не спешите, удивляясь пожимать плечами. Марсель Салимов в 1971 году с отличием окончил татарско-русское отделение филологического факультета Башкирского государственного университета. В студенческие годы был старостой литературного кружка «Акчарлаклар» при кафедре татарской филологии, выступал на научных конференциях, посвящённых творчеству татарских писателей, написал курсовую работу о пословицах и поговорках в произведениях Наки Исанбета, а дипломную работу защитил на тему «Образ Мусы Джалиля в татарской и башкирской драматургии». Вышеназванные сборники, включающие в себя юношеские стихи автора, можно рассматривать как своеобразное возвращение поэта к своей молодости. Если в биобиблиографическом справочнике «Наши писатели» *(Казань: Татарское книжное издательство, 2009)* указано, что «Мар. Салим – мастер юмора, владеющий всеми тонкостями башкирского, татарского и русского языков и успешно творящий на всех трёх языках» [1, 359], то в этом нет никакого сомнения. Это истинная правда.

Во-вторых, в отличие от других сборников, книга «Чорына күрә җыры» («По времени и песня») полностью раскрывает личность автора и многогранность его поэтического творчества. В первом разделе, названном «По времени и смех», он предстаёт как остроязычный сатирик. Во втором разделе, «Конфетная любовь», он раскрывается и как юморист, умеющий мягко, с теплотой и любовью указывать на недостатки, и как лирический поэт, подобно Маджнуну опьянённый любовью. Признаюсь, для меня было удивительно читать лирические стихи Мар. Салима – я даже не представлял, что в его душе бушует такой вихрь чувств. Впрочем, судите сами:

*С неба не снег не падает, душа моя,*
*Ты это знай.*
*Я жемчуг для тебя рассыпаю,*
*На луну поднявшись.* [3, с. 95] (Здесь и далее перевод наш. – И.Ф.)
***(«Если не знаешь – знай»)***

Эти строки, переведённые сегодня на многие языки (включая японский!), были написаны, когда автору было всего пятнадцать лет. Вот ещё одно юношеское стихотворение:

*…Буря не утихает.*
*Самолёты не летают.*
*Погода, говорят, не налаживается.*

*Нас с тобой разлучить*
*Даже АЕРАпорт не желает…* [3, с. 88]
***(«АЕРАпорт»)***
И для полноты картины ещё один пример:
*Сдерживая неудержимые чувства –*
*Мы яростно любим.*
*Чистые чувства на берегу реки жизни*
*Вёдрами раздаём…* [3, с. 85]
***(«Молодым девушкам»)***

Подумайте, разве сатирик способен писать такие, пропитанные тонким лиризмом строки? Нет, скажете вы? Поверьте, способен, друзья мои… Для этого нужно немногое. Достаточно быть Марселем Салимовым...

В разделе «Из песни слов не выкинешь» автор раскрывается как автор текстов множества популярных песен. С какими только композиторами он не работал! Их имена известны всем: Рим Хасанов, Раис Ханнанов, Муфтадин Гилязев, Васил Хабибисламов, Забих Мамалимов и другие. В студенческие годы каждый из нас напевал: «Поцелуй, не обижайся зря…», и я только недавно узнал, что автор слов песни «Не обижайся», не сходившей из наших уст, – Марсель-агай.

Тем не менее, главным жанром, определившим лицо поэта, остаётся сатира. Точнее, острая, жёсткая сатира, заставляющая скрипеть зубами от негодования реалиями современной жизни. На мой взгляд, чтобы понять творческое кредо Мар. Салима, достаточно прочитать стихотворение «Не был бы я сатириком», открывающее сборник.

Взяв в качестве эпиграфа слова великого Габдуллы Тукая: «…Я сам весь измарался, а мир очистить так и не смог», поэт удачно использует поэтические параллели. Он противопоставляет чувства, одолевавшие его в тридцать лет, ощущениям в своё шестидесятилетие:

*Когда мне было тридцать,*
*меня назначили главным редактором*
*острого, как лезвие,*
*журнала «Хэнэк».*
*Шестидесятилетние начальники*
*поучали:*
*– Брат, на ответственном месте*
*веди себя соответственно,*
*слова свои взвешивай.*
*Ох, язык твой слишком остёр!*
*Но я их не слушал…*
*Не послушав,*
*преуспел ли я,*
*или замёрз? – не понял.*
………………………………………………………
*Когда мне исполнилось шестьдесят,*
*служа круглолицым хозяевам,*
*тридцатилетние начальники,*
*грозя пальцем, поучали:*
*– Брат, язык твой слишком остёр!*
*Подумай, прежде чем говорить,*
*тебе ещё жить и жить!*
*А я, как и прежде,*
*по юношеской привычке,*
*не слушался «старших»,*

*их совсем не понимал…*
*Если бы я в жизни своей*
*слушался начальников,*
*садился бы в их телегу,*
*пел бы их песни,*
*я бы не стал сатириком.*
*Да и вовсе не родился бы!* [3, с. 6–8]

Читатели, причастные к башкирской журналистике, знакомы с реальной подоплекой этого стихотворения. В конце «нулевых» на руководящую должность в сфере СМИ был назначен бывший полковник полиции, уволенный за нерадивое исполнение обязанностей. Свою деятельность он начал с установления тюремных порядков в среде писателей, поэтов и журналистов, стремясь «выстроить в струнку» творческую интеллигенцию. В те дни Марсель-ага выступил на заседании Коллегии по делам печати, где, дрожа от страха сидели редакторы республиканских газет и журналов, и заявил о своём несогласии с происходящим. Как офицер, он подчеркнул, что честь для него дороже редакторского кресла, на котором он сидел тридцать лет, и, гордо подняв голову, сказал: «Генералы и маршалы, командовавшие армиями, не могли управлять юмором, а вы, товарищ полковник, стремитесь стать нашим командующим. Поэтому я освобождаю вас от обязанностей моего начальника!» И твёрдым шагом покинул зал. Остальные, опустив головы, остались сидеть… И сидят до сих пор… А тот «командующий» печатью, что пробыл в этой роли полтора года, тоже сидит… Но уже в тюрьме…

Это лишь один эпизод, раскрывающий личность Марселя Салима как творца. Поэт пишет:

*Как это ни странно,*
*сколько бы я ни боролся,*
*сколько бы сил ни тратил,*
*но зло на земле не исчезло.*
*Чтобы победить его,*
*одной моей жизни не хватило.* [3, с. 8]

Эти слова, подобно Тукаевским, отражают осознание поэтом безнадёжности своей борьбы, но, подобно Дон Кихоту, он продолжает сражаться с «ветряными мельницами». Мар. Салим не может жить иначе – в этом суть его жизни.

Судьба страны, её сегодняшний и завтрашний день – в центре внимания поэта. В стихотворении «Дойная корова» он сравнивает Россию с «тощей коровой» и ставит читателя перед дилеммой:

*На карте наша страна –*
*словно дойная корова.*
………………………………………
*Когда же хищники*
*перестанут*
*доить это создание?!* [3, с. 21]

Парадоксально, но именно это состояние страны порождает сатириков:

*Смешно ли это, или печально:*
*Недостатки России*
*рождают множество сатириков,*
*взращивают их,*
*заставляют жить в тьме,*
*И убивают их,*
*заставляя*
*обрести величие*
*и бессмертие.* [3, с. 11–12]
***(«Русский смех»)***

«Убивать ради бессмертия» … Как точно и остро сказано! Наши гении – Пушкин, Лермонтов, Тукай, Бабич и многие другие – не из этого ли ряда «убитых ради бессмертия»? И кто ещё пополнит эти ряды – неизвестно…

Серьёзные размышления о судьбе страны приводят поэта к созданию произведений ещё одного своеобразного жанра – басен. Басня – это аллегорический жанр, основанный на иносказании и имеющий воспитательную ценность. Она состоит из двух частей: повествовательной, напоминающей сказку, новеллу или анекдот, и морально-обобщающей, схожей с пословицами. Басня отображает поучительные или порочные явления жизни через конфликт аллегорических образов, обладающих противоположными человеческими качествами, и завершаясь нравственным обобщением [5, с 147].

Баснописцев в мире немного. Один из самых известных в России, Сергей Михалков, ознакомившись с баснями Марселя Салимова, в предисловии к его книге «Чёрным по белому» *(Уфа: Китап, 2009)* выразил своё одобрение, написав: «Басни Марселя Салима отличаются актуальностью, поскольку темы для них автор черпает из нашей повседневной реальности. Смех автора всегда социален, ведь его герои взяты из народной жизни» [2, с. 8].

При научном анализе басен поэта можно выделить несколько особенностей. Во-первых, их отличает условность сюжета, краткость и лаконизм изображаемых событий. Во-вторых, в центре внимания находятся аллегорические образы, отражающие абстрактные идеи. Эти образы, как правило, взяты из мира живой и неживой природы: старый баран, телёнок, лис *(«Кого поставить начальником?»)*; река, мост, берега *(«Сердитые берега»)*; комар, орёл *(«Начальник-комар»)*; сом, щука *(«Гладкий сом»)* и другие. Каждый из них, в традициях фольклора, воплощает в себе определённое человеческое качество. В-третьих, конфликт в баснях Мар. Салима обобщается через противопоставление идеей. В-четвёртых, морально-нравственная основа произведения выражается в нравственном, сатирическом или ироническом ключе. В-пятых, сюжет басен часто строится в форме диалога [5, с. 148].

Отдельные строки поэта уже сегодня становятся народными поговорками или афоризмами:

*Кто-то видит в работе сны…*
*А я и в снах работу вижу.*
***(«Работа и сны»)***
*Сменился «голова» на работе –*
*Что ещё увидят наши головы?*
***(«Что ещё мы увидим?»)***

Отношения между Татарстаном и Башкортостаном, татарами и башкирами всегда находятся в центре творчества поэта. В отличие от некоторых «горячих голов», Марсель Салим подходит к этой теме с тонким юмором, рассматривая её не через призму политики, а через отношения творческих людей и простых народов. Перед переписью населения, когда татарские и башкирские политики ломали копья, соревнуясь в своём величии, поэт в стихотворении «Пусть добрых людей станет больше» [3, с. 21] задаётся риторическим вопросом:

*Почему так быстро множатся*
*Плохие башкиры и плохие татары?*

И с присущим юмористу остроумием делает вывод:

*Пересчитывая людей,*
*Не упустить бы это.*

Казань очень близка сердцу поэта, настолько, что:

*Бабушки Казани*
*Для меня почти как девушки.* [3, с. 49]

И это неудивительно, ведь в Казани жили его старинные друзья – Зульфат, Роберт Миннуллин, Шахинур Мустафин, Ислам Ахметзянов, Рашит Закиев, Мунир Аглиуллин и многие другие. Общение с ними дарило поэту духовную силу и творческую энергию. Светом

искренней дружбы озарены стихи «Есть тысяча друзей», «Пробуждается Татарстан», «Дорога дружбы», «Сын Суня» и многие другие. Именно поэтому:

*Если в Уфе улыбается «Хэнэк»,*
*В Казани смеётся «Чаян».* [3, с. 50]
***(«Есть тысяча друзей»)***

Его верный друг Рашит Закиев, на протяжении десятилетий руководивший журналом «Чаян» в Татарстане, написал: «Полжизни я прошёл рядом с Марселем. Мы – те, кто дольше всех руководил сатирическими журналами в нашей стране. Нет нужды говорить, какой огромный вклад внесли «Чаян» и «Хэнэк» под нашим руководством в развитие татарской и башкирской сатиры и юмора – это знает каждый, кто умеет читать. Я до сих пор ощущаю тепло души моего друга Марселя Салимова, восхищаюсь и радуюсь его творчеству. Он – поистине певец, оседлавший свою эпоху!» [4, с. 12]

«Певец, оседлавший эпоху»… На мой взгляд, это самое точное определение поэту. Все противоречия нашего непростого времени, боль и радости наших современников находят в творчестве поэта наиболее полное отражение. Название сборника «По времени и песня» подтверждает это. Это и улыбка, пусть и с лёгкой грустью. Это и смех, но смех сквозь слёзы, вызванный размышлениями о нашем времени и нашем месте в нём. А будут ли это слёзы радости или печали – зависит от нас самих. Ведь, как сказал поэт:

*По лесу – и лисица,*
*По времени – и смех!*

**Список литературы**

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. – Т. 2. / төзүчеләре Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. *(на татарском языке)*

2. Салимов М.Ш. Белым по черному: сатира, юмор, и не только / пер. с башкирского Мустафин Я.М. и др. – Уфа: Китап, 2009. – 671 с.

3. Сәлимов М.Ш. *(Мар. Сәлим).* Чорына күрә җыры: сатира, юмор, лирика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 191 б. *(на татарском языке)*

4. Сәлимов М.Ш. *(Мар. Сәлим)*. Мар. Сәлим чыбыркысы: сатира, юмор (гына түгел). – Казан: «Ихлас» нәшрияты, 2023. – 160 б. *(на татарском языке)*

5. Фазлетдинов И.К. Замана тудыра шагыйрьне. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында Башкортстандагы татар шигърияте: монография. – Уфа: Уфа университеты, 2025. – 170 б. *(на татарском языке)*

© Фазлутдинов И.К., 2025

УДК 811.512.145+372.8

**Файзуллина А.Г.,**
*студент 4 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
**Сагидуллина Л.Р.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЯҢА СҮЗЛӘР МӘГЪНӘСЕН АЧЫКЛАУ АЛЫМНАРЫ

***Аннотация**. Мәкалә укучыларның туган телдәге сүзлеген баету проблемаларына багышланган. Яңа сүзләр барлыкка килүнең кайбер юнәлешләре һәм аларның мәгънәләрен ачу алымнары (контекст, сүзлек белән эшләү, тәрҗемә итү, синонимнар һәм антонимнар сайлау һ.б.) анализланды.*

***Терәк сүзләр:** сөйләм үсеше, татар теле, сүзлекне баету, яңа сүзләр, сүз мәгънәләрен ачу алымнары.*

Хәзер телгә өйрәтүнең төп максаты итеп укучыларда коммуникатив компетенция, ягъни аралашу осталыгы булдыру билгеләнә. Аралашу осталыгына ия булу өчен укучылар белемнәрне гамәли үзләштерергә, халыкның милли-мәдәни үзенчәлекләрен һәм сөйләм этикеты үрнәкләрен истә тотып, телдән яки язмача аралаша белергә, сөйләмне логик планда эзлекле, эчтәлекле, лексик, фразеологик, грамматик, стилистик яктан бай һәм дөрес итеп оештыра алырга, әңгәмә барышында тел «кытлыгын» җиңеп чыгарга, мәгълүматны сәнгатле итеп бирә белергә тиешләр.

Коммуникатив компетенциянең сыйфаты сөйләмнең төрле формаларында чагыла: уку, язу, сөйләү, тыңлау (аудирование), диалог, монолог һ.б. Уңышлы, нәтиҗәле сөйләм оештыру өчен төп төзелеш материалы булып сүзләр тора. Сүзлектән тыш элементар уку-язу күнекмәләренә дә өйрәтеп булмый, башка сөйләм формалары өчен дә сүз байлыгының булуы төп таләпләрнең берсе. Димәк, бүгенге шартларда укучыларның сүз байлыгын үстерү аша аларның сөйләм эшчәнлеген активлаштыру актуаль булып кала.

Һәр дәрес – яңа белем, яңа ачыш. Татар теле һәм әдәбияты дәресләре дә читтә калмый: укучылар яңа мәгълүмат ала, үз фикерләрен әйтергә өйрәнә, иң мөһиме – тел байлыгын арттыра. Әлеге процессның аерылгысыз өлеше булып яңа сүзләрнең мәгънәсен ачыклау тора. Чөнки яңа сүзләрне дөрес аңлау – текстны тирәнрәк үзләштерү, әсәрнең эчтәлеген төгәлрәк аңлау дигән сүз. Укучыларның сөйләмен үстерү иң актуаль методик мәсьәләләрдән, чөнки сөйләм юк икән – тел юк. Сөйләм үстерү укучыларның сүзлек байлыгын, аның күләмен һәм сыйфатын булдыру, яңа сүзләр, яңа мәгънәләрне үзләштерү, аларны активлаштыру белән бәйләнгән.

Тел – тере организм кебек, ул даими үзгәрештә, үсештә. Заман агымы, фәнни-техник прогресс, мәдәни бәйләнешләр һәм глобаль мәгълүмат киңлеге аркасында безнең сүзлек запасы даими рәвештә яңа сүзләр белән тулылана. Бу неологизмнар, алынмалар, профессиональ терминнар яки яңа мәгънә алган билгеле сүзләр булырга мөмкин. Күп кенә кешеләр яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлауда авырлыклар кичерә. Мондый хәл аралашуда тоткарлыкларга, хәтта мәгълүматны дөрес аңламауга китерергә мөмкин. Әлеге мәкаләдә без яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлату, ачыклау юлларына, алымнарына күзәтүнең кайбер нәтиҗәләре белән бүлешәбез.

Ни өчен яңа сүзләр пәйда була? Яңа сүзләрнең барлыкка килүе – телнең яшәү һәм үсеш билгесе. Бу процесс лингвистлар тарафыннан төрлечә аңлатыла [1; 4|. Алар, кагыйдә буларак, түбәндәге сәбәпләр аркасында барлыкка килә:

1. Яңа предметлар, күренешләр, төшенчәләр барлыкка килә: цифрлы технологияләр, фәнни ачышлар һәрдаим яңа атамалар таләп итә (мәсәлән, «гаджет», «блогер», «биткоин»).

2. Чит телләрдән алынмалар: глобальләшү процессында төрле мәдәниятләр һәм телләр үзара тәэсир итешә, бу чит тел сүзләренең (күбесенчә инглиз теленнән) безнең телгә үтеп керүенә китерә (мәсәлән, «офис», «менеджер», «стартап»).

3. Телнең эчке үсеше: иске сүзләр яңа мәгънәләр ала, яңа кушма сүзләр, кыскартмалар барлыкка килә. Сүз ясалышының бу төрләрен Р.Ф. Ягъфәров тикшерә [6; 89 б.].

4. Сөйләм модасы, яшьләр сленгы: Телнең бу катламында даими рәвештә яңа, кайвакыт тиз юкка чыга торган сүзләр барлыкка килә (мәсәлән, «краш», «чилл»).

Яңа сүзләрне аңлау һәм үз сөйләмеңдә дөрес куллану хәзерге дөньяда, белем бирү системасында мөһим компетенция булып тора. Сүзлек запасының әһәмияте турында төрле фәнни-педагогик басмаларда ассызыклана [4; 112 б.]. Беренчедән, яңа сүзләрне үзләштерми торып, эффектив аралашу мөмкин түгел, чөнки яңалыкларны, сыйныфташлар, хезмәттәшләрнең фикерләрен, интернеттагы мәгълүматны аңлау кыенлык тудырачак. Икенчедән, белем алу процессы авырлаша: күп кенә фәнни-популяр, профессиональ материаллар үз эченә яңа терминологияне ала. Өченчедән, мәдәни дәрәҗә түбәнәя: әдәбият, кино, музыканы тулысынча аңлау өчен бай сүзлек запасы кирәк. Һәм, ниһаять, сүзлек запасының җитәрлек дәрәҗәдә булмавы үз фикерләреңне төгәлрәк белдерү мөмкинлеген чикли.

Яңа сүзләрнең мәгънәсен ачыклау алымнары төрле. Аларны сайлап алу, урынлы куллану берничә шарт белән бәйле: укучыларның әзерлек дәрәҗәсе һәм сөйләм компетенциясе, укыту максаты, укучыларның яшь үзенчәлеге, укыту-методик комплекс үзенчәлекләре һ.б.

1. *Контекстны анализлау*. Сүзнең мәгънәсен аңлау өчен, ул кулланылган җөмләне, абзацны, бөтен текстны игътибар белән укыгыз. Еш кына тирә-юньдәге сүзләр аның мәгънәсенә ишарә итә: «Авыл читендә, зур елганың ярына терәлеп, иске, караңгы кабахәт йорт утыра иде. Күптән инде анда кеше яшәмәде, шуңа күрә ул ташландык хәлдә калган.» Бу җөмләдә *«кабахәт»* сүзе *«йорт»* сүзенә карата кулланылган.

• Йорт «иске» һәм «караңгы».

• Ул «авыл читендә, зур елганың ярына терәлеп» урнашкан.

• «Күптән инде анда кеше яшәмәде».

• Йорт «ташландык хәлдә калган».

Бу билгеләр *«кабахәт»* сүзен аңларга булыша. *«Кабахәт»* монда *«начар, ямьсез, хәерсез, караңгы, куркыныч»* дигән мәгънәләрдә килә. Йортның ташландык хәлдә булуы, кеше яшәмәве, аның гомуми күренеше «кабахәт»леген ассызыклый.

2. *Сүзлекләргә мөрәҗәгать итү*. Укучыларның сүз байлыгын үстерүдә лингвистик сүзлекләр укыту чарасы да, укыту методы да буларак кулланыла. «Тел дәресләрендә сүзлекләр белән эшләү һәрвакыт төрле укыту системаларында төп алымнардан исәпләнә, чөнки бу алым укучыларның мөстәкыйльлеген, эзләнү-табу-ачу ихтыяҗын, теоретик материалны гамәли эш белән үреп бару, телне гомуммәдәни, тарихи яссылыкта өйрәнү, сүз байлыгын киңәйтү һәм тирәнәйтү мөмкинлекләрен бирә» [2; 587 б.]. Укыту чарасы рәвешендә аңлатмалы, этимологик, тәрҗемәи, синонимик һ.б. сүзлекләр кулланыла. Хәзерге вакытта Татарстан фәннәр академиясендә төзелгән сүзлекләрнең электрон фонды методик әһәмияткә ия [5].

3. *Сүзнең этимологиясен өйрәнү*. Әгәр сүз чит телдән кергән булса, аның төп телдәге мәгънәсен белү ярдәм итә. Күп кенә алынмалар үзләренең башлангыч мәгънәсен саклап кала [6; 89]. Мәсәлән, *«айран (әйрән)»* сүзен аңлату.Укытучы, дәрес барышында, сыйныфка *«айран»* сүзен яза һәм сорый: «Бу сүз нәрсә аңлата? Бу нәрсә ул?» Укучылар, гадәттә, «айран» – ул бер төрле сөт ризыгы» – дип җавап бирергә мөмкин.Аннары укытучы *«айран»* сүзенең этимологиясен аңлата: *«Айран»* сүзе төрки телләрдән килеп чыккан. Күпчелек телләрне белгән галимнәр бу сүзнең борынгы төрки телдә «агыру», «йомырткалану»(сөтнең кату процессы) мәгънәсендәге «аер-» фигыленнән ясалганын раслый. Ягъни, *«айран»* дигән сүзнең тамырында «сөтнең кату процессы» ята. Башта сөт катырыла, һәм ул «айран»га әверелә.Шулай итеп, *«айран»* дигән сүз, башта «катырылган сөт» дигәнне аңлатып, вакыт узгач, шундый продуктның исеменә әверелгән.

4. *Күрсәтмәлелек куллану*. Күрсәтмәлелек – ул укыту процессында предметларны, күренешләрне, хәрәкәтләрне, сурәтләрне турыдан-туры күрсәтү. Яңа сүзләрне өйрәнгәндә, бу алым сүзләрне аңлауны һәм хәтердә калдыруны бик уңышлы итә.Мәсәлән, *«тулпар»* сүзе (татар мифологиясеннән). Тулпарның (канатлы ат) стильләштерелгән, матур, күрәнәш рәсемен яки иллюстрациясен күрсәтеп, «борынгы татар риваятьләрендә очрый торган, канатлы, гаҗәеп көчле ат – тулпар» дип аңлатырга мөмкин. Рәсемдәге атның канатларын, аның могҗизалы кыяфәтен күрсәтеп, *«тулпар»* сүзен аның белән бәйләү методик планда уңышлы алым.

5. *Тәрҗемә итү*.Мәсәлән,*»кызыклы»* сүзе. Укытучы сүзгә яңарак мәгънә бирүче җөмләләр уйлап таба: «Бу китап бик *кызыклы*. Аны укыганда вакытны сизмисең. Русча *«кызыклы»* сүзе *«интересный»* дигәнне аңлата.» «Кичә мин бер кызыклы фильм карадым» дигән җөмләне «Вчера я посмотрел(а) один интересный фильм» дип тәрҗемә итеп, «кызыклы» – «интересный» бәйләнеше чыга.

6. *Сүз ясалышы һәм төзелешенә таяну*.Мәсәслән*,»кульъяулык»* сүзе. Кушма сүзнең ике тамырдан торуын аңлату.Укытучы: «Без яңа сүз өйрәнәбез – кулъяулык. Бу ике сүзнең бергә кушылуыннан ясалган: кул + яулык. Кул – безнең әгъзабыз, яулык – бу баш киеме яки сөлге.

Шулай итеп, кулъяулык – кулга йомшаклык өчен яки киптерү өчен кулланыла торган кечкенә тукыма.» «Кул» һәм «яулык» сүзләренең мәгънәсен белү, аларның кушылуыннан «кулъяулык» дигән сүз килеп чыгуын аңлатыла.

7. *Синонимнар, антонимнар табу.* Мәсәлән, «матур» сүзенә синонимнар табуга мисал. Укытучы яңа сүзне биреп, укучылардан шул сүзгә охшаш мәгънәле сүзләрне табуларын сорый. «Без бүген «*матур»* сүзен өйрәнәбез. Бу сүзгә охшаш, якын мәгънәле тагын нинди сүзләр беләсез? Димәк, *гүзәл, чибәр, ямьле, күркәм* – болар барысы да *матур* сүзенең синонимнары». Укучылар *«матур»* сүзен *«гүзәл», «чибәр»* кебек сүзләр белән бәйләп, аның мәгънәсенең киңлеген аңлыйлар.

Антонимнарга күчкәндә, шулай ук *«матур»* сүзен кулланып мисал китерергә була.Укытучы: «Без *матур* сүзен өйрәндек. Ә аңа капма-каршы мәгънәле, ягъни киресен аңлаткан сүз нинди булыр? Әлбәттә, *ямьсез, чуар, чибәр түгел*.» *«Матур»* һәм *«ямьсез»* сүзләрен бер-берсе белән каршы куеп, *«матур»* сүзенең мәгънәсе ныгытыла, *ямьсез* сүзенең мәгънсе дә ачыклана.

8. *Лингвистик уеннар куллану.* «Лингвистик уеннарны бик еш кына «тел уены» яки «сүзләр белән уйнау» дип атыйлар, чөнки сүз – телнең иң мөһим һәм табигый берәмлеге. «Лингвистик уеннар» укучыларда, уенчыларда уенның эчтәлеге турында уйланучы, тел закончалыкларын ачуга сәләтле экспериментчы ролендә чыгыш ясау теләкләрен уята. Укучы лингвистик уеннар барышында сүзне тарката, җыя, мәгънәсен ача, үзгәрешләр кертә, шул үзгәрешләрне күзәтә, нәтиҗәләр ясый ала» [3; 181 б.]. Мәсәлән, «Эрудит» уены сүзнең мәгънәсен ачуга корылган. Җитәкче (укытучы яки укучы), бер сүз дә әйтмичә, һәркемгә аның лексик мәгънәсен аңлата (визуализация алымы). Балалар фаразлыйлар һәм язалар. Бу төр эш игътибарны үстерә, сүз байлыгын киңәйтә, әйдәп баручы укучыда җөмләләр төзү осталыгын формалаштыра.

9. *Башкалардан сорау.* Әгәр дә сез төгәл мәгънәсен белмисез икән, белгән кешеләрдән (укытучы, хезмәттәш, дус) сорарга оялмагыз. Бу – белем алуның табигый процессы.

10. *Интернет-ресурсларны куллану.* Google эзләү системасы, Википедия, ясалма фәһем (ИИ) кебек белешмәлекләр яңа сүзнең билгеләмәсен һәм кулланылыш мисалларын табарга ярдәм итә ала. Махсус лингвистик порталлар һәм форумнар да файдалы булырга мөмкин.

11. *Актив уку һәм тыңлау.* Китап, газета, журналлар уку, яңалыклар тыңлау, белем бирү тапшыруларын карау кебек гамәлләр сүзлек запасын тулыландыруның иң яхшы юлларының берсе. Очраткан яңа сүзләрне билгеләп бару һәм аларның мәгънәсен ачыклау.

Шулай итеп, яңа сүзләрне үзләштерү – сөйләм камилләштерү процессының аерылгысыз өлеше. Бу юнәлеш сөйләмне баетудан тыш, дөньяны тагын да тирәнрәк аңларга, мәгълүмат агымында югалмаска, аралашуда тагын да уңышлырак булырга ярдәм итә. Тел байлыгын саклау һәм үстерү өчен һәрберебез үз өлешен кертергә, яңа сүзләргә ачык булырга һәм аларның мәгънәсен өйрәнүдә даими активлык күрсәтергә тиеш.

**Кулланылган әдәбият**

1. Львов М.Р. Методика развития речи младших школьников. – М.: Просвещение, 1985. – 176 с.

2. Сагидуллина Л.Р. Возможности использования этимологического словаря татарского языка в системе образования / Актуальные проблемы татарской филологии: Материалы Всероссийской заочной научно-практической конференции с международным участием. – 15 декабря 2017 г. / отв. ред. И.Ф. Зарипова. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2017. – 612 с. – С. 586 – 589.

3. Сагидуллина Л.Р. Лингвистик уеннар нигезендә дивергент һәм иҗади фикерләү камилләштерү мөмкинлекләре / Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей VIII Всероссийской научно-практической конференции (11 декабря 2020 г.) / отв. ред. И.Ф.Зарипова. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2020. – 282 с. – С. 179 – 183.

4. Сафиуллина Ф. С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Мәгариф, 2002. – 240 б.
5. Электронный фонд словарей / https://suzlek.antat.ru/indexR.php
6. Ягъфәров Р. Ф. Татар теленең морфологиясе һәм сүз ясалышы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 192 б.
© Файзуллина А.Г., Сагидуллина Л.Р., 2025

УДК 821.512.145

**Фатхутдинова А.Д.,**
*студент 3 курса Елабужского института КФУ*
*Научный руководитель –* **Габидуллина Ф.И.,**
*доцент кафедры филологии Елабужского института КФУ,*
*г. Елабуга, Россия*

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ТӘНКЫЙДИ РЕАЛИЗМНЫҢ ФОРМАЛАШУЫ

***Аннотация**. Мәкаләдә XIX гасыр ахыры–XX гасыр башы татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның барлыкка килү һәм үсеш үзенчәлекләре карала. Гаяз Исхакый иҗатына аерым игътибар бирелә, анда әлеге метод иң тирән гәүдәләнеш ала. Тәнкыйди реализмның иҗтимагый-фәлсәфи нигезләре, аның рус һәм Европа әдәбияты белән бәйләнеше, шулай ук татар җәмгыятенең социаль һәм әхлакый проблемаларының чагылышы анализлана.*
***Терәк сүзләр:** тәнкыйди реализм, татар әдәбияты, Гаяз Исхакый, социаль проблематика, рухи яңарыш.*

Тәнкыйди реализм – дөнья әдәбияты тарихындагы иң мөһим юнәлешләрнең берсе. Ул чынбарлыкны сәнгати аңлауның бер формасы булып, тормышны бар хакыйкате һәм каршылыклары белән генә түгел, ә әхлакый һәм социаль күзлектән бәяләп күрсәтергә дә мөмкинлек бирә. Европа әдәбиятында тәнкыйди реализмның формалашуы XIX гасырның 1830 елларына карый. Русиядә бу ысул самодержавие-крепостной системасының таркалу чорында барлыкка килә һәм ил тормышында барган демократиягә омтылышларның әдәбияттагы чагылышы булып тора. Яңа юнәлешнең асылы – язучыларның чынбарлыкны объектив итеп сурәтләргә, җәмгыятьтәге каршылыкларны ачыкларга, кешене аны чолгап алган мохит белән бәйләнештә күрсәтергә омтылуында. Тәнкыйди реализмның үсешендә А.И. Герцен, В.Г. Белинский, Н.Г. Чернышевский, Н.А. Добролюбов кебек фикер ияләренең хезмәтләре зур роль уйнады. Белинский әдәбият «гади кешеләрне, халык массасын күрсәтергә» тиеш, дип язды. Реалист язучылар – Грибоедов, Пушкин, Гоголь, Некрасов, Салтыков-Щедрин, Толстой, Чехов – крепостной Россиянең каршылыкларын тирән ачып бирделәр, кешенең эчке дөньясын гына түгел, аны тәрбияләгән социаль мохитне дә сурәтләделәр [1; 56 б.].

Татар әдәбиятының үсеше дә гомумиевропа һәм рус әдәби процессына бәйле рәвештә барды. Тәнкыйди реализм ысулы әкренләп, мәгърифәтчелек реализмы һәм романтизм белән үрелеп формалашты. XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында татар җәмгыятендә зур үзгәрешләр башланды: милли аң үсте, мәгърифәтчелек хәрәкәте киңәйде, белем алу һәм шәхес иреге мәсьәләләренә кызыксыну артты. 1905 елгы беренче рус инкыйлабы татар зыялыларына көчле йогынты ясап, җәмәгать фикере һәм әдәбият үсешенә этәргеч бирде. Шушы чорда Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Сәгыйть Рәмиев, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов кебек язучылар әдәби мәйданга чыга. Аларның максаты – XIX гасыр мәгърифәтчеләре кебек идеаль геройларны түгел, ә реаль кешеләр язмышын,

аларның рухи кичерешләрен, гаделсезлек һәм җәмгыять авырулары белән бәрелешләрен күрсәтү була.

XX гасыр башы тәнкыйди реалистлары әдәбиятны «тормыш көзгесе» дип санады. Бу язучыдан җәмгыять процессларын тирән аңлауны һәм кешенең эчке дөньясына үтеп керү осталыгын таләп итте. Татар язучылары геройларын абстракт идея йөртүчеләр буларак түгел, ә мохит йогынтысында формалашкан тере шәхесләр итеп тасвирладылар. Яңа юнәлеш вәкилләре әхлак, гаделлек, шәхес иреге, хатын-кызлар тигезлеге һәм җәмгыятьнең рухи яңарышы кебек мәсьәләләрне күтәрделәр[1; 88]. Аларның әсәрләренә психологик тирәнлек, җәмгыяви яңгыраш һәм гуманистик рух хас. Татар әдәбияты көнчыгыш һәм мөселман традицияләрен саклап калып, шул ук вакытта рус һәм Европа мәдәнияте казанышларын актив үзләштерә. Чехов, Толстой, Тургенев, Гоголь иҗаты татар язучыларының художество фикеренә көчле тәэсир итә.

Тәнкыйди реализм формалашуында Гаяз Исхакый (1878–1954) иҗаты аерым урын тота. Ул – язучы, публицист, фикер иясе, татар халкының социаль һәм рухи эзләнүләрен тирән чагылдырган шәхес. Аның әсәрләренә гуманизм, кешегә ышаныч һәм җәмгыятьне яңарту идеясе хас. Исхакый күтәргән проблемалар чорның реаль чынбарлыгы белән бәйле: халыкның изелүе, тигезсезлек, рухи коллык, мөселман җәмгыятендә хатын-кыз язмышы. Тәнкыйди реализм идеяләре аның «Ябагы» (1907–1914) әсәрендә аеруча ачык күренә. Әсәрнең үзәгендә – яшь кыз Сагадәт язмышы: ятимлек, фәкыйрьлек, рухи төшенкелек һәм соңыннан яңарыш. Исхакый җәмгыять шартларының һәм социаль гаделсезлекнең кешене түбәнлеккә этәрүен күрсәтә. Әмма шул ук вакытта язучы кешенең иң авыр хәлләрдә дә намусын һәм рухи сафлыгын саклап кала алуына ышана [2; 76 б.].

Язучы геройларының эчке дөньясын зур психологик осталык белән ача. Сагадәт, язмышның авыр сынауларына карамастан, әхлакый чисталыгын саклый. Ул рухи уяну кичерә, белем алырга, камилләшергә, бәйсез булырга омтыла. Аның янында – Абдулла, вөҗдансыз һәм әхлакый кыйммәтләрдән мәхрүм кеше, җәмгыятьнең буржуаз катламын гәүдәләндерә. Бу образ аша Исхакый бай катлауның рухи бушлыгын һәм үзсүзлелеген тәнкыйтьли. Әсәр сюжеты Л. Толстойның «Терелеш» («Воскресение») романы белән аваздаш: Катюша Маслова да, Сагадәт тә газап аша чистарына. Ике язучы да рухи яңарышның кешенең эчке көрәше һәм үз хаталарын аңлавы аша гына мөмкин булуын күрсәтә [3; 36 б.].

«Ябагы» әсәрендә Исхакый XX гасыр башы татар җәмгыяте өчен бик әһәмиятле булган хатын-кызның иреккә чыгу мәсьәләсен күтәрә. Ул хатын-кызны мөстәкыйль шәхес, рухи үсешкә һәм актив тормышка сәләтле зат итеп сурәтл и Сагадәт образы аша язучы милләтнең киләчәгенә ышанычын белдерә [2; 88 б.]. Хатын-кыз, аныңча, яңа буынны тәрбияләүдә хәлиткеч роль уйный; димәк, аның иреге һәм белемле булуы – халыкның яңарышы өчен нигез шарт. Бу фикер татар әдәбияты өчен яңалык була. Исхакый җәмгыятьнең әхлакый һәм гадел була алмавын, әгәр анда хатын-кыз түбән хәлдә калса, раслый.

Исхакый иҗаты татар тәнкыйди реализмының югары ноктасы булып тора. Аның әсәрләренә социаль үткенлек, фәлсәфи тирәнлек һәм гуманистик юнәлеш хас. Язучы җәмгыятьнең бозык якларын фаш итә, рухсызлыкка, тигезсезлеккә һәм шәхесне изүгә каршы чыга. Ул акыл һәм әхлак көченә, халыкның рухи яңарыш мөмкинлегенә ышана. «Ябагы» романы Ф. Мусин, Җ. Валиди, И. Бикташев кебек әдәбият белгечләре тарафыннан югары бәяләнә: алар Исхакыйның реалистик төгәллеген, социаль тирәнлеген һәм сәнгать осталыгын билгеләп үтәләр [3; 65 б.].

Шулай итеп, тәнкыйди реализмның татар әдәбиятында формалашуы – аның үсешендә мөһим баскыч булды. XX гасыр башы язучылары, мәгърифәтчелек реализмы традицияләренә таянып, художество фикеренең яңа дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Гаяз Исхакый иҗаты татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбияты казанышларын үзләштереп, шул ук вакытта милли үзенчәлеген саклавының ачык мисалы булып тора. Тәнкыйди реализм татар язучылары өчен сәнгать ысулы гына түгел, ә чынбарлыкны аңлау, шәхесне тәрбияләү һәм гуманистик идеалларны гәүдәләндерү чарасы булды.

**Әдәбият әдәбият**

1. Баширов Ф.К. XX гасыр башы татар прозасының үсеш этаплары. – Казань, 2002. – 59 б.

2. Исхакый, Г. Г. Әсәрләр: 15 томда. – Казан, 2001. – 3 т. – 448 б.

3. Мусин Ф.М. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 172 б.


© Фатхутдинова А.Д., 2025

УДК 811.512.145


**Фахртдинова А.А.,**
*магистрант 1 г.о. Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
**Гайнуллина Г.У.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*


## ИЛДАР ЮЗЕЕВ ШИГЪРИЯТЕНДӘ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘРНЕ КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


***Аннотация***. *Әлеге мәкаләдә И. Юзеев шигъриятенең синтаксик үзенчәлекләре тикшерелә, шулай ук аның шигырьләрендәге катлаулы конструкцияләрнең стилистик роле карала.*



***Ачкыч сүзләр:*** *стилистика, синтаксис, синтаксик фигуралар, җөмләдәге сүз тәртибе, поэтика.*


Сөйләм типларының һәм стиль төрлелекләренең төзелешен, аларны барлыкка китерүдә сүзнең, грамматик форма яки фонетиканың ни рәвештә кулланылуын тикшерү эше тел белеменең бер тармагы стилистика өстенә төшә. Лингвистик стилистикасының максаты төрле яклы: ул билгеле бер телдә нинди сөйләм стильләре һәм чаралары булуын, аларның бер-берсенә бәйле һәм бер-берсеннән аерып тора торган үзенчәлекләрен, сөйләм төрен һәм стильне барлыкка китерүдә телнең лексик, грамматик һәм фонетик чаралары ни рәвешле кулланыла икәнен ачыклау; телнең үзенең билгеле бер мәгънә яки тойгы белдерүдә, кешенең аңына, уй-кичерешләренә тәэсир итүдәге көч-күәте һәм мөмкинлекләре нинди-моны өйрәнү шулай ук лингвистик стилистика эше.

Татар тел белемендә бүгенге көндә стилистика аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе булып кала. Татар язучылары һәм шагыйрьләренең телен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр булуга карамастан, поэтик синтаксиска багышланган мәкаләләр, монографиялар юк диярлек. Шул ук вакытта Башкортостанда туган һәм Татарстанда иҗат итүче талантлы шагыйрь Илдар Юзеев теленең синтаксик үзенчәлекләре моңа кадәр галимнәр тарафыннан тикшерелмәде.

Җөмләдә ике яки аннан күбрәк хәбәрлекле үзәк булганда, кушма җөмлә барлыкка килә. «Ике яки икедән артык хәбәрлеге булган җөмлә кушма җөмлә дип атала. Кушма җөмлә составындагы җөмләләр мөстәкыйль була алмыйлар. Алар бер-берсенә мәгънәсе, төзелеше, билгеле бер бәйләүче чаралар аша бәйләнеп киләләр. Кушма җөмлә составындагы җөмләләрнең бәйләнеше мәгънәви яктан да, логик яктан да, төзелеш ягыннан да тәэмин ителгән булырга тиеш. Кушма җөмләне тиңдәш хәбәрле һәм аерымланган хәлле җөмләләрдән аерып карага кирәк» [3, 314 б.].

Кушма җөмлә составында нинди җөмлә булуга карап, аларны – ике компонентлы кушма җөмлә һәм, икедән артса, катлаулы кушма җөмләгә бүләләр.

Аерым җөмләләре нинди чаралар белән бер-берсенә бәйләнүләренә карап, ягъни бәйләнеш төренә карап, кушма җөмләләр тезмә һәм иярченле кушма җөмләләргә бүленәләр.

Теркәгечләр катнашу-катнашмауга карап, тезмә кушма җөмләләрне теркәгечле һәм теркәгечсез җөмләләргә бүләләр.

Иярченле кушма җөмләләрне, бәйләүче чараларның төренә карап, аналитик һәм синтетик төрләргә бүлеп йөртәләр; җөмләдәге мәгънәләренә һәм функцияләренә карап, иярчен ия хәбәр, аергыч, тәмамлык, урын, вакыт, максат, сәбәп, кире, шарт, рәвеш, күләм, аныклагыч җөмләләргә бүләләр.

Катлаулы кушма җөмләләр, составындагы җөмләләрнең бер-берсенә нинди чаралар белән бәйләнүенә карап, күп тезмәле, күп иярченле һәм катнаш кушма җөмләләргә бүлеп йөртеләләр.

«Узара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә тезмә кушма җөмлә була. Аерым җөмләләре узара санау, каршы кую интонациясе аша бәйләнгән җөмләләрне теркәгечсез тезмә кушма җөмлә диләр» [3, 158 б.].

Башлар түбән иелгән лә,
Йөзләр кара коелган [4, 206 б.].
Каеннарның яшел толымнарын
Таңда җилләр тарый иделәр,
Нечкәбилләр тып-тын су өстенә
Көзге итеп карый иделәр [4, 123 б.].

Аерым җөмләләрне узара тезүче теркәгечләр белән бәйләнеп килгән җөмлә теркәгечле тезмә кушма җөмлә дип атала. Тезүче теркәгечләр үзләре өчкә бүленәләр: җыючы (һәм, да-дә, та-тә, ни-ни, янә-янә, тагын-тагын), каршы куючы (ләкин, ә, әмма, тик, бары, бәлки, исә), бүлүче (я-я, яки, яисә, әллә-әллә, әле-әле). Мәсәлән:

Бервакытны көзге усал
Җилләр исте
Һәм яшь миләш биек ярдан
Егылып төште [4, 24 б.].
Мин китәрмен, ә сораулар калыр...
Дөнья сораулардан яралган [4, 163 б.].
Кошлар белән бергә син китәсең,
әмма күңелсезлек тоймыйм мин [4, 47 б.].

Тезмә кушма җөмләләрне И.Юзеев шигъриятендә бик яратып куллана.

Тезмә кушма җөмләләр үзара антонимлар, алмашлыклар, уртак төзелеш ярдәмендә дә бер-берсенә бәйләнеп киләләр.

Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә санау интонациясе булса, җөмләләр арасына өтер куела; каршы кую интонациясе булса яисә тиз алмашынган вакыйгалар белдерелсә, сызык куела. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә аерым җөмләләр бер-берсеннән өтер белән аерылалар. Һәм теркәгеч алдыннан ике җөмлә өчен дә утрак кисәк булса, өтер куелмый.

«Бер җөмләнең икенчесенә ияреп килүе белән оешкан җөмлә иярченле кушма җөмлә дип атала» [3, б. 164].

Мин беләм: син исән, табармын [4, 73 б.].
Әлегә кадәр юкка мин үземне
Акыллы дип фараз иткәнмен,
Аксакаллар мәҗлесендә булдым:
Мин шактый ук надан икәнмен [4, 114 б.].

Ирячен җөмләләрне баш җөмләгә бәйләп килүдә төрле чаралар катнаша. Җөмләләр дә сүзләрне бер-берсенә бәйләп килгән чаралар аша бәйләнәләр. Кушма җөмләне өйрәнгәндә бу чараларны икегә төркемлеләр. Бер төркем чаралар иярчен җөмләнең хәбәре составында киләләр, хәбәр формасын тәшкил итәләр һәм ия белән ярашып та килмәскә мөмкиннәр. Бу чаралар күбеченсә фигыльнең затланышсыз формалары хәл, сыйфат, исем фигыль белән белдереләләр. Кушма җөмләләрдә ике кисәк бер-берсенә синтетик чаралар ярдәмендә бәйләнәләр. Аларга төрле кушымчалар (килеш кушмычалары, шарт, хәл, сыйфат, исем фигыль кушмычалары кебек, кайбер ясагыч кушымчалар –лы/-ле, -сыз/-сез, -ча/-чә, -дай/-дәй, -мы/-ме сорау кисәкчәсе), бәйлек һәм бәйлек сүзләр һәм янәшә килү чарасы керә.

Мондый чаралар белән баш җөмләгә ияреп килгән җөмләләрне синтетик иярчен җөмләләр дип атыйлар. Бу җөмләләр татар теленең башка Европа телләреннән аермалы булган җөмлә төрләрен тәшкил итәләр. Мәгънә буенча иярчен җөмләләрне 14 төргә бүлеп йөртәләр.

1. Иярчен шарт җөмләләр:

Сез, шомыртлар, аның зифа буен
Ап-ак чәчәк белән төрегез,
Мине сагынып әгәр яшь тамызса,
Иркәләгез аны, сөегез!

2. Иярчен кире җөмләләр:

Басылмады йөрәк ярсулары,
Басылса да юллар тузаны.

3. Иярчен рәвеш җөмләләр:

Килдем сиңа бары ике сүзне:
«Нихәл, күрше?» – диеп әйтергә,
Шигъриятнең бер илчесе булып,
Сөенеп һәм көеп әйтергә.

4. Иярчен сәбәп җөмләләр:

-Нәселемне минем таркатканнар,
Иманлыдан гаеп тапканнар,
Ә бабамны, мулла булган өчен,
Урыс авылында атканнар.

5. Иярчен ия җөмләләр:

Күз алдыма килә:
Горур атлап,
Вуз ишеген атлап керәсең.

6. Иярчен аергыч җөмләләр:

Хәзер инде башка кошлар сайрый
Ул су алган чишмә янында.

7. Иярчен тәмамлык җөмләләр:

Менә берәү җилләр исүенә
Тәрәзәсен ачып куйган да
Өзелеп-өзелеп синең көйне уйный
Чумган килеш тирән уйларга.

8. Иярчен аныклагыч җөмләләр:

-Әлегә кадәр юкка мин үземне
Акыллы дип фараз иткәнмен,
Аксакаллар мәҗлесендә булдым:
Мин шактый ук надан икәнмен.
-Алларында кызгылт ут яна:
Башын иеп, малкай туктала.

И. Юзеевның без тикшергән җыентыкларында 14 төр иярчен җөмләләрнең бары 8 төре генә күзәтелде. Автор иярчен шарт, кире, рәвеш, сәбәп, ия, аергыч, тәмамлык, аныклагыч җөмләләрне бик еш һәм уңышлы кулланыла.

Рус телендә синтетик иярченле кушма җөмләләр юк. Андагы иярчен җөмләләрнең хәбәре һәрвакытта затланышлы формада була, бәйләүче чара хәбәр составында түгел, ә аерым тора. Татар телендә бу җөмләләрне аналитик җөмләләр дип атыйлар. Хәбәре составында бәйләүче чара килмәгәнлектән, аналитик иярчен җөмләнең хәбәре баш җөмләнеке кебек үк тулы, затланышлы формада була. Аналитик чараларга мөнәсәбәтле сүзләр, ияртеүче теркәгечләр һәм көттерү паузасы керә. Мөнәсәбәтле сүзләр – иярчен җөмләләрне алыштырып һәм иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләп килә торган сүзләр. Алар күбесенчә алмашлыклар белән белдереләләр. Башка бәйләүче чаралардан аермалы буларак,

алар бәйләүче чара булып та, җөмләнең аерым бер кисәге булып та киләләр. Мөнәсәбәтле сүзләр парлы һәм ялгызак булалар. Парлы мөнәсәбәтле сүзләрнең бер өлеше - сорау, икенчесе күрсәтү алмашлыгы булып килә. Мәсәлән: кем-шул, кемнән-шунан, кайда-шунда, ничек-шулай. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләргә шуңа, шул, шуны, мондый, шуның өчен, шуңа карамастан, шулай да, алай да кертелә. Ялгызак мөнәсәбәтле сүз вазифасын менә нәрсә, менә шул, бер, аннары, югыйсә, юкса, алайса кебек сүзләр дә башкара ала.

Мөнәсәбәтле сүзгә карап, баш һәм иярчен җөмләләрне аерып була. Күрсәтү алмашлыгы белән белдерелгән мөнәсәбәтле сүз һәрвакыт баш җөмлә составында, сорау алмашлыгы булганы иярчен җөмлә составында килә. Мәсәлән:

1. Күңел тели шуны: иң ахыры
Сүзен эзлим Фатих Кәримнең.
2. Тоям: бу моң килә борынгыдан,
Шаулап-күкрәп миндә тынгандыр...
3. Була шулай: кайчагында
Таштай катып кала җаным... [4, 128 б.].
4. Сизәм ич мин: зур кайгың бар
Эчеңдә... [4, б. 127].

«Икедән артык хәбәрлеге булган җөмлә катлаулы кушма җөмлә дип атала. Аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнеп килгәндә, күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә барлыкка килә, икедән артык җөмлә ияртү юлы белән ияреп килсә, бу күп иярченле катлаулы кушма җөмлә була. Бер җөмләдә җөмләләр тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнеп киләләр, бу җөмлә катнаш кушма җөмлә дип атала» [12, 192 б.]. Мәсәлән:

1. Йомшак җилләр булып исәрмен дә
Тәрәзәңне килеп кагармын,
Мин кагармын, син качарсың, -
Йөрәгемә утлар ягармын.

«Күп тезмәле катнаш кушма җөмләләрдә икедән артык аерым җөмләләр төзүле бәйләнешне белдерүче чаралар – тезүче теркәгечләр, санау яисә каршы кую интонациясе ярдәмендә бер-берсенә бәйләнеп киләләр» [3, 378 б.].

- Әллә урман, әллә болыт,
Әллә рәсем, әллә чын.
- Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман,
Күңелем эзли сине, табалмый [4, 277 б.].

«Бер баш җөмләгә ике яки икедән артык җөмлә ияргәндә, күп иярченле катнаш кушма җөмлә барлыкка килә» [3, 379 б.].

- Юк, мин яши алмыйм алай:
Әзер утлар табып,
Җил кай якка иссә,
Шунда таба авып [4, 55 б.].
- Сау булыгыз,
Минем төсем итеп, сөйгәнемнең
Йөрер юлын бизәп торыгыз,
Җырлый-җырлый эшкә барган чакта,
Кара толымнарын үбегез! [4, 16 б.].
- «Тегеләй ит, болай ит!» дип,
Шайтаным котыртса да,
Кайвакытта төп башына
Шактый нык утыртса да,
«Азмыштан узмыш юк» диеп,
Аздырса да, кызмадым [4, 341 б.].

И. Юзеев шигырьләрендә гади җөенке, эмоциональ яктан бай җөмләләр күбрәк очрый, әмма катлаулы кушма җөмләләрне дә ул бик уңышлы куллана. Илдар Юзеевның шигырьләрен уку, аңлау һәм текст анализлау күнекмәләрен үстерү өчен татар теле дәресләрендә кулланыла ала. Аның хезмәте татар әдәбиятының искиткеч үрнәге булып тора һәм укучыларга татар халкының теле һәм мәдәнияте атмосферасына чумырга мөмкинлек бирә. Юзеев әсәрләрен өйрәнеп, укучылар сүз байлыгын киңәйтә, язу күнекмәләрен күтәрә һәм үзләрен төгәл һәм иҗади итеп татар телендә белдерергә өйрәнә ала. Татар теле һәм әдәбияты дәресләре бергә уздырылган очракта язучының иҗаты белән бергә җөмләләрне тикшерү һәм аларның тексттагы стилистик ролен билгеләү уңышлы алымнарның берсе булырга мөмкин.

**Список литературы**

1. Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан; Мәгариф, 2002. – 199 б.
2. Поварисов С.Ш. Сүз һәм сәнгатьле сөйләм. – Уфа: Китап, 1997. – 166 б.
3. Татар грамматикасы. 3 томда. – Т.III. – Москва: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 510 б.
4. Юзеев И. Мәхәббәт китабы. Шигырьләр, җырлар, поэмалар. Шигырь китапханәсе. Ринат Мөхәммәдиев кереш сүзе. – Татар. кит. нәшр., 1988 – 352 б.

© Фахртдинова А.А., Гайнуллина Г.У., 2025

УДК 1751

**Хазраткулова А.В.,**
*доцент кафедры узбекского и иностранных языков*
*Джизакского политехнического института,*
*г. Джизак, Узбекистан*

## КЛАССИФИКАЦИЯ ПАРЕМИЙ В РУССКОМ И АНГЛИЙСКОМ ЯЗЫКАХ

***Аннотация***. *Цель исследования – проанализировать различные подходы к дефиниции и классификации паремий (пословиц и поговорок) и их лингвокультурные особенности в русском и испанском языках. В статье определено понятие «паремия» и ее виды, изучена проблема характеристики паремий (в русском и испанском языках). Научная новизна заключается в примененном подходе рассмотрения широкого спектра паремиологических единиц, который позволяет установить происхождение паремий, определить их лингвокультурные особенности, коннотации, трансформации. В результате доказано, что изучение паремиологического фонда любого языка позволяет увидеть картину мира носителей данной лингвокультуры, потому что паремии показывают, как в данном языке отражаются различные исторические, культурологические, религиозные и т.д. явления и процессы.*

***Ключевые слова****: паремия; паремиология; лингвокультура; языковая картина мира.*

Актуальность исследования паремий объясняется тем, что, несмотря на большое количество работ по данному вопросу, до сих пор не существует единого определения и классификации паремий, также лингвисты расходятся в вопросе о том, к какой области относится паремия. Безусловно, паремия рассматривается как часть фольклора. В последнее время многие отечественные лингвисты также вносят ее в состав фразеологии (А. В. Кунина), некоторые исследователи (В.Н. Телия, Н.Н. Амосова, А.М. Бабкин) выступают против отнесения паремии к этому разделу лингвистики (Шайхуллин, Зарипова, 2017).

Кроме того, тема паремии является важной и актуальной, потому что пословицы и поговорки отражают видение народом, объединенным общей культурой, картины мира, его отношение к различным явлениям и проблемам, обобщают в единое целое и образно

оформляют мысли народа по разным вопросам (Рыбникова, 1961). Поэтому изучение паремий имеет непосредственную связь с изучением культуры, истории, языковой картины мира народа.

Интерес к исследованию паремий сформировался в 70-е гг. XX века после большого перерыва из-за утери термином своего исконного значения, связанного с религиозными текстами, и признания этого значения архаичным. Проблема определения и классификации различных устойчивых выражений, таких как поговорки, фразеологизмы и т.д., активно разрабатывалась в лингвистике в 60-80-х годах в работах В.В. Виноградова, В.Л. Архангельского, А.М. Бабкина, Б.А. Ларина, М.М. Копыленко, З.Д. Поповой, А.И. Федорова, С.Г. Гаврина, Л.И. Ройзензона, В.П. Жукова, Н.М. Шанского, А.М. Эмировой и других (Антонова, Бредис, Владимирова и др., 2020). Самыми выдающимися отечественными паремиологами являются Г. Л. Пермяков, С.Д. Мастепанов, В.М. Мокиенко, М.А. Черкасский. В 70-х гг. стали появляться первые дефиниции термина в актуальном значении. В последние годы было написано множество работ, посвященных именно определению термина «паремия» (Шайхуллин, Зарипова, 2017).

Пословицы и поговорки ученые и исследователи относят к паремиям, которые изучает и классифицирует такой раздел филологии, как паремиология (Шайхуллин, Зарипова, 2017). На данный момент уже имеется множество исследований в данной научной области, однако не существует единого точного определения понятия «паремия».

Для достижения цели исследования были поставлены следующие задачи: – определить понятие «паремия»; – сопоставить основные единицы паремиологии в русском (понятия «пословица» и «поговорка») и испанском («refrán», «dicho», «proverbio») языках. Основными методами исследования стали следующие: метод описания, сравнения, классификации, метод анализа и синтеза теоретического материала. Теоретической базой послужили работы в области фразеологии (Пермяков, 1970; Даль, 1989), в области паремиологии (Черкасский, 1978; Антонова, Бредис, Владимирова и др., 2020; Леднева, 2015; Мартынова, Митрофанова, 1986; Матвеева, Серегина, 2009; Меньшакова, 2020; Рыбникова, 1961; Соболев, 1983; Тарланов, 1999; Шайхуллин, Зарипова, 2017; Rodríguez Manzano, 2014; Zarate, 1999), в области имен собственных (Суперанская, 2007; Сызранова, 2013; Подольская, 1988), в области изучения агионимов (Бугаева, 2007; Лаврентьева, 2017; Коренева, 2013; Iglesias Ovejero, 1982).

Практическую значимость настоящей работы определяет возможность применения ее материалов и результатов при подготовке и проведении лекционных и семинарских занятий по курсам «Языкознание», «Лексикология», «Практика устной и письменной речи», «Стилистика», а также в рамках спецкурсов «Фразеология», «Ономастика», «Антропонимика», «История и теория фольклора». Основная часть Пословицы и поговорки ученые и исследователи относят к паремиям, которые изучает и классифицирует такой раздел филологии, как паремиология (Шайхуллин, Зарипова, 2017). На данный момент уже имеется множество исследований в данной научной области, однако не существует единого точного определения понятия «паремия». Рассмотрим этимологию понятия для более точного понимания его сущности. Слово «паремия» происходит от греческого «paroemia» и означает «притча».

По библиологической версии возникновения слова, изначально оно обозначало отрывок притчи из религиозных текстов в христианстве (Мень, 2002). Притча носит иносказательный характер и заключает в себе мораль, нравственное наставление. В начале прошлого столетия слово утратило свое исконное значение и сейчас является филологическим, а точнее фразеологическим термином (Шайхуллин, Зарипова, 2017). Необходимо рассмотреть, какие дефиниции дают лингвисты понятию «паремия». М. А. Черкасский (1978) определяет паремию как «минимальную единицу надъязыкового семиотического яруса, обладающую свойствами клишированности, афористичности и сентенциозности» (с. 36).

Согласно определению, данному Г. Г. Матвеевой и М. А. Серегиной (2009), «паремии – это одна из подсистем языка синтаксического уровня, представленная в виде полного или незаконченного предложения, обладающего лаконичностью и ритмичностью. Для них характерны устойчивость в языке и воспроизводимость в речи, частичное или полное переосмысление, а также семантическая многозначность. Они общеизвестны, широко используются народом, употребляются в дидактических целях, являются единицами осознаваемого выбора в зависимости от речевой ситуации, что делает их прагматически многозначными. К ним относятся пословицы, поговорки и пословично-поговорочные комплексы» (с. 178). Таким образом, несмотря на то, что слово «паремия» в своем исконном значении больше не употребляется и было признано архаичным, семантика слова сохранила поучительный, назидательный характер. Все исследователи паремиологии относят пословицы и поговорки к паремиям. Некоторые ученые, как, например, русский этнограф, фольклорист, писатель В. И. Даль (1989), считают, что кроме пословиц и поговорок к паремиям относятся и афоризмы. В. И. Даль относил к паремиям только те афоризмы, которые переходили в широкое употребление и передавались от поколения к поколению. Ученый-паремиолог, фольклорист Г.Л. Пермяков (1970) кроме всего вышеперечисленного также относил к паремиям сказки, басни, анекдоты.

Таким образом, среди ученых и исследователей нет единой конкретной дефиниции паремии и общепринятого мнения насчет их классификации, однако на основе толкования понятия различными исследователями можем сделать вывод о том, что в основном паремии представлены пословицами и поговорками. Необходимо разграничить эти два понятия. Согласно словарному определению, пословица – «образное выражение, созданное народом и передаваемое из поколения в поколение в устной форме, выражающее законченное суждение, поучение, применяемое ко множеству сходных ситуаций, имеющее иносказательный смысл» (Жеребило, 2010, с. 271). По сборнику пословиц В.И. Даля (1989), пословица – это «коротенькая притча, поучение, понятное и принятое всеми, высказанное обиняком, то есть иносказательно» (с. 14). По мнению З.К. Тарланова (1999), пословица существует только в форме предложения, не делится на меньшие части, выражает одно или несколько суждений.

Также пословицу нельзя распознать, заменив слова синонимами. Пословица отражает жизненный опыт народа и представляет его в виде неких правил.

Сравнительно-историческое, типологическое и сопоставительное языкознание примеры русских пословиц: «дорога ложка к обеду», «готовь сани летом, а телегу зимой» и т.д. Они являются неизменяемыми законченными суждениями, в которых заложен определенный смысл, поучение. Теперь приведем дефиницию понятия «поговорка».

Если снова обратиться к Лингвистическому словарю, найдется следующее определение: поговорка – это «образное выражение, созданное народом и передаваемое из поколения в поколение в устной форме, не представляющее собой законченного суждения. Это, как правило, образное сравнение, эмоционально окрашенное» (Жеребило, 2010, с. 265). Согласно В.И. Далю (1989), поговорка – это просто метафора без суждения и утверждения, только элемент пословицы.

Поговорками являются, например, следующие выражения: «собаку съел», «ума палата», «заблудиться в трех соснах». Они не представляют завершенных суждений, это лишь метафоры, которые могут являться элементом предложения или пословицы. Далее необходимо выделить общие черты данных видов паремии. Оба понятия означают образное выражение, не имеющее конкретного автора, следовательно, относящееся к фольклору, передающееся от поколения к поколению изустно. И пословица, и поговорка носят образный, метафоричный, иносказательный характер. Это значит, что пословицы и поговорки для извлечения заложенного значения нужно рассматривать не в прямом, а в переносном смысле.

Рассмотрим разницу данных понятий. Согласно А.Н. Мартыновой и В.В. Митрофановой (1986), пословица представляет собой законченную мысль, завершенное предложение, а поговорка – это лишь образная, метафоричная часть суждения. Принимая во внимание данную мысль и вышеприведенные определения, можно заключить, что различие

между этими двумя понятиями с точки зрения грамматики состоит в том, что пословица является законченным суждением, а поговорка – это лишь его элемент и не является предложением. Как считает Ф.М. Селиванов (Соболев, 1983), эти два вида паремии различаются своей грамматической и логической формой. Пословицы имеют форму законченного предложения, представляют собой синтаксическое целое и используются только в готовом виде, не изменяются. Поговорки не имеют такой законченной формы, они приобретают ее только в конкретной ситуации устного или письменного общения. Также пословица носит дидактический, назидательный характер, содержит в себе поучение, нравственный урок, передаваемый с помощью иносказания, метафоры. Она утверждает что-либо, проверенное на опыте поколений («один в поле не воин», «не мил и свет, когда друга нет»).

Поговорка – это лишь образное, гиперболичное, яркое сравнение, окрашенное эмоционально. Поговорки наполняют речь образами, помогают человеку в иносказательной форме оценить какие-либо события или явления (Рыбникова, 1961) («здоровый как бык», «свалиться как на снег на голову»).

Стоит отметить, что эти три пары единиц языка и в испанском, и в русском можно отнести к паремиям, так как некоторые отечественные ученые, в том числе В.И. Даль (1989), относили к паремиям не только пословицы и поговорки, но и афоризмы, если они переходили в общее употребление. Пословицы и поговорки, относящиеся к паремиям, являются «языковыми единицами, закрепившими опыт познания мира народом» (Леднева, 2015, с. 3). Паремии являются неотъемлемой частью любого языка. Безусловно, в языке всегда находят отражение менталитет, культура народа, его картина мира. Паремии очень важны не только с точки зрения лингвистики, но и с точки зрения истории и культуры, так как особенно ярко и четко менталитет народа, его культура, история, традиции и обычаи отражаются в пословицах и поговорках. Это происходит благодаря тому, что они имеют многовековую историю и, хоть и в образной, метафоричной форме, выражают важные идеи и мысли, актуальные для всего народа на данный конкретный период времени, хранят в себе народные наблюдения, представления о мире, сведения о жизни народа. Поэтому с этой точки зрения паремии отражают социально-исторический опыт народа, то, с чем ему пришлось столкнуться за всю свою историю, таким образом давая знания и уроки настоящему и следующему поколениям, отражают то, как данный народ видит окружающий мир. Заключение В современной лингвистике понятие паремия трактуется как единица языка, обладающая чертами лаконичности, афористичности, общеупотребительная и носящая дидактический характер. К паремиям принято относить пословицы и поговорки, однако некоторые филологи и исследователи относят к ним еще афоризмы, сказки, басни (носители фольклора). В испанском языке основными единицами паремиологии являются понятия «dicho», «refrán», «proverbio». Под пословицей в русском языке понимают законченное умозаключение с использованием иносказания, иногда с рифмой, носящее устный общеупотребительный характер и содержащее поучение, наставление. «Поговорка» означает образное выражение, метафору, которая может быть элементом, частью пословицы. В испанском языке понятия «refrán» и «dicho» можно соотнести с пословицей и поговоркой соответственно, на основе схожести их характеристик. «Refrán» представляет собой завершенное суждение, носящее поучительный характер, а «dicho» – меткое выражение, сравнение на основе метафоры. В испанском языке к паремиям относится также понятие «proverbio», которое можно сопоставить с афоризмом, так как это законченная мысль, носящая поучительный характер и изначально принадлежащая известному человеку или мудрецу, а затем перешедшая в общее употребление. Изучение паремиологического фонда любого языка позволяет увидеть картину мира носителей данной лингвокультуры, потому что паремии показывают, как в данном языке отражаются различные исторические, культурологические, религиозные и др. явления и процессы. Паремиологический фонд аккумулирует данные о жизни, истории и культуре народа. Перспективы дальнейшего исследования состоят в возможности изучения комплекса паремиологических источников в

русской и испанской лингвокультурах, в том числе методом сопоставления и сравнительноисторического анализа. Исследование паремий дополняет целостность языковой картины мира.

**Список литературы**

1. Антонова Е.Н., Бредис М.А., Владимирова Т.Е., Гишкаева Л.Н., Иванов Е.Е., Зиновьева Е.И., Комова Д.Д., Ломакина О.В., Макарова А.С., Мокиенко В.М., Нелюбова Н.Ю., Николаева Е.К., Селиверстова Е.И., Семененко Н.Н., Фаткуллина Ф.Г., Хайруллина Р.Х., Цао Ц. Паремиология без границ: монография / под ред. М.А. Бредиса, О.В. Ломакиной. – М.: Изд-во РУДН, 2020.

2. Бугаева И.В. Агионимы в православной среде: структурно-семантический анализ: монография. – М., 2007.

3. Даль В.И. Пословицы русского народа: сборник: в 2-х т. – М.: Художественная литература, 1989. Т. 1.

4. Жеребило Т.В. Словарь лингвистических терминов. Изд-е 5-е, испр. и доп. – Назрань: Пилигрим, 2010.

5. Коренева Ю.В. Онимы в концептосфере преподобнического жития // Вестник Московского государственного областного университета. Серия «Русская филология». – 2013. – № 3.

© Хазраткулова А.В., 2025

УДК 811.512.145

**Халикова А.Т.,**
*магистрант 3 г. о. Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель –* **Зарипова И.Ф.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЭВФЕМИЗМНАРНЫҢ СТИЛИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
(М. Мәһдиев әсәрләре материалында)

***Аннотация.*** *Мәкаләдә М. Мәһдиев әсәрләре материалында татар телендәге эвфемизмнарның стилистик үзенчәлекләре карала, аларның табигате, барлыкка килү сәбәпләре тасвирлана, эвфемизмнарның максатлары ачыклана. Автор эвфемизмнарның төрле сурәтләү чараларына туры килүче мисалларны тасвирлый.*

***Терәк сүзләр:*** *татар теле, когнитив лингвистика, М. Мәһдиев, эвфемизация, эвфемизм, табу, этикет.*

Кешелек тарихының иҗтимагый аң үсеше түбән булган чорларда сүзнең тылсымлы көченә ышанудан барлыкка килгән табу күренеше әйтергә ярамаган сүзләрне алыштыру өчен әйтергә яраганнарын эзләргә мәҗбүр иткән. Шулай итеп табулашкан сүзләр урынына эвфемизмнар (грек. euphemismos < eu – әдәпле, яхшы + phemio – сөйлим) барлыкка килгән [3, 288 б.]. Тел белемендә турыдан-туры әйтүе уңайсыз, әдәпсез, тупас килеп чыгу ихтималы булган сүзләрне алыштыра торган сүз, тәгъбирләрне эвфемизм дип атыйлар [4, 407].

Хәзерге тел эвфемизмнарының тамырлары ерак гасырларга кайтып кала. Лингвистик планда аларны 19нчы гасырда өйрәнә башлыйлар. 19нчы гасыр ахырында немец лингвисты Г. Пауль беренчеләрдән булып эвфемизмнарны аерып чыгара. Эвфемизация мәсьәләсе бигрәк тә узган гасырның 60-80 елларында популярлык ала. Бу чорда С. Видлак, Дж. Лоуренсның эшләре басыла. Тагын да Русиядә А.М. Кацев, В.И. Шувалов, Н.М. Бердяев һ.б.ларның диссертация эшләре яклана. Эвфемизмнарны төрле телләр материаллары нигезендә Дж. Уильямс, И.Р. Гальперин, В.Н. Телия кебек галимнәр өйрәнә [2, 37 б.].

Телче галимнәр эвфемизмга төрлечә билгеләмә бирә. Мәсәлән, Х. Фаулер (1957): «Тупас сөйләмне әдәпле, йомшак тәгъбир белән алмаштыру», – дип аңлата. Ч. Кейни (1960) фикеренчә, «эвфемизм – ул күңелгә ятышсыз, хурлыклы я курку уята торган сүзләрне башка йомшаграк термин белән алыштыру ысулы». И.Р. Гальперин (1981) эвфемизмны «уңайсыз әйтү ихтималы булганда кулланыла торган сүз яки сүзтезмә» дип билгели. Дж. Лоуренс (1973) эвфемизмга «тупас сөйләшүне йомшак итеп белдергән сүз формалары» дип аңлатма бирә [1, 37 б.]. Бу билгеләмәләрдән күренүенчә, эвфемизмнар синонимнарның бер төрен тәшкил итә.

Лингвистик әдәбият кысаларында эвфемизмнарның белдерелеше, классификацияләренә караган фикерләрне икегә бүлергә мөмкин: 1) кагыйдә буларак, сүзне тел системасындагы лексик-семантик берәмлек буларак карау (Б.А. Ларин, А.М. Кацев, А.С. Куркиев) һәм когнитив лингвистика юнәлешендәге тикшеренүләр (әзер текстлар материалы нигезендә эвфемистик алыштыруларга концептуаль анализ ясау мәсьәләсе белән шөгыльләнү) (Л.П. Крысин, В.И. Заботкина, Н.В. Тишина, В.П. Москвин).

Лингвистик теорияләргә мөрәҗәгать иткәндә, хәзерге җәмгыятьтә һәм мәдәнияттә эвфемизация төшенчәсенең эчтәлеге киңәюне күзәтергә мөмкин, чөнки галимнәр эвфемия феноменын, бөтен булган характеристикаларын күз уңында тотып, киң дәрәҗәдә билгелиләр (Е.П. Сеничкина, М.Н. Потапова). Эвфемизмнарның традицион аңламында, функциональ аспектны ассызыклап, «этик нормаларга ярашлы бизәү яисә әйтергә ярамаганны белдерү чарасы» дип бирелә (А.А. Реформатский). Бу очракта эвфемизация процессы номинация белән бәйле, ягъни кешеләрнең тормыш һәм эшчәнлегенә кагылышлы аерым темалар һәм өлкәләр эвфемизациягә дучар була – моның нәтиҗәсе буларак табу зонасы аерылып чыга.

Күренешләрнең чын мәгънәләрен яшерүче сәяси эвфемизмнар терминнар ярдәмендә ясала. Бу – төгәл мәгънәгә ия булган аудиториянең бер өлешенә таныш, икенчесенә таныш булмаган махсус сүзләр. Яңа мораль телдә һәм мәдәнияттә чагылыш таба. Иң мөһиме – бу терминнар, фәнни авторитетка ия булып, аңга магик тәэсир итә.

Туры итеп әйтмәү һәм тыюны белдерүче сүзләрне ачыклау, билгеләү, тасвирлау өчен критерийлар эзләү актуаль проблемаларның берсе булып тора. Эвфемиянең традицион төшенчәсе күп гасырлар дәвамында бәхәсләр уяткан синонимия белән тыгыз бәйләнгән. Хәзерге вакытта мәгънәләре белән якын булган сүзләр лингвистик әдәбиятта синоним дип билгеләнәләр. Андыйларга мәгънә уртаклыклары нигезендәге лексемаларның барлык диярлек бәйләнешләрен, шул исәптән, перифраз һәм эвфемизмнарны да кертәләр. Сүзләрнең синонимиясе, телдәге закончалыклар белән билгеләнүче тел күренеше буларак, әлеге сүзләрнең нинди предметка караганлыгына бәйле булып чыга. Төрле знаклар системасы шушы системага кермәгән сүзләрне билгеләү өчен кулланыла, һәм бу билгенең мәгънәсе системадан тыш кына ачыла (Д.Н. Шмелев, Ю.Д. Апресян, С.В. Лебедева).

Тел белемендәге тикшеренүләр буенча әлеге феноменны ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренчеләрендә проблематика теоретик аспектта тасвирлана, әмма теоретик фикерләр киң күләмле эмпирик материал белән дәлилләнми. Икенчеләрендә – алар күбесенчә сүзлекләр – киң күләмле эмпирик материал бирелә, ләкин теоретик нигезләрнең ышандырырлык көче аз.

Кешеләрнең сөйләм эшчәнлегендә эвфемизмнарның түбәндәге очракларын билгеләп үтү мөһим: кырыс булган сүзләрне йомшарту, дорфа һәм яман сүзләрне алмаштыру, әдәплелек нормасын бозган тәгъбирләрне алмаштыру; турыдан-туры әйтеп булмаган вакытта; хата яки аңлатманың чын асылын яшерү һәм архаик табулашкан тәгъбирләрне алыштыру. Гомумәдәби телнең бер өлешен тәшкил иткән эвфемизмнар белән беррәттән окказиональ һәм индивидуль-контекстуаль эвфемизмнар да аерыла.

Бер төркем галимнәр фикеренчә, эвфемизмнарның төп максаты – кешенең аңы белән идарә итү, бигрәк тә бу сыйфат сәяси эвфемизмнарга хас.

Бер төрле эвфемизмнарны тану кешеләрдә кыенлык тудырмый, эвфемизацияләүнең чикләре шул дәрәҗәдә җуела: тора-бара алар эвфемистик функция үтәмичә сөйләм нормасы булып китәләр. Икенчеләре – традицион булмаган яисә яңа эвфемизмнар. Эвфемизмнарны

билгеләүнең нигезләре дөнья образына һәм дөнья тел картинасына туры мөнәсәбәттә. Гадәти лексикадан аермалы буларак, эвфемизмнар теге я бу күренешләрнең иҗтимагый бәяләренә сизгер була. Бу эвфемизмнарның статусының телдә һәм сөйләмдә тарихи үзгәрүчәнлеге белән бәйле: бер буында эвфемистик атаулар уңышлы дип саналса, икенчеләрендә эвфемистик алыштыру таләп итүче дорфа сүзләр буларак санала. Эвфемизмнар кеше лексиконында үзгәрүчән, аларның «үз-үзләрен тотышы» «ачкыч» буларак индивидның дөнья образы фрагменты үзенчәлекләре белән билгеләнә. Шулай итеп, җәмгыятьнең үсеше белән эвфемизмнарның референт өлкәсе дә киңәя.

Хәзерге лингвистик әдәбиятта эвфемизмнарның интерпретациясе кешенең яшәеш даирәләре, нинди мотивлар буенча вуальләштерүгә дучар булулары, нинди вербаль чараларның мөһим функция үтәүләренә бәйле.

Эвфемизация феномены объектив факторлардан тыш, «тере» телдә семантик алыштыру үзенчәлекләрен тикшерүнең аерым методларын таләп итүче субъективизмның да әһәмиятле өлешен күз алдында тота.

Эвфемизмнар еш кына сөйләм этикеты чагылышы буларак кулланыла. Кешеләр әңгәмәдәштә уңайсызлык хисе тудырмаска омтыла. Эвфемизация ярдәмендә сөйләмдә, хәтта принципиаль рәвештә вербализацияләнмәгән темаларны да вербализацияләргә мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә, А.М. Кацев эвфемиянең бер-берсе белән үзара бәйле берничә аспектын аерып күрсәтә:

– социаль аспект (әхлакый, дини һәм сәяси мотивлар белән бәйле булган эвфемизмнар);

– психологик аспект (эвфемистик алмаштыруга бәйле әйтелешне йомшарту эффекты). Тыелган төшенчәне читләтеп билгеләү кешедә тискәре хис-кичерешләр тудырмый, мәсәлән, курку, оят, җирәнү, ачу һ.б.);

– лингвистик аспект (эвфемизмнарның билгеләре һәм шартлары ачыклана) [1, 25].

Эвфемизациянең максатлары һәм кулланылыш өлкәләре төрле булырга мөмкин.

Һәр милли әдәби телнең үз эвфемизмнар байлыгы бар. Алар халыкның иҗат казанышы булып исәпләнә. Шуларга карап, теге яки бу чорда халык теленең, әдәби телнең торышын, үсеш дәрәҗәсен билгеләп була. Беренче карашка берничә аерым кисәкләрдән торган, ләкин бер мәгънә белдерүче, тел байлыгының әһәмиятле күрсәткече булган сөйләүченең үз фикере белән бәйле эмоциональ бәя бирүче бу берәмлекләрне өйрәнү, аларга дөрес бәя бирү, бу байлыкны сөйләм телен үстерү максатыннан җәмгыятькә җиткерү – гаять әһәмиятле эш.

Эвфемизмнар – татар теле өчен хас күренеш. Алар көчле тәэсир итә торган сүзләрнең йогынтысын азмы-күпме йомшартып, аларны ятышлы, әдәпле яңгырашлы итәләр. Эвфемизмнарның стилистик үзенчәлекләрен, белдерелеш үзенчәлекләрен анализлау өчен М.Мәһдиев әсәрләренә мөрәҗәгать итик. Автор әсәрләрендә эвфемизмнарның еш кулланылуы – аның язу стиленең үзенчәлекле бер ягы.

Эвфемизмнарны белдерелеш үзенчәлекләре буенча берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин Мәсәлән:

1) Метафора белән белдерелгән эвфемизмнар: *Сигез тапкыр ияген тимергә тидерәм дип бәхәсләшеп менсә, аңа әлеге дә баягы үзенең* ***төп байлыгы*** *комачаулады: аның кыстырып куйган күлмәк итәкләре суырылып чыккан, чалбар каешы шактый түбән төшкән иде («Б.-41ел б.»); Сәгать икедә ашханәдә берәр савыт* ***өшегән кәбестә шулпасы*** *бирелә («Б. – 41 ел б.»); Бәлки бу* ***ватык арбаны*** *бераз рәтләп җибәрер ул («К.к. – җ.к.»); Ләкин класста балаларны күреп булмаслык* ***тузан болыты*** *иде («Ф.»);*

2) Чагыштырулар белән белдерелгән эвфемизмнар: *Йөрәк* ***ватык тегермән шикелле*** *кинәт кенә дулап ала да яңадан рәткә керә («К.к.»);*

3) Метонимия белән белдерелгән эвфемизмнар: *Менә син, туганкай, зур урындыкка утыргансың, ләкин бит үз тирәңә ярдәмчеләр итеп гел* ***йомшакларны****, булдыксызларны җыясың («Б.»); Аның каравы әнә – бөтен дөньяга исеме танылган балерина йоклый алмыйча ята: аның балалар бакчасына йөри торган малае эчем авырта дип кич белән әллә ничә*

*тапкыр* ***чүлмәккә утырды*** *(«Ф.»); Ул инде күптән* ***агачлыкка кайтып китте*** *(«К.к.»); Менә син, туганкай,* ***зур урындыкка утыргансың****, ләкин бит үз тирәңә ярдәмчеләр итеп гел йомшакларны, булдыксызлыларны җыясың («Б.»); Зур солдат фурашкасы күзенә үк төшкән,* ***борын аслары юеш****, балчыкка каткан тез башлары, чебиләнгән тәпиләр («К.к. – җ.к.»).*

4) Мейозис белән белдерелгән эвфемизмнар: *Менә гадәттән тыш зур энергияне сарыф итеп Былбылниса үзенең Хәкимҗанын саклый, гармунын кулына да алдырмый, чөнки белә – бераз төшереп алса, Хәкимҗанның* ***авызы ыргакларыннан ычкынып китә****, күзләре майлана һәм ул гармунын күтәреп хатын-кызларның авызы янына килеп аерым-аерым җырлатып йөрергә ярата («Ф.»); Ибруш малае Миңнулла – хатыны белән бозылышып, дилбегәсе койрык астына кереп йөргән көннәр иде –* ***җиңел баштан*** *өйгә үк килеп керде («К.к.»); Шмагин буйга да кечерәк,* ***белеме дә ремесленныйдан узмаган*** *(«К.к.»); Хатын белән расчет. Бик эт халык булып чыкты ул, малай.* ***Уҗымга йөрде*** *(«Ф.»); Бәлеш чыккач,* ***«бәлеш астына калдырыйк»*** *дип, тагын берәүне әдәп белән генә* ***төшерделәр*** *(«К.к.»); Хәтта тарихчыга да* ***чыбыркы очын шартлата*** *Әлтафи («Б. – 41ел б.»); Гата аның янына килеп русча эндәште. Аннан «без дә төшеп калганнардан түгел» дигән сыман* ***бер-ике фразаны немецча да сипте*** *(«Ф.»); ...Теге, яшь курсант вакытында,* ***«чәчәк аткан»*** *винтовкасын тотып полковник каршында дәшмичә торганда, карт офицер аңа болай дигән иде <...> («Ф.»); Чирәмгә чыгарып салгач, Гыйззәтуллинынның иң беренче эше – сеанс алдаыннан алып ашаган* ***сигез порция мороженоедан һәм әлеге инфузорияләрдән арыну булды*** *(«Б.-41ел б.»);*

4) Прономинализация аша белдерелгән эвфемизмнар: *Гөлчирәнең утыруы утыру түгел, чөнки бер төшереп алса, Сабир мәҗлестә хатын-кызлар белән бии башлый, каршысына чакырып алҗыта, өстерәп-суырып ала, чүгә-чүгә биегән вакытта, кызып китеп, хатын-кызның* ***теге төшенә*** *дә,* ***бу төшенә*** *дә кул сала («Ф.»); Әмма инде* ***андый җирләргә*** *үрелергә теләсә кемгә рөхсәт юк! Сез, кешеләрдә, бәлки* ***ул җиргә*** *шулай үрелгәләргә ярыйсыдыр, әмма менә бездә – сыер халкында – тәртип шулай («Ф.»); Бераздан* ***аны да*** *салганбыз – менә булдымы өченче ярты («К.к.»);* ***Теге елларда*** *мин чабата идемме? («Б.»);*

6) Перифраз белән белдерелгән эвфемизмнар: *Бөтен булган аермасы – фамилисендә һәм* ***... су коенганда гына күренә*** *(«Б.-41 ел б.»); Цепьнең иң кырыендагы бер малай, окобын казып бетергәч, бияләйләрен кар өстенә ташлаган да, чалбар төймәсен чишеп, кар өстенә* ***фамилиясен язып маташа*** *<...> Шуңа күрә имза бераз түгәрәгрәк булып чыкты («Ф.»); Инде мин үземнең* ***ялгышлыгымны*** *һәм сиңа күпме хәсрәт чиктергәнемне* ***аңладым*** *(«Ф.»); Төнге сменада ялгыз калып эшләгәндә Хәернисаны* ***харап иткәннәр*** *(«Б.»); Әнә шул* ***яман тавышларның*** *теге ягында ниндидер икенче төрле дәртле тавышлы тормыш бар иде бугай («К.к. – җ.к.»); Карт мичман* ***әшәке сүз*** *әйтеп төкерде (Ф.»);*

7) Синекдоха ярдәмендә белдерелгән эвфемизмнар: *Ә бер айдан авылга хәбәр килде:* ***тупый бүрек*** *яман кеше икән, элекке хатынын да газаплап үтергән икән, хатын-кызны санга сукмый икән («К.к.»); Менә хикмәт – шул кешене бервакыт кинәт кенә күтәрәләр,* ***урындыклы*** *итәләр («Урындагы кеше – шуннан алынган») («Б.»);* ***«А ля»*** *Нәркисне харап итте бугай, башта ул мәһабәт кенә итеп биеде <...> («Ф.»); Әскәрев якасыннан тотып өстерәп чыгарылган һәм класс ишеге янында, каршылык күрсәткәч,* ***артына*** *тез белән типкәннәр («Ф.»); И-и, ирләргә ышансаң, аларга* ***таза тән*** *генә булсын («К.к.»).*

8) Фразеологизм белән белдерелгән эвфемизмнар: *Коммендант Стессель хыянәт итмәсә, без* ***арт сабакларын укыта*** *идек ул макакаларга («Ф.»);* ***Малай тәпие юабыз*** *дип, беренче көннәрдә ир-ат кергәләп чыкты («К.к.»); Миңнулла кызмача хәлдә* ***тел ачты*** *(«К.к.»); Фәләхетдин салкын декабрь көнендә үз өендә, хатыны һәм балалары янында утырганда* ***җан биргән*** *(«Б.»); ...Бибиәсма җиңги* ***үлем түшәгенә яткач****, Фәхрислам, ничектер, йомыш белән кергән иде («К.к.»); Председатель кеше бервакытта да* ***башын ватмый*** *(«К.к. – җ.к.»); Монысына инде Хәмит үзе дә көч куйды,* ***акылын җикте*** *(«Б.»); Әти белән аларның* ***борчаклары бик пешеп җитми****, син күз-колак бул («К.к. – җ.к.»); Әнә сез нәкъ шуңа күрә дә ярлы булгансыз инде, – дип белемле председатель Шәйдулланы* ***төп***

***башына утырта*** *(«К.к.»); Семья шулай итеп* ***суга төшкән балта кебек*** *юк булды («Ф.»); Сугыш җирендә үлеп калган якын кардәшләрегезнең – барчасының* ***туфраклары җиңел булсын*** *<...> («Ф.»); Авыл советы катнашы белән төзелгән бу семьяда нәкъ өч айдан соң тап-таза бер малай* ***дөньяга килде*** *(«К.к.»);* ***Авызым бер тапкыр пеште*** *<...> («К.к.»).*

9) Чит тел сүзләрен куллану очраклары: *Ә син инде теге* ***«черная туча»*** *буласыңмы? Шундый бер егет бар дигәннәр иде мәктәптә? («Ф.»); Иң чибәрләренә* ***«f.off.»****, уртачаларына* ***«f.soll.»****дип язылган; Болары,- диде Рушад елмаеп торган гүзәлләрне күрсәтеп,-»фюр офицерлерен»- офицер сөяркәләре, ә тегеләре – «фюр зольдатен» – солдатлар өчен («Ф.»).*

Барлык вакыйгаларның юморга төрелеп бирелүе әсәрнең җәлеп итү көчен тагын да арттыра. Бу текстларны кат-кат укыйсы, язучынының җанлы итеп биргән образлары белән бер утырып сөйләшәсе, алар арасында кайнашасы килә. Башка тел-стиль сурәтләү чаралары белән беррәттән, эвфемизмнарны оста һәм уңышлы файдалану аркасында да әсәрләр зур уңышка ия дигән фикердәбез.

Димәк, эвфемизмнар лексиканың иң борынгы катламына керәләр һәм борынгы кешеләрнең сөйләмендә үк табигать көчләреннән курку тәэсирендә барлыкка киләләр, бу исә эвфемизмнар белән алыштырыла торган билгеле бер сүзләрне куллануга табу тудыра. Аларга кешеләрнең һәм төрле хайваннарның исемнәрен, авыруларны, үлемне, табигать күренешләрен белдерүче эвфемизмнар керә.

Кешенең социальләшүе һәм җәмгыятьтә яшәве эвфемизмнарның башка төрләрен барлыкка китерүгә дә этәрә, аларны этикет дип атарга мөмкин. Бу өлкәдә эвфемизмнар кешенең тышкы кыяфәтен һәм халәтен, кешеләрнең кимчелекләрен һәм әйтергә ярамаган сүзләрне тасвирлау өчен файдаланыла.

Когнитив лингвистика яссылыгыннан караганда, эвфемизмнарны тел системасының яшерен мәгънә чагылышлары буларак билгеләргә мөмкин. Алар яшерен мәгънәгә ия һәм әдәпсез сүзләрне һәм әйтелмәләрне социумда кабул ителгән сүзләргә алыштыру өчен, шулай ук башкалар алдында әдәплелек күрсәтү өчен кулланыла.

**Кулланылган әдәбият**

1. Кацев А.М. Языковое табу и эвфемия / А.М. Кацев. – Л., 2005. – 25 б.
2. Паращенко Ю.В. Явление эвфемии в русском и английском языках. – Барнаул, 2009. – 37 б.
3. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары өчен). – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Т. 3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 407 б.

© Халикова А.Т., 2025

УДК 821.512.145

**Халиуллина А.Г.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## АЙГИЗ БАЙМӨХӘММӘТОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КОНФЛИКТ ҺӘМ ГЕРОЙЛАР

***Аннотация****. Мәкалә танылган башкорт язучысы Айгиз Баймөхәммәтов иҗатына анализ ясауга багышланган. Тикшеренүнең төп предметы – «Калдырма, әнкәй!», «Кошка әйләнермен мин», «Әкиятсез балачак», «Алдакчы» һәм «Урын» әсәрләрендәге конфликтның сәнгатьчә чагылышы һәм чишелеше. Автор әсәрләрдә әхлакый-этик һәм социаль проблемаларның куелыш үзенчәлеген карый, шул исәптән ятимлек, гаилә бәйләнешләренең таркалуы һәм шәхеснең рухи деградациясе темасын да игътибар үзәгенә ала. Психологик яктан тулы характерлар тудыруда, милли-мәдәни детальләрне куллануда һәм полифоник хикәяләү төзүдә әдипнең осталыгына аерым игътибар бирелә.*

***Терәк сүзләр:*** *Айгиз Баймөхәммәтов, башкорт әдәбияты, конфликт, сәнгать образы, персонаж, ятимлек, гаилә кыйммәтләре, әхлак, сәнгать детале.*

Айгиз Баймөхәммәтов – язучы, журналист, Россиянең һәм Башкортстанның язучылар (2014) һәм журналистлар (2008) берлекләре әгъзасы, Шәехзадә Бабич исемендәге Башкортстан Дәүләт республика яшьләр премиясе лауреаты (2015). Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (2020). Башкортстан Язучылар берлеге рәисе (2022 елдан), Башкортстан Республикасының Салават Юлаев исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2025).

Айгиз Гыйззәт улы Баймөхәммәтов 1988 елның 27 октябрендә Башкортостан Республикасының Белорет районы Абзак авылында күп балалы гаиләдә туа. Иртә ятим калып, Сермән балалар йортында тәрбияләнә. Башкорт дәүләт университетының башкорт филологиясе һәм журналистика факультетын тәмамлый. Аның әсәрләре республиканың барлык басмаларында да даими басылып тора.

Әдәби барышка ятимлек темасын үзәккә алган «Калдырма, әнкәй» (2016) повесте белән килеп, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, гаилә кыйммәтләрен, яшәеш кануннарын ачыклаган башка чәчмә әсәрләре белән дә үзенә игътибарны җәлеп итте. Моңа кадәр әдәбиятта балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең бәхетсез, ә кайбер очракта өметле язмышы совет чорында билгеле педагог һәм язучы А. Макаренко «Педагогическая поэма» (1925-1935), А. Рекемчукның «Мальчики» (1970), А. Приставкин «Ночевала тучка золотая» (1981), соңрак А. Семёновның «Поминай как звали» (1999), А. Лихановның «Никто» (2000), Ф. Яруллинның «Яралы язмышлар» (1999), М. Петросянның «Дом, в котором…» (2009) һ.б. әсәрләре аша укучыларга таныш булса да, А. Баймөхәммәтов прозасы үзенең ихласлыгы белән укучыларны битараф калдырмады.

Язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе Айгиз Баймөхәммәтов башкорт әдәбиятын дөньякүләм танытуда да актив эш алып баруы, әсәрләренең бихисап телләргә тәрҗемә ителеп бастырылуы, театр һәм кино жанрына да күчүе сурәтләнгән вакыйгаларның драматик һәм ышандыргыч булуын тагын бер кат исбатлый.

А. Баймөхәммәтов әсәрләре татар газета-журналларында да еш басыла. Татар телендә «Калдырма, әнкәй!» (2018) [3], «Әкиятсез балачак» (2019) [2], «Нахак» (2021) [4], «Кошка әйләнермен мин» (2024) [7] исемле китаплары дөнья күрде.

Айгиз Баймөхәммәтов прозасының төп үзенчәлеге – вакыйгаларның тормышчанлыгында, әдәби материал нигезендә дөрес яшәү кануннарын кабат искә төшерә белү маһирлыгында. Язучы ялтыравык сюжетка, ясалма конфликтка, заман шаукымын чагылдырган геройларга кызыкмый, ә күбрәк яклаусыз калган «урам балалары» алдында торган кыенлыкларны, тормыштагы гаделсезлекләрне, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне тыгыз, халыкчан тел белән тасвирлый. Аерым очракларда гомумкешелек кыйммәтләренең чынбарлыктагы вәзгыятькә тәңгәл килмәве белән балачакның каршылыклы идея-эстетик моделен тергезә.

«Кошка әйләнермен мин» әсәренең композицион корылышы бер гаиләдәге вакыйгаларны өч ноктадан торып сурәтләү рәвешендә алып барыла. Хикәяләүнең субъективлаштырылган формасын сайлау язучыга сурәтләнелгән хәл-вакыйгаларга әти, әни һәм бала күзлегеннән чыгып бәя бирүгә, аларны бер тарихка җыюга мөмкинлек ача һәм сюжетның киеренкелеген тагын да көчәйтә. Автор сөйләме аның героеның эчке дөньясын тасвирларга ярдәм итә, хисчән хатын-кыз күңелен, уйчан ир-ат фикерләвен, беркатлылыгы һәм үҗәтлеге ташып торган малай уйлары белән үрелеп хисси ноктага җиткерелә. Прологта Клара исемле ханым белән очрашу мизгелен искә алуы авторның битарафлыктан ерак торуын, язганнарының укучылары күңелендә яңгыраш табуын искәртә.

Ун яшьлек Лачынның юлында очраган сынаулар яшьүсмернең тапкырлыгын, самимилеген дә ачып сала. Малайның өйдән качу, базарда куну, хастаханәгә эләгү, кафе хуҗасына коллыкка төшү, караклыкта гаепләнү вакыйгалары тизлеге, көтелмәгәнлеге белән кино кадрларын хәтерләтә башлый. Беренче карашка маҗаралылык итеп кабул ителгән картина аша язучы бала күңелен, бала хыялын югары күтәрә. Гомумән, балачак сурәте, бала

шәхесе белән бәйләп бирелгән эш-гамәлләр, уй-фикерләр язучының әхлакый принципларын ачык чагылдыра. Соңгы еллар татар, башкорт әдәбиятына хас булган «тирән психологизмга омтылу» [8, 323 б.] да үзен ачык сиздерә

Кош булып очу, иңендә канатлар хис итү хыялы повестька романтик буяулар да өсти. Баланы чорнаган чарасызлык, әрнү, сагыш, курку кебек хисләр әти-әнисенә булган мөнәсәбәттә аларның уңай һәм кире якларын күрергә мөмкинлек ача. Әсәр ахырында малайның әтисен яратуы, юксынуы, әнисен бәхетле итеп күрү теләге гаиләдә барлыкка килгән салкынлыкны, аңлашылмаучанлыкны җиңеп чыгарга сәбәп булыр кебек кабул ителә. Гаиләдәге җылы мөнәсәбәтләрнең югалуы ир белән хатын арасындагы аңлашылмаучанлыктан тыш, килен-кайнана бәйләнешләренең катлаулы булуында да чагыла.

Әсәр бер гаилә тарихы кебек бирелсә дә, үзәккә салынган фикер баланың бәхете гаилә бөтенлегендә дигән фәлсәфәне калкытып куя. Ата-анадан торган гаилә моделенең җимерелүе бала аңы кабул итмәслек фаҗига рәвешен ала. Повестьтагы вакыйгалар тәрбия, әдәп-әхлак яссылыгыннан тыш иҗтимагый-фәлсәфи ноктада да үз чагылышын таба. Шәхси трагедия чикләреннән гомумкешелек кыйммәтләре катламына чыккан сюжет ата-ана бурычы, җаваплылык, тугрылык кебек төшенчәләрне ассызыклый.

Кешенең сыеныр урыны, рухи кальгәсе гаилә дигән фикер «Алдакчы» повестында да дәвам ителә. Ялгызы ике бала үстергән Нәфисәнең яклар кешесе булмаганлыктан кыерсытылуы, төрле нахак бәлаләр ягылуы конфликтның нигезен тәшкил итә. Тирә-яктагылар белән күптәннән килгән каршылык улы Идел һәм сатучы малае Ханиф арасында булган бәрелештән соң тагын да куера. Балалары өчен җанын фида кылырга әзер ана, сеңлесе Алтынайны яклап чыккан Идел – бер йодрык, бер кальгә. Нәфисәнең авырлыклар алдына баш бирми, югалып калмый дөреслеккә баруы сокландыра. Әхлакый кыйммәтләрне, яшәеш нигезен ныклы саклаган хатын балаларының киләчәге өчен борчылып эш итә. Авыл кибетендә ялган акчага улына кроссовкилар алырга җыенуда гаепләнгән Нәфисә комиссия алдында куркып калмый, бер чиләк җиләк өчен акчаны полиция лейтенанты бирүне балалары белән өчәүләп дәлиллиләр. Лейтенантның да бу эштә турыдан-туры гаебе юклыгы әсәрдәге конфликтны уңай якка чишәргә мөмкинлек ача.

«Әкиятсез балачак» повесте башта әнисе, күп тә үтми әтисе үлгәннән соң балалар йортына эләккән, авыр шартларда чыныгу үткән Ильяс Мөхәмәтов исемле герой тарихын сөйли. Алдагы ике повестьтан аермалы буларак, бу әсәрдә персонажларның күплеге, үзәк герой тирәсенә туплаган вакыйгаларның төрлелеге игътибарны җәлеп итә. Колейдоскоп көпшәгендәге төсле ташлар сыман ялтырап киткән вакыйгалар чылбырында һәр персонаж үз характер-сыйфатлары белән ачыла. Үзәк герой тирәлегендә хәрәкәт итүче нечкә күңелле Рөстәм, җырчы Айнур, нахакка кыерсытылган Альберт, тыйнак Фәрит, күңелендә авыр кичерешләр йөртүче Рамил, беркатлы куштан Динар, юха, әмма туры сүзле, максатчан Әмилә аерым-аерым вакыйгаларга бәйле күрсәтелә. Тормышка, кешеләргә үчле булып үскән мәкер җанлы Даян сызыгы әсәрнең башыннан ахырына кадәр калкып-калкып китә. Үзәк герой белән бәрелешкә кергән Даян язмышы язучы тарафыннан рухи деградация, кешенең түбәнгә тәгәрү күрсәткече рәвешендә уйланылган. Ильяс өчен әнисеннән калган бердәнбер истәлек – магнитофон кассетасына яздырылган җырны җуйдыручы, татлы-сусыл груша ашау турында хыялларган чакта аны череп аккан җимешкә алыштыручы, әтисенең җылысын саклаган күн каешны талап алучы, кимсетер өчен кушамат тагучы да – Даян. Бер үк шартларда тәрбияләнгән малайлар арасында өстенлеккә омтылган Даянның кансызлыгы, кешелексезлеге җәмгыятьтәге тигезсезлек, шәхси бәхетсезлек кебек уйлануларга алып чыга. Ахырда аның чүплектә ризык эстәп йөрергә мәҗбүр булуы, кайчандыр урланган күн каешка асылынып дөньядан китүе үзе кебек үк ятимнәрнең, яшьтәшләренең күз яше, кылган явызлыклар, күңел тарлыгы өчен түләнәсе җәза рәвешендә кабул ителә. Язучы Даян һәм Ильяс мөнәсәбәтләрен үрә-үстерә барып үзәк геройны характер буларак тулырак ачуга ирешә. Бу адым-кылыклар геройның шәхсән сыйфаты буларак кабул ителүдән бигрәк гомуми, йөзәрләгән, меңәрләгән ятим балалар язмышына хас булган типик күрсәткеч кебек калкытыла. Ахырда хикәяләүченең: «Бер түбә астында яшәп, бер төрле кием киеп, бер үк

ризык ашап үстек. Тик безне язмыш нигә төрле якларга борды соң?» [7, 169 б.] дигән уйланулары укучыны битараф калдырмый.

Язучы балалар йортындагы ятимнәр тормышын явызлык белән изгелек көрәше рәвешендә сурәтләүдән баш тартып, аның катлаулы социаль-психологик укылышын бирә. Җәмгыясенең битарафлыгы тарафыннан тудырылган каты бәгырьлек феномены, беренче чиратта, өлкәннәрнең ятим балалар язмышына каршы күрсәткән системалы битарафлык нәтиҗәсе буларак күренеш таба. Ләкин А. Баймөхәммәтов чынбарлыкны караңгы буяулар белән генә чагылдырмый; аның сәнгати дөньясы беряклы түгел, анда кешелеклелек һәм изгелек кебек төшенчәләргә дә урын бирелә. Повестьта матур, ихлас, күңелдә өмет уяткан мизгелләр дә бихисап. Ачык йөзле, киң күңелле Нәсыйха апа, үзләренә яшәргә алырга килгән Наилә апа образлары аша ышаныч һәм киләчәккә өмет фаразлана.

Балалар йортындагы көнкүрешне чагылдыру, мөдир-тәрбиячеләрнең эш-гамәлләрен күрсәтү геройның тигезлеккә омтылудагы субъектив карашына яшерелгән иҗтимагый тәнкыйтьне тоемларга мөмкинлек бирә. Язучы балаларның авыр көнитеш шартларын, ачлы-туклы тормышын шактый җентекле һәм ышандыргыч итеп сурәтли (сөяк кимерү [7, 118–123 б.], бүләккә комак алып кайту [7, 96–107 б.], металл җыю тарихлары [7, 154–161 б.], һ.б.).

Шулай ук, язучы яхшылык һәм мәрхәмәтлелек, явызлык һәм рәхимсезлек кебек күренешләр белән бәрелешкән катлаулы чынбарлык аша яшүсмернең күңел дөньясын күрсәтә, психологик динамикасын ачыклый. Мәсәлән, тәрбияче Рәйфә Түләбаева образында катыбәгырьлек һәм гамьсезлек сыйфатлары үзенең тулы эчтәлеген таба.

Повесть бүлекләргә аерылган һәм аларның исемнәренә герой күңелендә уелып калган гыйбрәтле, я булмаса аерым бер фикер-нәтиҗәләргә китерерлек хәлиткеч бер вакыйга тергезелгән, төп сюжет сызыгын ачуда ярдәмче булып торалар. Хәзерге әдәбиятта коллаж алымына корылган әсәрләргә хас булганча, «вакыйгаларның үзаллылыгы төп геройга бәйле» [9, 200 б.] итеп оештырыла, бер ноктага туплана.

Әкият – ышаныч, өмет, хыял белән ассоциацияләшә. Ышанычны җимерерлек мохиттә дә омтылышларына тугры калган герой (университетка укырга керү хыялы, һ.б.) үз намусына таяна.

Туганлык хисенең ныклыгы «Әкиятсез балачак», «Алдакчы» әсәрләрендә ачык тоемлана.

Язучы әсәрләренә милли-мәдәни детальләрне оста файдалана, хисси-эмоциональ башлангычны калкытып җибәрә (бал ашау, эти каешы, истәлек дәфтәре, һ.б.).

А. Баймөхәммәтовның «Урын» [6] хикәясендә төп герой – яшь белгеч Зәбир. Вакыйгалар Зәбирнең оешма җитәкчесе Флорид Әгъзамович белән кәләше Сәлимәнең туган ягына – Таулы районына командировкага барырга җыену вакыйгасы белән башланып китә. Сәлимәне дә үзе белән алып барырга ниятләгән Зәбир җитәкчесенең моңа каршы булуы белән очраша. Флорид Әгъзамовичның башка кеше утыртып алып барырга риза булмавы, җитмәсә, тагын кешеләр аласы бар дип ялган сәбәп табуы, төп геройның күңелендә каршылык һәм ачу уята.

Язучы геройлар алдына бер-бер артлы сынаулар куя: район үзәгенә барып җитәләр, ләкин район башлыгы урынында юк, килгән юлда нык буран күтәрелә, кире юлга чыгу мөмкин түгел. Шулай итеп, хикәядәге ике юлчы герой Зәбирнең кайнәсе, Галимә әбинең өенә кунырга мәҗбүр булалар.

Хикәянең төп темасы һәм идеясе булып кешелек сыйфатларының дәрәҗәдән өстен булуы тора. Автор Зәбир образындагы гадилек, түземлек, хезмәтсөючәнлек кебек сыйфатларны Флорид Әгъзамовичның рәсмилеге, горурлыгы, үзен югары势 势 сануы белән каршы куя. Шулай ук артык гади тормышта яшәгән Галимә әбинең киң күңеллелеге, мәрхәмәтлеге – кешеләрнең эчке байлыгы тышкы ялтыравык сыйфатларыннан мөһимрәк икәнен күрсәтә.

Хикәяләү тормышчан, гади тел белән алып барыла, сөйләшү-аралашулар геройларның характерларын ачып салырлык диалогларга корылган. Уңышлы кулланылган тасвирлауларга

(буран, кайнәнең өе) «урын» сүзен уйнату кушыла. «Күңелең киң булса, урын табыла ул, ди торган иде борынгылар» [6, 143 б.] дигән юллар аша язучы әсәрнең төп идеясен җиткерә.

Гомумән алганда, А. Баймөхәммәтов әсәрләре ышаныч, хыялга тугрылык турында сөйли. Үз-үзеңә, көч-куәтеңә ышаныч белән янәшә кешенең тормыш юлын дөрес сайлау хакында уйлана. Бу ышаныч инсанның рухи бөтенлегенә, гаилә ныклыгына, җәмгыятьтәге кыйммәтләргә дә турыдан-туры бәйле. Язучы укучыны һичнәрсәгә дә карамыйча, үзенең хыялыңны эзләп, күккә, биеккә, яңа омтылышларга очарга, яхшылыкка, яктылыкка омтылырга өйрәтә.

**Кулланылган әдәбият**


1. Баймөхәммәтов А. Әкиятсез балачак // Казан утлары. – 2018. – № 10. – Б. 92–146.
2. Баймөхәммәтов А. Әкиятсез балачак: повесть, мәзәкләр. – Уфа: Китап, 2019. – 157 б.
3. Баймөхәммәтов А. Калдырма, әнкәй! – Уфа: Инеш, 2018. – 176 б.
4. Баймөхәммәтов А. Нахак: повесть, хикәя: – Казань: Идел-Пресс, 2021. – 160 б.
5. Баймөхәммәтов А. Урам балалары // Казан утлары. – 2019. – № 11. – Б.89–122.
6. Баймөхәммәтов А. Урын // Казан утлары. – 2020. – №8. – Б. 138–144.
7. Баймөхәммәтов А. Кошка әйләнермен мин. Повестьлар. – Казан: Язучы, 2024. – 172 б.
8. Galina G. G., Gareeva G., Alibaev Z. A., Khaliullina A. G. Poetics Of Psychologism In Bashkir And Tatar Prose Of The Twentieth Century / // European Proceedings of Social and Behavioural Sciences EpSBS : Humanistic Practice in Education in a Postmodern Age (HPEPA 2019), Ufa, 15–16 ноября 2019 года. Vol. 93. – Ufa: БГПУ им. М. Акмуллы, 2020. – P. 323-333. – EDN KAWLYV.
9. Халиуллина А.Г. Коллаж как постмодернистский эксперимент в литературе // Национальные литературы Поволжья и Приуралья: исследовательские парадигмы и практики: материалы Всероссийского научно-практического семинара, Казань, 24–25 апреля 2024 года. – Казань: Институт языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова АН РТ, 2024. – С. 198-204. – EDN HMMLWX.


© Халиуллина А.Г., 2025

УДК 373.31

**Халиуллина Н.У.,**
*заведующий кафедрой татарского языка и литературы БГПУ им. М. Акмуллы, г. Уфа, Россия*
**Якупова З.Ф.,**
*учитель МБОУ СОШ № 1 имени Героя Советского Союза В.Д. Паширова, с. Кушнаренково, Россия*
**Гандалипова А.А.,**
*студент 3 курса БГПУ им. М. Акмуллы, г. Уфа, Россия*

## УКУЧЫЛАРНЫҢ ГОМУМ ПСИХИК ҮСЕШЕ ӨЧЕН ЙӨГЕРЕК УКУНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

*Статья выполнена в рамках научно-исследовательских работ по приоритетным направлениям научной деятельности вузов-партнеров*

***Аннотация***. *Мәкаләдә рус һәм чит ил фәнендә йөгерек укуга теоретик якын килүләргә күзәтү тәкъдим ителә, уку тизлеген арттыруның гамәли методлары карала, шулай ук йөгерек укуның шәхескә йогынтысына анализ ясала.*

***Терәк сүзләр:*** *тиз уку, туган тел, шәхес үсеше, тиз уку, артикуляция, укыту, өйрәнүчеләр.*

Бүгенге көндә кешелек дөньясы үзенең акылы үсешенең әйләнә-тирә дөньяга йогынтысы нәтиҗәләре белән очраша башлады. Техник казанышлар дәрәҗәсе еш кына аларны куллануның һәм бөтен тармакларда җәелдерүнең нәтиҗәләрен дөрес бәяләү һәм хәл итү мөмкинлекләрен шактый узып китә. Без мәдәни мирасны тапшыруның хәзерге мөмкинлекләрен һәм формасын дөрес бәяләргә һәм мондый сорауга җавап табарга тиешбез: дөньяның хәзерге үсеш темпыннан калышмыйча, һәрдаим артып торган мәгълүматны бербөтен буларак ничек үзләштерергә?

Уку белем алуның иң мөһим ысулларының берсе булып кала. Башлангыч мәктәптән алып аның югары баскычларына кадәр белем алу процессы текстлы мәгълүмат белән эш итүгә корылган. Кешенең уку күнекмәсенең ни дәрәҗәдә уңышлы булуыннан аның гомум үсеше, белем алудагы, профессиональ яктан казанышларыда билгеләнә. Хәзерге шартларда зур күләмле мәгълүмат белән эш итү сәләте сорала. Уку компетенциясен үстерү мәсьәләсе 2007-2020 елларга төзелгән «Укуны үстерү һәм аңа ярдәм итү милли программасы»нда ук чагылдырылган булган: «Чтение – это важнейший способ освоения базовой социально значимой информации – профессионального и обыденного знания, культурных ценностей прошлого и настоящего, сведений об исторически непреходящих и текущих событиях, нормативных представлений, – составляющей основу, системное ядро многонациональной и многослойной российской культуры» [7]. Димәк, уку компетенциясен үстерүне, күләмле басма мәгълүматның сыйфатын югалтмыйча үзләштерүне социаль ихтыяҗ буларак билгели алабыз. Шундый шартларда соңгы елларда популярлык казанган йөгерек уку заман таләбе булып кала.

Йөгерек уку (кайбер чыганакларда тиз уку) – укуның ике төп компоненты – уку техникасының һәм укыганны мәгънәви үзләштерүнең югары тизлеген берләштергән уку формасы. Йөгерек уку вакыт аралыгында күпсанлы билгеләрне укуны һәм аны үзләштерүнең югары сыйфатын күз уңында тота. Бүгенге көндә бу компетенциянең нигезендә ятучы психологик эзләнүләр, йөгерек укырга өйрәтүдә аларның әһәмиятен бәяләүче методикалар җитешми. Моңа өстәп, туган телдә йөгерек уку феноменын тикшерүгә багышланган хезмәтләрнең бөтенләй булмавын билгеләргә кирәк.

Йөгерек уку күнекмәсен системалы рәвештә үстерү омтылышлары беренче тапкыр 20 гасыр башында исәпкә алына. 1945 елда укытучы һәм социаль педагог Эвелин Вуд уку тизлеген арттыру буенча гамәли курслар булдыра. Хезмәтенең кереш сүзендә ул үзенең дусты һәм укытучысы, Юта Университетыннан доктор Лоуэлл Лисның (минутына 6000 сүздән артык тизлек белән) искиткеч тиз укый алуына һәм шул ук вакытта укыганны бик яхшы аңлавына игътибар иткәнен сөйли. Эвелин Вуд раслаганча, ул шундый ук сәләтле 100 дән артык кешене тикшергән, алар минутына 1500 сүздән артык тизлек белән укый алган (ул бу тизлекне минималь планка сыйфатында билгеләгән). Югары тизлек белән укучыларның күз хәрәкәтләрен өйрәнгәндә, ул аерма тапкан. Аларның күзләре азрак туктап тора. Бу аларның берьюлы бер сүздән артыграк күрүен аңлата. Юллар буйлап горизонталь рәвештә хәрәкәт итәсе урында, аларның карашы гадәттә диагональ буенча аска таба хәрәкәт итә. Бер фиксация өчен алар тулы бер төркем сүзләрне укыйлар һәм беркайчан да укыганнарына кире кайтмыйлар (регрессия булмау). Үзенең тикшеренүләре нигезендә Эвелин Вуд 12 ел узгач «динамик уку» дип аталган системаны эшкәртә. «Динамик уку» ярдәмендә югарыда күрсәтелгән техникаларга теләгән һәркем өйрәнә ала иде. Бу система турындагы китап 1959 елда [6] дөнья күрә. Вакытлар узу белән, «динамик уку» системасы нигезендә укытуның башка методикалары барлыкка килә.

Эвелин Вуд системасын популярлаштыручысы Питер Камп була. 1979 елда ул үзлегеннән өйрәтүче хезмәт бастыра, балачактан таныш булган процессны аның тәкъдимнәре һәм күнегүләре ярдәмендә яңадан аңларга тәкъдим итә, Автор текстны аңлау кагыйдәләренә

игътибар итә, «нәтиҗәле тиз уку үз эченә югары тизлекне дә, дөрес интерпретацияне дә ала», дип саный [6].

Россиядә XX гасырда уку тизлеген арттыру проблемасы тикшеренүләр өчен мөһим, ләкин аз өйрәнелгән дип телгә алына. Лев Семенович Выготский хезмәтләрендә «уку тизлеген арттыру тексттагы мәгълүматны кабул итү һәм аны эшкәртү системасын камилләштерүгә китерә», дип билгеләнә: «Обычно думают…, что понимание лучше при медленном чтении, однако… при быстром чтении понимание идет лучше, ибо… сама скорость понимания отвечает более быстрому темпу чтения». Ләкин, автор дәвам итүенчә, уку «бик катлаулы психик процесс буларак түгел, ә катлаулы сенсомотор күнекмә буларак карала. Күрү механизмының эше билгеле бер дәрәҗәдә аңлау процессына буйсынучан була» [3, 169 б.]. Алга таба укуның катлаулы психофизиологик эшчәнлек, анда югары психик функцияләрнең турыдан-туры катнашуы, һәм уку үсешенең баланың үсешенә туры пропорциональ булуы билгеләнә. Текстны аңлау «сүзләрнең авырлыгы (мәгънәсе) суммасын» тигезләштерүне күз уңында тота. Шушы пропорция сакланмыйча уку максаты тормышка ашырылмый. Хикәяне аңлау математикада мәсьәлә чишүгә охшаган. Ул ситуациянең дөрес элементларын сайлап алудан һәм аларны дөрес тәңгәллекләрдә тоташтырудан, шулай ук аларның һәркайсына дөрес мәгнә, бәя һәм әһәмият бирүдән гыйбарәт. Уку процессы, укырга өйрәтү эчке сөйләм үсеше белән тыгыз бәйләнгән...» дип өсти автор [3, 169б.].

«Акрын» һәм «тиз» уку терминнары укылган тамгалар / сүзләрнең минут эчендәге санча күрсәткечләре белән конкретлаштырылмый. Уку тизлеген арттыру буенча гамәли киңәшләр өлкәсендә О.А.Андреев һәм Л.Н. Хромовны искә алырга кирәк. Алар интеллектуаль үсеш элементларын (игътибар, хәтер күнегүләре) һәм аутотренинг, релаксация, медитация методларын үз эченә алган тиз укуга өйрәтү программасын эшкәрткәннәр [1].

Авторлар текстны комплексы кабул итәргә тәкъдим итәләр, моның өчен интеграль уку алгоритмы кулланыла. Әлеге алгоритм схематик рәвештә текстның кайсы компонентларын истә калдырырга кирәклеген күрсәтә. Моннан тыш, укучы алдында нинди максатлар куелуына карап, авторлар укуның берничә төрен билгелиләр [1]:

1) Тирәнтен уку. Укуның бу төрендә детальләргә, аларны анализлауга һәм бәяләүгә аерым игътибар бирелә. 2) Ппанорамалы тиз уку. Укуның бу төре тиз укуның камилләштерелгән техникасы нәтиҗәсе булып тора. 3) Сайлап уку. Тиз укуның бер төре булып тора. Аның аермасы шунда ки, тулаем бөтен текст түгел, ә аның билгеле бер фрагментлары гына укыла. Укучы үзенә мәгълүматның нинди аспектлары кирәклеген мөстәкыйль билгели һәм бары тик аларга гына игътибарны юнәлтә. Калган текстны ул укый, ләкин аның эчтәлегенә игътибар итми. 4) Уку-караштыру. Укуның мондый төре китап белән алдан танышу өчен кулланыла. 5) Сканерлау – тексттан кирәкле фактны: исемне, датаны, билгеләмәне тиз эзләп табу.

Рациональ уку мәктәбенә нигез салучы булган М.А. Зиганов йөгерек укуны алшартсыз үзләштерелгән күнекмә буларак билгели һәм фикерләү, игътибар, хәтер механизмнарыннан аерым карый. Тиз уку нигезенә М.А. Зиганов 4 төп уку стратегиясен салган [4]: – карау – эзләү – аналитик – сайлап алу.

С.Е. Михайлов үзенең күнегүләр җыентыгында укыганда «кирәксез бизәкләр»не кисеп ташлауга юнәлдерелгән берничә методика һәм күнегүләр тәкъдим итә. Алар, С.Е. Михайлов фикеренчә, уртача статистик текстларда артыгы белән була [5].

Югарыда санап үтелгән барлык авторлар билгеләп үтүенчә, уку тизлеген мәгълүматны кабул итү һәм аны эшкәртү күнекмәләрен камилләштерү аша үстерергә мөмкин. Нәтиҗәле һәм тиз уку компетенциясенә ия булып, текстны аңлау сыйфатын да сизелерлек арттырырга мөмкин. Гамәли әсбапларның авторлары текстның эчке, мәгънәви ягы белән эшләүгә дә игътибар итәләр, укыган мәгълүматны махсус алгоритмнар ярдәмендә структур кисәкләргә бүлгәләргә тәкъдим итәләр [1]. Авторлар фикеренчә, аңлауның югары дәрәҗәсен саклап уку тизлеген арттыруга йогынты ясый торган төп факторлар булып тел күнекмәләре (текст язылган телгә ия булуның югары дәрәҗәсе) һәм сүзләрне танып белү тизлеге тора.

Димәк, йөгерек уку нигезендә катлаулы когнитив процесслар ята. Аларның үсеш дәрәҗәсе күнекмәнең автоматлашу дәрәҗәсенә дә, уку аша алына торган мәгълүматны интеллектуаль эшкәртү тизлегенә /нәтиҗәлелегенә дә йогынты ясый. Башкача әйткәндә, йөгерек уку күнекмәсен үстерү гомумән кешенең интеллектын үстерүнең бер формасы булып тора.

Гадәти уку – аваз-хәреф һәм мәгънә бәйләнешләрен булдыру. Тиз уку исә «антиципация» дип аталган катлаулы когнитив күнекмәне тагын да интенсиврак куллануны күздә тота. Монда фаразлау, укыла торган текстны алдан күрә белү, укылган материалны кешедә булган когнитив база нигезендә анализлау сәләте. Укучы мәгънәви эчтәлекне генә түгел, ә шәхси тәҗрибәгә нигезләнгән интерпретацияне, эмоциональ һәм логик ассоциацияләрне, шәхси бәяләүне һәм үзенчәлекле кыйммәтләрне үз эченә алган модельне төзи. Бик кыска вакыт эчендә эшләнү сәбәпле, мондый бурыч җитәрлек дәрәҗәдә игътибарны туплауны, шәхеснең барлык интеллектуаль, эмоциональ һәм ихтыяр ресурсларының киеренке эшчәнлеген таләп итә.

Шулай итеп, йөгерек уку компетенциясенә югарыдагыча якын килү аны интеллектуаль хезмәтнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм оптимальләштерү алымы гына түгел, ә гомумән шәхесне камилләштерү һәм үстерү ысулы да була ала, дип ышанычлы әйтә алабыз. Бу күнекмә уку процессын тизләтүдән дә бигрәк аны камилләштерергә мөмкинлек бирә. Тиз уку игътибарны активлаштыра, хәтерне мобилизацияли, интенсив фикерләүне үз эченә ала, укыганны тирәнрәк аңларга һәм ныграк үзләштерергә мөмкинлек бирә.

**Список литературы**

1. Андреев О. А., Хромов Л. Н. Учитесь быстро читать. – Краснодар: Просвещение, 1991. – 170 с.

2. Билая А.М. Скорочтение как инструмент развития личности // Инновационная наука: психология., педагогика, дефектология. – 2020. – Т. 3 № 2. – С.32–48.

3. Выготский Л. С. Выготский: [Сборник]. – М.: Амонашвили, 1996. – 222 с.

4. Зиганов М. А. Скорочтение. Уникальный курс по развитию навыков рационального чтения. – М.: Эксмо, 2012. – 224 с.

5. Михайлов С. Е. Лучше, чем скорочтение: Как научиться читать быстрее. – Ростов-на-Дону: Феникс, 2007. – 255 с.

6. Камп П. Скорочтение: как запоминать больше, читая в 8 раз быстрее. – М.: Манн, Иванов и Фербер, 2016. 305 с.

7. Якупова З.Ф., Халиуллина Н.У., Гандалипова А.А. Виды упражнений для развития скорочтения на материале татарского языка). // Вопросы языковых контактов и литературных взаимосвязей в полилингвальном и поликультурном образовательном пространстве: Сб. материалов Всерос. научно-метод. семинара, посвященного 60-летию доктора филологических наук, профессора Илшата Сахиятулловича Насипова, Республика Башкортостан, г. Уфа,11-12 апреля 2024 г. / Сост-ли: И.С. Насипов, И.С. Мансуров. – Уфа: БГПУ им. М. Акмуллы, 2025. – С.538–542.

8. Национальная программа поддержки и развития чтения, 2007. URL: http://www.library.ru/1/act/doc.php?o_doc=1122&o_s

© Халиуллина Н.У., Якупова З.Ф., Гандалипова А.А., 2025

УДК 811.512.145

**Хаматзянова Ф.С.,**
*учитель татарского языка и литературы*
*МБОУ «Сармановская СОШ»,*
*с. Сарманово, Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕН УКЫТУНЫ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИК НИГЕЗДӘ ОЕШТЫРУ

***Аннотация**. Тәкъдим ителгән мәкалә татар телен укытуда лингвистиканың бер тармагына – лингвокультурологиягә багышланган. Туган телне белү – үз рухи дөньяңны баету, үз халкыңның, Ватаныңның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген танып белү ул, шуңа күрә татар теле укытучылары туган тел дәресләрендә башка халыкларның теленә, мәдәниятенә карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән бурычлар куярга һәм хәл итәргә тиеш: 1) күнегүләр һәм эш формалары ярдәмендә үз халкына мәхәббәт һәм тугрылык формалаштыру.2) тел материалы өстендә эшләү, туган телгә, мәдәниятkә һәм РФ халыкларының милләтара аралашу теле буларак рус теленә мәхәббәт тәрбияләү; 3) башка халыкларның телләренә һәм мәдәниятләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; 4) Ватанның үткәненә хөрмәт хисе тәрбияләү, үз халкыңа һәм башка илләрдәге халыкларга хөрмәт тәрбияләү; 5) милли үзаңның аерылгысыз өлеше булган Туган илнең табигатенә мәхәббәт тәрбияләү.*

***Терәк сүзләр:** лингвистика, лингвокультурология, компонент, лингвокультурологик ориентация, лингводидактика, билингвизм һәм полилингвизм формалаштыру, психологик-педагогик, лингводидактик һәм лингвистик нигезләр, укыту методлары.*

Соңгы ике дистә елда илебез тормышында булган икътисади һәм сәяси үзгәрешләргә һәм җәмгыятьнең глобальләшүе процессларының тирәнәя баруына бәйле рәвештә, берничә телне белү кешенең социаль һәм икътисадый уңышының мәҗбүри өлешенә әверелде. Килеп туган ситуациядә күптелле пространствода тиз һәм нәтиҗәле ориентлашырга кирәк. Хәзерге заманда әлеге проблема мәктәпләрдә, югары уку йортларында өстәмә белем бирү юлы белән хәл ителә.

Тел мәдәният белән тыгыз бәйләнгән. Ул аңарда үсә һәм аны чагылдыра. Бу идея нигезендә яңа фән – лингвокультурология барлыкка килә, ул XX гасырның 90 нчы елларында лингвистиканың мөстәкыйль юнәлеше буларак формалаштырыла.

Лингвокультурология – лингвистиканың лингвистика белән культурология кисешкән урында барлыкка килгән тармагы, ул телдә чагылыш тапкан.

Культурологиянең игътибар үзәгендә телне һәм мәдәниятне йөртүче буларак кеше тора, аның белеме, милли үзенчәлекләре, үз-үзен тотышы нормалары тора. Бу нормалар аны әлеге мәдәният вәкиле итә. Күптелле җәмгыятьтә телнең яшәеше һәм өйрәнүенә кагылышлы про блемалар тел ситуациясенең гомуми картинасы фонында карала. Аның компонентлары булып Тел статаусы, тел сәясәте,тел компетенцияләре тора.

Әлеге проблеманы аңлау лингводидактика фәненең максаты һәм бурычлары белән тыгыз бәйләнгән: укытучыларның татар теле дәресләрендәге күнегүләрнең лингвокультурологик эчтәлеге аша татар телен укытуның иң рациональ методларын табарга омтылуы.

Укытучы алдында продуктив билингвизм һәм полилингвизмны формалаштыру һәм үстерү, тел шәхесен формалаштыру бурычы тора. Бу проблема хәзерге вакытта аеруча кискенләшә бара, чөнки күпмилләтле дәүләтебездә икетеллелек һәр кеше өчен нормага әверелергә тиеш.

Әлеге бурычны тормышка ашыру мәктәптә татар телен укытуның нәтиҗәлелегенә бәйле, чөнки бу чорда аның нигезе салына, аның нигезендә телне һәм мәдәниятне

үзләштерүнең барлык алга таба процессы төзелә, уңай психологик караш тудырыла, аларга кызыксыну формалаша.

Белем бирүдә лингвокультурологик ориентация югары уку йорты укытучысыннан студентларны сүз белеменә генә түгел, ә тел шәхесен формалаштыручы мәдәни – тарихи мохиттә халыкның тарихы, менталитеты чагылдырылган матди һәм рухи мәдәният феноменына да тартуны таләп итә. Лингвокультурологик материал булган күнегүләр ярдәмендә мөгаллим дөньяның тел картинасын тудырырга, татар халкының мәдәниятен чагылдырган лексика, фразеологизмнар, текстлар белән таныштыра алачак. Татар теле дәресләрендә лингвокультурологик төшенчәләрне формалаштыру процессы туган мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләү, башка халыкларның телләренә һәм мәдәниятләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү, аларны дөнья мәдәниятенә тарту белән тыгыз бәйләнгән.

Бүген шәхеснең рухи-әхлакый үсешен тәэмин итүче лингвомәдәни белем бирүнең әһәмияте, аның дөньяга караш потенциалын тәшкил итү кирәклеге һәм дөнья мәдәниятенә интеграция шартлары буларак лингвомәдәни үзаңны формалаштыру аеруча кискен актуальләшә бара. Шуңа бәйле рәвештә тел белән мәдәниятнең үзара бәйләнеше проблемасы актуальләшә, чөнки кешеләрнең рухи аралашуы, халыкларның аңлавы һәм хезмәттәшлеге нәкъ менә мәдәнияттән башлана, ә мәдәниятләр аралашуы шәхесләрне кызыксындыру белән актуальләшә, аның төп чарасы тел булып тора.

Туган телне белү – үз рухи дөньяңны баету, үз халкыңның, Туган илеңнең үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген танып белү ул, шуңа күрә татар теле укытучылары туган тел дәресләрендә башка халыкларның теленә, мәдәниятенә карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән бурычларны куярга һәм хәл итәргә тиеш: 1) күнегүләр һәм эш формалары системасы белән үз халкына, әйләнә-тирәдәгеләргә мәхәббәт һәм тугрылык формалаштырырга; 2) тел материалы өстендә эшләп, туган телгә, мәдәнияткә һәм РФ халыкларының милләтара аралашу теле буларак рус теленә мәхәббәт тәрбияләү; 3) башка халыкларның телләренә һәм мәдәниятләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; 4) Ватаныбызның үткәне истәлегенә хөрмәт хисе үстерү, үз халкыңны һәм башка ил халыкларын хөрмәт итү; 5) милли үзаңның аерылгысыз өлеше булган Туган ил табигатенә мәхәббәт тәрбияләү.

Бу бурычларны тормышка ашыру өчен уку материалының түбәндәге төрләрен кулланырга кирәк: 1) конкрет грамматик материалны өйрәнгәндә, укучыларда югарыда күрсәтелгән хисләрне тәрбияләргә ярдәм итә торган тематик дидактик текстларны куллану; 2) дәресләрдә шулай ук тарихи, туган якны өйрәнү материалларын, аерым алганда, Татарстан тарихыннан һәм Россия Федерациясе халыклары тарихыннан файдалану; 3) укучыларның игътибарын Россия Федерациясе халыклары телләренең һәм мәдәниятләренең бер-берсенә тәэсир итешү фактларына юнәлтү, шул ук вакытта укучыларның Россия Федерациясе халыкларының милләтара аралашу теле буларак безнең илдә рус теленең ролен аңлавы, шулай ук туган телгә һәм рус теленә, ерак һәм якын чит ил халыклары телләренә хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләүгә ярдәм итү; 4) ватанпәрвәрлекнең бер чагылышы – туган телгә мәхәббәт булуын ассызыклау.

Татар теленә өйрәтүгә эшләнә торган лингвокультурологик концепциясе телләргә өйрәтүнең гомуми психологик – педагогик, лингводидактик һәм лингвистик нигезләренә таяна. Шул ук вакытта ул лингвокультурологик нигезләрне күздә тота һәм лингвокультурология фәненең төп төшенчәләренә таяна.

Телне лингвокультурологик планда өйрәнүнең төп аспектлары булып түбәндәгеләр тора: 1) телне тарихи формалашкан система буларак өйрәнү; 2) телне йөртүче халыкның рухи һәм матди культурасын туплаучы буларак өйрәнү; 3) укучыларның лингвокультурологик компетенциясен формалаштыру. Телгә өйрәтү, бу телдә аралашу процессында мәдәниятсез булмый. Тел күренешләре артында дөньяның социомәдәни картинасы ята. Сөйләм телен чын-чынлап файдалану өчен, телдән тыш фактлар җыелмасын, тел артында яткан нәрсәләрне белергә кирәк.

**Кулланылган әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.
2. Гарипова Л.Р. Концепты татарской языковой картины мира: репрезентация в лексеме «ДӨНЬЯ»: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2007.
3. Зайнуллин М.В., Зайнуллина Л.М. Общие проблемы лингвокультурологии: курс лекций. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2008.
4. Закирова Р.Р. Концепт «моң» в татарской языковой картине мира: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2008.
5. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф. – 352 б.

© Хаматзянова Ф.С., 2025

УДК 811.512.145

**Хаматханова А.Ш.,**
*студент 2 курса Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель* – **Гайнуллина Г.У.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

# ИНТЕРНЕТ ЧЫГАНАКЛАРДА АЛЫНМАЛАРНЫ КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (ВКОНТАКТЕ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЕ МАТЕРИАЛЫНДА)

***Аннотация***. *Бу мәкаләдә Интернет чыганаклардагы алынмаларга анализ ясала, аларның урыны һәм татар теленә йогынтысы ачыклана.*

***Терәк сүзләр:*** *лексика, алынмалар, Интернет теле, сленг, жаргонизмнар.*

Хәзерге заманда мәгълүмат чараларының үсеше, интернет ресурсларның киң таралуы тел үзгәрешләренә зур йогынты ясый. Интернет челтәрендә язма һәм сөйләм теленең үзенчәлекләре формалаша, бу исә яңа лексик берәмлекләрнең барлыкка килүенә, чит тел сүзләренең киң кулланыла башлавына китерә. Аеруча инглиз, рус һәм башка телләрдән кергән алынма сүзләр еш очрый, һәм алар татар интернет киңлегендә дә актив рәвештә кулланыла.

Татар телле кулланучылар интернетта аралашканда төрле алынма сүзләрне татар грамматикасы кысаларында үзләштереп кулланалар. Бу күренеш телнең динамик үсешен, адаптация мөмкинлекләрен күрсәтә, әмма шул ук вакытта милли телнең сафлыгына да йогынты ясый ала. Шуңа күрә, интернет чыганаклардагы алынмаларны өйрәнү – бүгенге көндә тел галимнәре, лингвистлар өчен мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Бу эштә интернет чыганакларында кулланыла торган алынма сүзләрнең төрләрен, аларның кулланылыш үзенчәлекләрен, килеп чыгышын һәм функциональ ролен ачыклау күздә тотыла. Материал сыйфатында татар телендә алып барылучы Telegram төркемнәре, ВКонтакте битләре, сайтлар кебек интернет платформалар сайланып алынды. Алар арасында «Өмет», «Татарча квартирник», «Intertat», «Матбугат.ру» кебек популяр ресурслар бар.

Интернет теленең тагын бер мөһим үзенчәлеге – анда сөйләм теленә, сленгка, молодёжный жаргонга киң урын бирелү. Чөнки күпчелек интернет-контентны яшьләр тудыра, һәм алар, кагыйдә буларак, тел нормаларыннан ирекле, үзара аңлашыла торган "код"лар куллана.

Слэнг – төркемгә караган кешеләр арасында кабул ителгән, рәсми булмаган сүзләр җыелмасы. Интернетта киң кулланылыш алган слэнг сүзләре: «лайк», «репост», «хайп», «топ», «краш», «рофл», «фейл», «угар», «срался», һ.б. Слэнг еш кына аңлатмага мохтаҗ: ул кыска, ирониялә, еш кына эмоциягә йөз тота.

Хәрефләрне махсус рәвештә үзгәртү (капслок: «ЯРЫЙ», сузу: «ррррәхмәт», кыскарту: «бт», «хз», «лол») – интернет теленең үзенчәлекле стиле. Язуда кириллица белән латиницаның аралаш кулланылышы («poka», «rakhmat») очрый.

Язуда сөйләм яңгырашын тудыру омтылышы: «шшшшт», «кхм», «әәәә», «гыгы», «вжух» телнең экспрессиясен көчәйтә, сөйләмне тереләй тапшыру хисе бирә.

Соңгы дистә елларда телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, аеруча актив лексик үзгәрешләр күзәтелә. Бу үзгәрешләрнең төп сәбәпләренең берсе – глобализация процессы, ягъни дөньядагы икътисади, мәдәни, мәгълүмати бәйләнешләрнең көчәйүе. Шуның нәтиҗәсендә дөньядагы телләр арасында, бигрәк тә инглиз теле белән бәйле рәвештә, тыгыз бәйләнешләр урнаша.

Татар телендә бу күренеш аеруча яшьләр сөйләмендә, интернет текстларда, социаль челтәрләрдә актив чагылыш таба:

• технологияләр өлкәсе: компьютер, браузер, киберспорт, стрим, хештег, гаджет, контент, фишка, лайфхак;

• социаль челтәрләр һәм массакүләм мәдәният: лайк, пост, чат, блогер, сторис, тренд, хайп, краш, фейк;

• мода һәм көнкүреш: лук, шопинг, бренд, фудкорт, ланч, фастфуд, фитнес, топ, стил.

Бу алынмаларның күбесе инглиз теленнән турыдан-туры яки рус теле аша керә. Кайберләре татар телендә үзләштерелә, җөмлә эчендә төрле килешләрдә кулланыла: «постны укыдым», «лайклар җыя», «стрим карыйм», «контент тудыра». Шулай итеп, алынма сүзләр татар теленең морфологик системасына да яраклаша.

Инглиз теленең тәэсире – фәкать лексик яктан гына түгел, ә фикер йөртү, аңлатма бирү, җөмлә корылышы кебек өлкәләрдә дә сизелә. Бу бигрәк тә яшьләр сөйләмендә күренә. Татар телендә «интернациональ стиль» калыплаша бара: кыска, динамик, эмоциягә корылган җөмләләр, слэнг һәм хэштеглар кулланыла. Мәсәлән: Бу идея бөтенләй топ! Реально шәп контент! Блогерлар аркасында шундый тренд барлыкка килде.

Татар тел җәмәгатьчелеге, тел галимнәре һәм иҗтимагый активлар бу процессны игътибар белән күзәтәләр. Кайбер терминнарга милли аналоглар тудыру омтылышы да бар: контент – эчтәлек, лайк – ошату билгесе, сторис – кыска видеоязма, чат – аралашу бүлмәсе, пост – язма хәбәр. Тик бу аналоглар һәрвакытта да киң кулланышка кереп китә алмый. Чөнки глобаль коммуникация тизлеге, технологияләргә ияләшү темпы алынма сүзләрне өстенлекле итә.

Телгә интернациональ алынмалар – ул күп телләрдә бер үк мәгънәдә кулланыла торган, гадәттә, фән-техника, мәдәният, икътисад, массакүләм коммуникация кебек өлкәләрдән алынган сүзләр. Бу сүзләр, кагыйдә буларак, дөньяның төрле халыклары өчен уртак төшенчәләрне белдерә һәм күпчелек вакытта инглиз, француз, латин, грек, немец телләреннән керә. Татар телендә дә мондый интернациональ алынмалар еш кулланыла һәм бигрәк тә интернет-текстларда, яшьләр мохитендә киң таралган.

Бу төр алынмалар телгә универсальлек, заманча яңгыраш кертә. Алар еш кына яңалык, заман белән бергә атлау билгесе булып тора. Күп очракта бу сүзләр татар теленең фонетик һәм грамматик кагыйдәләре буенча үзләштерелә яки оригинал формасында кулланыла. Кайвакыт алар җөмлә эчендә бөтенләй үзгәрешсез кала.

Тикшерүләр күрсәткәнчә, Telegram төркемнәрендәге язмаларда, Instagram һәм YouTube постларында алынма сүзләр еш кулланыла. Аларның төп функциясе – интернет аралашуның тизлеген, уңайлылыгын тәэмин итү; яңа күренешләрне, техник терминологияне, глобаль мәдәнияттән килгән концептларны аңлату. Мәсәлән, лайк, фолловер, сторис, стрим, креатив, вайб кебек сүзләрне татар телендә еш очрату мөмкин.

Мондый алынма сүзләр сөйләмгә яңа төсмерләр кертә, аны эмоциональ, стилистик яктан баета. Алар еш кына татарча сөйләмгә яраклаштырылган формада языла: лайкладым, контентлар, сторисны карагыз кебек конструкцияләр сөйләмдә һәм язуда актив кулланыла. Бу сүзләрнең кайберләре татар телендә тулы эквивалентларга ия түгел, шуңа күрә аларны

алыштыру мөмкинлеге чикләнгән. Шул сәбәпле, алар татар интернет-мәгълүмат даирәсендә үз урынын тапкан, телнең яңа сөйләм стилен формалаштыручы элементлар булып тора.

Алынма сүзләр татар теленең төп лексик фондын тулыландыра, аеруча яңа төшенчәләрне ачык белдерүдә зур роль уйныйлар. Заманча технологияләр, интернет-медиа, мәдәни һәм социаль күренешләр белән бәйле терминнар (стрим, блогер, контент, лайк, сторис һ.б.) татар телендә дә актив кулланыла башлады. Бу сүзләрнең кулланылышы, беренче чиратта, татар теленең лексик байлыгын арттыруга, аның сөйләмдәге функциональ мөмкинлекләрен киңәйтүгә китерә. Шулай ук алынма сүзләрнең татар теленең грамматик һәм морфологик үзенчәлекләренә җайлашуы, кушымчалар алу (сторислар, блогерлар, лайкладым) һәм яңа сүзтезмәләр төзелүе (контент ясау, креатив фикер) аларның телдә урнашуының ачык күрсәткече булып тора.

Интернет-текстларның үзенчәлекле лингвистик даирә булуы һәм яшьләр телен формалаштырудагы роле дә аерым игътибарга лаек. Телне киң куллану һәм аралашу өчен иркен шартлар тудыручы Telegram төркемнәре, социаль челтәрләр яшьләрнең телгә булган мөнәсәбәтен һәм аны куллану стильләрен үзгәртә, шул ук вакытта телдәге инновацион лексик берәмлекләрнең таралуын һәм кабул ителүен тизләтә. Мондый мәйданчыкларда алынма сүзләр иҗади һәм табигый рәвештә, бер-берсенә кушылып, телнең сөйләм стилен һәм эмоциональ төсен формалаштыра. Кайбер очракларда бу күренешләр телгә байлык өсти, ләкин икенче яктан, туган телнең сафлыгы, аутентиклыгы кимү куркынычы да тудыра. Чөнки алынмалар арткан саен, ана телендәге традицион сүзләр, милли лексика кырына этелә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Закиров, М. Глобализация һәм тел: татар теле контексты. – Казан: Казан дәүләт университеты нәшрияты, 2020. – 280 б.

2. Әхмәтова, Ф. Ә. Татар теленең интернет-мәгълүмат мохитендәге үсеше // Тел фәннәре. – 2019. – № 2. – Б. 110–118.

3. Гобәйдуллина, Л. Л. Социаль челтәрләрдә алынма сүзләрнең лингвистик анализы. – Казан, 2021. – Б. 78–85.

© Хаматханова А.Ш., 2025

УДК 1751

**Хамдамова Х.Ш.,**
*доцент кафедры узбекского и иностранных языков,*
*Джизакский политехнический институт,*
*г. Джизак, Узбекистан*

## ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ СТАТУС ПАРЕМИЧЕСКИХ ЕДИНИЦ

***Аннотация.*** *В данной статье рассматривается паремии, которые являются значительной частью фразеологического фонда русского языка. Это родовое понятие, включающее паремии, поговорки, присловья, приметы и др. Как правило, в паремиях сформулирована некая истина или побуждение (императив). Данные языковые единицы обобщают, часто в образной форме, коллективный жизненный опыт и отражают культурные установки и стереотипные представления общества, поэтому паремии представляют собой богатый материал для лингвокультурологических исследований.*

***Ключевые слова****: паремии, культура, поговорки, присловья, приметы.*

К современным паремиям отнесены паремии, поговорки, крылатые единицы, а также их трансформации, созданные современными носителями русского языка. Источниковой базой выступает современные толковые и энциклопедические словари, «Большой словарь

крылатых слов и выражений русского языка», словарь «Антипаремии русского народа», современные сборники русских паремий и поговорок.

Исследователи неоднократно отмечали эту «парадоксальность», «действительность», «срединное положение», «амбивалентность» пословично-поговорочных изречений, позволяющую рассматривать их и как языковые, и как речевые знаки. Характерной особенностью паремии является тот факт, что, с одной стороны, она принадлежит системе языка, а с другой, тесно связана с конкретной речевой ситуацией, т.е. текстом. Особенность паремии заключается в том, что она, как правило, «несёт в себе информацию не об элементе, а о фрагменте внеязыковой действительности» (Савенкова, 2002), что даёт возможность отнести паремии и поговорки к дискурсивным знакам. Однако несмотря на тесную связь семантики паремии с её конкретной реализацией в речи, данные единицы не могут быть рассмотрены только как элементы дискурса вне своего места в языковой системе, поскольку он представляют собой устойчивые, клишированные выражения, зафиксированные в словарях и фольклорных сборниках.

Некоторые исследователи придерживаются противоположной точки зрения, например, Н.Н. Амосова считает, что ни по содержанию, не по функции паремии не могут быть включены во фразеологию (Амосова, 1963). Г.Л. Пермяков пишет, что паремии сложнее фразеологизмов, поэтому можно говорить об отдельном паремиологическом уровне языка (Пермяков, 1998). При определении лингвистического статуса паремических единиц паремических единиц важно принимать во внимание, на изучение какого аспекта паремий и фразеологизмов нацелено то или иное исследование.

Е.Ю. Никтовенко считает, что «в тех исследованиях, в которых акцент делается не на структурные, а на семантические особенности языковых единиц, разграничение фразеологизмов, паремий, поговорок, и афоризмов не является принципиальным» (Никтовенко, 2013).

С учётом существующих подходов к изучению паремиологического фонда русского языка было принято широкое понимание паремии, включающее паремии, поговорки, а также мелкие жанры (как, например, молвушки), при этом паремические единицы отнесены к фразеологии. Такое понимание данного явления отвечает целям работы и позволяет более полно проанализировать прагматический и лингвокультурологический потенциал паремических единиц.

В современной паремиологии актуализируются три из пяти смысловых зон образа «Родина». Две смысловые зоны – страна, гражданином которой являешься, и место рождения – составляют ядро концепта, три другие входят в периферийную зону и незначительны по объёму. В качестве синонимов лексемы родина, согласно данным «Словаря синонимов», выступают слова отечество, отчизна, колыбель, а также словосочетания родная сторона (сторонка), родной край, отчий дом, родное пепелище. В контекстном употреблении лексема родина нередко отождествляется с Россией, Русью, страной, русскими, народом. Следовательно, и данные слова, находясь в логическом центре паремий, репрезентирует изучаемый концепт. Очевидно, что в качестве вербализаторов образа Родина названные лексемы и словосочетания будут служить объективаторами информации о месте рождения человека в конкретном ключе и в целом создавать полное представление об исследуемом концепте.

К современным паремиям отнесены паремии, поговорки, крылатые единицы, а также их трансформации, созданные современными носителями русского языка. Источниковой базой выступает современные толковые и энциклопедические словари, «Большой словарь крылатых слов и выражений русского языка», словарь «Антипаремии русского народа», современные сборники русских паремий и поговорок.

Анализ толковых и энциклопедических словарей позволяет выявить пять основных лексико-семантических вариантов имени концепта:

1) место рождения (все толковые и энциклопедические словари);

2) страна, гражданином которой являешься (все толковые словари);

3) место возникновения конкретного этноса;

4) место комфортного существования [Ожегов 2006: 578];

5) место возникновения или происхождения чего-либо (все толковые и энциклопедические словари). Выявленные лексико-семантические варианты представляют одновременно основные смысловые зоны образа Родина, соотносимые с вполне конкретными репрезентантами.

Вербализаторами смысловых зон «место рождения» и «место комфортного существования» выступают лексемы и словосочетания родина, отечество, отчизна, дом, отчий дом, родная сторона (сторонушка, сторонка). Вербализаторами смысловых зон «страна, гражданином которой являешься» и «место возникновения конкретного этноса» выступают лексемы и словосочетания Россия, Русь, страна, русские, народ, святая Русь.

В переносном употреблении часть названных репрезентантов (имя образа «Родина» и лексема колыбель) могут выступать вербализаторами смысловой зоны «место возникновения или происхождения чего-либо». Когнитивный анализ высказываний обнаружил, что чаще всего актуализируется смысловая зона «страна, гражданином которой являешься». Детализация означенного смысла осуществляется через оценку взаимоотношений государства и гражданина.

Таким образом, С. Байков внес огромный вклад в изучение жизни и творческой деятельности Ш. Мухаммедова. Его деятельность по пропаганде художественного наследия писателя не прошла бесследно, его труды стали основой для будущих изысканий татарских литературоведов по творчеству Ш. Мухаммедова.

**Список литературы**

1. Байков С. Шакир Мухаметов // Чкаловская коммуна. – 1939. – 3 апрель.
2. Байков С. Язучы Ш. Мухамедов турында // Совет әдәбияты. – 1940. – № 4. – Б. 91–96.
3. Гарифуллина В.И. Идейно-художественное своеобразие творчества Шакира Мухаммедова: автореферат дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2009. – 22 с.
4. Гимадиев У.И. Карсыга – революцион-демократик сатира журналы. – Өфө: Башкорт. кит. нәшр., 1976. – 136 б.
5. Мөхәммәдев Ш. Сайланма әсәрләр / Тезучесе М. Гайнуллин /. – Казан: Таткнигоиздат, 1958. – 402 б.
6. Нуруллин И.З. Путь к зрелости (о зарождении и развитии критического реализма в татарской литературе). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. – 270 с.
7. Сафуанов С.Г. Из когорты первооткрывателей // Ватандаш. – 2009. – № 2. – Б. 65–70.

© Шарипов М.С., 2025

УДК 821.512.145

**Юнусова Э.Ф.,**
*студент 3 курса Елабужского института КФУ*
*Научный руководитель* – **Габидуллина Ф.И.,**
*доцент кафедры филологии Елабужского института КФУ,*
*г. Елабуга, Россия*

# НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВАНЫҢ «СИХЕРЧЕ» ПОВЕСТЕНДА ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫ

***Аннотация***. *Әлеге мәкаләдә Нәбирә Гыйматдинованың «Сихерче» повестендагы хатын-кыз образлары тикшерелә. Нәбирә Гыйматдинова – танылган татар язучысы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе, 1956 елда Татарстанның Аксубай районында туа. Аның иҗатына проза һәм шигъри әсәрләр, шулай ук публицистика керә. Әдипкә дөньякүләм танылу китергән әсәрләрнең берсе – «Сихерче» повесте. Аның үзәгенә мистик һәм фәлсәфи мәгънә белән тулы Сәвилә, Убыр, Мәликә образлары алынган. Табигатьне саклау һәм гаделлек өчен ихласлык күрсәтеп көрәшүче Сәвилә образы аерым урын алып тора. Повесть кешенең табигать белән бәйләнешенең мөһимлеген ассызыклый һәм тискәре сыйфатларның әйләнә-тирә дөньяга ничек йогынты ясавын күрсәтә.*

***Терәк сүзләр:*** *татар әдәбияты, проза, поэзия, повесть, экологик проблемалар, табигать, гаделлек, татар язучысы, бүләкләр, мистик-фантастик стиль, образ, герой.*

Нәбирә Минәхмәт кызы Гыйматдинова (Бикчурова) 1956 елның 20 октябрендә Татарстанның Аксубай районы Карасу авылында туа. 1971 елда Карасу сигезьеллык мәктәбен тәмамлый һәм Иваново шәһәренә китеп, Туку комбинаты каршындагы училищеда эрләүче һөнәренә укырга керә. 1973 елда Казанга күчеп кайта, анда төзелеш оешмаларының берсендә маляр-штукатур булып эшли башлый, хезмәтеннән аерылмыйча укып, кичке урта мәктәпне тәмамлый. 1976-1981 елларда Н. Гыйматдинова Казан дәүләт университетының журналистика бүлеге студенты була. «Университетны тәмамлагач, ВЛКСМның өлкә

комитетында республикадагы әдәби түгәрәкләр һәм берләшмәләрнең эшен оештыру җитәкчесе булып эшли. Аның турыдан-туры ярдәме белән һәм шәхси катнашында Татарстан районнарында дистәләгән әдәби түгәрәкләр оештырыла» [1; 175].

1989 елның июлендә, татарча «Идел» яшьләр журналы чыга башлаганнан соң, Н.Гыйматдинова бу журналның бүлек мөхәррире вазифасын башкара, ә 2006 елдан башлап ул баш мөхәррире булып эшли.

Н. Гыйматдинова – татар язучысы, проза һәм поэзия жанрдагы әсәрләр авторы. Аның иҗатына хикәяләр, повестьлар, шулай ук публицистик мәкаләләр дә керә. Әсәрләре үзенчәлекле мистик-фантастик манерада языла. Н. Гыйматдиновага табигатьнең серле көчләре белән кызыксыну хас. Аның геройлары – авыр язмышлы һәм гаделлек турындагы үз карашларын кыю яклаучы кешеләр.

Язучының беренче әсәрләре («Йолдызлы кичтә», «Таңсылу») матбугатта 70 елларда күренә башлый. Әлеге хикәяләр 1974 елда «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») һәм «Идел» альманахы битләрендә дөнья күрә. Аннан соң республика газета-журналларында яшьләр тормышыннан алып язылган бер төркем хикәяләре һәм «Китмә, улым» (1977), «Су хикәяте» (1978) исемле лирик повестьлары һәм 1981 елда аерым җыентыгы басылып чыга.

Нәбирә Гыйматдинова күптөрле исемнәргә һәм бүләкләргә лаек. 1985 елда ул Шәйхи Маннур, 2001 елда Фатих Хөсни, 2009 елда Муса Җәлил, 2013 елда Тукай премияларның лауреаты була. 1996 елда Татарстан республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исем ала. Аның «Сихерче», «Бүре каны», «Бер тамчы ярату» повестьлары Аксубай, Түбән Кама һәм Казандагы Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәләрендә куелды. Аның китаплары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Милли китапханәсе үткәргән «Ел китабы» рейтингында җиде тапкыр беренче урыннарны яулады. Аның әсәрләре «Татар әдәбияте» мәктәп программасына кертелде. 2016 елда Н. Гыйматдиновага «татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен» Татарстан Республикасының халык язучысы исеме бирелә һәм 1981 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы булып санала. Хәзерге көндә Нәбирә Гыйматдинова иң яратып укыла торган авторларның берсе булып санала.

Әйтеп китергә кирәк, язучыны дөньяга таныткан әсәрләрнең берсе – «Сихерче» повесте. Төп герой – Сәвилә. Икенче дәрәҗәдәге геройлар – Убыр, Мәликә, Тәминдар һәм башкалар. Убыр – бик тә белемле карчык. Ул дару үләннәренең, табигатьнең шифаларын белә, аның иманы нык. Ләкин кешеләргә изгелек эшләүдән үзенә бик күп зарар ала. Кешеләр аның үзләре кебек булмавыннан куркалар, шуңа да читләшә башлыйлар һәм тора-бара бөтенләй исемен дә онытып, кушамат белән дәшә башлыйлар. Аның иманының ныклыгы, дөреслекне ярып әйтә белүе башкалар өчен шулкадәр куркыныч була, хәтта ул үлгәч аның йортын да тизрәк яндыру ягын карыйлар. Сәвилә – Убыр янына аның гыйлемнәрен өйрәнергә һич куркусыз йөри, чөнки ул үзе дә Убыр шикелле үк төркемнән аерым. Ул да дөреслекне ярып әйтүче, кыю. Ләкин әле бу образ үсештә, формалашып бетмәгән. Мәликә – азгын, куштан, алдакчы. Тәминдар образын калкурак ачар өчен бу образга кара бояу бик күп салына. Тәминдар – Мәликәнең ире. Автор безгә әлеге гаиләнең туу тарихын сөйләми, ләкин шунысы билгеле – Тәминдар Мәликә белән бәхетсез. Тәминдар хәтта үз-үзенә кул салыр дәрәҗәгә җитә. Сәвилә ирен ярата, аның бәхетле булуын тели. Кызны коткарам дип ут эченә ташланган ир, әлбәттә, бәхеткә лаек. Ләкин Сәвилә моны ирнең үзенең аңлавын тели.

Аландагы очрашу – Тәминдарның хисләре уянуы ул. Хисләр уяну өчен табигатькә якынрак булырга, янәшәңдә синең күңелеңне аңлаучы булуы кирәк. Аланда Сәвиләне Тәминдар күбәләккә тиңли. Күбәләк – матурлык, ирек символы. Күбәләккә иркенлек кирәк. Аны тоткын итеп булмый. Сәвиләнең хисләре дә шул күбәләк кебек. Ул кулыннан күп нәрсә килсә дә, Тәминдарны үзенә бәйләр өчен бернәрсә дә эшләми, мәхәббәттә ирек кирәклеген дәлилли.

Әлеге повестьнең геройлары уңай да, тискәре дә түгел, аларда яхшы да, начар сыйфатлар да бергә үрелеп яши, ләкин кайбер персонажларда я усаллык, я шәфкатьлелек артыграк. Язучының төп геройлары үзләренә көчне табигатьтән алалар. Алар – табигать

балалары. Әдип кешеләрне табигать кочагына кире әйләнергә өнди, табигать белән тыгыз бәйләнештә булмаганда адәм баласы шәфкатьлелек, бер-береңне аңлау, ягымлылык, хөрмәт итү һәм башка шундый сыйфатларны югалта баруын күрсәтмәкче була.

Сәвиләнең максаты – табигатьне саклау, башкаларны да шуңа өндәү. Автор моны төрле яссылыкта исбатлый – агуланган чикерткә язмышы моңа мисал була ала. Чикерткә кешеләр – явызлыгының корбаны. Ә кешеләр табигатьтән ераклашкан саен явызланан баралар һәм үзләренең явызлыкларының корбанына әвереләләр. Әнә табигать өчен борчылып йөргән Сәвиләне мыскыл иткән көтүче Җәлилнең авызы чалшая. Аяклары йөрмәгән нәни кызчыкны бары табигать кочагында, аның шифасы белән аякка бастыра. Шунысына игътибар итәргә кирәк – Сәвилә дәвалаган кешеләр барысы да кешеләр явызлыгының корбаннары: исерек атадан куркып калган кыз, ярамаган агулы сыеклык эчкән исерек ир, тормыш авырлыгыннан кырысланган каты куллы ана.

Сәвиләнең тормыш максаты аркылы табигатькә сакчыл караш, экологик проблема күтәрелә. Чишмәгә, болынга, кырларга булган мөнәсәбәт аркылы автор укучыны уйланырга чакыра. Бу төп проблема.

Гаилә ныклыгы проблемасы Мәликә белән Данияр вакыйгасы, Тәминдар белән Мәликә мөнәсәбәтләрендә ачык чагыла. Гаилә нык булсын өчен дөрес, тугрылыклы мөнәсәбәтләр кирәклеге дәлилләнә. «Повестьта мәхәббәтнең сихердән дә көчлерәк булуы ассызыклана. Әмма Тәминдарның җәмгыять кануннары буенча яшәргә омтылуы өстенрәк булып чыга. Сәвиләне калдырып, хыянәтче хатыны Мәликә белән шәһәргә юллануы – Тәминдарны тирә-яктагы битараф кешеләр рәтенә куя» [4; 144], – дип билгеле әдәбият белгече А.Хәлиуллина.

«Нәбирә Гыйматдинова әсәрләрендә төп геройларны бер уртак сыйфат берләштерә: хатын-кызлар башкаларга охшамаган, дөньяга үзләренчә карыйлар, изге-олы күңелле, чибәр һәм мәрхәмәтле, тәбигатьне бөтен җаннары белән яраталар һәм аның телен, җанын аңлыйлар. Алар чын, керсез, тирән ярату белән ярата беләләр, ләкин тормышта бәхеткә ирешә алмыйлар. Беренче карашка әсәрләрдәге башка геройларга замандаш түгел кебек. Матди байлык артыннан күбрәк куып, табигатьтән ераклаша бару, азгынлык, эчкечелек кебек сыйфатларның бүгенге тормышыбызга үтеп керүе, кешеләрнең явызлануы, тупаслануы фонында төп геройларның уй-кичерешләре, характерлары күңелләрне айкап алырлык, тирән уйлануларга мәҗбүр итәрлек дәрәҗәдә укучыга җиткерелә ала» [1; 178].

**Кулланылган әдәбият**

1. Гыйләҗева-Хәмидуллина Р. «Сихерче»ләр кирәк дөньяга // Казан утлары. – 1994. – № 4. – Б. 175–178.

2. Гыйматдинова Н. Сихерче: повестьлар, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 286 б.

3. Заһидуллина Д. Яңа дулкында // Казан утлары. – 2003. – № 1. – Б. 133–135.

4. Халиуллина А. Заман һәм герой. – Уфа: Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы, 2007. – 206 с. – EDN VVVCOZ.

© Юнусова А.Ф., 2025

УДК 372.881.161.1

**Юсупова Л.Р.,**
*преподаватель Казанского колледжа технологии и дизайна,*
*г. Казань, Россия*

# ФОРМИРОВАНИЕ КОММУНИКАТИВНОЙ КОМПЕТЕНЦИИ У СТУДЕНТОВ СПО В ПРОЦЕССЕ ИЗУЧЕНИЯ ЛИНГВИСТИЧЕСКИХ ДИСЦИПЛИН

***Аннотация.*** *В статье рассматривается сущность коммуникативной компетенции как комплексного образования, включающего совокупность знаний, умений, навыков и мотивационных компонентов, необходимых для эффективного общения в профессиональной и социальной сферах. Коммуникативная компетенция понимается не только как владение языковыми средствами, но и как способность адекватно воспринимать и интерпретировать язык в различных контекстах, учитывать коммуникативные цели и особенности собеседника. Особое внимание в работе уделяется интеграции теоретических знаний с практическими упражнениями, также предложены рекомендации по организации учебного процесса, способствующего повышению уровня коммуникативной компетентности студентов. Формирование коммуникативной компетенции у студентов СПО является ключевым элементом развития их личностных и профессиональных качеств.*

***Ключевые слова:*** *компетенция, коммуникативная компетенция, студенты СПО, развитие коммуникативной компетенции, учебный процесс.*

Среднее профессиональное образование представляет собой важный и неотъемлемый элемент системы российского образования. Оно функционирует как связующее звено в единой структуре непрерывного образования и направлено на удовлетворение различных потребностей личности, общества и государства. Основная задача данного уровня образования – обеспечить граждан квалифицированными знаниями и сформировать профессиональные компетенции, необходимые для квалифицированной работы специалистов среднего звена. При этом СПО способствует социально-экономическому развитию страны, готовя квалифицированные кадры, востребованные на рынке труда и способные адаптироваться к вызовам современного производства и технологий.

Лингвистическое образование является важнейшей составляющей профессиональной подготовки будущих специалистов. Оно занимает ключевое место благодаря своему значительному потенциалу для развития личностных качеств, способности к саморегуляции и эффективному межкультурному взаимодействию. Кроме того, лингвистическое образование способствует формированию навыков коммуникации и адаптации в многоязычной и многокультурной среде, что особенно важно в условиях глобализации и профессиональной мобильности.

Коммуникативная компетенция – ключевой компонент профессиональной подготовки студентов среднего профессионального образования (СПО). В современных условиях она становится важным инструментом успешной социальной и профессиональной адаптации выпускников. Лингвистические дисциплины играют значительную роль в формировании этой компетенции, обеспечивая развитие навыков эффективного межличностного общения, понимания речевых норм и культурных особенностей. Коммуникативная компетенция включает в себя не только знание языка, его грамматики и лексики, но и умение использовать эти знания в реальных коммуникативных ситуациях с учётом социально-культурного контекста, целей и ролей участников общения. В рамках СПО она подразумевает формирование речевой, социокультурной, стратегической и языковой компетенций.

Проблема формирования коммуникативной компетенции широко освещена в научных исследованиях, среди которых выделяются работы Куницыной В.Н., Гордон Т., Емельянова Ю.Н., Холодной М.А., Столяренко Л.Д., Хаймса Д. и других авторов.

Понятие «коммуникативная компетенция» возникло в 1960-х годах XX века и было введено Деллом Хаймсом. Он определял этот термин как область эффективного общения, основанную на освоении средств и стратегий речевого взаимодействия, которые поддерживаются языковыми навыками и речевыми умениями [3].

Он характеризовал её как способность использовать различные виды компетенций:

– языковую компетенцию – умение создавать и понимать правильные речевые сообщения;

– дискурсивную компетенцию – умение актуализировать текст в конкретных условиях общения;

– иллокутивную компетенцию – формирование и реализация коммуникативных намерений в сообщении;

– социолингвистическую компетенцию – учет социального контекста ситуации общения;

– стратегическую компетенцию – планирование начала, хода и завершения коммуникации для достижения успеха;

– паравербальную компетенцию – использование невербальных средств общения, таких как интонация и жесты;

– лингвокультурную компетенцию – соблюдение культурных и этических норм общения;

– межкультурную компетенцию – знание и понимание ценностей как своей, так и другой культуры [2].

Коммуникативная компетенция – это умение эффективно достигать целей в устном и письменном общении; уметь собирать необходимую информацию, анализировать её и ясно выражать свои мысли публично, при этом проявляя уважение и понимание к мнениям и ценностям других людей [5].

По мнению Вербицкого А.А., коммуникативная компетенция – это «совокупность знаний об общении, умений и навыков, нужных для понимания чужих и построения собственных программ речевого поведения, адекватных целям, сферам и ситуациям общения» [1].

Так, коммуникативная компетенция представляет собой освоение всех видов речевой деятельности, умение воспринимать чужие и создавать собственные речевые модели, соответствующие целям, сферам и ситуациям общения. Она охватывает знание ключевых речевых понятий: различные стили и типы речи, структуру описания, повествования и рассуждения, способы логического связывания предложений в тексте, а также развитие навыков анализа текста.

Целью развития коммуникативной компетенции студентов является подготовка будущего специалиста, владеющего способностью и готовностью реализовать свой профессиональный коммуникативный замысел [4, 36].

Русский язык является базовой дисциплиной, в процессе изучения которой обучающиеся развивают коммуникативную компетенцию, необходимую для самоопределения и самореализации. Формирование коммуникативной культуры начинается ещё в детском саду. На протяжении обучения в начальной и основной школе одной из ключевых видов деятельности остаётся развитие речи, умение вести диалог и монолог, а также слушать собеседника.

Главная задача урока русского языка, помимо совершенствования устной и письменной речи и её правильного использования, заключается в формировании у обучающихся умения свободно выражать свои мысли полно, логично и уверенно, не боясь проявлять свою индивидуальность.

Элементы профессиональной направленности можно вводить на любом этапе занятия: при объяснении нового материала, его закреплении, выполнении творческих и самостоятельных заданий, практической работе или на уроках контроля. Для более полного

раскрытия творческого потенциала студентов, активного общения и свободного выражения мыслей эффективны нетрадиционные формы уроков и разнообразие видов деятельности.

Групповая работа и уроки-диспуты являются одними из наиболее эффективных методов, позволяющих детям выстраивать взаимоотношения на основе терпимости и уважения. В процессе коллективной работы обучающиеся учатся учитывать мнение каждого участника, аргументированно отстаивать собственную позицию, достигать совместных результатов. Это формирует у них навыки активного слушания, умение слышать собеседника. Так, на уроках, посвящённых функциональным стилям русского языка, при изучении особенностей официально-делового стиля обучающиеся знакомятся с оформлением различных документов, например, трудовых договоров, статьями Трудового кодекса РФ. Аналогичный подход применяется при разработке текстов технологических карт в профессиональных направлениях, таких как «Торговое дело» или «Технология текстильных изделий», что помогает студентам не только понять стиль и структуру профессиональной документации, но и приобрести важные компетенции для дальнейшей деятельности.

Занятия, которые начинаются с постановки проблемной ситуации, создают условия для формирования коммуникативной компетенции обучающихся. Они стимулируют студентов анализировать возникшие вопросы, искать возможные пути их решения, брать на себя ответственность за результаты, а также выражать свои предположения с убедительной аргументацией. Так, можно провести урок-практикум «Как написать резюме?» ув группах в рамках изучения темы «Официально-деловой стиль», что позволит не только освоить теоретический материал, но и применить его на практике. Также можно провести в учебных группах обсуждения профессиональных речевых ситуаций, где отрабатываются важные умения и навыки: профессиональная речевая культура, культура телефонного разговора с соблюдением норм и техники, а также правила корректного поведения в конфликтных ситуациях. На практических занятиях по разделу «Лексика» можно работать с различными группами слов, в том числе с профессионализмами. Важную роль в развитии коммуникативной профессиональной компетенции играет работа со словарём специальных терминов: студенты учатся находить дополнительные лексические значения профессиональных слов, расширять и обогащать свой активный словарный запас либо уточнять значение уже знакомых терминов. Такой подход способствует более глубокому пониманию профессиональной лексики и её грамотному использованию в коммуникации.

Лексико-семантическая работа со словарными словами включает в себя несколько эффективных методов. Учащимся предлагается подобрать синонимы к профессиональным терминам, составить тесты с использованием ранее изученной на спецпредметах терминологии, зашифровать слова в ребусах или создать кроссворды на основе словарных слов. Формулирование вопросов к кроссворду способствует усвоению терминов и научит правильно их использовать в речи будущего специалиста.

Традиционная работа с текстом может быть тесно связана с изучаемой профессией. Например, обучающимся даётся задание подобрать тексты из научной литературы по специальным предметам и распределить их по трём функционально-смысловым типам речи: описание, повествование и рассуждение. Работа с текстом выступает универсальным инструментом, который помогает не только решать задачи предметного обучения, но и повышает интерес к будущей профессии. При помощи специализированных текстов можно проводить комплексный анализ, актуальный на любом этапе усвоения материала – от изучения и закрепления до обобщения и контроля знаний и навыков.

На занятиях языка можно применять следующие типовые задачи, направленные на развитие коммуникативных учебных действий:

1. Аудирование и понимание текста (прослушивание аудиозаписи с последующим ответом на вопросы (общего и частного характера), выполнение заданий на выбор правильного варианта ответа, вычленение ключевой информации (например, отметка правильных утверждений, заполнение таблиц);

2. Диалогическое общение (ролевые игры (ситуация на работе), интервью или опрос одногруппника по заданной теме, вопросно-ответные упражнения с партнером (обсуждение хобби, планов);

3. Монологическая речь (подготовка и устный рассказ по теме (описание героя, памятного события), составление и защита своей точки зрения по предложенной проблеме, пересказ прочитанного текста или серии картинок с логической связью);

4. Чтение и интерпретация текстов (чтение текста с последующим составлением плана, ответы на вопросы разного уровня сложности, сопоставление информации из нескольких текстов и ее краткое пересказ);

5. Письменное выражение мыслей (написание эссе или сочинения с введением, основной частью и заключением; составление письма (официального или неофициального), составление заметки, отзыва или описания);

6. Работа с языковой нормой (выполнение упражнений на подбор правильных форм слов и грамматических конструкций, исправление речевых ошибок в устных и письменных высказываниях, упражнения на произношение и закрепление орфоэпических норм).

Каждая типовая задача включает разнообразные задания, которые развивают разные аспекты коммуникативных умений: понимание речи, говорение, чтение, письмо, а также контроль языковой правильности, что способствует целостному формированию коммуникативных учебных действий.

Таким образом, формирование коммуникативной компетенции у студентов СПО посредством изучения лингвистических дисциплин является необходимой предпосылкой успешной профессиональной деятельности и социальной интеграции выпускников. Эффективная методика обучения, основанная на сочетании теоретических знаний и практических навыков, способствует развитию комплексных коммуникативных умений, востребованных в современном обществе и профессиональной среде.

**Список литературы**

1. Вербицкий А. А., Ларионова О.П. Личностный и компетентностный подходы в образовании. Проблемы интеграции. – М.: Логос, 2009. – 336 с.

2. Зимняя И. А. Компетенция и компетентность в контексте компетентностного подхода в образовании // Иностранные языки в школе. – 2012. – № 6. – С. 2-10.

3. Изаренков Д.И. Базисные составляющие коммуникативной компетенции и их формирование на продвинутом этапе обучения студентов-нефилологов / Д.И. Изаренков. – Текст: непосредственный // Русский язык за рубежом. – Москва, 1990. – 255 с.

4. Коммуникативная компетенция и ее развитие у студентов вуза в условиях преемственности образования: монография / М. В. Стурикова. – Екатеринбург: Изд-во Рос. гос. проф.-пед. Ун-та, 2020. – 164 с.

5. Кретинина Г.В., Гончарова Н.А. Аксиологический компонент процесса обучения студентов иностранным языкам // Теория и методика обучения иностранным языкам: традиции и инновации. Шатиловские чтения. – Санкт-Петербург, 2018. – С. 121-123.

© Юсупова Л.Р., 2025

УДК 821.512.145

**Юсупова Н.М.,**
*профессор кафедры татарской литературы КФУ,*
*г. Казань, Россия*

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ПОЭЗИЯСЕНДӘ ПОСТМОДЕРНИСТИК ЭЗЛӘНҮЛӘР

***Аннотация***. *Әлеге мәкаләдә хәзерге татар шигърияте үсешенең һәм трансформациясенең төп тенденцияләре ачыклана. Шигъри әсәрләр материалында хәзерге татар поэзиясенең үсеше традицион, модернистик һәм постмодернистик парадигма арасында катлаулы юлдан бара дип әйтелә. Тикшерү барышында хәзерге татар поэзиясендә постмодернист тенденцияләрнең үзенчәлекле әдәби моделе формалашуы күзәтелә. Постмодернист әсәрләрдә лирик геройның яңа тибы – перформатив герой формалаша: аның «ике дөньялы» онтологиясе бар: бер яктан әсәрнең аерымланган эчке дөньясында булуы, икенче яктан, аны тудырган авторга хас билгеле бер модус буларак, «безнең дөнья» чикләрендә аңа бер мизгелдә булуы.*

***Терәк сүзләр:*** *хәзерге татар поэзиясе, постмодернизм, тенденция, лирик герой.*

Хәзерге татар поэзиясе яңа экспериментлар ясау мәйданына әверелде. Әлеге яңарыш, иң беренче чиратта, татар шигъриятендә лирик герой концепциясенең үзгәрүеннән һәм дөнья сурәтенең алмашынуыннан башланып китә. Р. Зәйдулла, Р. Аймәт, Й. Миңнуллина, Б. Ибраһимов, Р. Мөхәммәтшин, Л. Гыйбадуллина һ.б. шигырьләрендә эзләнүләр аеруча көчле булып тоела.

Классик булмаган дөнья сурәтендәге хаотик тормышта ачыклык таба алмаган лирик геройның аң-фикер агышы Зөлфәт шигырьләреннән тамыр ала дисәк тә ялгышмабыз. «Ил халәте» (2001), «Безнең чор агайлары» (2002), «Каргыш» (2003), «Болгавыр» (2005), «Караңгы төнге җилләр» (2002), «Аймылыш» (2002), «Талсиртмәдә талбишек» (2002), «Читән күләгәсе» (2003), «Ялган ямь» (2004), «Соңгы язмыш яры» (2003), «Кое кибә...» (2006) кебек җәмгыятьтәге хаксызлыклар хакында сөйләгән шигырьләрендә әдип лирик геройның тәртипсез, бер-берсен еш алыштырып килгән хис-кичерешләр дулкынын сурәтләү объекты итеп күтәрә. Хаотик тормыш-яшәештә, дисгармоник тормышта өметләрнең акланмавын тойган лирик герой чарасызлык, үкенеч, фаҗига, югалу дулкынында сурәтләнә, ялгызак шәхескә әверелә. Еш кына ул кайгы, чарасызлыктан туган сызлану чигеннән битарафлыкка күчә яисә сагыш аша шатлыкка омтыла. Әлеге халәт әсәрләр структурасында монолог, төш, еш алышынган күзаллаулар аша җиткерелә.

Алга таба бу тип лирик герой Л. Зөлкарнәй тарафыннан үстерелеп китә. Әмма Зөлфәт шигырьләрендә хаотик халәт еш кына җәмгыятьтәге, лирик геройны әйләндереп алган тышкы дөньядагы хәл-халәткә мөнәсәбәтле булса, Л. Зөлкарнәй шигырьләрендә инде ул геройның үз эчке дөньясындагы, фикер-күзаллауларындагы үзгәрешләргә бәйле формалаша. Бу үзенчәлек татар шигъриятендә яңа сүз булып яңгырый. Л. Зөлкарнәй шигырьләрендә лирик геройның уй-фикерләре тоташ рефлексия төсен ала, аның хаотик халәттәге аң агышы импрессионистик алымнар ярдәмендә җиткерелә. Әлеге тип лирик герой урын алган шигырьләр еш кына Ш. Анак тарафыннан яратып кулланылган сөйләм шигыре формасында иҗат ителә. Мисал өчен, «Монолог» шигырендә лирик герой халәте шигырьнең исеме – көчле позиция аша ук төгәлләштереп куела, хаотик кичерешләр монолог төсендә җиткерелә:

Көйсез көнем, тезләреңне кочып утыр, / ә мин биим, биим бүген егылганчы, / биим менә елый-елый! [6, 290].

Саташулы, нәфрәтле халәттәге лирик герой яшәештәге күренешләрне үзгәртә алмаудан гаҗизлек баскычына килә. Лирик герой халәте туктаусыз әйләнгән, өзлексез хәрәкәттә булган Җир, иске тәлинкә образлары ярдәмендә ачыла, иске тәлинкә лирик геройның психологик яше белән биологик яше арасындагы аерманы да җиткерә. Шигырь ахырда үз чарасызлыгын аңлаган лирик геройның шушы халәте өчен әйләнә-тирәдәгеләрдән

гафу үтенүе белән каймап алына: Рәнҗемәгез, рәнҗемәгез миңа зинһар, / Ни хәл итим – елыйм бары, / Ни хәл итим – елыйм бары... / Елыйм [6, 290].

Әлеге тип лирик герой алга таба Сөләйман, Р. Аймәт, Л. Гыйбадуллина шигъриятендә үстерелеп китә. Сөләйманның лирик героенда, гомумән, хис-кичерешләрнең хаотик тәртибе, эзлексезлек, бер чиктән капма-каршы булган икенчесенә ташлану сыйфаты көчле: Ап-ачык, / Ап-ак, / Яп-якты – / Әҗәл. / Буталчык, / Кап-кара, / Караңгы – / Яшәү. / Гомер буе тартылабыз / Ачыклыкка, / Аклыкка, / Яктылыкка [9, 209].

Р. Аймәт шигырьләрендә дә хаотик яшәештәге лирик герой халәте аң агышы ярдәмендә сурәтләнә. Дисгаромник яшәештә бәхет тапмаган лирик герой, бу халәт-яшәешне үзгәртә алмавын аңлап, кешеләрдән читләшә («Мин җирләргә төштем», 2001), хыял дөньясына юл ала («Эзләмәгез мине», 2000).

Постмодерн эзләнүләр әкренләп шәхес концепциясеннән поэтик яссылыкка күчә бара. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, мондый әсәрләрдә дөньяны, яшәешне катлаулы бербөтен, театраль тамаша итеп сурәтләргә омтылу, җемелдәү эстетикасы (мотивларның җемелдәп алуы), күпъяклылык һәм фрагментарлык күренешләре урын ала [5, 190].

Әлеге алымнар белән Л. Гыйбадуллина шигырьләрендә очрашабыз. Мәсәлән, «Бер карышка – бер җан, бер карышка – мөлдерәмә тулы мизгел бары» башламы астына тупланган шигырьләргә кабатлау эстетикасы хас, бер үк элементларны, образларны кабатлау яңа мәгънә бөтенлекләренә алып чыга, иллюзияле сурәтлелек, эзлекле, төзек композициядән китү сыйфаты күренә. Шагыйрәнең шигъри теле образлы, ул киң кулланылыштагы образларны яңа мәгънәви бөтенлекләр белән баета, бер-берсенә тәңгәлләшмәгән образларны янәшә куеп, образларның мәгънәви чикләрен киңәйтә. Нәкъ шушы сыйфатлар төрле баскычтагы мәхәббәт тойгысын – илаһи мәхәббәтне, сөйгән ярга мәхәббәтне, милләткә мәхәббәтне сурәтләргә мөмкинлек бирә. Шушы мизгелләрне бер карышка җыя алган кеше җаны югары күтәрелә: Мин сине тапмаган дөньяда / Язларың, язларың сызлана... / Илереп җил елый, тәрәзгә / Тымызык көн нуры сылана... / Мин әзер, карадан киенеп, / Көз булып сурәткә төшәргә [4, 62].

Шушы ук үзенчәлек «Бу гавам сагыштан яралган» шигырендә дә күзгә ташлана, ак, кара образларын кабатлау төрле мәгънә бөтенлекләренә алып чыгарлык итеп корыла, яшәештәге һәр кыйммәтнең иллюзия булуы дәлилләнә: Бу гавам сагыштан яралган, / Төне дә, көне дә бер төстә. / Юллары ярылган, аклары каралган, / Каралык агарган бер кичтә, / Хыялдан коелган бу дөнья, / Уелган җаннарга ак сагыш, / Күкләрдән сак кына сибелгән / Мең сөю, мең ялгыш һәм каргыш [3, 107].

«Җир караңгы» шигырендә исә караңгы күк, караңгылык, шомлы җил, ялгыз ай кебек бик күп образлар аша төн картинасы тудырыла. Бер караганда, пейзаж лирикасы кебек кабул ителә. Әмма икенче строфага кертеп урнаштырылган бер фраза аны бу чикләрдән алып чыгып китә һәм кеше яшәешенә кагылышлы фикер белән баета: Йолдыз чүпләп караңгыдан гомер кичә…[2, 6]. Ул караңгы яшәештән яктылык эзләп яшәргә мәҗбүр кеше тормышын сурәтли башлый. Шуңа бәйле төстә ялгызлык мотивы җемелдәп китә.

«Соры томан арада…» шигыре дә шуңа охшаш. Автор халык җырына стильләштерелгән текст ясый, билгеле фольклор образларын яңарта: Соры томан арада, / Күк ярлары аллана. / Ә төн, ай-һай, кара ла… / Таң җиле юлда уйный, / Сулыгып йолдыз сулый, / Һәр нурдан кояш ургый, / Иртәнге чыкны урлый [2, 6]. Халык җырларындагы кебек үк, шигырьнең беренче өлеше табигать күренешләре хакында сөйли, ә икенчесендә лирик герой яшәүнең шатлыгы турында хәбәр итә, шуңа бәйле елмаю барлыкка килә.

Лириклык һәм символик сурәтлелеккә, детальләштерүгә, интертекстуаль бәйләнешләргә омтылыш Й. Миңнуллина иҗатының да үзәгендә тора. Шигырьләренең исемнәре үк көчле позициядә аерым фрагментлардан җыелган мәгънәне төгәлләштереп бара. Шул ук вакытта шигырь исемнәрендә асмәгънәгә ишарә ясала, һәм еш кына шул исем әсәр структурасына яшеренгән доминанта мәгънәне төгәләштереп куя. Мисал өчен, «Тиңсезлек» шигырендә озын һәм фрагментар монолог төрле дини юнәлешләрдәге яшьләрнең мәхәббәт тарихына ишарә итә. Әмма текстның үзендә әлеге мәгънә символик образ-детальләр артына яшерелә. Текст үсеп барган мәхәббәт хисе хакында сөйләп бара һәм ахырда аңардан баш

тарту белән тәмамлана. Әлеге мотивны әсәрнең буеннан-буена үзенчәлекле образ-символлар әйдәп бара: чәчкәләр – сары тюльпаннар, ясмин, роза; тавышлар: трамвай рельслары, паровоз тавышы, (тур быргысы – сур быргысы: дөньяның ахырын, кыямәт көнен символлаштыручы образ); хәрәкәтләр: урам, трамвай, Кабан күле, кафе, йорт, трамвай тукталышы, тимер юл вокзалы. Ел фасыллары бер-берсен алыштырып килә: карлы кыш, февраль – яз – җәйге яңгыр – көзге яңгыр. Мондый ассоциатив образлылык укучының игътибарын төрле якларга юнәлтә, яшь поп, дин вәкиленең мөселман кызына гашыйк булуы хакында сөйли. Шигырь ахырында лирик геройның әлеге кыз белән тәңгәлләштерелүе күзәтелә.

Ассоциатив сурәтлелек аша төзелгән катлаулы текст бик күп мотивларны бер бәйләмгә тупларга мөмкинлек бирә: мәхәббәт мотивы гөнаһ мотивы белән алышына; соңгысы мәхәббәт өчпочмагына ишарә ясый; анысы гомуми фикер белән тәмамлана: Исән генә йөрсен, / исән генә.... [7, 12].

Әмма боларның берсе дә автор фикере белән тәңгәлләшми, шагыйрә әсәр исеме аша гына аның тиңсезлек булуын төгәлләштереп куя. Әнә шулай әлеге әсәр, У. Эко терминологиясенә таянсак, «ачык текст» [8, 286] буларак бәяләнә ала, ягъни мәгънә мозаика формасында җиткерелә, һәм ул укучы аңына бәйле формалаша.

«Бозлы тәрәзәдә бармак эзе» шигырендә гадәти тормыш картинасы тергезелә: лирик герой шәһәрне күзәтә. Типик мозаик сурәтлелек урнаштырыла: кыш, әби оныгына оекбаш бәйли, мәчет каршында бер ир өеннән төнге шәһәргә чыгып югала. Әлеге фрагментар, аерым-аерым тезелгән детальләр иң соңгы ике юлда автор фикерен формалаштыра: Тоныклана бара шәһәр... / тының белән җылытмасаң әгәр [7, 13].

Автор фикеренчә, һәр кеше үз тирәлеген үзе булдыра, шул тирәлектә яшәү мәгънәсен дә үзе билгели, яшен кебек ялтырап үткән яшәештә үз урынын үзе билгели, бармак эзе әнә шуңа ишарәли.

Э. Байназаровның «Без» (2014) шигырендә дә охшаш образлылык һәм мотив чагылыш таба. Гомумән, бу яшь шагыйрьнең иҗатында образлы сурәтнең көчле булуы күзгә ташлана, ул катлаулы, көтелмәгән янәшәлекләр ярата (мәсәлән, «Кечкенә мәгънәсезлек»), композицион алымнардан сирәк мөрәҗәгать итеп торган монтаж алымын отышлы куллана. Мәсәлән, «Мүкләнгән диварлар җылысын кызганды» (2014) шигырендә укучы тыгыз сурәтлелек белән очраша, мүкләнгән дивар, бәсләнгән ирен кебек эпитет-метафоралар мәхәббәтнең салкынлыгын җиткерү юлында файдаланыла: ...Мүкләнгән диварлар җылысын кызганды, / бәсләнгән иреннәр дәшмәде артыгын; / бер язга сыймады атасы таңнары, / бер таңы җитмәде әйтергә актыгын [1, 140].

Ассоциатив сурәтлелеккә омтылган әсәрләр Р. Харис иҗатында да урын ала. Мәсәлән, күпкатламлы, күп мәгънәле метафорик-символик сурәтлелеккә корылган, укучының үзенә чишәргә калдырылган шигъри табышмакларны хәтерләткән, әзерлекле укучыга юнәлтелгән «Кара түгәрәк» шигыренә күз ташласак, сәнгати чаралардан көтелмәгән борылышлар, катлаулы чагыштырулар, сынландыру, янәшә кую, бер күренешнең мәгънәсен икенчесеннән табу, өченчесе ярдәмендә ачу – Р. Харисның лирик фикерләү үзенчәлеге – бу шигырьдә дә актуаль булып калуын күрәбез. Шигырьдә Малевичның «Кара квадрат»ындагы сурәтлелек шигъри метафора ролен башкарып, кара, яшел, сары һәм ал сызыклар яшәешне, кеше тормышындагы аерым мизгелләрне бәяләү югарылыгына күтәрелә. Кара / чиксезлек янәшәлеге аша автор мәңгелекне төгәлләштерә, мәңгелек / фани каршылыгының чиген акыл билгели: ...һәм яңадан каралыкка бата... / Аргы ягы аның – Чиксезлек!.. / Чиксезлекнең бу ягында тота / Акыл билгеләгән чик безне... [10, 6].

Шагыйрь фикеренчә, кеше яшәеш дәвамында мәңгелектән килеп, акыл белән танып-белеп булмый торган мәңгелеккә өзлексез төстә омтыла, шушы омтылыш кеше тормышында түгәрәкне хасил итә. Ассоциатив сурәтлелек аша яшәешкә (җиһан) һәм җир тормышына, кешегә бәя бирү омтылышы Сөләйманның «Татар бишегендә татар баласы», «Канатларны – каурый каләм иттем» кебек шигырьләрендә, «Югалыр күк бу мизгел» шигырьләр бәйләменә тупланган үрнәкләрендә һ.б. көчле чагыла.

**Кулланылган әдәбият**

1. Байназаров Э. Мүкләнгән диварлар җылысын кызганды // Казан утлары. – 2014. – № 9. – Б. 140.
2. Гыйбадуллина Л. Тынлык кайтавазы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 39 б.
3. Гыйбадуллина Л. Бу гавам сагыштан яралган // Казан утлары. – 2016. – №1. – Б. 107.
4. Гыйбадуллина Л. Кайту. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 70 б.
5. Загидуллина Д.Ф. Татарская поэзия рубежа XX-XXI веков (1986–2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски. – Казань: Фэн, 2017. – 266 с.
6. Зөлкарнәй Л. Мәңгелектән исә җил. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 367 б.
7. Миңнуллина Й. Күк тирмәсе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 48 б.
8. Поэтика: словарь актуальных терминов и понятий / Под ред. Н.Д. Тамарченко. – М.: Inrada, 2008. – 357 с.
9. Сөләйман. Сүтелә йомгак... – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 414 б.
10. Харис Р. Кара түгәрәк // Казан утлары. – 2014. – № 2. – Б. 6.

© Юсупова Н.М., 2025

УДК 372.881.1

**Яхина Д.Р.,**
*магистрант 1 г. о. Высшей школы отечественной филологии*
*Института гуманитарных и социальных наук УУНиТ*
*Научный руководитель* – **Зарипова И.Ф.,**
*доцент кафедры татарской филологии и культуры УУНиТ,*
*г. Уфа, Россия*

## МӘКТӘП ПРОГРАММАСЫНДА ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫ ӨЙРӘНҮ

***Аннотация.*** *Әлеге мәкаләдә гомуми белем бирү мәктәпләрендә фразеологияне укытуның теоретик һәм методик нигезләре тикшерелә. Автор фразеологик берәмлекләрнең тел, мәдәният һәм милли үзенчәлек чагылышы буларак әһәмиятен ассызыклый. Фразеологияне укытуның белем бирү, үстерү һәм тәрбияви потенциалы анализлана, укучыларда тел байлыгын, сөйләм культурасын һәм образлы фикерләү сәләтен формалаштыруда аның роле билгеләнә.*

***Терәк сүзләр:*** *тел, сөйләм, тел байлыгы, мәктәп, фразеологизмнар.*

Заманча гомуми белем бирү мәктәбендә тел курсының бер бүлеге буларак, фразеология белем бирү, үстерү һәм тәрбия потенциалына ия. «Фразеологик берәмлекләр, үзләренең семантикасында халык мәдәнияте үсешенең дәвамлы процессын чагылдырып, мәдәни күрсәтмәләр һәм стереотипларын теркәп куялар һәм буыннан буынга тапшыралар. Бу милләтнең рухы һәм үзенчәлеге кабатланмас рәвештә чагыла торган һәрбер милли телнең җаны» [5, 78].

30нчы елларда ук күренекле методистлар К.Б. Бархин һәм М.А. Рыбникова башлангыч мәктәптән үк фразеологик берәмлекләрне өйрәнү һәм үзләштерү кирәклеге турында әйтәләр. Аларның фикерен Е.В. Вальчук, С.В. Сысоева һәм Е.Д. Шевлякова хуплый. Алар рус фразеологиясенең байлыклары белән танышу мәсьәләләре буенча берничә тикшеренү үткәрә. Бу чорда ук укытучылар һәм башлангыч мәктәп укучылары өчен тәгаенләнгән мәкаләләр, дидактик әсбаплар, белешмәләр басылып чыга.

Фразеологияне өйрәнүгә К.Д. Ушинский зур игътибар бирә. Ул «Әлифба»дан башлап ук мәктәп дәреслекләренә фразеологизм кертү кирәклеген белдерә.

Фәнни монографияләр белән беррәттән, мәктәптә фразеологияне өйрәнүгә багышланган кулланмалар да басылып чыга. М.Т. Баранов әйтүенчә, «мәктәптә лексика һәм

фразеология танып белү һәм гамәли максаттан өйрәнелә. Танып белү максаты укучыларның дөньяга карашын формалаштыруны, лексика һәм фразеологиядән ныклы белем бирүне, аларда эстетик сөйләм идеалын булдыруны күз уңында тотса, гамәли максат исә укучыларда лексик һәм фразеологик берәмлекләрне куллану күнекмәләрен булдыруга юнәлтелә, телнең төрле тармакларындагы эш өчен (орфография, грамматика, укучыларның сүзлек запасын баету) алшарт булып тора» [2, 10].

Л.А. Веденская, М.Т. Баранов, Ю.А. Гвоздарев һәм башка галимнәрнең хезмәтләрендә билгеләп үтелгәнчә, фразеология бүлеген өйрәнү барышында укучылар түбәндәге белемнәргә ия булырга тиешләр:

1) фразеологиянең гомуми тел системасындагы урынын, төп үзенчәлекләрен, аларга нигезләнеп бүленеп чыккан төркемнәрне, ясалыш ысулларын, тотрыклы сүзтезмәләрнең вазифасын, телнең фразеологик составы үзгәрү сәбәпләрен, төп фразеологик сүзлекләрне һәм белешмә китапларын күз алдында тоту;

2) тексттан фразеологизмнарны аерып ала белү, аларның җөмләдәге синтаксик ролен билгеләү, мөмкин булган очракларда фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәсен билгели белү, сөйләмдә аларның стилистик үзенчәлекләрен исәпкә алып куллану.

М.Т. Баранов әлеге таләпләрне тагын да ачыграк билгели. Аның фикеренчә, «укучылар сүзләрнең һәм фразеологизмнарның лексик мәгънәсен аера белү; таныш сүзләр һәм фразеологизмнарның мәгънәсен аңлату; контекстта сүз яки фразеологизмнарның кайсы мәгънәдә кулланылганын билгеләү; тексттан өйрәнелгән лексик һәм фразеологик күренешләрне табу; бирелгән тексттан лексик күренешләрне һәм фразеологизмнарны сайлап ала белү; өйрәнелгән лексик күренешләрне һәм тотрыклы сүзтезмәләрне төркемли алу; төрле аңлатмалы сүзлекләр, шул исәптән фразеологик сүзлекләрне дә куллана белү кебек күнекмәләргә ия булырга тиеш» [2, 14].

Татар һәм рус телләрендәге күп кенә фразеологик берәмлекләр мәгънәләре белән генә түгел, формалары белән дә бер-берсенә туры киләләр. Мәсәлән: *яблоко от яблони далеко не падает – алма агачыннан ерак төшми, кояш чыгу – восход солнца* һ.б. Бу очракта рус телендә сөйләшүче укучылар татар фразеологизмнарын дөрес кулланырга тиз күнегәләр.

Гадәттә фразеология тел дәресләрендә төп гомуми белем бирү мәктәбендә өйрәнелә. Тармакны өйрәнү берничә этапта бара:

1. Пропедевтик этап (фразеология практик рәвештә өйрәнелә, терминологияне кертмичә).

Әлеге этапның максаты – балаларның игътибарын матур әдәбият әсәрләрендәге образлы берәмлекләргә, шулай ук җанлы сөйләмгә җәлеп итү; балаларның фразеологизмнарга кызыксынуын уяту; аларны өйрәнү өчен уңай мотивация булдыру.

Әлеге этапта фразеологизмны беренчел кабул итүне тәэмин итә торган күнегүләр төп урынны били. Пропедевтик этап ике бүленештән тора: тотрыклы берәмлек төшенчәсен кертү һәм укучыларны фразеологизмның әһәмиятен аңлатуның төрле алымнары белән таныштыру.

6-7 яшьлек балалар тотрыклы сүзтезмәләрне аңлау гына түгел, үз сөйләмендә куллана да ала. Хәзерге вакытта фразеология мәктәп белеменең урта звеносында гына түгел, башлангыч мәктәптә дә өйрәнелә.

2. Систематик этап («Фразеология» бүлеген өйрәнү).

Бу этапның максаты – укучыларга семантиканы үзләштерергә ярдәм итү һәм сөйләмдә фразеологик берәмлекләрнең кулланылышын өйрәтү.

Бу этапта төп методлар булып әңгәмә, күзәтү, текстны реконструкцияләү һәм төзү тора. Күнегүләр арасында иллюстратив, беркетү, кабатлау-гомумиләштерү тибындагы күнегүләрне аерып күрсәтергә була.

Хәзерге уку комплексларында фразеология 5-6 нчы сыйныфларда өйрәнелә. Мәсәлән, Т.А. Ладыженская, М.Т. Барановның «Рус теле» дәреслегендә фразеология «Фразеология и культура речи» бүлегендә 6 сыйныфта бирелә. Фразеология В.В. Бабайцева, Л.Д. Чеснокованың «Рус теле. Теория. 5-9 классы» уку комплексында 5 нче сыйныфтан ук өйрәнелә башлый.

Л.М. Рыбченкова, О.М. Александрова, О.В. Загоровская һәм А.Г. Нарушевич уку комплексында фразеология 5-6 нчы сыйныфларда, «Лексикология», «Фразеологизмнар», «Канатлы сүзләр» бүлекләрендә тәкъдим ителә. Урта гомум белем бирү мәктәбе өчен хәзерге рус теле дәреслекләренә анализ ясау түбәндәгеләрне күрсәтә: «авторлар теге яки бу күләмдә фразеология буенча махсус биремнәрне һәм күнегүләрне күз алдында тота» [6, 97].

Дәреслекләрдә бирелгән материал һәм фразеологияне үзләштерү эшен оештыру һәм үткәрү буенча авторларның тәкъдимнәре ярдәмендә, укытучылар, урта сыйныф укучыларын фразеологиягә өйрәткәндә, иҗади алымнар кулланырга мөмкин. Фразеология өлкәсендә махсус күнекмәләрне уңышлы формалаштыру өчен, күнегүләр зур әһәмияткә ия. Фразеология буенча күнегүләрнең төрләре М.Р. Львов, Л.А. Введенская, М.Т. Баранов, Ю.А. Гвоздарев тарафыннан эшләнгән.

3. Кабатлау һәм гомумиләштерү этабы (7-9 сыйныфлар)

Фразеологияне укыту методикасында, телне укыту теориясе һәм укытуның башка бүлекләрендәге кебек үк, гомумдидактик принциплар (фәннилек, күрсәтмәлелек, системалылык, аңлылык, аңлаешлылык, һәр укучыга индивидуаль алым, эзлеклелек, теория һәм практика бәйләнеше) һәм хосусый методик принциплар кулланыла.

В.Ф. Гутенев фикеренчә, «фразеологизмнар белән эшләүнең иң мөһим өлеше аларның мәгънәсен ачыклауда, аның дөреслеге күбрәк контекстка бәйле, ә кайчакта этимологик анализга мохтаҗлык барлыкка килә (компоненты аңлашылмаган мәгънәне аңлату рәвешендә; әдәби яисә башка телле чыганакларга күрсәтү рәвешендә; фразеологизмның барлыкка килүенә ярдәм итүче тарихи вакыйгалар, халык гореф-гадәтләре һәм йолалары, аларның көнкүреше турындагы хәбәрләр рәвешендә (*деньги не пахнут; не поминай лихом; тянуть лямку*))» [4, 26]. В.В. Виноградов билгеләвенчә, «кайбер очракларда әдәби әсәрнең эчтәлеге белән бәйле булган нинди дә булса тотрыклы сүзтезмәнең мәгънәсен ачу өчен кыска гына белешмә җитми башлый. Рус телендә мондый мисаллар тәкъдим итәргә мөмкин: *подковать блоху* (Н. Лесковның «Левша» повестеннан), *как белка в колесе* (И. Крыловның «Белка» мәсәленнән); *великий комбинатор* (И. Ильф һәм Е. Петровның «Двенадцать стульев» һәм «Золотой телёнок» әсәрләреннән)» [3, 102]. Мондый очракларда фразеологизмның мәгънәсен төгәлрәк ачу өчен, укучыларга әсәрнең үзен укырга тәкъдим итәргә кирәк.

Анализлау өчен шулай ук Р.К. Сәгъдиева, К.Ф. Фәйзрахманованың «Туган тел» [8, 14] дәреслеген карап китик. Монда балаларга фразеологимнар турында киләсе төшенчә бирелә: «Күчерелмә мәгънәдә килеп, бер мәгънә аңлата торган сүзләр тезмәсе (сүзтезмә) фразеологизм дип атала. Аларны башка бер сүз белән алмаштырып була» [7, 106]. Фразеологизмнарның аңлатмасыннан соң *баш вата – уйлый, авызы колагына җиткән – шатланган* дигән мисаллар китерелә.

Укучыларны кызыксындыру өчен Р.К. Сәгъдиева, К.Ф. Фәйзрахманова дәреслегендә кызыклы күнегүләр тәкъдим ителә. Мәсәлән, «Лабиринт буенча барып, төшеп калган фразеологизмнарны әйтү» [7, 107]. Күнегү кызыклы, аңлаешлы һәм укучыларның яшь үзенчәлекләренә карап төзелгән. Башта фразеологизм туры мәгънәдә күрсәтелгән, икенче юлда фразеологик төшенчә рус телендә бирелгән һәм соңгысы, татар телендә, шушы ике шартка туры килгән фразеологизмны табып, язып кую. Бу күнегүне эшләгәндә балалар киләсе универсаль уку гамәлләрен (УУГ) тормышка ашыралар: үзлектән эшләү, үз фикерләрен формалаштыра һәм дәлилли белү (регулятив УУГ); уку проблемасын билгели һәм аны чишү юлларын мөстәкыйль төзи алу (танып белү УУГ); үз фикерләрен тулы һәм төгәл итеп, телдән җиткерә белү (коммуникатив УУГ).

Димәк, «укытучы фразеологизмнар турында мәгълүмат бирү, аларны истә калдыру һәм сөйләмдә дөрес куллана белү кебек максатларга ирешергә тиеш» [8, 87].

Р.К. Сәгъдиева, К.Ф. Фәйзрахманованың уку комплексы 5 сыйныфтан алып 9 сыйныфка кадәр алып барыла. Һәр сыйныфның дәреслегендә фразеологизмнарга урын табыла.

10-11нче сыйныфта фразеологизмнарны кабатлауга юнәлтелгән махсус дәресләр юк. Шуңа карамастан укытучы әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрне укыганда, аларда очраган

фразеологик берәмлекләрне табу, мәгънәләрен аңлату эшләрен оештыра ала. Мондый эш төре, «беренчедән, балаларның сүзлек байлыгын арттыруга юнәлтелгән. Икенчедән, алар ярдәмендә укучыларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерүгә мөмкинлекләре арта. Өченчедән укучылар ике телдәге фразеологик берәмлекләрне чагыштырырга, уртак һәм аермалы якларын билгеләргә күнегәләр» [1, 18].

